# КАЗАН УТЛАРЫ

www.kazanutlary.ru

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*


Бу санда


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Ленар ШӘЕХ. Тынычлыкка сусау. *Шигырь.* ...3
Хисам КАМАЛ. Каһәр. *Роман.* ...4
Мөхәммәт МИРЗА. Бакы – кубарык җил. *Поэма.* ...84
Фирдәвес ХУҖИН. Сугыш күләгәсендә. *Повесть.* ...89
Таһир ШӘМСУАРОВ. Җыры барның – чиксез гомере! *Шигырьләр.* ...126
Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Татар әреме. *Хикәя.* ...130
Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА. Аннары – мәңгелек сагыну... *Шигырьләр.* ...139
*Җәһәт тәнкыйть:* сәхифәне Дания ЗАҺИДУЛЛИНА алып бара. ...143
Гомәр ДАУТОВ. Генерал. *Хикәя.* ...145
Рифкать ХУҖИ. Карт кыз. *Юмористик хикәя.* ...153

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Наталья ХАРЛАМПЬЕВА. Җан яктысын яудыра. *Шигырьләр.*
*(Якутчадан Ленар ШӘЕХ тәрҗемәсе.)* ...150

«ХӘЗИНӘ» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Гөлфия СОЛТАНОВА. Факел. *Хикәя.* ...160

БУЛАТ СӨЛӘЙМАНОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Флёра СӘЙФУЛЛИНА. Туган як моңы… ...165

ПУБЛИЦИСТИКА

Айдар ГАРИПОВ. Язмыш сынауларына бирешмичә. ...169

СӘНГАТЬ

Айсылу ИМАМИЕВА. «Милли үзаң булмаса, үсеш тә юк» *(Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Айдар Хафизов белән әңгәмә).* ...178

КИТАП КҮЗӘТҮ

Мөдәррис ВӘЛИЕВ. Мөбарәк тәсбихның бер төймәсе. ...182
*Безнең календарь:* Зариф БӘШИРИ. ...184
*Үткәннәр сагындыра:* Туфан МИҢНУЛЛИН. Энесе кем – абыйсы шул... ...185
*Юмор-сатира:* Роберт МИҢНУЛЛИН тупламасыннан. ...186
*Укучы фикере:* Лилия ФӘТТАХОВА. «Җәһәт тәнкыйть»кә кайтаваз.
Ирек ФИРГАЛИЕВ. Максатчан әсәр. ...188
«Казан утлары» архивыннан. ...158
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ...190

Гамәлгә куючы –
«Татмедиа»
акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР –*

**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Рәдиф Җамалетдинов**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Зиннур Мансуров**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Вакыйф Нуриев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Данил Салихов**
**Айрат Сибагатуллин**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Илсур Һадиуллин**
**Рәфикъ Юныс**

---

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Фәнил Гыйләҗев, Айсылу Имамиева, Камил Кәримов.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров.**
*Сайт мөхәррире:* **Рәзилә Хәйретдинова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Люция Сөләйманова** (баш бухгалтер).

---

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип һәм проза бүлеге – 222-09-83 (өст. 1613)*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1266), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
: **Факс** – (843) *222-09-83 (өст.1612).*
: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 27.04.2018, график буенча 27.04.2018.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ Е-1078. Тираж 4250.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен), П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), 16262 (Татарстаннан читтәге юридик затлар өчен), П2368 (Татарстандагы юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2018 ел

Ленар
Шәех

## ТЫНЫЧЛЫККА СУСАУ

«Бу дөньяда тынычлык бар!» диеп,
Кемнәр әйтер, кемнәр дәлилләр?
Ялган тынычлыкның тырнагында
Иза чигә бүген күп илләр.

Җәфалана, чәбәләнә алар,
Бер алдангач, юктыр котылу.
Бу – көчсезнең,
көчле басымында,
Юк булуга бару, йотылу!

Кешелеккә тыныч яшәү – хәрәм;
Дәлилме бу, әллә фаразмы?..
Тыныч башланыр, дип көтеп алам
Чираттагы елны һәм язны!..

Уйлауларым, юрауларым белән
Юкка чыга инде тагы ла...
Бер тарафта ун ел сугыш бара,
Бер тарафта яңа кабына.

Җир җитмиме безгә, ил җитмиме?.. –
Нәрсә җитә дөнья ямьлегә?!
Бер уч гомер эчләрендә кеше,
Байлык диеп, тауга бәрелә.

Кыяларга оча, упкыннарга,
Су төбенә китеп югала.
«Кабат сугыш була!» – кешелекнең
Киләчәге шулай юрала.

«Бу дөньяда тынычлык бар!» диеп,
Кем соң әйтер, ә кем дәлилләр?
«Тынычлык»ның канлы тырнагында
Җәфалана бүген күп илләр!..



Хисам Камал

# КАҺӘР

РОМАН

I

Динә Әхәтовна иң элек эш урыны турында белешергә тотынды:

– Альфредның кәефе ничек? – Ул дикъкать белән шәфкать туташы Танянын йөзенә төбәлде.

Таня күрәнсу битле, төз борынлы, бантик иренле, коңгырт күзле кыз иде. Һәр ир-атның карашы иярә аңарга. Ләкин Танянын тыйнак йөзе, хәрәкәтләре, бераз төксерәк мимикасы ул карашларга бик тиз чик куя, өметләрен сузмаска кисәтә кебек иде.

– Кулында һаман китап... – диде Таня, ничек дип әйтергә белмичә.

– Синең белән сөйләштеме?

– Юк.

– Ә син сүз куертып маташасыңмы инде? Горурлыгыма көч килер дип курыктың инде, ә? Их, горурлык, безне бәхеттән мәхрүм итә торган нәрсә...

– Кешегә көчләп ничек тагылырга мөмкин, Динә Әхәтовна? Ул үзе дә бик горур зат бит! Әгәр «агрессиямне» сизсә, миннән тәмам йөз чөерер.

– Ничектер аның белән уртак тел табарга иде. Күңеленә керергә иде, ә? Таня, моңа бары синең генә әгъвәң җитәр.

– Ул эш көчләп эшләнми, үзегез дә беләсез.

– Син аны сөйләштер, укыган китаплары турында сораштыр, кызыксын. Кайсы язучыларны ярата икән ул?

– Завхоз Ваня абый аша Сорочидан алдыра, диләр.

– Алайса, бик кызыклы китаплардыр инде?

– Ул миңа бераз кырын карый төсле. Уңайсызлана да шикелле. Без аның «секретларын» белгәнгә ачуы килә, ахрысы. Үзенең начар хәлдә калуын белгән шаһитларны кеше яратмый. Табигый хәл...

– Нишләргә инде, ә? – дип, Динә Әхәтовна тәрәзәгә таба башын борды да тынып калды. Ул уйлана иде. Матур төз маңгаенда, чүмечкә алган суда нечкә

---

Хисам КАМАЛ (1926-2016*)* — *Татарстанның халык язучысы, сугыш һәм хезмәт ветераны. Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, биш томлык «Сайланма әсәрләр» һәм төрле телләрдә дөнья күргән күпсанлы китаплар авторы. Роман – авторның соңгы әсәре.*

дулкыннар барлыкка килгән төсле, җыерчыклар пәйда булды. Ханымның мөлаем йөзе җитдиләнде, анда читен хәлдән чыга алмаудан гаҗизлек төсмере шәйләнә иде.

Тәрәзәдән каршы яктагы госпиталь һәм аның бакчасы күренә. Бакчада – яралылар. Кайсылары – кәстилдән, кайсыларының сыңар кулы юк, кайсыларының ияклəре башына ак бинт белән бәйләнгән – болары «челюстник»лар, теш казналары яраланган кешеләр. Мең тугыз йөз кырык алтынчы елның көзе җитүгә карамастан, сугышта яраланганнар бик күп әле. Һаман төзәлеп бетә алмыйлар. Каты яра алганнар шул. Әмма кайберләренең ярасы гомергә төзәлмәс. Алар еллар буе госпитальләрдә, больницаларда ятачак. Әйе, сугыш бар адәм балаларын яралап бетерде. Сугышта булганнарын да, булмаганнарын да! Нишләмәк кирәк, без врачларның эше дәвалау да дәвалау инде. Әйтерсең, адәм балалары яралану һәм дәвалану өчен генә дөньяга килә.

Моннан ай ярым чамасы элек шул госпитальдән лейтенант Альфред Бачуринны ГИДУВка күчерделәр. Динә Әхәтовна аңа операция ясады. Таня ассистентлык итте. Альфредның ярасы нечкә җирдә иде. Бу – инде икенче операция. Динә Әхәтовна аңа сигез ай элек, госпитальгә барып, беренче операция ясаган иде. Өметләндерә торган нәтиҗәләр беленде. Шуңа күрә Альфредны бирегә, Динә Әхәтовна карамагына күчерделәр. Моңа гаҗәпләнеп тә булмый. Альфредның әтисе – генерал, Германиядәге безнең гаскәрләр башлыгы. Өлкә комитетына гына шалтырата. Генералның хатыны – врач-терапевт, беренче операция ясалганчы ук, Динә белән элемтәгә керде. Хат аша да, телефон белән дә. Яшереп торасы юк, Динәгә посылка белән бик күп әйберләр җибәрде алар. Динә баш тартып карады, әмма генерал аның авызын тиз япты: без андагы хәлне беләбез, зинһар, тыйнак булып маташмагыз, диде. Яхшы врачка бүләк бирү – элеккедән калган халык гадәте, аның бернинди мораль дә, политик та гаебе юк, янәсе. Беренче операция өмет уятырлык билгеләр күрсәткәч, генерал аңа контейнер белән үк әйберләр җибәрде. Берничә зур-зур ковёр, көзгеләр... Альфред аларга сөенечле хат язгандыр, мөгаен. Терелүгә барам, дигәндер. Ләкин егет үзенең сиземләүләрендә, өметләнүләрендә алданмады микән? Динә Әхәтовна курка калды, үз кулларына үзе ышанмаган халәттә нык борчуга төште. Операцияләре көткән нәтиҗәне бирмәсә, нишләр ул? Оятын ничек күтәрер? Бу бүләкләр аны тәмам кыен хәлгә куйды. Мондый нәрсәләрне күрмәгән, хуплауларга өйрәнмәгән ул. Телефон аша бик нык карышып та маташты, әмма генералның үз сүзе сүз иде. Беркөнне Динә Әхәтовна исеменә язу килде. Станциядә сезгә контейнер бар, тизрәк алуыгыз сорала, диелгән иде анда. Шулай итеп, Динә Әхәтовна ике ут арасында калды. Ничек аңардан баш тартасың?.. Бүтән берәү булса, моны шулай тиеш дип кабул итәр иде, әмма Динә Әхәтовна курыкты. Альфредка тагын берничә операция ясалырга тиеш иде әле. Операцияләр рәтле булып чыкмаса, ул аларга ни йөз белән күренер? Кыскасы, бер бәлагә әйләнде бу бүләкләр. Җанны кимереп, бимазалап тора башлады. Хәзер инде аңа ничек тә Альфредны сәламәтләндерерлек, нормаль кеше итәрлек операцияләр ясарга кирәк иде. Ә бит ул, шундый зур бүләкләр бирмәсәләр дә, операция уңышлы чыксын өчен, бар көчен куя иде. Хәзер исә әллә ничегрәк. Операция, гомумән, дәвалауда арттырып җибәрү бар эшне харап итә. Биредә артык тырышлык еш кына уңыш китерми, киресенчә, кире нәтиҗә бирә... Менә ул нәрсәдән курка... Динә, уйларының җебен теше белән өзгән кебек итеп, бүленде дә Таняга таба борылды.

– Альфред сиңа ошыймы? Кеше буларак, дим? – Аның йөзенә кызыклы сөйләшүгә ишарәле торган нурлар тибеп чыкты.

– Сәер, нигә шулай сорыйсыз? – Таняның каратут йөзендә шулай ук кызыксынучан төсмер чагылып китте.

– Ә син сорауга җавап бир.

– Белмим, ничектер, уйлаганым булмады.

– Яшермә, ул синең уйларыңа күп мәртәбәләр кереп чыкты, – дип, Динә елмаеп куйды. Таня да бераз кызарып киткән төсле булды да көләргә үк керешә.

Динә дә аңа кушылды. Үзенең гөманы дөрескә чыгуына күңеле булды аның.

– Син Альфред белән шаяра башларга тиешсең, – дип, көлүен дәвам итте Динә. Бу хакта көлеп сөйләшү килешеп тә бетми, әмма һәр шаян сүздә бер чын мәгънә була бит. Таня сүз сөрешен аңлар, бик сизгер күңелле кыз ул.

– Тычканмы, мәчеме? – дип, Таня да һаман көлде. Ләкин үзен очсызлый торган көлү түгел бу. Кайбер кызлар, үзләренең күңел ишекләреннән тиз үтеп булганын белгерткәндәй, көчәнүсез генә көлә торган була. Әрсез егетләр бу ишарәне бик тиз аңлап ала. Таняның көлүендә күңел ишекләре ябык, һәм үтеп булмаслык чытырманлыклар шәйләнә. Егетләр бик сизгер, алар Таняга елыша алмый, чигенергә туры киләчәген алдан ук чамалый.

– Әллә уйныйсың килмиме? – диде Динә, җитдиләнеп. – Синең борчуларыңны аңлыйм, әти-әниеңнең язмышы һаман билгесез. Ә сиңа Елгавага кайтырга рөхсәт итмиләр әле. Ләкин, Таня, әз генә сабыр итик, мин кайбер начальниклар белән сөйләштем. Латвиядә хәзер хәлләр катлаулы икән. Көтәргә куштылар... Ә безгә иң элек Альфредны аякка бастырырга кирәк. Аның әти-әнисе хәлне аңлый. Мин синең хакта яздым аларга, телефоннан сөйләшеп торабыз. Хуплыйлар, үз кызыбыз кебек булыр, диләр, бары Альфред кына ошатсын, дип, авыз суларын корыталар. Альфредның кылын тартып карадым, син аның күңеленә кергәнсең шикелле. Син, Таня, теләсә нинди таш йөрәкне эретә ала торган...

– Фу, мактаганны яратмыйм. Мактау – ялганлау ул, французча «комплимент» – ялганлау дигән сүз, – дип, Таня Динәнең сүзен бүлдерде.

– Ә күпләр ялганны ярата, – диде Динә. – Юк, мин ялганламыйм, Таня, сиңа чынын әйтәм.

– Нигә әйтәсез, менә хәзер шик төште...

– Синең тормышыңны җайламакчы булам, Таня, калганын теләсә ничек аңла, – дип, Динә җитдиләнеп калды.

– Тычканмы, мәчеме, дидегез бит, – диде Таня, көлеп. Аның Динә сүзләренә тамчы да каршы килмәве күренә иде.

– Әйе, уен зарури синең ише кызга! «Серкәләнү» кирәк. Ә уйнамыйча «серкәләнеп» булмый. Һәр чәчәк серкәләнергә ашыга...

– Сез философ та икән! – Таня тагын тыенкы гына көлеп алды.

– Альфредның холык-фигыле болай ипле булырга охшаган... – Динә үз фикерен ныгытырга тели иде.

– Юк, биредә белеп булмый аны, чын холык-фигыль гаиләдә генә беленә, диләр бит... – Таня эшлекле һәм кызыксынучан сөйли иде.

– Чамаларга була инде, – диде Динә. – Гаиләдә бердәнбер малай, варис...

– Бер булганга шыр булган, диләр.

– Альфредны алай дип әйтә алмыйсың, юк!

– Ул минем кайдан, кемнәр баласы икәнемне белсә, үзе үк йөз чөерер. Әтисе дә шулай кушар. Алар политиканнардыр, мөгаен.

– Син катлауландырма, Таня. Ул мәсьәлә алга килеп басса, үзем рәтләрмен.

– Барча нәрсә дә политика бит хәзер. Беләсез. Ир белән хатын арасында да – политика, хәтта ятакларында да шул ук нәрсә! Баш җитәрлек кенә түгел.

– Әнә үзең дә аңлыйсың икән. Әйбәт. Адәм баласыннан нәрсә таләп ителә? Шул шартларга җайлашу таләп ителә. Телисеңме, теләмисеңме, шартларны атлап узып булмый. Без генә түгел, беркем дә уза алмый, Таня! Минемчә, Альфред белән борчак пешерә алсаң, ким-хур булмассың...

– Кем белгән аны, алдагы язмыш – суга сәнәк белән язылган.

– Алай димә, Таня, читкә чәчелмә! Туктале, әллә берәрсе үзеңә кармак салдымы? Ә? Җим бик тәмлеме әллә? Юк, мин болай, хатын-кыз буларак кына кызыксынам. – Ул кызга сынап карап торды.

– Күлгә кармак салмый тормыйлар инде, Динә Әхәтовна, – диде Таня һәм тамак төбе белән генә кет-кет көлеп алды.

– Мин әйткәнне тыңла, Таня. Минем сиңа яхшылык кына теләгәнемне аңлыйсыңдыр... – Динә җитдиләнеп китте. Ул чын күңеленнән яхшылык эшлисе килеп тырыша иде. Таня бусын инде яхшы белә һәм шуңа күрә күңеленнән Динә әйткәннәрне ничек тормышка ашырырга дип, хисләре үлчәвенә бер салып, бер алып карый. Җаен, чамасын табарга итә. Альфредның генерал улы икәнен белгәч, ул башта сузылган нәфес хисләрен таяклап дигәндәй кире үз урынына куып җибәрде һәм шуның белән үзендә читләшү иммунитеты эшләп чыгаргандай булды. Ул хисләр кысрыклавына кабат колак салмаска, әйләнеп кайтмаска дип фикер төйнәде. Белә ул андый югары дәрәҗәдәге кешеләрне. Әз генә башка төрле политикага бирешү дә бик куркыта. Чөнки шул политиканы башка нәрсәдән өстен куеп, бары политикача яши алганга күрә генә, алар югары дәрәҗәгә ирешкән. Политиканың тылсымлы көче белән шул югарылыкта торалар. Бер карыш читкә тайпылырга кан калтырыйлар, чөнки чак кына, бер генә адым кырыйга авыштыңмы – беттең, упкынга төшәсең дә югаласың... Шуңа аларның кешечә тормышлары да юк. Колларча буйсынып, гел шул нәрсәгә генә бирелеп яшәргә мәҗбүрләр. Аның каравы алар матди яктан яхшы тәэмин ителә. Алар һәр төштә өстен... Адәм баласын, гадәттә, әнә шул ягы кызыксындыра. Таня хәзер кемне үз, кемне үги итүләрен бик яхшы белә. Үзе татып, үзе кичереп...

Алар аулаграк бүлмәдә утыра иде. Бер шәфкать туташы килеп керде. Ниндидер эш буенча Динә Әхәтовнага хаҗәте төшкән. Туташ татарча сөйләшә, авылдан килгән булса кирәк. Динә исә аңа русча гына җавап кайтара. Таня гаҗәпкә калыбрак торды. Нигә үз телләрендә генә сөйләшмиләр? Уйлагач, төшенде. Биредә дә шул ук политика. Татарча сөйләшкәнне русларның кайберләре өнәп бетерми, кырын карый башлый. Динә Әхәтовна шуңардан сагая, ышанычын югалтасы килми. Гел үз телеңдә генә сөйләшсәң, билгеле, ышаныч кими. Табигый хәл. Моны гаеп итеп буламыни? Әгәр рус кешесе янында бүтән телдә сөйләшсәң, аны кимсетү шикелле килеп чыга. Бу – гади этика, биредә бернинди сәясәт дигән нәрсә юк икән.

Шәфкать туташы киткәч, Динә үзенең төп фикерен урау юллар аша Таняга аңлатырга тырышты. Альфредка ясалган операция нинди нәтиҗә биргәнен сынап карарга кирәк. Моны бары хатын-кыз аркылы, хатын-кыз белән генә эшләргә мөмкин. Дөрес, Альфредка операция уңышлы үтте, хәтта көлә башладым, дип язган әти-әнисенә. Динәгә генерал Бресттан шалтыратты. Германиядән шунда командировкага кайткан булган. Ләкин ул бар нечкәлекләрне, катлаулылыкларны белеп бетерми. Бәлки, гөманы белән аңлыйдыр, шулай да ул хакта сөйләшү мөмкин түгел. Төгәл сүзләре дә юк аның. Альфред та әти-әнисенә барысын да әйтеп бирә алмый. Теләсә дә, белгертә, аңлата алмас иде. Альфредның чын хәлен,

авыруын бары врач Динә Әхәтовна, тагын бер-ике невропатолог һәм Таня гына беләбелә. Белергә тиешлесен генә белә. Аның әле тиешле булмаганы һәм мөмкин түгеле күпме! Альфредның үзеннән дәвалаучы врач та турыдан-туры сорый алмый. Дөрес, психология ярдәмендә күп нәрсәләрне белеп була. Ә биредә эш тоташ психологиядән тора. Альфредның кәефен һәр көнне күзәтеп барырга һәм, истә тотар өчен, язып алырга туры килә. Динә Әхәтовна моны бик теләп эшли, чөнки киләчәктә диссертация әзерләргә хыяллана ул. Һәр авыру турында көндәлек алып бара, күзәтүләрен теркәп куя.

– Безгә Альфредны сынап карарга кирәк, – диде Динә Әхәтовна Таняга. – Ирлеге кайтканмы әле, әллә юкмы? Аңлыйсыңмы? Моны бит аның үзеннән сорап булмый. Үзенең дә белмәве мөмкин. Төшенәсеңме?

– Ә ничек сыныйсың аны?

– Бар кыенлыгы да шунда, Таня, – дип, тавышын әкренәйтте Динә Әхәтовна, гүя алар бик зур сер бүлешә, моны беркем дә белмәскә тиеш иде... Ул бераз тын торды да әйтте: – Син Альфредны үзеңә кунакка дәш... – диде. Аның сүзләреннән Таня аптырап китте һәм, гаҗәпләнеп, рәнҗеп, Динәгә карады. Юньле-рәтле киемнәре дә юк бит ичмасам...

– Барысы да бар: табынга куя торган нәрсәләрне, кәләшкә, ягъни сиңа дигән эчке һәм тышкы киемнәрне генерал контейнер белән җибәрде. Гаҗәпләнмә, мин синең хакта аларга яздым, фотоңны да җибәргән идем. Бик ошатканнар. Әйтәм бит, сиңа да бик вакыт... Шулай түгелмени?..

– Нишлисең, мин сезне тыңларга күнектем инде, – дип, көлгәндәй итте Таня.

Кич булган, күз бәйләнгән иде. Киенеп тышка чыктылар. Комлев урамы буйлап атладылар. Динә Әхәтовна үзе Гоголь урамында яши иде.

– Ашап-эчеп, күңел ачып утырырсыз, – дип сүзне ялгады Динә Әхәтовна. – Ә аннары... Үзең беләсең инде...

– Аның белән йокларгамы? Юк, булмый, Динә Әхәтовна, – дип кырт кисте Таня.

– Юләр, әгәр йокларга теләсә, бу бик зур уңыш, Таня! Медицина ягыннан карап әйтәм. Җиңү! Димәк, безнең операция дөрес ясалган. Аңлыйсыңмы?

– Аңлыйм да соң, шуның өчен мине корбан итмәкчесезме? – диде Таня, үпкәләгән кебек.

– Туктале, әллә үпкәли үк башладыңмы? Таня, күгәрченкәем, Альфредны тик шулай гына сынап була. Безнең операцияләрнең нәтиҗәсен шул юл белән генә тикшерергә мөмкин. Бу – безгә йөкләнгән бурыч. Әйе, задание.

– Ул теләсә, мин бөтенләй дә каршы килергә тиеш түгелмени? Задание, дисез... Мин бит кыз кеше...

– Ничек инде кыз кеше, юкны сөйләмә...

– Шулай, кыз кеше, әйе, үземне сакладым... Бик зәһәр бәйләнүчеләр булды, билгеле...

Таняның бу сүзләренә Динә ышанырга да, ышанмаска да белмәде, телсез калды. Өч ел буе бергә эшләсәләр дә, ул Таняның эчке дөньясына кермәде. Дөрес, аларның якынаеп китүенә ел ярым чамасы гына. Таня Эдуард Хәлимович кул астында эшләде. Бервакыт алар арасында ниндидер интим бәйләнешләр турында да сүз йөрде. Әллә гайбәт, кеше сүзе генә булдымы? Эдуардның хатыны килеп җәнҗал кубарып йөргәч, Таняны Динә группасына күчергәннәр иде. Андый бәйләнешләргә Динә үзе чагыштырмача җиңел карый. Медицина күзлегеннән фикер йөртә. Ир белән хатын-кызның бер-берсенә күңелләре, җаннары туры килеп, алар үзара уртак тел таба ала икән, моның әллә ни гөнаһы булмаска тиеш. Җаннарның бер-берсенә туры килүе бик сирәк була бит ул...

Таняның гыйффәтле кыз булуы мәсьәләне катлауландыра, билгеле. Әмма Динәнең моңа һич тә ышанасы килми. Таня үзенең бәясен, абруен күтәрү өчен генә шулай әйтә торгандыр. Әллә таныйсы килмиме? Андый хатын-кызлар да була бит. Әллә ничә ир-ат кочагында булган, ә үзен һаман кыз кеше дип йөри. Юк, Таня андый булмас, чөнки медицина кешесе бу мәсьәләне артык катлауландырмый. Физиологик, табигый күренеш итеп карый. Аңа артык зур әһәмият бирми, аңардан һич тә фаҗига ясамый инде. Юк, бу – әхлаксызлык түгел, йөгәнсезлек дип тә әйтеп булмый моны. Бу – бары кеше табигатен аңлау һәм ул күренешне табигатьчә бәяләү генә. Артык та түгел, ким дә түгел.

– Эдуард белән синең арада берни дә булмадымыни? – дип, уңайсыз булса да, сорарга кыйды Динә. – Сөйләгәннәр иде...

– Шул Лиза Маркова чакты инде, көнләшеп...

– Эдуардның бик ертлач икәнен яхшы беләм... – диде Динә һәм уйлап куйды: Эдуард үзенең хезмәте өчен бәхилләтү көткәндер, билгеле. Ул бер нәрсәне дә бушка эшли торган адәм түгел. Ә Таня ни белән түләсен? Хатын-кызның әлеге дә баягы шул тән инде, аның тагын нинди байлыгы булсын.

– Мин, ничектер, алай сизми идем. Ул миңа квартира мәсьәләсендә булышты... – Таня сүзен тагын әйтеп бетермәде.

Динә теге уен кабат дәвам итте: Эдуард – тиярен дә, тимәсен дә ала торган, иртәгәгә калдырмый торган кеше. Миннән дә алды ул, Лизадан да... Лизаның Танядан көнләшүе табигый.

Алар ярым караңгы тротуардан бераз сүзсез генә атлады. Аннары, трамвай юлын аркылы кисеп чыгып, аска таба төшеп киттеләр.

– Син бер карчыкта фатирда яши идең, әйе бит? Ул карчык үлде. Бүлмәне сиңа калдыру буенча Эдуард чабып йөрде. Шулай бит? Обкомда аның танышлары күп шул.

– Мине аның сөяркәсе дип, сүз тараттылар. Кайбер кешеләр бер-берсенә яра салудан рәхәт таба бит, Динә Әхәтовна, – дип, Таня акланган сыман әйтеп куйды.

Таня, дөресен әйткәндә, Динәнең сүзләрен бераз шаяру кебек кабул иткән һәм аңа ышанмаган иде. Ничек инде, Динә Әхәтовна сүзенә карап, заочный кәләшкә дип әйбер-кара җибәрсеннәр. Шултикле беркатлы, китапча кешеләрнең булуы мөмкин түгел. Дөрес, Альфредның ярасы бик җитди. Ата-анасына да бер генә малай. Генерал үзе зур урында эшли, әнисе – шулай ук абруйлы врач. Ире генерал булгач, аның хатыны да барыбер капитан дәрәҗәсеннән дә ким йөрми инде. Гәрчә үзе хәрби булмаса да. Ирнең абруе хатынының да дәрәҗәсен бермә-бер күтәрә. Бу – бик билгеле хәл. Хатын-кызларда «йолдыз»га омтылу чире юкка түгел. Хатыннар ирләре белән мактана, алардагы дәрәҗәнең яртысын үзләренә ала, үзләренеке дип белә һәм шуңа ышанып яши. Хатын-кыз – бик сәер халык ул...

– Менә ачылмаган-тимәгән, шәхсән сиңа тәгаенләнгән, – дип, Динә Әхәтовна, караңгы бүлмәдән зур гына ике картон тартма чыгарып, аның алдына куйды. Таня исе китеп карап катты: чынмы бу, әллә ул төш күрәме? Төш дияр идең, Динә Әхәтовнаның тавышы бик ачык булып ишетелә.

– Ничек инде, белмәгән-күрмәгән кешегәме? Шаярту болай булмый, Динә Әхәтовна.

Таня өстәл янындагы урындыкка барып утырды. Динә иреннәрен кысты, аның инде ачуы килә башлаган төсле иде. Әмма ул – ачуын эчендә җиңә ала торган хатын. Юк, ачуланмаган икән, менә ханым матур, тактага яза торган акбурдай ак тешләрен күрсәтеп елмаеп куйды. Хәлне еракттан башлап сөйләп, аңлатып бирергә кирәк иде. Динәнең әти-әниләре Альфреднықылар белән

электән үк таныш. Арча кырындагы хәрби шәһәрчектә яшәгәннәр. Динәнең әтисе – хәрби, әнисе – шулай ук врач. Динә үзе Альфредны малай чакта берике мәртәбә генә күреп калган. Аны әтисенең Мәскәүдә яши торган югары чиндагы бабалары үзләрендә тәрбияләгән. Сугыш алдыннан гына Альфредның әти-әнисе дә каядыр күчерелгән. Мәскәүдәге бабалары исә каһәргә юлыккан. Ул елларда бик күп хәрбиләрне кулга алдылар шул. Ә Альфредның әнисе бездәге Тарковскийларга чыбык очы тиешле икән.

– Бердәнбер малайлары хәл эчендә, үзең дә күреп торасың. Әти-әнисе моны яхшы аңлый һәм бернәрсәләрен дә кызганмый. Уллары белән чагыштырганда, бу чүпрәк-чапрак нәрсә инде?! – диде Динә Әхәтовна, ачыргаланып.

Таня хәзер аңлады инде: югарыдан Динә Әхәтовнага бик ныклап бурыч йөкләтелгән. Альфред Бачуринны ничек тә терелтергә, аякка бастырырга! Нинди генә әмәл белән булса да! Обкомнан ук әйттеләр микәнни? Шулай сизелә. Генералның анда да танышлары бардыр, ахрысы. Булмаса, Мәскәү аша эш йөртәдер. Казанга Мәскәү боерыгы күктән атылган яшен кебек тәэсир көченә ия. Казанда Мәскәүнең бер әмере дә үтәлмичә калмый. Казан ул күндәм, таш яуса да, авыз-борыныннан кан акса да, боерыкны барыбер үтәп чыга. Шулай итеп, Таня мәсьәләнең җитди икәнлегенә тәмам төшенде. Димәк, шундый катгый бурыч куелган. Ничек инде аңа каршы киләсең? Минминлегең, горурлыгың белән ничек санашып торасың?

– Менә, барысы да сиңа, әйдә, ач, кара, үлчә, – диде Динә Әхәтовна, елмаеп. – Мин ботканы пешердем, әмма ашатуы кыен...

Ул, мул күкрәкләре өстенә учын куеп, көлгәндәй итте. Динә Танядан үзен аңлавын һәм кире какмавын сорый төсле иде. Таняның башында һаман бер уй болгана: димәк, Тарковскийга өстән басым ясаганнар, Тарковский исә – сектор мөдиренә, сектор мөдире – Динә Әхәтовнага, Динә Әхәтовна үз чиратында – аңа. Бәлки, Таняга бәхет шулай кул сузадыр? Бәхетне сайлап алып булмый, диләр бит. Кешегә яман һәм әйбәт хәлләр үз чираты белән килә. Адәм баласы шуларның барысын да тигез күтәрергә тиеш. Начарын да, яхшысын да. Шул хәлләр аны сыный, имеш. Начар хәлләрне дә сыкранмыйча, шыңшымыйча үзең күтәрсәң, сеңдерсәң, гафил калмыйсың, имеш. Барыбер бәхетең сиңа бер елмая, ди.

Таня шундый юк-бар нәрсәләргә дә әһәмият итә һәм ышана иде. Моның мәгънәсез бер эш икәнен аңласа да, шул нәрсәләр иркенә бирелә. Тартмаларны ачтылар. Анда ефәк тә вискоза иде. Елык-елык итеп торалар. Болар – билгеле, Таняга бик тансык, кирәкле нәрсәләр. Ул комбинацияләр, ул үтә күренмәле оеклар дисеңме – бездә боларның берсе дә юк. Төшеңә дә керми торган әйберләр.

– Син, Таня, бер дә аптырама, алар моны акча түләп алган дисеңме? – диде Динә. – Анда, байлар ташлап киткән кибетләрдә, моның ише ганимәтләр тулып ята, ди. Вагонлап ал, имеш. Шуның өчен, күңелең тыныч булсын, бер дә борчылма. Альфредны караган, тәрбияләгән өчен бүләк бу. Миңа да җибәрделәр. Һич икеләнмичә кабул иттем. Врач-сестраларга бүләк бирүнең бернинди хилафлыгы юк аның. Электән килгән бер йола гына...

– Шулай да бүләкләр бик күп бит, мин аклый алырмынмы соң? – диде Таня, вискоза комбинацияне баш аркылы кия-кия.

– Борчылма, барысы да әйбәт булыр. Минем киңәшне генә салып таптама...

Динә кызның шоколад төсле матур йомры иңнәреннән карашын шудырып узды. «Таняда теләсә нинди бирешмәс йөрәкне эретеп, үзенә кол итә торган гәүдә-сын икән ич... Их, миндә булса иде ул шундый яшь, җәлеп итә торган гүзәллек!»

– Сез Альфредка беренче кичне үк бирелергә кушасыз, Динә Әхәтовна, – диде Таня, шаяртулы тон белән. – Менә болар барысы да шуңа хәзерлекме инде?

– Беренчеме, икенче кичме – анысы барыбер, Таня.

– Әгәр миннән булмый, дисәм, Динә Әхәтовна? – диде Таня, көмеш кебек елык-елык килеп торган лифен чишә-чишә.

– И-и, Таня, син артта калган кеше икән. Хәзерге кызлар шуның белән санашып торамы инде? Үзләре ир-ат кочагына атылырга тора.

– Башта язылышыйк, Динә Әхәтовна, аннары...

– И-и, Таня, син нәрсә инде, ә? Шундый егеткә...

– Минем бит кияүгә чыгасым бар, Динә Әхәтовна.

– Юкка борчыласың икән, әгәр Альфредның ирлек сәләте кайтса, ул сине хатынлыкка алмас дисеңмени? Ала, билгеле! Синдәй гүзәлне ычкындыраламы соң? Бигрәк тә син эти-энисенә бик ошагансың. Юк, ике дә уйлама, ала ул сине, ала!

– Кем белгән аны, Динә Әхәтовна. Беренче кичтә үк ул миннән бизсә? Мин аңа кайсы ягым беләндер ярамасам? Әнә иптәш кызым белән дә шулай булды. Танышып, бер-берсен яратышып өйләнештеләр һәм озак та үтми аерылыштылар. Иптәш кызым әйтте: беренче төндә үк безнең элеккеге мәхәббәт чәлпәрәмә килде, диде. Кыз сизгән: егет аны ошатмаган. Иртән йокыдан бер-берсеннән читләшеп торганнар. Егет, аска караган килеш, карават янына утырып тәмәке тарткан да тәмәке тарткан. Авыр көрсенгән. Кызга күтәрелеп карарга кыймаган. Салынып төшкән җилкәләре генә кыймылдап-селкенеп торган. Көндез чыгып киткән дә бүтән кайтмаган... Әгәр әнә шулай булса?

– Юк, алай булмас, Таня, менә әйткән иде, диярсең. Альфред – бик намуслы кеше. Андый нәрсәләргә сәләтсез ул.

– Динә Әхәтовна, әйтик, минем аңа кай ягым белән ярамавыма ул гаепле түгел бит, мин дә гаепле түгел. Менә хикмәт нәрсәдә...

– Ул мәсьәләдә артык нәзберек булырга ярамый, Таня, тирәнгә керергә дә кирәк түгел. Ну, син нәрсә югалтасың?

– Язмышымны хәл итә торган нәрсәне югалтам, Динә Әхәтовна.

– Тагын катлауландырасың, Таня. Ни мәгънә? Әгәр син Альфредның дәрте кузгалганда киреләнсәң, аңа бик тирән яра ясыйсың һәм операцияне юкка чыгарасың. Аңлаттым бит, врач рецепты буенча Альфредка шулай тиеш. Син аңа – дару урынына...

– Сез аның турында гына кайгыртасыз, мине дару итеп...

– Табибларның язмышы шундый инде, Таня. Чын врач, авыруны терелтер өчен, бернәрсәсен дә кызганмый. Хәтта гомерен дә.

– Анысы әүвәлге заманнарда булган, хәзер башка...

– Альфред белән сөйләшәм дә сине аңа димлим, шулай бит. Ә? Бәлки, ул үзе дә язылышмыйча риза булмас. Ә? Психик яктан бик нечкәргән ул, көне-төне китап укый. Беркем белән сөйләшми. Синең белән сөйләшү аңа күңелле, ахрысы? Ә?

– Болай йөзендә нур кабынып киткәндәй була анысы. Сизүемчә, ул мине өнәмәс, Динә Әхәтовна. Ник дисәгез, мин аның кимчелекле ягын беләм бит, ә кеше андый затны өнәми. Менә шул яктан чыгып әйтүем. Сезнең тактика дөрес микән соң?

– Таня, син кушканны гына үтә. Бу мәсьәләдә без киңәштек, белештек, шундый фикергә килдек. Мин үзем генә карар кабул итмәдем...

Таняны өенә озата чыккач та, сүз һаман шул юнәлештә дәвам итте. Ахырда

кыз Динә кушканнарны үтәргә риза булды. Табиблар, үз-үзләрен корбан итеп булса да, авыруларны терелтергә тырышкан. Элек шулай иткәннәр, ләкин хәзер дә намус дигән нәрсә гел үк бетеп җитмәгән ич әле. Таня кебек кызларда бар әле ул, калган икән. Әйе, ул үзенең сафлыгын корбан итәргә әзер, тик яралы лейтенант кына сафка бассын. Фашистларны җиңүдә аның да өлеше бар, йә, ничек аның хәленә кермисең ди?!

Ихтимал, ул Альфредны ярата алыр кебек. Тик менә аның Эдуардка булган хисләре дә сүнмәгән, сүрелмәгән. Бик яшерен рәвештә генә ир бер-ике мәртәбә Таня янына да килде. Кочты, үпте. Хатынын бер тамчы да яратмавын ачынып сөйләде. Әмма кечкенә кызы өчен үлеп тора икән, куен кесәсеннән фотосын алып күрсәтте. Менә шуның хакына гына шул убыр белән яшим, диде. Гадәттә, ир-ат, үзенекен алыр өчен, әллә нинди кыяфәтләргә керә. Йомшак куян кебек була, юмалана, ялагайлана, тирәндә арты белән шуып йөри, матур сүзләр сөйли, чын артистка әйләнә. Шулай синең аңыңны томаламакчы була. Шунда син һаман бирешмисең, каты торасың, һәм теге кинәт ачулана, бүртенеп чыга һәм ерткычларча сиңа килеп ябыша... Таня андыйларны да күрде, кичерде. Ә Эдуард андый түгел, стенага китереп терәми, эчке культурасы бар. Кыз аңардан: «Нигә аерылмыйсың?» – дип сорады. Эдуардның битләре җыерылып килде, йөзе чытылды. Кулын өметсез селтәде. «Үзең беләсең, аерылу гаять катлаулы бит, – диде. – Бар законнар хатын-кыз ягында. Аерылсам, мине партиядән сөрәчәкләр, мөдирлектән алачаклар. Уф, син дә мине аңламыйсың», – диде. «Аңлыйм да соң, хатының бар бит», – диде Таня...

Эдуард үзенең кызга күрсәткән игелеге өчен бәхилләтү өмет иткәндер, билгеле. Берни дә бушка гына эшләнми, һәрнәрсә өчен түләргә туры килә. Ә Таня салкын канлылык саклый алды. Ир дә артык тукынмады, тик иңбашын борганда гына яңак сөякләре тартышып-тартышып куйганы шәйләнде.

Шул көннән соң ул Танядан тәмам ерагайды. Очрашканда да, элеккеге ерак таныш шикелле, ияк кагып кына исәнләште, икесе генә калган чакларда да сөйләшмәде, өзлексез тәмәке генә тарта иде. Аның кайгылы йөзеннән убыр белән яшәүнең никадәр авыр һәм үкенечле икәнен сизәргә була иде.

Ә менә Альфред белән ничек булыр? Акылы белән кыз аңа омтыла, акылы белән аны уйлый, чөнки күңелендә тормышны рәткә сала алмаммы дигән өмет уянды. Аннары, хисләргә караганда, акылны күбрәк тыңларга кирәк, диләр ич.

Альфред хәзер үз хәлен тәгаен аңлаган иде. Ләкин җаны бу хәлгә буйсынырга теләми, бунт күтәрә, ачулана, бәргәләнә. Бу тартышлар барысы да аның күңелендә бара, ул аларны тышка чыгармый иде. Шуңа күрә башында уйлары, умарта кортлары кебек, һәрчак гөжләп тора. Уйлардан беркая да качып булмый... Нүжәли ир-ат хатын-кыздан башка яши алмый, тормыш итә алмый икән? Дөрес, ул тәнендә дегенерация күренешләрен сизми дә шикелле. Әллә бу процесс сиздерми генә барамы? Юк, әз булса да сизелер иде ул. Беркөнне невропатолог аңардан шаяртып кына сорап та куйды: башыңа кызлар турында уйлар киләме, янәсе. Ул кызарып китте, битендә кайнарлык сизде. Һәм игътираф итәргә базмады. Хәер, врач көтелмәгән сораулары белән гел шаккатырып тора. Альфредның уенда гел кызлар гына булмаса да, ул хакта да еш уйландыра, билгеле. Врачка да шулай әйтте. Эчеңдә нәрсә бар, берсен дә яшермәскә кирәк. Врач шуны таләп итә. Бу – дәвалауны планлы һәм максатлы юнәлештә алып бару өчен мәҗбүри нәрсә, ди. Чынлап та, аның авырту-сызлауларын, эчке хаҗәтләрен кем белеп бетерсен соң? Белмәгәч, ничек итеп дәваласыннар? Врач хаклы. Ләкин аңа да барысын әйтеп бетереп булмый.

Чөнки үз халәтен ул үзе дә аңлап, белеп бетерми. Бик сәер бу. Әмма, уйлап карасаң, адәм баласы үзен-үзе бик аз белә икән. Эчке тойгыларын аңлатырга сүзләр юк, тәгъбирләр җитми. Галимнәр берсен-берсе кабатлый. Практикадан чыгып язучылар бик аз. Күбесе, теориядән этәрелеп китеп, интуициягә бирелә. Үзенең версиясен тасвирлый. Ул, әлбәттә, үзеннән чыгып фикер йөртә. Ә һәр затның үз сыйфатлары, үз тойгы-сиземләүләре бар.

Ә бит гомер буе өйләнмичә яшәгән ирләр дә бар. Алар нинди хисләр кичерә? Нигә хатын-кызга якын бармыйлар? Әллә аның кебек авырыйлармы? Ә бит табигатьтән дә хатын-кызны чит күргән, аны кұралмаган ирләр була, ди. Хатын-кызга ул үзе ничек карый соң? Кызыксыныпмы, әллә салкын битарафлык беләнме? Әллә аңа бәла китерә торган зат дип, куркып-шүрләпме? Боларны үзең өчен тәгаенләргә кирәк. Әмма күп нәрсәләргә егетнең уй ихтыяры җитми. Уйлый башласа, башын томан сара, һәм уй җепләре шул томан эченә батып югала. Очларын табып булмый. Уйлар ерак китә алмый, сазлыкка эләккән юлчы кебек, кире борыла. Элек исә уйлары ерак-ерак китә, әллә кайларга барып җитә торган иде. Барысы да шушы каһәр суккан яра галәмәтедер инде.

Ярасы исә бик яман иде. Ике бот төбе дә яраланган, эчке яктан да, тышкы яктан да ядрә ярчыклары белән теткәләнгән, мунчалаланып беткән иде. Шунда ук бәвел каналы да зарарланган. Эче бик зур шар кебек күпкән булган, шул хәл аңын җуйдырган. Бәвел куыгы турысыннан тишеп, шланг-катетер куйганнар. Үзе җиде көн аңына килә алмаган, чөнки сидек канга үтеп керә башлаган.

Альфред ярты ел чамасы биленә шешә асып, сидек куыгыннан килә торган нечкә шлангны шуңа тоташтырган килеш йөрде. Боттагы яралар озак төзәлде. Тәненнән ит качып беткән иде. Сидекнең канга эләгүе бик тә хәтәр, организмны тәмам агулый икән.

Ә иң яманы – нәрсәдер эчне пошырып, ямансулатып тора. Шул ярадан микән инде ул? Күңелне билгесезлек басып, изеп тора. Җан беркая да омтылмый, берни белән дә кызыксынмый. Юктан гына да ачу кабына, эчкә ут агыла. Нишләргә, кая барып бәрелергә белмисең. Бу изә торган халәттән нәрсәдер эшлисе, котыласы килә. Нәкъ читлеккә бикләнгән җәнлек кебек сизәсең үзеңне. Әйе, аның тәне түгел, рухы яраланган булса кирәк. Таза вакытта егет һич тә мондый халәттә калганын хәтерләми. Ул һәр якты көнгә сөенә, эчендә шатлык уяна, куян кебек сикергәли, шаяра иде. Авыр, кискен вакытларда да күңеле төшми, кайгыны бик тиз үткәреп җибәрә иде. Ә хәзер нииндидер билгесезлек аны чыгырдан чыгара, зиһенен томалый, һәр теләген бетерә. Аңарда хәзер бернинди кызыксыну калмады. Китапларны да эч пошуны басу, вакыт үткәрү өчен генә укый. Нәрсә инде бу? Ни булды аңа? Шулай да рәткә керә алмас микәнни? Ичмаса, яраң бүтәннәрнеке кебек беленеп торса иде. Кешегә әйтергә оят. Бер врач та тәгаен генә берни белми. Ул үзе дә ачык кына әйтә алмый. Элек аның уйлары, ният-теләкләре ап-ачык иде. Хәзер теләк-омтылышлар сүнгән, беткән, көле генә калган кебек. Менә шул көлдә казынып ят инде. Шул көлләрне актарырга гына калды, әй, егетләр! Ничек килеп чыкты соң бу?

## II

...Латвия белән Литва чигендә Пепкуле дигән шәһәрчек бар иде. Немецлар анда хәзер гел оборона тота. Кырык дүртенче ел тәмамланып килә. Башка фронтлар бик нык алга китте, Балтыйк буе гына тоткарланды. Бу хәл, билгеле, командованиедә борчу тудыра иде. Шуңа «һөҗүмгә күчәргә» дигән боерык шактый еш килә. Ә һөҗүмне бик җентекләп әзерләргә кирәк. Һәр һөҗүм РС

батареяларының залпы белән башлана. Цельләр алдан әйтелми, сер итеп саклана иде. Ә без – каторжаннарга снарядлар ташучы взвод. Минем карамакта – дүрт студэбеккер. Дошман кулына төшү куркынычы булганда, без снаряд төялгән машиналарны шартлатырга тиеш. Моның өчен ПОУ дигән прибор куелган. Шуның рычагын тартасың да – вәссәлам. РС снарядлары, билгеле, җитәрлек кадәр тылдарак, шулай да алгы сызыкка да бик тиз илтеп җиткерергә кирәк була...

Безнең янәшәдә махсус пропаганда хезмәтләре урнашкан иде. Аларның юка броня белән бөркәлгән машиналары түбәсенә зур динамик куелган, ә эчтә – мегафон приборлары. Төнлә алгы сызыкка бик якын урнашып, немецларга динамик аша сөйлиләр. Безгә әсир төшкән зуррак чиндагы немецларны сөйләтәләр. Лена Лузина шул бүлектә тәрҗемәче булып эшли иде. Дивизия штабы янәшәсендә бергә ашап-эчеп йөргәндә танышып киттек. Ничектер үзеннән-үзе килеп чыкты. Хисләр һәрчак уяу, һәрчак эзләнә, ничектер ихтыярың белән дә санлашмаска итә. Башта шаярып-уйнап сөйләшеп йөрдек, аннары чынга әйләнде. Икебез дә бер-беребезгә тартыла башладык. Моны инде эчтә йомып кына калдыру, сүндерү мөмкин түгел иде. Лена тыйнак, җитди кыз иде. Уртачадан биегрәк буйлы, йомры иңле, озын муенлы, түгәрәк битле. Кыска итеп алган чәче өстендәге коңгырт береты, сержант погонлы гимнастёркасы аның туры, килешле гәүдәсен тагын да мөлаем итә кебек. Барыннан да бигрәк тавышы һәм сөйләшүе үзенә бертөрле ягымлы иде.

Яңа елда без старшина каптёркасында икәү генә калдык, һәм мин Ленаны кочаклый, үбә башладым, ә ул иркәләүне салкын кабул итте. Мин аны үзем кебек «кабындырмакчы» булам, әмма ул салкын, «кабынмый». Ахыр чиктә мин кыюланып ук киттем. Лена, корт чаккандай, кинәт торып басты. Киемнәрен төзәтте, ә чыраена ризасызлык төсмере чыкты.

– Безнең арада мәхәббәт дип торам, – диде ул, әле генә ашап-эчеп утырган өстәл янына барып. – Юк икән, юк!

– Ә нәрсә соң безнең арада, Лена? Йә инде, ачуланма! Хисләремне ничек аңлатыйм соң?

– Ярату булмаган, юк, әллә нәрсә! Син алырга телисең, мин бирмәскә телим. Шулмы ярату, ә? Ярату мөнәсәбәте түгел бу, алыш-биреш мөнәсәбәте, икенче төрле әйткәндә, сату-алу мөнәсәбәте. Нәкъ политэкономиядәгечә килеп чыга...

– Безнең мөнәсәбәтләр чын дип уйлаган идем мин, Лена.

– Мин дә чын дип ышана башлаган идем, Альфред, ә уен гына булуын үзең белгерттең...

Лена ачуланмый, чыгырыннан чыкмый, тыныч кына сөйли. Гүя ул моны көткән һәм шуңа әзерләнгән дә шикелле иде. Билгеле, бире дә аңа бәйләнүчеләр бардыр. Минем кебек яшь лейтенантлар шактый күренә. Барысы да чибәр, кире какмаслыклар. Кайбер кызларның башлары әйләнсә дә, гаеп итәргә тел бармас. Ә адәм затына бирелгән хисләр фонды – кызларда. Шул фонд белән ничек идарә итә аласың, хикмәт шуңарда.

Авыр тынлык урнашты. Элемтәләрне өзәсе килми, эчтәге тойгылар аваз сала, килеп чыккан кытыршылыкны тизрәк бетер, бетер, дип әйткән кебек иде.

– Юк, мин уйнамыйм, Лена. Яратуымны шулай белгертмәкче идем.

– Бу – яратуны белгертү түгел, алырга дигән ниятне белдерү.

– Хисләр шулай кушкач, нишлим соң, Лена? Әйт, өйрәт.

– Хисләр юләр ул, Альфред, аларга карап йөрсәң...

– Күрәм, синең хисләрең булмаган, ихлас тойгыларым белән бозга килеп бәрелгән күк иттең. Бу – минем беренче хисләремдер, беренче өметләремдер,

ә син... Лена, ну, нәрсә булды, ә? Ярар, бу – синең беренчесе түгелдер, ә минем – беренчесе. Шуңа бик авыр булды.

– Ну, Альфред, шыттыра беләсең дә инде!

– Исбатлап маташмыйм, ә синең беренчесе түгел икәнен генә бик яхшы аңлыйм, Лена.

– Билгеле, миңа беренче генә бәйләнмиләр, әйе. Бәйләнүчеләр күп булды, яшермим. Барысы да вакытлы гына элемтә ягында иде, ә миңа гомерлек булсын, вакытлычага мин риза түгел. Сиңа да мин вакытлы гына кирәк, шулай бит? – Лена һич тә ачуланмый, чәүчәләнми, зар авазы да чыкмый үзеннән.

– Мин чын хисләремне әйткән идем, Лена, ачуланма инде, зинһар!

– Вакытлы гына кузгалган хисләр, Альфред, – диде Лена, бик гади нәрсә хакында әйткән төсле. – Приступ шикелле, хисләр приступы, ә? Өянәк үтә ул...

– Син «атака»ны кире кайтарырга остарып беткәнсең димме?

– Дөнья өйрәтә, Альфред, дөнья. Ә без – дөньяның мәхлуклары.

– Юк, миңа әллә нәрсә булды, Лена. Син миңа ышанмыйсың, шулай бит? Димәк, миңа карата хисләрең булмаган... Шулай да...

– Син миңа ошыйсың, Альфред, чөнки син берни дә вәгъдә итмисең, ялганламыйсың, мине, ымсындырып, алтын элмәккә эләктерергә тырышмыйсың. Шуңа күрә, әллә синдә чынлап та беренче хисләр микән, дип уйлап та куйдым. Юк, булмас, дидем эчемнән генә, алданма... Хәер, барыбер бер алданырга туры килер, мөгаен...

– Әйе, адәм баласы иң элек мәхәббәттә алдана, аннары бүтән нәрсәләрдә, диләр... Ә без бер-беребезне алдамыйк, Лена, яме.

– Ә бу мөмкин эшме соң? Хисләр үзгәреп тора, бүген бар ул хис, иртәгә бетә дә куя. Синең белән шундый хәлләр булдымы?

– Минем хисләр алай тиз алышынмый, Лена. Бу, ахры, табигатьтән килә. Ә синеке һава торышы кебек тиз алмашынып торамыни?

– Әйе, һава торышы кебегрәк шул. Кайчак үз-үземне аңламыйм, үз-үземә җирәнгеч булам. Уф! Юк, мин үземне яратмыйм. Ә син үзеңне яратасыңмы?

– Мине үземне ярата торган итеп тәрбияләгәннәр. Нигә, бу начармы әллә?

– Әйтә алмыйм, үзен яратмаган кеше бүтәннәрне дә ярата алмый, ди аналитиклар...

– Димәк, бу әйтем сиңа туры килә. Ник үз өстеңә сөйлисең, Лена? Болар берсе дә дөрес түгел бит.

– Ир-ат кыска «элемтәләрне» ярата, хатын-кызга гомерлек булсын. Менә безнең аерма шунда, Альфред.

– Лена, бер сүз әйтимме? Син артык акыллы, бик исәп-хисаплы, ә?

– Миннән дә ахмакны таба алмыйсың, әйтмә! Мин ул сүзләрне чынга алмыйм, чөнки уйлап җиткермәүчәнлегем миңа адым саен аяк чалып тора.

– Алай мескенләнмә, Лена. Бик әйбәт кеше, диләр сине.

– Кемгә әйбәт, ә кемгә начар. Син дә бар кешегә дә яхшы түгелсеңдер әле.

– Билгеле инде. Юк, мин үземне яхшы кеше дип беләм. Мактанып әйтүем түгел.

– Мин үземне алай раслый алмыйм. Чын яхшы кеше булу мөмкинме икән? Юктыр, мөгаен. Яхшы булып кыланганнарны җенем сөйми.

– Мин дә яхшы булу уенын уйныйммы?

– Белмим, Альфред, мин сине эштә сынаганым юк. Болай, сөйләшкәндә, үзен һәркем хаклы, фәрештә итеп күрсәтә. Адәм баласы үзенең теләсә нинди әшәкелеген дә аклый, нигезли. Үзен хаклыга чыгара...

– Синең белән сөйләшүе күңелле, Лена, чын менә.

– Ягъни безнең «җитештерү мөнәсәбәтләре» барып чыкмады, шулай бит?

Лена елмайды, бит очында матур чокырчыклар пәйда булды. Алар нindидер нур бөрки иде. Нишләп шултиклем ымсындыргыч соң бу Лена? Бүтән кызлардан нәрсәсе беләндер аерылып тора ул... Артык аек фикер йөртүе һәм яшьләрдә күзәтелә торган романтик чалымнарның бер дә булмавы беләнме? Аны мәхәббәт иллюзияләре адаштыра алмастыр. Әллә ул хыялларның чәлпәрәмә килү чорын инде узганмы? Тормыш мәктәбе аны шулай барына да ис китмичә генә карарга өйрәткәнме? Ә бергә шаярып-көлешеп йөргән чакта, Ленаның характеры җиңелдер шикелле тоела иде. Хәтта җилбәзәк кыз түгел микән бу, дигән уй да килә иде. Шулай җиңел булып күренүе дә хисләргә ирек бирде бугай. Җиңел уйлаучы кызлар белән элемтәгә дә җиңел кереп була. Җиңел генә дуслашасың да җиңел генә аерылышасың. Ул да яшь түкми, син дә уфтанмыйсың. Сагынып сөйләрлек бер истәлек кенә кала. Җиңелләр белән әйбәт, эшне катлауландырмыйлар, зурга җибәрмиләр. Ул кызларга егетләр дә рәхмәтле була. Ләкин андый кызларны, гадәттә, тормыш юлдашы гына итмиләр. Ә Лена – четерекле зат. Һәрнәрсәгә артык җитди карый. Үз-үзенә ышанып җитмидер, мөгаен. Әллә таяныр, булышыр кешеләре юкмы, һәрхәлдә, бар авырлыкны үзе генә күтәреп яшәгәнгә охшый ул.

Минем хисләр, Ленаның каршылыгына очрап, барыбер сүрелмәде, отыры көчәйде генә. Мин-минлек тә үҗәт авазлар белән үчекләп торган кебек иде. Ничек инде, мин аңа чын тойгыларымны белгертәм, ә кыз барын да кире кага. Мине юкка чыгара, хисләрне генә түгел, мине шәхес буларак та танырга теләми. Асылда шулай килеп чыга бит... Үзенең бетүе, чүпкә калуы белән кем килешә алсын? Юк, Лена алай итмәсен, мине беткәнгә санамасын. Мин алырга гына телим, имеш. Әллә чынлап та шулаймы? Адәм баласын иң күп алдаучы – ул аның хисләре. Әллә мине дә хисләрем алдыймы?

Лена белән ара өзелмәде, киресенчә, тагын да якыная гына барды. Безнең ачыктан-ачык аңлашу ярдәм итте бугай. Ул минем кайбер сыйфатларымны белде, мин – аныкын. Лена да уйлана иде шикелле. Очрашкан саен әйбәтләнә, йомшара барган төсле иде. Хисләренә дә ирек биргәли, иркәләүләргә җавап кайтара, кире җибәрми иде. Берсендә шулай әйтеп тә куйды:

– Син мине барыбер ташлаячаксың, шулай бит, йә, боргаланмыйча гына әйт әле? – диде һәм торып утырды, чәчендәге приколкаларын алып, авызына капты, төзәтенә башлады. Үзенең күзе гел миндә иде. Мин ни әйтергә белмәдем, өйләнергә дигән уем да юк иде. Ялганларга кирәк иде, шайтан, кызлар янында гел дөресен генә сөйләп утырып булмый. Үзеңне тоттырмаска тиешсең. Артык хисләнгән чакларда телдән ычкынган борчак шыттыруларга үзеңнең эшләреңне дә туры китерергә кирәк. Авызым, корт чаккыры, борчакны чамаламыйчарак сибеп ташлады, ахры. Өйләнәм дип үк әйттем микәнни?

– Юк, ташламыйм, Лена, нигә ышанмыйсың? Ну, инде нигә ташлашырга? – дидем мин, кыюланып китеп.

– Миннән матурракларга күзең төшәр дә... Ирләрнең табигате шундый, ди бит... – Лена мөлаем гына көлеп куйды. Приколкаларын, ирен арасыннан алып, чәченә кадады...

Чынын әйтә бит кызый, минем эчтә нәрсә ятканын сизеп фикер йөртә. Менә тагын ялганларга туры килә инде. Юк, алай түгел, минем күңел бүтәннәр өчен бикле, мин әйтәм. Лена тамчы да ышанмый шикелле. Юк, ышана, дөресрәге, ышанырга тели кебек.

– Син минем күземне бәйләдең инде, хәзер ул бүтәннәрне күрмәячәк... – Мин моны бик ышандырырлык тон белән әйттем. Битемә әз генә кызыллык

йөгергәнен сиздем. Ленага беленмәсен дип курыктым. Ул мине үзенеке генә итмәкче була, фронт шартларында элемтәләрнең ничек, кайчан өзеләсен яки өзелмәсен һич тә алдан гөманлап булмый. Ул шул хәлне исәпкә алып җиткерми, әллә үзенең башка планнары бармы? Мин исә реаль уйлыйм, сугышта берни дә тотрыклы була алмый. Якын элемтәләр, туганлык мөнәсәбәтләре бик тиз чәлпәрәмә килә. Бирелдә бернигә дә ышанырга, таянырга мөмкин түгел. Лена ышанырга, таяныч булдырырга тырыша. Шуңа күрә миңа эчтән бер төрле уйлап, тыштан икенче төрле сөйләргә туры килә. Һич тә гаиләгә җигеләсе килми, мин шул нәрсәдән нигәдер куркам да. Кызлар белән танышканда уйлыйм, борчылам: бу мине гаиләгә китереп бәйләмәсме? Шартларның яман булуы гына сәбәпме минем куркуыма? Әллә мин белмәгән башка сәбәпләре бармы? Мин Лена белән гаилә кору ягында түгел. Нигә, шулай бер-береңне яратышып кына очрашкалау начармыни? Кай төшең кими аңардан? Лена исә моңа риза түгел. Мине гомерлеккә үзенеке итәргә өметләнә. Шул юнәлештә үзенчә мине тәрбияләргә тырыша. Зиһене бик уяу, үткер кыз. Хәер, минем үземнең дә Ленага карата хисләрем чын бит, ихлас яратам мин аны, әмма гаилә камытына һич тә керәсе килми. Эчтә протест кузгала. Чын хисләр белән генә булмый икән, аңардан өстен нәрсәләр дә бар.

– И ялганчы, сөйләп торган буласың бит! – дип, Лена, яратып, җилкәмә төртеп куйды. Ул минем ике төрле сөйләвемә ышанып бетми, бергә булуга өмет итә, шул ук вакытта нидер сизенә дә. Начар очрак өчен үзен алдан әзерли кебек. Мин дә бит, гаилә тормышының җаваплы һәм авыр булуыннан шүрләп, алдан әзерлек эшләре алып барам. Лена белән артык тирәнгә кереп сөйләшмим, берни дә вәгъдә итмим. Үземне кыерсытылган, язмыш тарафыннан рәнҗетелгәнрәк итеп күрсәтәм. Янәсе Лена ымсынмасын, иллюзияләр кормасын. Алдагы тормышымны да томанлы итеп сурәтлим. Анысы чынлап та шулай: алда гомер әллә бар, әллә юк. Моны Лена үзе дә яхшы аңлый.

– Син менә үзеңнекен алдың да хәзер миннән ничек котылу җаен эзлисең бугай... – диде Лена, ничектер күңеле төшкән кыяфәт чыгарып.

– Лена, минем хакта начар уйлыйсың икән, ай-яй! – Ничек тә аның күңеленә килгән бу фикерләрне таратырга, юкка чыгарырга кирәк. Әмма көчем җитеп бетми, дөресне юкка чыгару – шактый мәшәкатьле, күп көч сорый торган, нечкә эш. Чынлап та, миңа шундыйрак уйлар килгәли иде. Безнең якынлык очрашкан саен тирәнәя бара иде. Башта ул минем хисләрдә генә иде, хәзер тәнгә һәм акылга үтеп керә башлады. Бу хәл мине шактый ук борчый иде. Бер яктан – яратышу, рәхәтлек, икенче яктан – эчне таракан кебек кырып, бимазага салып торган халәт. Нәрсәгәдер борчылам, уйсыз гына тора алмыйм. Ленаны кызгана башлыйм. Лена бит ул миңа ышанды, үзен җәлләмәде, ә мин аны алдарга җыенам шикелле. Башта ук безнең бәйләнеш вакытлы гына булырга тиеш дип уйланылган иде. Әллә шуңа микән, минем алдау бер дә алдау түгелдер кебек тоела. Лена өчен ул алдау булыр инде, ә минем өчен гөнаһлы нәрсә түгел. Мин һаман гаепне үз өстемнән читкә шудырмакчы булам. Нәрсәдән бу? Фронт шартлары, сугыш климатыннанмы? Аннары иң зур тынычландыру дәлиле башыма килә: Лена өчен мин беренчесе булмадым бит. Шулай булгач, җаваплылыкның яртысы үзеннән-үзе чуттан төшә. Аңа нәрсә – берәү артык, берәү ким – барыбер түгелмени? Юк, мин мең мәртәбә хаксыз болай уйлавым белән. Бу – начар уй, культурасызлык, намуссызлык! Үзен синең ирекккә куйган кыз турында ничек әшәке уйларга мөмкин? Димәк, мин үзем әшәке, беткән зат булып чыгам. Менә бит ир-ат хатын-кыз алдында нинди икейөзлегә әйләнә! Гаҗәпкә калырсың. Минем бүтән чакта

болай монафикъ булганым юк, була да алмыйм. Хатын-кызлар алдында әллә нинди түбәнлекләргә төшәсең дә куясың, үзең дә сизмисең. Лена берчак шулай терсәге белән мендәргә таянды да чәчләремнән сыйпады.

– Әллә ни уйлама, – диде ул, икенче учы белән ачык күкрәген каплап. – Мин сине җәлләдем, минем алда үзеңне түбәнсетүгә кадәр җитүең намусыма тиде. Шул сындырды, кешенең түбәнсенүен күрү түзеп булмаслык хәл бит...

– Син бик әйбәт кеше, Лена! Байлыгыңны миннән җәлләмәдең. Рәхмәтле мин сиңа...

– Тукта, син минем белән саубуллашасың түгелме соң? Аерылышканда гына шундый сүзләр әйтәләр.

– Син нәрсә, Лена? Юк, һич юк... – дидем мин, ләкин әйткәннәрне кире алып булмый иде. Артыграк ачык күңелләләнеп киткәнмен, шайтан алгыры! Үзем дә сизмәстән, күңел халәтемне әйтеп, үземне сатып ятам икән... Лена бу юлы минем сүзләргә нык әһәмият бирде, зиһене бик уяу икән. Шуннан ул торып утырды да, бик күңелсезләнеп, башын аска иде. Озак кына эндәшми торды. Аның уйлары эшли, хәрәкәт итә, моны битендәге әле яктырган, әле караңгыланып киткән шәүләләрдән чамаларга була иде.

Лена ничектер дөрес сизгән: без шул кичтән соң бүтән очраша алмадык. Мин машиналар белән РС снарядлары илтергә алгы сызыкка киттем. Йөкләрне тиешле батареяларга тапшырдык. Көн яктырып беткән иде. Соңга калганыбызны аңлап, ачык урыннардан тизрәк элдердек. Ләкин бер урман арасында немецның ерактан ата торган туплары утына юлыктык. Нишләптер снарядлар еш төшә иде. Узып китеп өлгереп булмады, машинадан ерак түгел авыр снаряд шартлады. Мин, ул-бу булган очракта тизрәк җиргә сикерер өчен, кабина ишеген ачып куйган идем. Әмма өлгерә алмадым – бер мәлгә машина әллә кая очып киткән кебек булды, нәрсәдер кабинадан мине суырып алды, шатыр-шотыр килеп киемнәремнең эләгеп ертылган тавышы колакка керде кебек. Шуннан соң берни белмим. Кем мине җыеп алган, кем санбатка алып кайткан – барысы да билгесез. Аңга килгәндә, янымда врачлар-сестралар иде. Бу – безнең санбат түгел, бүтән частьның госпитале иде...

Аңга килеп, бераз рәтләнә башлагач, үзебезнең частька хат яздым. Озак җавап килми торды. Фронт штабына язгач кына, «Часть таратылды» дигән ике генә сүзле җавап килде. Ленага да яздым, ләкин үземнең нинди яра алуымны ул чакта аңлап һәм белеп җиткермәгән идем әле. Аңсыз көе шундый ахмаклык эшләп куйганмын. Ярый әле аңардан бер хәбәр дә килмәде. Югыйсә ярамны ничек тасвирлап язар идем икән. Каһәр суккыры! Минем яралануны эти-әни дә врачлар белән элемтәгә кереп кенә белә алды. Күпме генә кыстасалар да, мин яза алмадым. Әни, врач буларак, һаман диагноз таләп итте. Ачуланып бетерде.

Минем белән бергә яткан лейтенант, ярамның нинди икәнлеген белгәч, әйтә куйды:

– Син хәзер кеше түгел инде, – диде. – Туры әйткәнгә үпкәләмә, зинһар! Мәсьәләгә аек карарга кирәк...

– Ничек инде кеше түгел? – Мин аны шаярта дип торам. Йөзенә карыйм, бик җитди әйтә. Дөрес, минем рухсызлык, сүнгәнлек бар кыяфәтемә чыккан. Шуннан чыгып әйтә торгандыр инде.

– Эчеңдә стерженең булмагач, булмый инде, – дип куйды ул, минем сүзләрне ишетмәгәндәй.

– Кешене шул гына кеше итәмени соң? Юк, дөрес түгел, – дидем мин, эчемдә кузгалган каршы тору үҗәтлеге белән. Әмма сүзне дәвам итә алмадым, чөнки

фикер очы югалды, аңымның дәрте, егәре бетте. Хәер, моның әһәмияте юк та сыман тоелды. Үртәлү, гарьчеллек хисләре дә үтмәсләнеп беткән икән миндә... Бары рәнҗүле, мескен хисләр генә кузгалып куя. Алар мине аска таба тарта, җирдән үрмәләргә мәҗбүр итә шикелле. Юк, мин җирдә мүкәләп йөрергә, түбән тәгәрәргә тиеш түгел. Мин шундый егет идеммени? Яра мине бөтенләй бетереп ташладымыни? Аяк-кулым исән, күзем күрә, гәүдәм дә бөтен килеш, нүжәли мин беткән кеше инде?! Дөрес түгел, ышанмыйм мин моңа. Адәм баласын нәрсә йөртә, актык чутта нәрсә яшәтә? Нәрсәдәндер мәгънә таба, шуның мәгънәсенә ышана, һәм шул ышанычы йөртәме аны? Ихтыяҗ, кирәклек йөртә, дип яза галимнәр. Ә ихтыяҗ, кирәклелек каян килә? Алары кешенең эчендә: тәнендә, җанында, башында, ди. Туганда ук, кан аша нәселдән бирелә. Шул нәселдән килгән ихтыяҗ кешене әллә ниләр эшләргә мәҗбүр итә. Урман кистереп, өй салдыра, җир сөрдереп, иген иктерә. Тагын бик күп, бик күп эшләр эшләтә. Барына да шул кандагы ихтыяҗ, хаҗәт көч бирә. Кеше тир түгә, кан коя, әмма барыбер хәрәкәттән туктамый. Чыкмаган җаны һаман яшәргә омтыла. Бу омтылыш бик көчле. Җанның омтылышы, яшәргә ашкынуы бернинди киртәләрне танымый. Ул комачау иткән һәрнәрсәне җиңә, ватып-җимереп булса да үтә, алга китә. Ә менә аның двигателе ни хисабына, нинди «ягулык» хисабына эшли соң? «Ягулыксыз» гына табигатьтә берни дә эшли алмый. «Ягулык»ка өстәмә тагын нәрсәдер бар, чөнки адәм баласы икмәк белән генә тук тора алмый, икмәккә генә риза булып яшәми. Аңа тагын нәрсәләрдер кирәк. Шатлыклар белән генә дә канәгатьләнеп яши алмый ул. Аңа газаплар да кирәк. Нинди генә авыр хәлгә калганда да, тәмам беттем дигәндә дә, адәм баласы өметен өзми. Тере җанда өмет бар, диләр. Ә җан үзе нәрсә? Кешене яшәтүче, алга омтылдыручы атом кебек ул җан. Атомның көче бик зур булган кебек, җанның да көче биниһая. Минем әнә шул җан җирем яраланып эштән чыккан. Тән ярасы төзәлә, җан ярасы төзәлми, диләр. Мин дә төзәлә алмам микәнни? Юк, дөрес түгел, мин терелергә тиеш. Үзең терелергә теләмәсәң, тырышмасаң, сине врачлар гына кеше итә алмый... Нишләп мин шултикле кайгырам әле? Ә бит кайбер ир-атлар гомер буе өйләнми, хатын-кыз янына барып та карамый ич. Дөресме шул хәл? Нигә дөрес булмасын? Ә бит аларның барча әгъзалары таза-сау. Нәрсәсе бар ул хатын-кызның? Ирләргә нигә кирәк алар? Бары нәсел калдыру өченме? Ә күпме адәмнәрнең бернинди нәселе-нәсәбе калмый! Ә нигә ул нәсел калдыру? Калмаса, нәрсә була? Нәсел калдыручылар дөньяда болай да җитәрлек. Ярар, нәсел калдыра алдың ди. Шуннан нәрсә? Моның нинди мәгънәсе бар соң? Менә минем нәселем кала дип сөенүме? Ә нигә сөенергә? Нәселең сине искә дә төшереп карамаска мөмкин бит. Син үлеп җир астына кергәч, аның искә алуыннан ни мәгънә соң? Юк, шулай да искә алуларын тели күңел. Ни өчен? Миңа бит салкын җир куенында искә алсалар да, алмасалар да барыбер булачак. Нилектән күңелнең бер почмагында онытмасыннар иде дигән теләк аваз сала. Юкса барыбер түгелмени?

Шулай да һаман шул бер сорау баш миен бораулый: нәрсә йөртә соң адәм баласын? Дөньяга килгәнгә күрә генә яшиме ул? Чөнки кеше дөньяга үз ихтыярыннан тыш килә. Дөньяга килүендә аның бер катнашы да юк. Менә аны, тормыш биреп, якты дөньяга чыгардылар, һәм ул бар көченә яшәргә омтыла башлады. Ни өчен туганын, ни өчен омтылганын белмичә. Һәр тере җан яшәргә тырышкан кебек, адәм заты да шуңа омтыла. Бары тере җан булган өчен генәме? Аның яшәүдән башка бер максаты да булмый. Ул үзеннән алда килгәннәр төзегән әзер тормышка килә. Шул тормыш тәртипләре белән, телиме,

теләмиме, яшәвен дәвам итә. Ә аңардан алда килеп киткәннәр коточкыч әшәке дөнья төзегән. Үзләре төзегән, үзләре законнар чыгарган һәм шул коточкыч тормышта газапланып яши бирә. Әллә нинди аллалар уйлап чыгарганнар. Алар адәм балаларын аскан-кискән, канын эчкән. Ә адәм балалары шуның өчен аллаларга рәхмәт укыган, зурлаган. Нәрсә инде бу? Үзеңнең каныңны эчкән, балаларыңны тартып алган аллаларга табынып гомер ит, имеш! Кем көлә бу адәм затыннан шултикле? Кем аны шултикле мыскыл итә? Гомерен бәхетсез иткән, тормыш көтәргә мөмкинлек бирмәгән залимнәргә бил бөгеп, аларның табанын ялап яшәргә адәм баласын нәрсә мәҗбүр иткән?..

### III

Урамга чыккач, Альфред үзенең нык кына мәлҗерәгәнен тойды. Шактый булынган икән, шайтан алгыры!

Бераздан ул үзен үзе тыңлап бара башлады. Элек, фронтта чакта, ядрә кыйпылчыгы эләккәнче, авызга әзрәк эчемлек керсә, төрле инстинктлар кузгала, тәнне кайнарлата иде. Сөйләшәсе килә, хатын-кыз кочагына керәсе килә. Бер уңышлы операциядән соң аларга шактый эчемлек тәтегән иде. Альфредны көчләп эчерделәр. Ир кешеме син, әллә ирлегеңне төшереп калдырган мәхлукмы, дия-дия, мин-минлегенә тиеп беттеләр. Эчми кара шуннан соң. Эчеп куйгач, рәхәт булып китте. Башына акыллы фикерләр килә, теленә матур сүзләр өелә башлады. Тойгылар урыныннан кузгалды һәм тышка ыргылырга тотынды. Ул Ленаны эзләп китте. Аның эштән чыкканын озак көтеп утырды. Тәнендә сызып, йөгереп тизләнеш алган тойгылар бары тик Ленада гына тынычлык табар иде шикелле. Көтеп утырганда, ул хисләренең үзен ничек газаплавын, теңкәсенә тиюен аңлады. Ир-атка хатын-кыздан башка бик авыр һәм начар икәнен белде. Озак көтте. Тойгылар кыставы шундый көчле иде, хәтта күз аллары караңгылангандай булды. Ленаны ул көчкә көтеп алды. Кыз киреләнмәде, чәүчәләкләнмәде. Шунда Альфред аңа эчтән генә мең рәхмәтләр укыган иде...

Ә хәзер ул хисләр бөтенләй юк. Кая китте шул рәхәт тетрәндерә торган тойгылар? Юк, тойгысыз адәм тулы канлы була алмый. Тойгысыз бик яман. Бәлки, берәр хатын-кыз аның тойгыларын уята алыр? Мәскәү институтыннан килгән профессор да шул хакта ишарә ясады бит. Хатын-кыз белән ныклап якынаерга кирәк, диде. Альфред бераз уңайсызланды, ләкин берни эшләр хәл юк. Бу – аның өчен тормыш мәсьәләсе. Хатын-кыз белән танышу өчен, әрсезлек һәм кыюлык кирәк, ә аңарда ул юк. Шуңа күрә бераз хәмер кулланырга өйрәнмичә дә булмас. Ул тартыну хисен җиңәргә ярдәм итә. Сәламәт кешеләр аракыны кыюлык өчен махсус та эчә. Димәк, аңа, яралы кешегә, ул гел дә зарури. Дару шикелле. Әмма хәмергә ияләнеп китүең дә бар, ә бу һәлакәткә тиң. Әллә аңа врач белән киңәшеп карарргамы? Ул, билгеле, ярамый, дияр. Бик әз генә кулланып кара, дип әйтүе дә бар. Альфред та бит, бераз гына, ди. Әллә ул хәмернең бик яман нәрсә икәнен белмиме, аңламыймы? Аңардан да әшәке әйбер юк, ул теге әкияттәге шешәдән чыккан гыйфрит белән бер. Аның тозагына бер эләксәң, ычкына алмыйсың инде, юк! Стаканга батып, күпме әйбәт кешеләр харап була! Альфред алай бетәргә теләми. Аракыга бер күнексәң, ул бар ихтыярыңны сындыра, ди. Кыскасы, уңга китсәң дә, баш бетә, сулга таба китсәң дә – чоңгыл! Сират күпереннән ничек барырга?

Егет сизә: бу яра аның бар вөҗүден үзгәрткән, ахрысы. Таза чакта ул болай түгел иде. Эченә әз генә эчемлек керсә, күңеле шундук хатын-кызга тартыла,

яратасы килә башлый иде. Хәзер исә берни юк, хатын-кызның матурлыгы да күзенә күренми. Аларда бернинди сер, вәсвәсә калмады. Ә ничек соң алар Лена белән бер-берсенә йөрәкләрен ачты? Ни этәрде? Нинди көч, кодрәт? Хәзер ул көч кая киткән? Гомергә югалганмы? Каһәр суккан яра! Ә яшәүнең мәгънәсе фәкать шуңарда гынамы? Моны ничек аңларга? Адәм баласының двигателе әллә шул микән? Тукта, кайчандыр укыды бит ул: борынгы Римның бер скульпторы, бар энергиясен эшкә генә бирү өчен, үзен печтергән, имеш. Әйе, әйе, бу – чын, булган хәл. Димәк, яшәүнең мәгънәсе аңарда гына түгел икән. Яшәү мәгънәсен сынчы эштә, хезмәттә генә тапкан, билгеле. Иң начар очракта аңа да әнә шундый мөмкинлек бар икән бит...

Ә хәзергә үзенә массаж ясаучы шәфкать туташы Аняның кылын тартып караргамы әллә? Әмма ул бик фәкыйрь күренә. Артык фәкыйрьлек аңа кире тәэсир итә. Бервакыт алар Латвиядә ярлы гына утарга тукталды. Хуҗалары – бетерешкән, алама-салама кигән карт белән карчык иде. Бәрәңге пешергән булдылар, чикләвек зурлыгындагы вак кына бәрәңгеләр. Ике яклап ярылган агач коштабакка салып, өстәлгә куйдылар. Иптәшләре ашагандай итте, ә аның тамагыннан үтмәс кебек иде, шуны сизеп, ул табынга утырырга да базмады. Үзенә эш тапкан булып, тышка чыгып китте. Ничек шул ярлыларның ризыгын ашарга мөмкин?! Хәерчене талаган кебегрәк килеп чыга ич бу. Шуңа күрә Аня белән дә шулай килеп чыгар дип курка. Юк, ул үзеннән дә фәкыйрьрәкләрдән берни дә ала алмый. Сәбәбен генә белми. Хәер, кеше үзенең бик күп нәрсәләрен белми әле.

Юк, Аняны алдарга ярамый. Ул болай да язмыш тарафыннан рәнҗетелгән кебек күренә. Үзе бик аз сүзле, күңеле төшенке. Ачлы-туклы яшиләр, ахрысы. Аның янына ни йөрәгең җитеп бармак кирәк? Хәтта барысына риза булган очракта да. Юк, мондый киртәне атлап чыга алмый ул. Үзеңә тиңне табарга кирәк. Аняның киемнәре дә искедән сүтеп тегелгән... Альфредның ярлылыкка йөз чытып караву һич тә аристократ психологиясеннән түгел, ә шул ярлылык өчен үзен гаепле итеп санавыннан. Әйе, үзенең ниндидер гаделсез эшләре аркасында алар шулай ярлы булган шикелле тоела аңа. Моның абсурд икәнен ул җаны-тәне белән аңлый, әмма ярлыларны күрсә, шундый авыр хис кичерә. Үзен гаепле санаган кебек була. Һәркем кемдер алдында булса да гаепле, диләр. Моны ул матур сүзләр генә дип уйлап йөри иде. Түгел икән. Әллә бу яра аның күңелен артык нечкәрттеме? Нечкәрү артыкка китсә дә әйбәт түгел бит. Ялгыш тарафка алып китүе бар. Реальлекне югалту тарафына...

## IV

Динә Әхәтовна белән Таня Свияжскига килде. Биредәге психбольницада Динәнең ире Нәсих ята иде. Ул сугышның беренче көннәрендә үк утка кергән. Киев тирәсендә чолганышта калып, әсирлеккә эләккән. Польшаның кайсыдыр шәһәрендә, концлагерьда аны бик нык җәзалаганнар, башын төйгәннәр. Баш сөяге берничә төштән чатнап, эчкә батып кергән. Маңгаеның уң ягында сөяк бөтенләй юк, чокыр. Эчкә баткан яра эзе йөрәк тибеше ритмында селкенеп тора.

Бу беренче килүләре генә түгел. Моннан алда да Динә Таняны үзе белән алып килгән иде. Шулай бер-берсенең кайгы-хәсрәтен уртаклашып, үзеннән-үзе якынаеп киттеләр. Динә кызны сынаган, аңардан сер яшерми, теге яки бу хәлләр хакында аның белән киңәш-табыш итә. Таняның төпле, реаль фикер йөртүче кыз икәнен аңлады ул. Аның үз иптәшләрен сатмавын, сөйләгән серләрне читкә чәчмәвен дә бәяләмичә мөмкин түгел иде.

Пароходтан төшеп, үргә шактый озак күтәрелделәр. Менә зур гына, әллә

ничә гөмбәзле кызыл кирпеч чиркәү янына килеп җиттеләр. Ихатасы чәнечкеле тимерчыбык белән уратып алынган. Динә сакчыга ниндидер кәгазь чыгарып күрсәтте дә, аларны эчкә үткәреп җибәрделәр.

Ярым җимерек ишектән керделәр. Шыксыз коридорның стеналарындагы штукатуркалар кубып-кубып төшкән. Кызыл кирпечләр ничектер чи яраны хәтерләтеп тора, һәм тәнгә каз тәнчекләре йөгерә иде. Динә, арырак китеп, ак халатлы, беләген сызганган, таза гәүдәле санитар белән исәнләште, иренең хәлен сорашты. Нәсихның хәле билгеле инде – ул «өметсезләр» исемлегендә иде.

Көтү бүлмәсе дә тәнне чымырдатырлык күңелсез иде. Анда идәнгә беркетелгән, каралып, киртләнеп, пычранып беткән озын өстәл дә берничә артсыз урындык кына бар иде.

Менә теге таза санитар Нәсихны беләгеннән тотып бүлмәгә алып керде дә өстәл янына утыртты. Аннары аңа бармак янарга кереште, янады-янады да чыгып китте. Динә алып килгән ризыкларын иренең алдына куйды. Нәсих, хатынына карап та тормастан, аларны ашык-пошык ике куллап авызына тутырырга тотынды. Күзләре тәмам акайды, ак бильярд шарлары кебек, як-якка тәгәрәшә иде. Әйтерсең, азыгын алып китәрләр дип шикләнеп, кабаланып, тирә-ягына карана-карана, кемнәндер качып ашый иде. Ашавының да чик-чамасы булмады. Тәгамне туздырып, ваклап бетерде, валчыкларны җыеп авызына озата торды. Үзе, сыер кебек, бүлмәне тутырып мышный иде. Менә ризык бетте. Ул күзләрен алга төбәде, шунда Динәне, Таняны күрергә тиеш иде. Ләкин аның күргәнлеге һич сизелмәде. Нәсих капчык кебек кара киндер күлмәген күтәрде, бүксәсенә учы белән суккалап алды. Шул мәлдә күзләренә аң кергән сыман булды, хатын-кызларга текәлеп карап алды. Ләкин аңы шунда ук сүнде. Ул көрәк шикелле зур учы белән битен сыпыргалады, борыны, авызы һәм маңгае җыерылып килде. Аның куллары, аяклары симметрияне бозарлык дәрәҗәдә зур. Күрәсең, баш миендәге ниндидер үзәкләре дөрес эшләми иде. Ул кинәт торып басты, авыз эченнән нидер мыгырдый башлады: «Мин, – диде ул, быгыр-быгыр килеп һәм мышнап, – кичә Калинин белән сөйләштем. И-и-и, синең кызыңны коткарам... И-и-и...» – Нәсихның башы өстәлгә таба иелде, үзе еш-еш сулый, нәкъ чабып килеп туктаган ат кебек иде. Ул өстәл кырыена куллары белән ябышкан иде, өстәл тактасы шатыр-шотыр килеп кубып та чыкты. Юләрдә көч күп була шул. Нәсих елаганга охшаган нечкә тавыш чыгарырга тотынды. Зи-и-и, зи-и-и... Әллә нинди кыргый маймыл чыелдыймыни. Ул кинәт калкынып куйды, бер кулын югары күтәрде һәм тагын авыз эчендә ботка пешерә башлады: «Мин Калинин белән сөйләшеп утырдым!» Ул тагын нидер мыгырдады, ә төс-кыяфәтендә горурлык һәм эрелек галәмәте шәйләнә иде. Нинди хәлдә диген! Кешедә үзен башкалардан өстен итеп күрсәтү инстинкты һаман бетмәгән. Адәм баласының чын, битлексез йөзе әллә шушымы? Һәр кеше тормыш иткәндә битлек кия, менә без дә – битлек белән. «Калинин бабай үлде шул инде», – дип куйды Динә, кайгылы тон белән. Нәсих аның сүзләрен ишетмәде, аңы саңгырау булгач, колагына да берни керми иде, ахрысы. Динәнең йөзе тагын да караңгыланды, җилкәләре салынып төште. Кайчандыр йөрәккә якын кешесенең шулай беткәнен күреп тору чиксез авыр иде аңа. Ул инде аның терелә алмаячагына үзен, врач буларак, тәмам ышандырган, бу хәсрәтне күтәрергә күңелен әзерләгән. Ләкин аңа әле дә булса авыр. Таня Динәне болай йөрәккә якын ала дип белми иде. Тере, каны кайнап торган хатын ир-ат белән дә чуалгалый, аңардан кайгы да шуып кына үтәдер, дип уйлый иде. Баксаң, барын да эчендә саклап йөртә, ахрысы. Әллә ул бәлане, күзе белән күргәч, авыр кичерә дә, күз алдыннан киткәч, аны онытамы? Андый затлар да

була. Әйтик, мәсәлән, Динәнең һәрчак шат күңелле булуын ничек аңлатырга? Врачның вазифа-бурычы дипме? Ә бит ясалма рәвештә күтәренке күңел белән йөрү кайчандыр барыбер фаш булыр иде. Юк, биредә нәрсәдер аңлашылып бетми. Алла бәндәсе Динәнең бәхетен тәмам җимергән, җанын тоташ газапка дучар иткән. Ә җанын, күңелен богауланган көе яшәү җиңел була аламы соң? Ходай күрсәтмәсен! Аның да бүтән хатын-кызлар кебек чәчәк атып яшәргә хакы юкмыни? Бар, билгеле. Ләкин башка хатын-кызлар да дошман кулы астында нинди генә газаплар кичермәде бит! Менә бу хәл Динәне үз бәласе, бәхетсезлеге белән килешергә, элеккеге ире булган затны кызганырга этәрәдер. Ул да шушы хәлгә үз ихтыяры белән төшмәгән ич. Фашистлар ерткычлыгы корбаны булган. Ничек аны исәпләмисең? Шул ук вакытта Нәсих Динәгә үз тормышын корырга комачау итеп тә тора. Хатын-кызны, гадәттә, итагать, әдәплелек кысалары бик нык тәртип-низамда тота. Аларга ул табигать тарафыннан бирелгән. Аннан болай гына котылып булмый. Җилкәңнән селкеп кенә төшерә алмыйсың. Шуңа хатын-кызның бәхете бары ирләрдән генә торуы өстәлә. Хатын-кыз – ирләр ихтыярында. Алар аны теләсә ни эшләтә ала. Табигать тә ир-атка күбрәк көч биргән. Кем көчле – шул властьлы.

Нәсих өстәл тактасын тагын кубарып ала башлады. Таня, куркып, ишеккә таба ыргылды, санитарны алып керергә итте. Ә ул үзе кереп килә икән. Нәсих аны күрми, тактаны кадаклардан каера бирә. Санитар аның каршына килеп баскач кына, ул һушына кайткан кебек булды, тактаны кинәт ычкындырды. Иләмсез зурайган сай күзләрендә идиотларга хас мәгънәсезлек, бушлык иде. Бөтен төс-кыяфәтендә өн беткән. Аңарда кеше йөзе юк. Йөзгә бик күп нәрсәләр языла бит. Ә моңарда сәламәтлеккә хас төсмер, «язулар» бетерелгән, сызып ташланган, эчтәлексез калдырылган. Ә гәүдәсе галәмәт таза күренә. Куллары зур, көчле. Нинди нык кадакланган тактаны бер талпынуда шартлатып суырып алды.

## V

Коридорның теге башындагы бүлмәдә бер бала елый иде. Яшь бала түгел, алты-җиде яшьләрендә булырга тиеш. Шунда карлыккан исерек хатын-кыз тавышы һәм ишек дөбердәтү ишетелде. «Ач ишекне, ач! – дип ду кубара иде хатын. – Ач, хәзер кирәгеңне бирәм. Ачасыңмы, юкмы?..» Эчтән теге малайның еламсыраган тавышы килде: «Ишекне таба алмыйм, кая соң ишек? Утны кабызып булмый...»

Таня Альфредка аңлатып бирде: киоскта сыра сатучы Айша шулай төн уртасында исереп кайта. Ә малае йокыдан уяна алмый, әнә шулай йокылы-уяулы ишекне таба алмый изалана мескен. Авыру малай. Һәрчак астын юешли. Шуның өчен әнисе аны бик каты кыйный. Миңгерәүләтеп бетергән, ахрысы. Көн саен диярлек шундый хәл.

– Бала елаган тавыш җанга тия, – дип куйды Альфред, өстәл яныннан кечкенә диванга күчеп утырып.

– Мин дә бала елавын күтәрә алмыйм... – Таня торып басты, ачылган изүен рәтләде. – Мин ул Айша белән әллә ничә кычкырыштым, шул малайны яклап. Дарулар алып кайтып бирдем. Эчермәгән, чүплеккә аткан.

Таня өстәл лампасын кабызды, түшәмдәгесен сүндерде һәм Альфред янына килеп утырды. Егет аны кочып алырга тиеш иде. Кызның бар төс-рәвеше шуны көтеп тора. Әмма эчтә дәрт юк шул. Акыл эшчәнлеге белән туган омтылыш ясалма һәм салкын килеп чыга. Хикмәт – хисләрдә генә. Шунсыз адәм баласы исәп-хисаплы бүкәнгә әйләнә. Альфред, ихтыярын җигеп, кызны кочагына

алды. Кыз аңа туп шикелле атылды һәм кайнар беләкләре белән муеныннан кысып алды да үбәргә кереште. Куллары муенны пешерерлек кайнар, иреннәре исә тагын да утлырак тоелды. Ләкин егеттә җавап хисе уянмады, шуңа ул тәмам каушап төште. Кызның тәненнән чыккан чаткылар егеткә килә дә сүнә, килә дә сүнә кебек иде. Күпме чаткылар җибәрергә һәм аларны күпме сүндерергә мөмкин соң? Моны Таня сизсә, бик хәтәр бит. Коточкыч рәнҗер. Гәрчә ул Альфредның хәлен аңласа да, бөтенләй белеп җиткерми... Альфред, эчтән каушаганын белгертмәс өчен, кулларын эшкә җиккән була. Куллар да аны «сата» шикелле – дәртсезләр, салкыннар. Кызның ялкыннарына су сибәләр, су чәчрәтәләр кебек. Кыз исә моңа әһәмият итми, ялкынланганнан-ялкынлана бара. Әллә ул да акыл көчен җигәме? Юк, бик ихлас ялкынлана. Менә кызның тәне тоташ ялкын кебек булып кызды: «Альфред, җаным, Альфред, бәгърем», – дия-дия, үзенә буйсындыра торган ниндидер бер дәрт ирегенә бирелде. Кыз егеттән һаман җавап – дәрт өмет итә, үз ялкынына егет ялкыны да килеп кушылыр дип көтә. Кайнар иреннәре, күкрәкләре, куллары ач сусын белән тулган, сусынны бетерер өчен берни белән санашып тормас шикелле. Альфред кыздагы вулкан кебек дәрт ташкынына эчтән генә гаҗәпләнде. Шушы чаклы ихласлык, шушы тиклем бирелгәнлек. Моны ничек аңларга?

– Син мине яратмыйсың, Альфред, – диде Таня, тыны беткәч, егетнең иңенә башын куеп. Аның чәчләреннән килә торган хуш ис ничектер күңел кайтаргыч төче сыман тоелды.

– Ярату турында сөйләмә, – дип шаяртты егет һәм бер шигырь әйтеп бирде: «Ярату турында сөйләмә син, Хис теләген чынга ашырыйк. Бар гаделлек шунда, үзебезне Хисләр ирегенә тапшырыйк...»

– Син шаяртасың, Альфред, мин чынлап...

– Яратуны аңламыйм мин, Таня.

– Синең хатын-кызларың булгандыр, мөгаен, ә? – Кызның көнче сүзләре хисләренең җитди булуын белгертә иде.

– Юк, юк, Таня, – дип ялганлады егет һәм уйлап куйды: нигә хатын-кызлар янында дөресен әйтмәскә туры килә икән? Аңа тиз ышанганга күрәме, әллә ялганны ярата төшкәнгәме?

– Хатын-кызлар сиңа үзләре сыланадыр?

– Минем тарафтан реакция булмагач, тиз таялар, – дип куйды егет. Таня соравын астарлы итеп биргән иде, үзенең егеткә бик хисләнеп ябышуына ничек карый икән, гаеп итәме, әллә аңа әһәмият бирмиме, дип. Beләсе килеп. Әмма кыз берни дә белә алмады.

– Күңелгә ошаганнары очрамыймы?

– Бу хакта уйлаган булмады. Ярату юктыр ла ул. Уйлап чыгарылган нәрсәдер. Энгельс яза, капиталистлар мәхәббәтне үзләренең кереме өчен файдалана, ди. Димәк, мәхәббәт тә балансга.

– Аңлап җиткермим, ничек балансга?

– Менә, әйтик, ир белән хатын-кыз бер-берсен тигез яратышып яшәсә, алар җитештерүдә дә әйбәт нәтиҗә бирә. Нормаларын арттырып үти. Хатыны белән талашып, нервланып эшкә килгән ир, әлбәттә, начар эшли.

– Ягъни без дә балансга инде, ә? Ә син балансга керергә телисеңме соң?

– Балансга цифр булыр өчен генәме?

– Без бит кайдадыр барыбер цифрлар. Соңгы чутта мәхәббәт балансына цифр булып керергә...

– Юк, минем цифр буласым килми...

– Телисеңме-юкмы, барыбер цифр буласың. Син – «А», димәк, «1»ле цифры. Мин – «Т», димәк, «20»ле.

– Кара, 1 + 20 = очко була икән!

Альфред көлеп җибәрде, бусы Таняга да кызык тоелды, ул да:

– Кешеләрне плюс белән генә кушып булмый, – дип, күңеле булып, тыенкы гына көлеп куйды.

– Була, нигә булмасын? – диде Альфред. – Кешеләр белән ниләр генә эшләмиләр...

– Күңелгә ошау гына кешеләрне бергә кушарга тиеш.

– Кайберәүләр очраклы кушыла, аннары гына бер-берсенә ошый башлый.

– Юк, мин бер-береңә карата хис булса гына кушылу ягында.

– Хис бит соңыннан да килә. Күпме андыйлар! Ә кайвакыт бер-берсен кайнар яратып кушылганнар бергә тора алмыйча аерылыша. Менә сиңа хис. Элек әнә татар кызларын бөтенләй күрмәгән-белмәгән кешегә биргәннәр. Кая андаярату дигән нәрсә...

– Ул чагында хатын-кыз үз дәрәҗәсе хакына көрәшә алмаган, ирексез булган...

– Ireккә ирешү белән, тойгы-хисләре күбәйгәндер дисеңме? Табигать бирмәгән булса...

– Ну, хәзер хатын-кызлар үзләрен яклый һәм ирне сайлый ала. Бу бик мөһим. Чөнки яраткан ирдән генә яхшы балалар туа, ди.

– Монысы инде аның философлар сүзедер. Ярату-яратмау балада чагыла микәнни? Сез, медиклар, бу мәсьәләдә, бәлки, күбрәк беләсездер? Ләкин мин тормышта башкачарак күрдем. Әйтик, мосафир ир бер хатын янында бары бер төн кунып чыкты. Кичтән килде, иртән китте. Шуннан бер малай туды. Ул малайның яхшылыгына, акыллылыгына исең китәр иде. Яратудан туган баламы ул? Юк, билгеле.

– Шул мәлдә, бәлки, алар бер-берсен яратканнардыр. Ә нигә, шулай булуы мөмкин түгелмени?

– Ярату хисе ул кыска арада гына туа алмый.

– Нишләп туа алмасын? Туа, ничек кенә туа әле!

– Хатын-кыз ул якны, бәлки, нечкәрәк беләдер. Минемчә, бер-береңне белмәгән көе хисләр тумый. Адәм баласы хайван түгел лә...

– Ә үзең бая «ярату уйлап чыгарылган нәрсә бугай», дидең.

– Мин тормышта күргән-белгәнемнән чыгып әйттем. Ә монысын – үземнән...

– Кешедә дә хайвани сыйфатлар бар ич.

– Билгеле, кешегә карата кулланганда, исемнәре генә башка...

– Кайбер кешеләр тышкы кыяфәтләре белән дә җәнлек-хайваннарга охшап тора. Мин үзем төлке чырайлы кешене беләм.

– Тычканга охшаган йөзле бер кеше безнең палатада да ятты. Холык-фигылендә нәрсәдер бар иде: көндез йоклый, кич булгач җанлана, астан гына эш йөртә башлый.

– Йә, әйт әле, менә мин нинди җәнлеккә охшаган? – дип көлеп куйды Таня.

Альфред та кушылып көлде, чөнки бу шаян сорауга җавап биреп булмый иде. Таняда тегенди-мондый ят чалымнар беленмәгәнгә генә түгел, кызга бик матур сүз әйтәсе килгәнгә, шул сүзне таба алмаганга. Шуңа, икесе бергә көлеп, бу сорауны йомдылар. Альфред торды, өстәлдәге шешәдән әз генә эчемлек салып эчте, кызга да тәкъдим иткән иде, ул баш кына селекте.

Таня иске генә шифоньердан ак җәймәләр, мендәр алып, диванга урын

җәяргә кереште. Инде вакыт соң иде, Альфред кайтып йөреп булмаслыгын аңлады. Госпитальдә ул врачтан рөхсәт алып китте (операциядән соң аны тагын госпитальгә күчерделәр. ГИДУВка исә врачларга каралырга гына чакырып алалар иде. Бу хәл Альфредка Таня белән ныграк якынаерга да ярдәм итте. Таня үз караватыннан бер одеял алып, аңа ак тыш кидерде, диванга куйды. Альфред ишекле-түрле йөренә иде. Нидер уйлана, ә уйлары күңелсез шикелле – йөзенә үк чыккан. Таня өстәлне җыйгалады, газеталар белән каплаштырды. Ә үзенең төсендә, хәрәкәтләрендә киеренкелек сизелә, әмма ул сер бирмәскә тырыша иде.

– Утны сүндер, – диде Таня өстәл янында басып торган Альфредка һәм, күз караңгыга ияләнеп өлгергәнче, тиз генә күлмәген салды да юрган астына чумды. Альфред күзе караңгыга ияләнгәнче басып торды, аннары диван янына килеп чишенде. Таняның уңган, зиһенле кыз булуы урынны ике җиргә җәюендә дә күренә иде. Барысына да риза булуын белгертте бит. Әллә егеткә ышанып бетмәдеме? Юк, бу гамәле белән ул үзенең саф булуын әйтергә теләде, ахрысы. Бер бүлмәдә ир-ат белән хатын-кыз аерым-аерым ята аламы? Ир-ат, ни генә булса да, хәтта үз-үзенә каршы килеп, хатын-кыз янына үрмәли инде. Табигать тарафыннан ир-ат хатын-кыз тозагында итеп яратылган. Берни эшләр хәл дә юк. Ләкин фронтта алган яра Альфредны шул тозак хисеннән мәхрүм итте. Үзең теләп керә торган рәхәт тозак хисеннән. Ә тозактан башка яшәү мөмкин түгел, диләр. Нигә? Менә ул яши түгелме соң? Әмма мондый «тозаксыз» яшәүне яшәүгә санамыйлар, тереклек итү генә, диләр. Кыскасы, тозак ул – яшәүнең бик кирәкле бер компоненты.

Альфред тиз генә йокыга китә алмады. Аңа үзен ничек тә сынап карарга кирәк дигән уй килде. Үзенең вөҗүден тыңлап торды, әмма кыз янына барырга чакыру ишетмәде. Әмма эчке өндәүне, омтылышны көтеп ятарга кирәкме икән? Таня да әнә ятагында боргалана-сыргалана, йоклап китә алмый ята ич. Альфред вөҗүдендәге каршы тору көче белән көрәшә-көрәшә торып утырды да тәвәккәл генә бер адым атлады. Кыз аны көтеп кенә торган икән, ул шунда ук юрганын ачып урын бирде. Шул мәлдә үк ут кебек кайнар Таня егет кочагына кереп бетә язган иде. Ә егеттә бернинди дәрт уянмады, ул үлгән шикелле ята бирде. Ихтыяр көче белән генә кызны үпкән, кочкан булды. Ә каны кызмый, тамырларында кан түгел, боз ага кебек. Нишләп болай? Операциянең бернинди нәтиҗәсе булмады микәнни? Нинди зур «светило» дигәннәр иде ул профессорны. Нәрсә инде бу?! Ул бит әлеге операциягә бик зур өметләр баглаган иде. Дөрес, операцияне алдан төгәл гөман итеп булмый, нәтиҗәсе йә плюс, йә минус булуы ихтимал, дигәннәр иде. Билгеле, сукыр эчәккә ясаган гап-гади операция дә ике төрле була. Ә бу – нечкә, нейрохирургик операция... Кара инде, Таняның утлы тимер мич шикелле кайнар тәне канны әз генә дә җылыта алмый. Әйе, нервылар тәмам беткән икән, хәерсез. Нишләргә соң?

Таняда бик булдыклы кызлар сизгерлеге бар. Ул үзен тулысынча егет иркенә куйды. Моңа үзен әзерләгән, алдын да, артын да уйлаган, күрәсең. Бернинди таләп-дәгъва куймый. Бары егеткә сәламәтлек кенә кайтсын. Ул аның хакына үзен корбан итәргә дә әзер. Яратмаса, бәйләнеп-тагылып йөрмәячәк. Альфредны тулы канлы тормышка кайтару өчен, кызлык дәрәҗәсе дә, үзенең исеме дә җәл түгел. Егет кенә терелсен, бәхетле тормыш өчен аңа мөмкинлек тусын. Әгәр сафка кайтып, бәхетен Таня белән бүлешә икән, бик хуп, әгәр бүлешми икән, аның аңа һич кенә дә хәтере калмаячак. Димәк, язмыш үзенә шундый өлеш чыгарган дияр дә тынычланыр. Кешене мәҗбүр итеп яраттырып булмый. Үзен яратмаган кешедән мәхәббәт теләнүне Таняның күңеле кабул

итә алмый. Мәхәббәт теләнчесе булып яшәү... Фу! Ә бит яши кайберәүләр... Бәгъзеләрнең холык-фигылендә теләнчелек психологиясе була. Алар өчен ул нормаль хәл санала. Кешеләр холык-фигыльләре ягыннан төрле дәрәҗәдә. Бер ишләре югарыда, бер ишләре түбәндә тора. Чокырда. Үз чокырларыннан чыгарга куркалар. Таня гына качып яши торган әкәм-төкәм кебек. Әмма нәсел дәвам итүнең бөек чакыруы аларны чокырдан чыгарга мәҗбүр итә. Шул чакта югары һәм түбән баскычтагы холык-фигыльлеләр бергә очраша. Нindидер парлар югары күтәрелә, ниндиләредер түбәнгә китә.

Егетнең берни дә эшли алмаудан гасабилануын Таня сизде. Аны әкрен генә юатты, табибларча тынычландырды.

– Альфред, син бер дә борчылма, барысы да әйбәт булыр, – диде, аны үбә-үбә. – Яле, киеренкелегеңне бетер...

– Ничек итеп? – дип пышылдады маңгае манма су булган егет.

– Ихтыяр көчеңне эшкә җик, паникага бирелмә, үзеңне үзең ышандыр...

– Булмаган нәрсәгә ничек үз-үземне ышандырыйм соң?

– Әйтәм бит, барысы да үз урынына кайтыр. Син бу хакта алдан артык күп уйлагансың, артык күп кичергәнсең һәм өмет баглагансың. Кинәт шуның киресе килеп тугач, синдә шок барлыкка килгән. Тынычлан, кара, нинди паникёр икәнсең...

– Син миңа, Таня, үз бәлам белән килешергә кушма!

– Соң, без бит әле бер-беребезгә бөтенләй ияләнмәгән. Сизәсеңме? Без бер-беребезне белмибез. Тора-бара әкренләп ияләнү, аңлашу килер. Ансат кына булмый ул. Син, Альфред, катлаулы шәхес. Катлаулы шәхесләр белән шулай була. Аптырама... яме. Мин кичә дежурда идем, бер дә баш төртеп булмады. Йоклыйм әле, үпкәләмә...

– Йокла, Таня, йокла, – диде Альфред.

Кыз егетнең кочагыннан чыкты да борылып ятты, тәмам изрәп, берни белмәс, сизмәс булды.

Альфредка йокы кермәде. Шайтан алгыры! Бар өметләре чәлпәрәмә килде бит. Киләчәктә бернинди яктылык әсәре шәйләнми. Ичмаса, бер чаткысы гына беленсен иде! Юк бит, бөтенләй үлгән-беткән, дөм караңгылык. Тукта, нигә ул моңа шултиклем борчыла соң? Юләр, кайбер кешеләр бар әгъзалары таза килеш тә хатын-кызсыз яши. Хатын-кыз дигән тозакка керми генә. Ул да тора алмасмыни? Иң мөһиме – бу яраны бүтәннәрдән яшерергә кирәк. Бер дә серне ачмаска. Таза дип белсеннәр. Ә хатын-кызлардан качу гайре табигый хәл, кешеләрдә төрле халәтләр уятыр, гөманнар тудырыр. Кешеләргә гайбәт кенә булсын. Чүпрә сала-сала чәйниләр. Ә гайбәтләрдән үзеңне ничек араларга? Ышыклану өчен өйләнергәме? Ул шәп ышык, капкын булыр иде, билгеле. Кызыксыну уятмыйсың – барысы «шито-крыто». Чынлап та! Ә менә авыру кеше репутациясе белән гомер кичерү бик кыен. Ул аны күтәрә алмас. Шуның өчен пәрдә артына керми булмас. Мөмкинме шул хәл? Моңа нинди хатын-кыз риза булыр икән? Башта ризалашыр да ди. Ә тора-бара? Кеше дигәнең көн саен диярлек үзгәреп тора. Кем аның өчен үзенең яшь гомерен әрәм итәр? Шуңа бәрабәр ул аңа нәрсә бирә ала? Җитешле матди тормышмы? Әти-әнисе ярдәмендә анысы да булыр. Әмма мондый тормыш барыбер уңайсызлык китереп чыгарыр.

Әйе, чынлыкта бер-береңә күнегергә, ияләшергә кирәктер. Таня белми әйтмәс. Нигә әле егет шултиклем югалып калды. Дөрестән дә, ул операциядән соң тәмам терелермен, нормаль хәлгә килермен дип нык өметләнгән иде. Артык нык ышанды, күрәсең. «Осечка» булу ихтималын башына да китермәде.

Әтисе каршына да авыру кеше булып барасы килми. Ул аңардан күпне күткән иде. Хәзер җаны кыйналыр инде. Аларның нәселе артык горур, гадел шул. Курляндиягә эшкә билгеләнгәч, әтисе улына: «Син анда үсә алмассың, перспектива юк», – дип язган иде. Альфредны бүтән фронтка күчертергә дә уйлаган иде. Әмма кешеләрдән уңайсызланды, ул ниятеннән кире кайтты. Әнисе дә катнашкандыр, билгеле. Урыныңнан файдалангансың, дип әйтерләр, безнең әз генә җитешсезлекне дә сагалап кына торалар бит, дигәндер. Егет үзе дә, иптәшләрдән уңайсыз, кирәкмәс, дип язган иде. Кайда ничек, нәрсә килеп чыгасын алдан белеп булмый, әлбәттә. Шул сүз белән күңелне тынычландырасың, язмышка сылтыйсың. Әйе, язмыш чынлап та бар, ахрысы.

Менә бу кызны да аңа язмыш бүләге дип әйтергә була. Ул да егеттән күп нәрсәләр көтә. Альфред исә Таня өмет иткәнне бирә алмый. Ул алданыр, аны каһәрләр. Йөр аннары өстеңдә кеше каһәрен күтәреп. Нинди тормыш ул?! Сине кайдадыр бик ачы каһәрләсеннәр, ә син берни булмагандай тыныч кына яшә. Юк, ул алай булдыра алмый. Ә кемнәрдер шулай яши бирә.

Аны инвалидлыкка гына чыгара күрмәсеннәр. Менә нәрсәдән сакланырга кирәк. Тагын да авыр фаҗига булачак. Нерв авырулы дип табып, группа бирсәләр, беттең. Альфредка хәзер бер юл бар: мин төзәлдем, минем барысы да нормаль дип раслау. Ә Таня серне чишмәскә тиеш. Аңардан белешерләр, ә ул ялганлый алырмы? Шайтан алгыры, тагын ялганларга! Әмма бу ялган чын дөреслеккә бәрабәр булачак ич. Ялган да дөреслек урынына йөри ала. Шулай булгач, ялган тормышта ничек бетсен?! Дөреслек ала алмаган «крепость»ны ялган бик ансат кына алып та куя.

Альфред караваттан төшеп, бүлмәнең ишек катындарак торган, җыйнак кына эшләнгән мич янына килде. Үрелеп аның юшкәсен ачты. Кечкенә плитәсе янына утырды да тәмәке кабызды. Барыбер йокы алмый иде.

Бераздан өстәлдәге будильник шырыйлап шалтырарга тотынды. Таня, караватыннан сикереп төшеп, аның төймәсенә басты. Мич янында басып торган Альфредны күреп, бер дә гаҗәпләнмәде. Аңа плитәгә ягып җибәрергә кушты. Аралыкта өелгән утыннар пәрдә белән каплап куелган икән.

Чәй эчкәндә, Альфред Танянық кулыннан тотып алды.

– Таня, син ризамы? – дип сорады.

Кыз аңа томырылып карады, күз алмалары түгәрәкләнеп килде, караңгырак ут яктысында чаткылар сипкән кебек булды, ләкин сөенечен яшерергә тырышты.

– Син чынлапмы, Альфред? – диде ул. – Барысын да уйладыңмы? Ашыкмыйсыңмы? Юк, кабат уйла әле...

– Җиде кат үлчә, бер кат кис, әйеме?

– Мондый җитди адым атлаганда зыян итмәс.

– Күпме генә үлчәсәң дә, шул бернәрсә, Таня. Ә син?

– Һи-и, – дип көлде Таня. – Хатын-кыз таяк янында нуль булырга әзер инде ул.

– Мин чынлап әйтәм, Таня.

– Ми тартмаңда шул мәсьәләне тагын бер кайнат әле, ә?

– Мин шундый карарга килдем, Таня, син миңа ярдәм ит. Хәлемне үзең күрдең, аңладың.

– Сиңа нык кына дәваланырга кирәк, Альфред. Биредә түгел, Мәскәүдә...

– Синнән башка дәвалана алмыйм мин. Инвалидлык бирмәгәйләре дип куркам. Син ничек уйлыйсың?

– Андый куркыныч бар.

– Аны ничек читләтеп үтәргә? Монда миңа син генә ярдәм итә аласың, Таня, – диде Альфред, тирән мәгънә аңлата торган тавыш белән.

– Динә Әхәтовна миңа болай уңай карый...

– Юк, андый мәгънәдә түгел... Әйдә, эшкә соңга каласың. Юлда аңлатып карармын. Үз сүзеңне аннан соң әйтерсең...

Альфред, учакта ут калдырмас өчен, вак кисәүләрне кәкре тимер белән суккалап сүндергәләп маташты. Шул арада Таня урыннарны җыйды, рәтләде. Ул һәр төштә пөхтәлекне ярата иде. Бер дә иренеп тормый.

Таня өстенә киенгәч, Альфред та шинелен, фуражкасын киде. Иртә иде әле, алар шыпырт кына адымнар белән гомуми коридор аша бардылар. Тышкы ишекне япкач кына сөйләшергә тотындылар.

**VI**

Динә Әхәтовна минем шикле биографиягә бер дә исе китмичә карады. Ул әллә үз өстенә тиешледән күбрәк алучылардан идеме? Кайберәүләрне шелтәләгәндә, каты бер дәлил итеп үз өстеңә күпне аласың, дип әйтәләр иде. Шул сүзләрдән кайберәүләр бик курка иде. Шул ук Эдуард Хәлимович та бервакыт әзрәк спирт капкан иде, ачылып китте: «Хатын миңа, соңга калып кайтсам, үз өстеңә күпне аласың, чамала, дип яный, куркыта. Ә кемне генә хатыны куркытмый икән? Таня, син дә иреңне газаплап яши торган җен хатыны булып китәрсеңме? Ә? Юк, әйт, китәрсеңме?..» – дип тукынды. Мин әйттем: «Әгәр иргә чыга калсам, мин аңа тулы ирек куячакмын», – дидем. Ул ышанмады, башын як-якка чайкап: «Син әле хосусый милек белән авызланмаган, син әле ул хисне белмисең, – диде. – Хатын бит иренә гомер буе имеп торырга тиешле шәхси милке итеп карый. Менә кем ул ир дигән зат. Хатынына гомере буе төшем биреп торучы, закладка салынган байлык. Кайбер хатыннар ирләрен фәкать шәхси милек итеп саный». «Ирләр дә бит хатыннарын шәхси милек итә, дидем мин, Эдуард Хәлимовичка каршы төшеп. – Ирләргә ярага хатыннарга ярамыймыни?» «Ярый, – диде Эдуард, – хатыннар – ирләренә, ирләр хатыннарына шәхси милек итеп карый. Шуңа күрә бездә ир белән хатын арасы гаять киеренке, катлаулы. Хатын, мәсәлән, мине теләсә нишләтә ала, ә мин хатынны берни дә эшләтә алмыйм. Бу хәл дә бик четерекле, күп кенә низагларны кискенләштерә һәм фаҗигале итә. Хатын белән ир арасы төрле богаулардан азат булырга тиеш, чөнки кешелек җәмгыяте эшләп чыгарган әхлак нормалары бар: ир белән хатын арасында ирек булмаса, мәхәббәт тә булмый...» «Анысы тагын нәрсә, аңламыйм», – дидем мин. «Син әле аны аңламыйсың, – диде Эдуард Хәлимович. – Менә иргә чык, сине үзенең шәхси милке итеп караучы кешегә туры кил, шул чакта аңларсың...» «Андый ирләр сирәк буладыр, Эдуард Хәлимович». «Сирәк, но була. Биредә ир-атка вакчыл булырга ярамый. Менә мин хатыныма шәхси милек итеп карамыйм, һич тә!» «Ә ул сезгә карый...» «Бу – үзенә күрә ярату билгесе. Әмма хатыннарның бу хисенә күп кенә бүтән хисләр кушыла. Иргә чыгуны алар зур горурлык һәм уңыш саный. Үзең дә беләсең, хатыннар ирләре белән ничек кенә мактанмый, ә? Синдә дә шундый хис йоклыйдыр әле». «Юк, миндә андый хисләр, Эдуард Хәлимович». «Кияүгә генә чык, барысы да кинәт уяныр», – диде Эдуард һәм көлеп җибәрде. Аңа кушылып мин дә көләргә тотындым.

Билгеле, Эдуардның гаиләле булуы күңелдә кузгалган тойгыларны да кире куа, салкын су сипкән кебек итә иде. Эдуард белән утырганда, мин гел

шундый каршылыклы уйлар кичердем. Эдуард янәшә булмаганда, миндә акыл өстенлек итә, хисләрне уятырга ирек бирми иде. Озаграк очрашмый торылса, үзен бөтенләй оныта башлыйм. Берни дә булмаган кебек...

* * *

Алар Ирек мәйданы аша үткәндә, Альфред төзелеп ята торган театр бинасына ымлап әйтте. «Анда фрицларны эшләтәләр», – диде. «Күргәнем бар», – диде Таня. Альфред ничектер шуны сизде, аның фрицлар турында мыскыллы тонда әйтүен Таня бүлешкән шикелле булды. Икенче мәлдә Альфредка барып җитте: фрицларны бирегә эшләтүдән канәгатьлек табу, болай уйлап караганда, обыватель эше, шактый сай нәрсә иде.

Бераз тын гына бардылар, аннан Альфред тагын сүз башлады.

– Таня, син дөресен әйтмә, – диде көлемсерәп. – Барысы да нормально, диген. Ә?

– Альфред, син нәрсә хакында әйтәсең, ә? – Таняның күзләре гаҗәпләнүдән зур булып ачылып, түгәрәкләнеп китте.

Альфред аның кулын тотып, учында каты гына кысты.

– Таня, син минем белән уйнама! – диде ул, тавышын күтәреп.

Таня шунда ук тынды, каршы килмәде, тын гына бераз уйланып барды. Аннары:

– Альфред, дәвалану өчен зарар итәрбез бит, – диде. – Ә сиңа... бу очракта яшерү әйбәт булмас, чирен яшергән үләр, ди татарлар.

Шуны әйтергә кирәк, Таня татарча яхшы аңлый иде. Динә Әхәтовна аны үзе белгән бик чиста бер татар карчыгына фатирга урнаштырган иде. Карчыкның беркеме дә юк, холкы да күркәм иде, аналы-кызлы кебек яшәделәр. Карчык русчаны начар белә, ярым русча, ярым татарча сөйләшә иде. Күңеле нечкәреп киткән чакларда, бүлмәне сиңа калдырам, дигән сүзләр дә ычкындырды. Аны кайсыдыр ерак туганы, җылы яктан кайтып, үзләренә алып китәргә тиеш иде. Ул һаман шуны көтте, өметен өзмәде. Чөнки аңа бер дә җылы җитмәде, гел күшекте дә күшекте ул. Җылы көннәрне зур бәхет көткәндәй зарыгып көтеп ала иде. Җылы якны бик сагынды. Әмма аннан хәбәр килмәде дә килмәде.

Бер иртәне, Таня төнге сменадан кайтканда, карчык телдән калган, дөнья белән бәхилләшеп ята иде.

Әмма карчыкның коммуналкадагы бүлмәсен Таня исеменә күчерү бик мәшәкатьле булды. Эдуард Хәлимович ярдәм итмәгән булса, эш бөтенләй өметсез иде.

– Таня, минем сүзне аяк астына салмачы?! – диде Альфред, тагын да ныграк ялынып сораган кебек.

– Үзеңә генә начар эшлисең, Альфред, – дип, Таня үз дәлилләрен китерде. – Сиңа яңа дәвалар бирерләр иде, Мәскәүгә юллама алырга да нигез булыр...

– Алар бозып кына бетерәләр, – диде Альфред. – Организм үзе дәвасын, әмәлен табарга тиеш.

– Кем әйтте сиңа бу фикерне?

– Үзем шундый нәтиҗәгә килдем. Медицина гарипләгән кешеләр азмыни? Күргәнем бар...

Альфредның бу дәлиленә каршы Таня берни дә әйтә алмады. Мондый очракта кайбер врачлар «дело хозяйское» дип, җаваплылыкны өсләреннән төшереп, авыру җилкәсенә сала.

Таня, эшкә килгәч, врачлар күзенә чалынмаска тырышыбрак йөрде. Ничек дип әйтергә? Аңардан Динә Әхәтовна сораячак бит. Альфред кушканча

эшләргәме, әллә дөресен әйтеп бирергәме? Бу Альфред нәрсә эшләмәкче була? Нигә шулай әйтергә куша? Ирлек горурлыгымы, әллә дәвалауга ышанычы беткәнме? Нишләргә? Таня Динә Әхәтовнага ялганлый алмый. Альфредны тыңламаска да хакы юк. Йә тегеләй, йә болай. Нишләп аңа шулай гел ике ут арасында калырга туры килә? Моңа әллә бәхетсез характеры гаепleme?

Альфред тәкъдименә ышанырgамы? Ә ышанмаска нигез бармы? Ул моны уйлап эшләдеме, әллә уйнапмы? Әгәр чынлап икән, кыз Альфред сүзен тыңларга тиеш. Ул бит икесе генә белгән серне ачмаска кушты. Бер-берсенә физик яки рухи якын кешеләр арасында сер булырга тиеш. Сер булмаса, якынлык та булмый. Икенең берсе серне ачса, ул хыянәтче санала. Альфредка хыянәт итәргәме? Әгәр серне ачса, аның Танядан тәмам йөз чөерүе мөмкин. Чөнки бу хәл аның минминлеге, горурлыгы белән бәйләнгән. Кинәт ачудан бар мөнәсәбәтне өзеп куйса? Нервлары тәмам какшаган кешедән барын да көтәргә була. Әле холкындагы яшьлек кискенлеге дә чыгып бетмәгән, очлы почмаклары бик күп.

Хуш, Таня Динә Әхәтовнага дөресен дә сөйләсен, ләкин ул моны авыруга берничек тә сиздермәскә тиеш. Менә хәлдән чыгу юлы бар икән бит. Ләкин Динә Әхәтовнаның артык беркатлы булып ала торган чаклары да була. Шунда берәр сүз ычкындырмаса гына инде. Әгәр ычкындырса, Альфред сизеп алса, баш бетте дигән сүз инде. Уф! Нишләп ул шушындый икән? Гомер кыл өстендә генә тора... Кыз Альфред белән ара өзелүен теләми, чөнки аның хыяллары, өметләре шул егеткә бәйләнде, ул аңарда таяныч тапкандай булды...

Альфредның исә үз планы бар иде – Таняга өйләнергә һәм үзенең авыруын шуның артына яшерергә. Гаилә пәрдәсе белән капларга. Кемнең ни эше бар? Тату гына ирле-хатынлы кешеләр, берсе – хәрби, икенчесе – медицина хезмәткәре. Алар арасындагы серне кем белер? Юк, беркем дә белмәс. Ә Таня моңа риза булырмы соң? Булыр, һичшиксез булыр. Бунт күтәрсә дә, фәкать берничә ел үткәч кенә күтәрер. Ә ул чакта инде Альфредның, бәлки, бу ярасы төзәлгән булыр, бәлки, бүтән берәр хәл килеп чыгар. Анда күз күрер әле. Ә хәзер гаилә корырга да эшкә урнашырга кирәк. Тик менә врачлар, хәерсезләр, үзәк нерв системасы бик нык зарарланган, тузган, дип бара. Бу диагноз белән аны хәрби учёттан төшерүләре дә бик ихтимал бит! Шайтан алгыры! Менә чын бәла кайчан булачак. Гражданскида ул нишли ала? Юк дәрәҗәсенә төшә. Авызын корт чаккыры! Кая бара эшләр? Прәме ят та үл, җиргә башыңны ораора ела, бу бәладән беркая да кача алмыйсың.

Тукта, аның хәле шулай ук өметсез микәнни? Нәрсә тоя ул? Элеккедән аермалы буларак, бик тиз кабынып китә, ни әйткәнен һәм нинди хәрәкәт ясаганын контрольдә тота алмый. Тиз кабынып китә торган кешеләр бер бәла ул, әмма шул мәлдә нишләгәнеңне белмәү – бу инде бик җитди симптом булырга охшый. Барысы да шул үзенчәлекле яра аркасында килеп туганмы? Тик аңа бу авыру иркенә бирелергә ярамый. Гомумән, ул үзен нормаль тоя кебек. Әллә нидер аңлап җиткермимме? Шунысы кыен, баш миендә томан кебек нәрсә, ачыклык юк, тәгаенлек юк. Менә шул нәрсә эчен пошыра, сөлек кебек, җанны авырттырып, имеп тора. Хикмәт шунда: баш яхшы эшләсә, бар нәрсәне майтарып, булдырып була. Моңа ничек ирешергә? Элек тә Альфредның башы мактанырлык эшләми иде. Хәзер бөтенләй куе томан эчендә кебек. Ничек арынырга бу авыр, күңелне гел басып торган томаннан? Әллә ныклап дәваланып карарgамы? Әтисенең элеккеге таныш профессоры әйтә: организмның үзенә ирек бирергә кирәк, ди. Ул бит үз-үзен дәвалый, аңа комачау итмәү яхшы, ди. Көн дә физкультура белән шөгыльләнергә куша.

## VII

Зур сумка белән азык-төлек күтәреп, Радик кайтып керде. Күпме генә кытлыкта яшәсәләр дә, әнисе Клара улының бу нигъмәтләренә сөенеп карамады. Сынаганы бар: Радик азык-төлек алып кайтса, өйдә тавыш куба. Егет әтисе белән бәхәсләшә, аңа басым ясый башлый. Әйе, әйе, һөҗүм итә, дөресрәге, аның рухына тукына, дөньяга карашыннан көлә, һәм шул кыланышы әтисен чыгырдан чыгара, провокация ясаган кебек итә. Аңлы рәвештә белеп эшлиме, әллә берәр максатны күз алдында тотамы ул?

Радик әнисенә ит консервасы ачып бирде, шуның белән бәрәңге кыздырырга кушты. Элеккеге иждивенец малайдан ул хәзер гаилә башлыгына әйләнеп бара иде. Немецлар аны ничектер шәһәр магистраленә эшкә алды. Радик телне әйбәт белә иде. Шунда эшли башлаганнан бирле, егет бик нык үзгәрде. Әнисенең сораулы карашыннан уңайсызланып, беркөнне әйтеп тә куйды: «Немецлар мине үз тәртипләренә өйрәтә, мин аларга совет тәртипләрен аңлатам», – диде. Әнисе аңа, ачуын китермәслек йомшак тавыш белән: «Кеше газапларына сәбәпче була күрмә», – диде. Соңгы вакытларда бик күтәренке кәеф белән йөрсә дә, егет бер сүздән дә кинәт кабынып китүчән була башлады. Нидән бу? Үзенең мөстәкыйльлеген тануданмы? Әллә моның артында бүтән нәрсә ятамы? Элек ул мыштым иде, хәзер исә аның йөзендә «мин беләм, ә сез берни дә белмисез» дигән нәрсә шәйләнә. Әллә немецлар аны тәмам үз кулларына алырга өлгердеме? Алар әнә шундый яшьләрне үз кармагына эләктереп сыный да үзләре яклы итеп эшкәртә. Моның өчен аерым кешеләре бар. Радик та шундый эшкәртүче кулына капканмы әллә? Алай булса, бик хәтәр бу. Ире Андрей үзенең сиземләвен әйткәч, хатыны аңа ышанып җитмәгән иде. Ләкин беркөнге сөйләшү бик нык сагайтты. Кич белән чәй эчеп утырганда, Радик:

– Немецлар Мәскәүне алган... – дип, ниндидер канәгатьлек белән әйтеп куйды.

Андрей улының немецлар белән уртак тел табуын бер дә өнәмәде, шуңа күрә аңа шикләнеп һәм куркып карый иде. Әнисе дә эндәшми кала алмады.

– Сөйләмә юкны, кеше ышанмастай сүзне! – диде ул кырыс кына. – Безне сынар өчен генә әйтәсең...

– Әни, син күп нәрсәләрне белмисең әле... – Радикның күзләре еракка караган кебек кысылды.

– Син әллә немецлар кубызына биисеңме? Алдыңны-артыңны чамала, уйла! – диде әнисе, кисәтүле тавыш белән.

– Нәрсә уйларга? Сайларга мөмкинлек юк...

– Немецларның әкиятләренә ышанма. Әнә ничек шапырыналар...

– Әни, син политиканы аңламыйсың, әти йогынтысыннан чыга алмыйсың.

– Тукта, шапырыну нәрсәдән килеп туды, ә? Нинди кеше шапырынучан була? Йә?

– Адәм баласын бөгеп буламыни? Көчлелектән дә шапырыналар. Син нәрсә?

– Көчлелектән беркем дә шапырынмый. Ә үз көченә ышанмаудан шапырыну килеп туа.

– Син әти фикерләрен тукыйсың...

– Анысы мөһим түгел, ә үз көчеңә ышанмаудан шапырыну хакында әйтәм мин.

– Немецлар – бик исәпле халык... Аннары...

– Хискә бирелмә, улым, хис алдый ул. Немецлар шуңа исәп тота.

– Аларда бар төштә дә төгәллек, әни. Син әти сүзләрен сөйлисең.

– Төгәллек белән әллә кая китеп булмый. Менә филне әнчек җиңә аламы?

– Филне кырмыскалар да җиңә ала, әгәр фил тирән чокырга төшсә, – дип, Радик көлеп куйды.

– Ул аерым очрак кына, ә безнең ил аерым очрак кына түгел, улым. Ул – бик көчле фил.

– Әнә бит немецлар кая кадәр керде хәзер. Ленинградны алырга җыеналар...

– Вакытлыча андый нәрсәләр булуы мөмкин. Шул хакта шапырынулары аларны сата да. Шапырыну аларның үзләренең дә күзен томалый һәм бу нәрсә, һичшиксез, җиңелүгә китерәчәк...

– Әни, син ничек шулчаклы ышаныч белән раслыйсың, ә? Әти тәмам миеңне чүпләп бетергән икән.

– Бар нәрсәне экономика – материаль ресурслар хәл итә.

– Безнең әти һаман шул экономик теориядән аерыла алмый инде. Хәзер бар эшне политика хәл итә.

– Политика вакытлыча гына ота ул, фәкать экономика гына тотрыклы эш итә. Бу – немецларның әлегә политик отуы гына. Ул озакка бара алмый.

– Һаман әти фикерләрен сөйлисең. Политик отуны экономик оту белән ныгыталар да, менә шул чын оту була. Әллә немецлар шуны белми дисеңме? Без белгәнне алар әллә кайчан чыгарып элгән.

– Аларның политик оту уңышыннан башлары әйләнгән. Уңышлардан һәркемнең башы әйләнә ул. Әйтәм бит, политик оту бары вакытлыча гына була ала.

– Әни, сукыр булма, әти хаталана. Нигә ул немецларга ышанмыйча карый, ә? Моның начар булып бетүе дә ихтимал бит...

– Ә нигә син әтиеңнән баш тартасың әле? Син аның улымы?

– Баш тартмыйм, әни, мин хәзерге шартларны гына күздә тотам. Яшәр өчен шул таләп ителә. Кем шартларга җайлаша алмый, шул бетә. Табигать законы. Шартларга яраша алмаган күпме кешеләр харап була.

– Немецлар чын ерткычлар, Радик, үз күзләрең белән күреп торасың. Күпме гаепсез кешеләрне концлагерьларга озаттылар?!

– Юк, әни, немецлар уйлап эш итә. Ул кешеләр Советлар тарафыннан подпольеда эшләргә калдырылган булган. Аларны үз араларыннан берәү саткан. Партийный хатын. Ничек кеше сатлык җан булып китә? Менә бу сатылуларны күргәч, мин шул хакта көне-төне уйланам...

Радик китап шкафы янына килде. Аның пыялалы ишеген иплән кенә ачты да Пушкин томын алып актара башлады...

## VIII

Алар хәрби шәһәрчектәге фатирларыннан китеп, бер танышларының ике бүлмәсенә урнашырга өлгерде. Бу эз югалту өчен дә эшләнде. Йорт хуҗасы гимназия укытучысы булып, анда рус теле һәм әдәбияты дәресләрен алып бара иде. Аның хатыны әбиләре ягыннан Кларага чыбык очы туган иде. Милашлар бергә килгәч тә элемтәгә кергән иде. Бер-берсенә кунакка йөрештеләр. Ләкин хуҗаны безнекеләр кулга алды. Моның башбаштаклык икәнен белеп, Андрей күпме чапты аны араларга, күпме тырышып карады, әмма берни булдыра алмады. Ул ниндидер яшерен политик оешмада торган. Ул оешманы Советлар алдан ук белгән булган. Әлеге оешмадан берәү Советлар ягына чыккан да шул исемлекне ачкан. Шуннан берәм-берәм чүпләгәннәр. Нинди яшерен оешма – анысын шайтан белсен. Русларга каршы оешма булды микәнни? Андрей берни

дә беләалмады... Балалары булмаган, бүтән туганнары да юк иде, Клара хуҗа карчыгына бердәнбер якын кеше булып калды.

Алар Добелэдән кайтырга җыенып йөргән көндә генә сугыш башланганлыгын әйттеләр. Әле бернигә ышанырлык түгел иде. Өйлә җитәрәк, канатларында зур-зур тәреле самолётлар шәһәр өстеннән түбәнтен генә очып үтте. Ул арада кичкә таба шосседан танклар хәрәкәт иткәне күренде. Танклар артыннан күтәрелгән тузан, куе томан булып, бар тирәне сарып алды. Андрей тизрәк биредән ычкыну хәстәрен күрә башлады. Аны бигрәк тә Таня борчый, ул аның язмышы турында кайгыра иде. Бүтән нәрсә хакында колагына да керми иде. Тегендә дә, монда да барыбер түгелмени хәзер? Андрейның күзләрендә бизгәк уты янып торды. Ул үзенә урын таба алмый йөдәде. Дөрес, аның болай ашкынуы бер Таня өчен генә булмаска тиеш кебек иде. Рита да, баласын алып, алар белән Митавага китәргә карар кылды. Әмма Отто, нидер сизенеп, моңа ризалашмады. Шәһәрләрдә хәзер ачлык булачак, ә аларның ерак түгел хуторда үз җирләре бар. Советлар килгәч, әле җирләрне тартып алырга өлгермәгән иде. Хәер, Оттоның алыр нәрсәсе юк, бер гектар чамасы урман кисәге, ике гектар булыр-булмас көлсу туфраклы сөрү җире генә бар иде. Шулай да мондый чакта бу җир белән дә ачка үлмәскә булыр дип уйланылды. «Ә без нишләрбез, безнең җиребез юк», – диде Клара. «Сезгә дә җир табылыр, биредә калыгыз, – диде Отто. – Анда, шәһәрдә яман булачак...» Андрейның боларны ишетәсе дә килмәде. Ул бик ашыктырды. Күп бәхәсләр, ачуланышулар, үпкәләшүләр булды. Рита баласы белән Андрейларга иярергә теләде. Нигә шулай итте икән, әллә Оттоның бик үк ышанычлы түгеллеге белендеме? Араларыннан кара мәче үттеме? Алай дисәң, соңгы вакытларда Оттоны эш урынында күтәргәннәр, директор урынбасары иткәннәр, аңа ышаныч арткан иде. Отто шуңа бик горурлана. Рита да моңа бик канәгать иде кебек. Оттоның горурлануы хәзер артык-портык сүзләр сөйләшмәвендә дә күренә иде. Элеккеге кебек, ул бернинди сорау бирми, бернигә ачуланмый-борчылмый иде шикелле. Күп нәрсәләрне үзе аңлаганмы, әллә үз эченә бикләнгәнме? Шартлар белән килешмәгән кешеләр, бер авызлары пешкәч, үз эчләренә бикләнеп яши башлый. Отто да шулай булганмы? Тормыш шартлары адәм баласын кырыкка бөгә. ӘммаРитаның да тәэсире булмый калмагандыр. Ул җылы җилнең кай яктан искәнен бик тиз сизеп ала, нәкъ флюгер кебек. Һәм кыйбласын шуның уңаена юнәлтә. Бу аның сәләтле булуыннан килә торгандыр. Ләкин Кларада, күпме тырышса да, андый сәләт юк. Андрей исә башка сорт кеше, хатынының аны хәзергә чаклы аңлап бетергәне юк.

Отто аларга ат һәм олау тапты. Завод хуҗалыгында атлар күп иде, шуннан бер ямчы яллады. Әзерләнеп беткәч, Рита, баласын кочаклап, арба янында буталды, менеп үк утырды. Отто аны һәм малаен арбадан күтәреп төшерде. Рита еларга тотынды, Кларага килеп асылынды. Ул, аптырап, бер Оттога, бер Андрейга карады. Алар икесе дә күзләрен читкә яшерде. Нигә Андрей шулай эшләде икән? Үз өстенә йөк аласы килмиме? «Ритага Отто янында хәвефсезрәк булыр, – дип пышылдады ул хатынының колагына. – Отто, ни әйтсәң дә, гәрчә латышлашкан булса да, немец. Алар үз милләттәшенә рәхимлерәк булыр. Мин менә шулай сизәм». Рита исә: «Безне бетерәчәкләр, – дип, ачыргаланып еларга кереште. – Отто бит русларга эшләде, русларга яраклашты, немецлар әллә исәпкә алмаслар дисеңме?..» Сүзгә Андрей кушылды: «Хәзер немецларга яраклашырга туры киләчәк. Берни эшләр хәл юк...» – диде. «Ике дингә дә чукынырга без әллә тегеләйме?» – дип куйды Рита. «Чараң булмагач нишлисең, чукынасың, – диде Андрей. – Адәм баласына тия торган өлеш әнә шундый.

Элек тә, хәзер дә...» «Элек алай булмаган, – дип, Андрей сүзләренә ачуы чыгып чәрелдәде Рита. – Хәзер генә бар төшкә политика катнаштырып, тормышны газапка әйләндерделәр. Ир белән хатын арасына политика китереп керттеләр, ата белән баланы шуның аша дошманлаштырдылар...» «Әнә немецлар ирек алып киләбез дип дөнья кубара, – диде Андрей. – Бәлки, рәтле тормыш корып бирерләр?» – Аның тавышында зәһәр киная ишетелде. «Алар безне кызыллар дип эзәрлекләячәк, ул фашистларга ышанмыйм мин. Әнә Тельманны нишләттеләр? Роза Люксембургны? Аларның бит тамчы да гаепләре булмаган. Бары тик карашлары өчен генә җәзага тартканнар. Шулармы ирек алып килер? Ирек дигән нәрсә юк ул хәзер, була да алмый, бары сүзләр генә!..»Ританың сүзләреннән Андрей да уйга калды, йөзенә икеләнү төсмере чыккандай булды. «Болай итәбез, – диде ул, ниһаять, бер карарга килеп, – без хәзер Митавага кайтабыз, Таняның хәлен беләбез. Аннары берничә көннән шушы ук олау белән барыбыз бергә сезнең янга киләбез. Отто канаты астына. Оттога үзебезгә ышанган кебек ышанабыз. Аның утарындагы җирдән безгә дә туенып торырга мөмкин булачак... Отто, син бу планга ничек карыйсың?» «Уңай карыйм, – диде Отто, аптыравын җиңә алмыйча. – Ни күрсәк тә бергә дигәндәй». «Немецлар сиңа тимәскә тиеш», – диде Андрей. «Кем белгән, кем белгән...» – дип куйды Отто. Аның куш ияге уртасындагы чокыр кып-кызыл булып тора иде...

Олау янында шундый әйткәләшү булып алды. Аңлашу рус һәм немец телләрендә барды. Ямчы латыш иде, ул русча да, немецча да аңламый иде шикелле. Шулай итеп, алар шушы олау белән берничә көннән соң кире әйләнеп кайтырбыз дигән карарга килде. Биек маңгайлы картуз кигән, түгәрәк битен керпе энәләре кебек каты төк баскан ямчы җирдән дилбегәсен иелеп алды да атны алгарак тарттырды. Бу тизрәк булыгыз дигәнне аңлата иде. Отто аңа латышча кат-кат аңлатты: олы юлдан йөрмә, хутордан хуторга бара торган ян юлларны чамала, диде.

Ямчы аларны шәһәргә илтеп җиткерде. Артык газап күрмәделәр. Ләкин курку һәркайсының өнен алып бетергән иде, шуңа күрә җаннары уч төбендә булды. Аларның элеккеге ихтыяры беткән, барысы белән курку идарә итә иде. Юл узган саен, курку арта гына барды. Бер юл чатында әсир кызылармиячеләрне күреп, йөрәкләре тәмам ярыла язды. Берничәсенең кулбашы яраланган, аны марля белән түгел, эчке күлмәкне ертып бәйләп куйганнар иде. Куллары, битләре шешенгән. Тукта, болар биредәге частьлар түгелме соң? Арадан берәрсе үзләрен танып алса нишләргә? Йөрәкләрен шул нәрсә дә чәнчеп куя иде. Алар белән бергә алып китүләре дә мөмкин ич. Андрей шуңа аска карабрак утырды. Клара да читкә карамаска тырышты. Гәрчә алар хәрби частьта эшләсә дә, хәрбиләр түгел иде. Әмма үзләре хәрби паёк белән яшәде. Кием-салым алырга литер биреп торалар иде.

Аларны хәрби шәһәрчеккә кертмәделәр. Анда сак куелган иде. Клара каравыл начальнигы белән дә сөйләшеп карады. Ул хатынның сорауларына җавап бирмәде, гел аның немецча белүе белән кызыксынды. Үзләренә эшкә чакырды. Клара, квартирама үткәрегез, анда безнең балабыз калды, диде. Ләкин каравыл начальнигы риза булмады, кулын гына селтәде.

Алар шәһәр үзәгендәрәк, елганың аргы ягында яшәүче теге кардәш әбигә килеп ауды. Туганнарын күрүгә, карчык әй шатланды, әй куанды. Ә тегеләрнең сөйләшерлек хәле дә юк иде. «Таня кайда, ничек?» – дип ут йотты алар. Әби хәрби шәһәрчектән бар кешеләрне шәһәргә күчерүләре турында әйтте. Әмма Таня биредә күренмәгән икән.

Алар Таняны эзләргә кереште. Каян, ничек эзлисең? Клара берничә танышына барып карады, ләкин берсен дә очрата алмады. Әллә ишекләрен ачмадылармы? Бөтенесе урамга чыгарга куркып ята. Әмма урам да буш түгел, таныш түгел җирле халык әллә кайдан гына пәйда булган сыман иде. Клара урамга бары үзенең немецча белүенә ышанып кына чыкты. Чынлап та, тел белү бик нык ярдәм итә иде... Ә Таня табылмады. Тик менә өйгә ничек керергә соң? Анда, бәлки, ни дә булса калдыргандыр ул? Ләкин шәһәрчек чәнечкеле тимерчыбык белән уратып алынган, беркемне кертмиләр. Начальниклар да «белмим»нән башканы әйтми иде.

Төнлә Андрей да «ау»га чыгып керде. Аның хатыныннан яшерен адреслары булырга тиеш иде. Һәрхәлдә, Клара шулай сизә, әмма аңардан берни төпченми иде. Андрей үзе дә әйтми. Биредә подпольеда эшләргә кемнәрнедер калдырган булырга тиешләр бит. Андрей шуларны да эзли иде. Әмма ул хатынына бу хакта белгертүне кирәк санамады. Моңа, әлбәттә, сәбәпләр дә күп булды. Андрей белән Радик тәмам дошманлашып бетте. Табын янына бергә утыра алмыйлар, ачуланышып китәләр. Ризык җыю дигән изге гадәт бозылышу белән бетә, тәгамнең бәрәкәтен җибәрә. Радикның немецлар ягына бик тиз авышуы җанны кыйнап тора, Андрейга исә бу хәл бигрәк тә нык суккан иде. Эчтән рухы сынган кебек йөрде ул. Шулай булмыйни, ничек рух сынмасын? Совет мәктәбендә укыган, совет гаиләсендә тәрбияләнгән малай немецлар белән якынаеп китте, алар идеологиясенә ышана башлады. Моңа, билгеле, телгә сәләте булуы да ярдәм иткәндер. Немец телен ярыйсы белә иде ул. Кечкенәдән әнисе аның белән немецча сөйләшергә тырыша иде. Элек башына сеңгән сүзләр хәзер, кирәге булгач, калкып чыкканмы? Кеше организмына гаҗәпләнерсең. Аңарда әллә нинди сәләтләр үз шартларын көтеп ята шикелле. Адәм баласында теләсә нинди мохиткә җайлаша ала торган көчләр бар. Моны бер Радик мисалында гына түгел, күпләрдә күрергә була. Шәһәр башкарма комитетының медицина-санаторий бүлеге мөдире, ягымлы гына Гульманис фамилияле адәм, мәсәлән, хәзер немецларда бик югары постта хезмәт итә икән. Клара моңа бик нык аптырады. Ничек шулай үзгәрергә, кыйбланы шулай тиз алыштырырга мөмкин? Моны аның аңы сыйдыра алмый иде. Теге чакта Клара Гульманис янында ике-өч тапкыр булды, ул эш эзли, аңа хәрби частьтан китәргә кирәк иде. Үзенә дә, иренә дә җитәкчелек тарафыннан басым нык көчәйде. Юкка да бәйләнә башладылар. Политик карашларны көн саен диярлек төрле юллар белән сынап торалар. Алар нindидер пунктка да туры килми, моны үзләре дә яхшы сизеп йөри иде. Частьның политидарәсендә эшләүче өлкән политрук хатынына һәм тагын нindидер якыннарына эш урыны кирәк икән дип тә ишеттеләр. Шулай да сәбәпнең иң зурысы – аларның сәяси карашларының нindидер пунктка туры килмәве иде. Шул төп аргумент, ә сәбәпләрне бик күпләп табарга була. Беркем дә гөнаһсыз түгел. Клара бер кызылармиянең сукыр эчәгесе авырта дип диагноз куйган иде. Берничә тапкыр өянәк булгач, шул диагноз буенча операция ясадылар. Ләкин эчәгесе таза булып чыкты. Аның бөерендә таш булган. Таш бәвел юлыннан чыкты, ә сукыр эчәгесенә ясалган яра төзәлмәде. Әллә нинди дәвалар кулланып карадылар, әмма терелтә алмадылар. Яраны яңадан ачып карарга булдылар. Кызылармиянең хәле тагын да начарланды, аннары үлде. Андрейның да шундый «ялгыш»ларын искә төшерәләр иде. Врач, билгеле, Алла түгел. Алар да күп нәрсәләрне белми. Юк, Клара моның белән акланырга теләми. Әгәр кеше врачлар хатасы аркасында дөнья куя икән, бу – зур җинаять. Ләкин бу шәхсән аларның гына

бәласе түгел. Ул медицина өлкәсендәге гомуми белемнәр җитенкерәмәүдән, диагноз куя торган бернинди инструмент булмаудан да килеп чыккан бәла.

Шул рәвешле, аларны үз теләге белән китәргә мәҗбүр иттеләр. Радик, моны белгәч, бик нык борчылды. Әти-әнисенә шырпы кадый-кадый, кинаяле сөйләшкәләде. Менә, намус саклап йөргән идегез, күрдегезме, сезнең намуслылык нәрсәгә китерде, янәсе. Намус дигән нәрсә сүздә генә бит ул!..

Андрей шулчак корт чаккандай кинәт сикереп торды да Радикның яңагына чалтыратып җибәрде. Егет нишләргә белмичә аптырап торды, атасы исен җыеп өлгерде һәм: «Гафу ит!» – диде. Радик, берни әйтмичә, үз ягына кереп китте. Шул көннән соң ул бөтенләй сөйләшмәс булды.

Алар, хәрби частьтан китеп, үзләренә эш эзли иде. Гульманис шәһәр больницасында эш вәгъдә итә итүен, ләкин аның юлламасы белән барсалар, бездә урын юк, дип җибәрәләр иде. Баш әйләндергеч нәрсә булды. Шул чакта аларны Отто килеп алды.

Яңа власть урнашкач, кешеләрнең кинәт үзгәрүе иң гаҗәпләндергән, таң калдырган нәрсә булды. Әле кайчан гына Май бәйрәмен билгеләп үткән тантаналы җыелышта речь сөйләгән Гульманис – киң маңгайлы, фырт ир-ат – бүген икенче властька теләп хезмәт итә. Ничек иманны шулай тиз алмаштырырга мөмкин? Иман бит ул кешенең рухы, җаны. Андрей хатынын юата: аны безнекеләр немецларда эшләү өчен махсус калдырган булырга тиеш, ди. Әмма моңа ышануы кыен, чөнки шәһәрдә аны күпләр таный бит. Немецлар белми дисеңме? Һәр адымын, һәр гамәлен күзәтәләрдер. Әгәр дә инде ике якка да уйнау политикасын алып бара икән, шулай ук ышандырмый. Элеккеге большевик Самарецны кулга алдылар. Гульманисның кулы уйнаган, дип сөйләделәр. Андрей аның янына барып, кылын тартып карарга булды. Безгә эш кирәк иде, эш белешүне сәбәп итәргә уңай мәл иде, һәм, чынлап та, Гульманис Кларaны бер больницага рекомендация белән җибәрде. Андрейга ни өчендер андый язуны бирмәде. Соңрак килерсез, мин хәзер ул эшләрдән ерак, диде. Шулай да ул аларны таныды. Шуңа сөенделәр. Әллә безнекеләр калдырганмы, дигән фикер аларда да ныгыган кебек булды. Тик аның Андрейга ышанып җитмәве беленде. Бу исә ир белән хатынның ныгый башлаган фикерләрен тамырдан какшата иде. Нинди битлек кигән ул? Кемгә хезмәт итә – Аллагамы, Иблискәме? Битлек – көчсез рухлы кеше коралы. Ә алар нигә битлек кия белми? Юкса үзләрен көчлеләрдән дә санамый ич. Ә битлек артына посарга тартыналар. Оялалар, чөнки аларда оят бетмәгән. Бүтәннәр әнә бик тиз алмашына бит, ә алар нигә булдыра алмый? Радик менә ул яктан ата-анасына охшамаган икән. Тизрәк җайлашу сәләтенә ия, ахрысы. Әллә соң тормышта гаделлек юк, дигән фикер аңарда тамыр җибәреп өлгергәнме? Әгәр шулай булса, аның тиз алмашынуы беркадәр аңлашыла. Әлбәттә, тормышта килеп туган гаделсезлекләрне Радик күргәләде. Ләкин ул кимчелекләр гаделсезлекләр генә идеме соң? Гомумән, бер-бер кимчелексез тормыш була алмый бит. Һәр кимчелекне гаделсезлек дип санарга ярамый. Радик менә шул нәрсәне аера белми иде шикелле. Аерырга яше дә җитмәгән. Малайның уй-фикере генә түгел, тәне-каны да утырып җитмәгән. Кыскасы, теләсә кем теләсә ничек бөгә ала торган вакыты аның. Моңа әнисе бик курка иде. Андрей да аның яшьлегенә, яшь кан котыруы чорын үтеп җитмәвенә ташлама ясый. Шулай да немецлар идеологиясен тиз кабул күрүен барыбер гафу итә алмый. Әнисенә исә Радик якын, әмма ул ике ут арасында яши. Немецларның ерткычлыкларын үз күзләре белән күрә башлагач, үзе дә аларга төкерер, бизәр дип үз-үзен юата. Хәзер әле ул сукыр көе йөри. Немецларда күзне сукырайтырлык нәрсәләр дә

бар шул. Тик алар вакытлыча әйберләр. Шулай булгач, фашистлар үзләре дә вакытлыча. Әмма моны Радикка һич төшендереп булмый иде.

...Радик, ниһаять, Пушкин томыннан үзенә кирәкле битне эзләп тапты, ничектер канәгать чырай белән укып та китте: «На всех стихиях человек – тиран, предатель или узник»...

– Син үзеңнең немецларга тәлинкә тотуыңа аргумент эзлисең, – диде әнисе. – Йә, йә?

– И әни, хыянәт итми торган кеше юк ул.

– Немецлар үзләренең канлы эшләрен әнә синең кебекләр кулы белән эшли. Шундый эшләргә тартырлар дип куркам. Бер буялдыңмы, тормышың бетә инде, бетә! Аңлыйсыңмы шуны? Кеше канын коярга сәбәпче икәнсең, син кеше булып яшәүдән туктыйсың. Ерткычка әйләнәсең! Йә, шушындый кан кою озак дәвам итә аламы? Кеше каны бит ул!

– Үзегезнең дә сөйләгәнегез бар, тегe елларны бездә дә күпме яхшы кешеләрне нахакка әрәм иткәннәр. Кемгә нәрсә булды? Исәннәр рәхәтләнеп яшәде, – диде Радик. Әнисен ялган өстендә тотмакчы булды.

– Бездә андый хәл булмады, улым, ялгышма!

– Соң, бер сүз өчен безнең тарих укытучысын утырттылар. Утыз тугызынчы елда. Булмады, имеш...

– Нигә немецларны безнең ул чактагы хәлләр белән чагыштырасың? Бездә партия сафларының чисталыгы өчен көрәш барды. Бездә бөтенләй башка, улым...

– Нинди генә сәбәп белән булмасын, барыбер кеше канын кою ул! Кешене харап итәргә бернинди сәбәп булырга тиеш түгел. Әйе, түгел! Бу – закон!

– Шулай да меңләгән гаепсез кешеләрне кыралар, бетерәләр! Мин әйткән закон немецларның үзләренә кагылмыймыни?

– Билгеле, кагыла. Алар, без дөньяны һәртөрле пычрактан чистартабыз, диләр.

– Адәм затларын кырып, дөнья чистара димени? Ничек шуны уйларлык та башың юк синең? Кан коюдан да пычраграк эш юк. Димәк, дөньяны ныграк пычракка батыралар, тормышны тәмугка әйләндерәләр. Әнә Рига янындагы концлагерьга туганнары янына барып кайтучылар бар. Анда көн дә меңәрләгән кеше ачтан үлә, ди. Син моны беләсең, ишетәсең һәм кайбер нәрсәләрне күрәсең дә. Синең күңел күзеңне немецлар ничек сукырайтты? Һич аңламыйм.

– Мине беркем сукырайтмады, – диде Радик, китапны шкафка урнаштырып. – Бәхәсне туктатыйк, әни, мин ачыгып кайттым. Ач кешенең ачуы яман, диләр.

Алар кухняда өчәү бергә чәй эчәргә утырды. Клара ит консервасы белән бәрәңге кыздырган иде. Ул шундый тәмле булган. Әллә мондый ризык бик сирәк эләккәнгә шулай инде. Клара да, Андрей да рәхмәт әйтә-әйтә ашады. Радикның шуңа бик кәефе булды, әмма аның бераз салмыш икәне ничектер менә хәзер генә беленде. Ул көтмәгәндә этисенә бәйләнергә тотынды.

– Әти, син нигә немецларны кабул итмисең, ә? – диде ул, һаман үзенең ниндидер властен сиздереп.

Андрей аптырап калды. Немецларны кабул итмәүне тану үлем белән бер икәнен белә ул. Радикка һич ышаныч юк иде. Әти-әнисе аның алдында немецларны начар итеп телгә алмаска дигән карарга килде. Андрейга ялганлаудан башка әмәл юк иде.

– Ни сөйлисең, улым, – диде ул, ялагайланып. – Немецларны хөрмәт итәм мин. Аларның техникалары иң камиле. Музыкалары бөтен дөньяда яңгырый.

– Әти, сиңа карашыңны үзгәртергә кирәк, – дип куйды Радик, аның сүзләренә ышанмыйча.

– Ничек үзгәртергә? – диде Андрей. – Әйтәм бит, немецларга уңай карыйм, дим.

– Уңай карашыңны гамәлдә күрсәтергә кирәк, эти. Немецлар сүзгә ышанмый, алар башка. Бездә генә кызык сүз сөйләп карьерага үрлиләр иде, шул карьеристлар Россияне харап итте дә! Немецларда башка...

– Аларда да карьеристлар җитәрлек...

– Немецлар бүтән, эти. Ә Россияне карьеристлар, яһүдләр шул хәлгә төшерде. Моны танырга кирәк инде...

– Россияне, улым, бернинди карьеристлар да, яһүдләр дә харап итә алмый, – диде Андрей, тыныч кына тавыш белән нык итеп. – Россия бит ул гаять зур континент. Әнә Себергә крепостное право да үтеп керә алмаган һәм анда колхоз төзүләр дә булмаган. Себернең үз законнары. Шуның шикелле, рус халкының үз характеры, үз холык-фигыле. Ул берәр нәрсәсен югалта башлагач кына, чынлап торып кузгала...

Андрей тагын нәрсәдер әйтмәкче иде, Радикның йөзе чытыла башлагач туктады. Ул аның ачуын гына китерер һәм араны тагын да катлауландырыр дип шикләнде.

– Юк, карашыңны уңга таба борырга кирәк сиңа, – дип, Радик башын күтәрде, аның йөзе тартылган, иреннәре кысылган иде. Борын яфраклары да киеренкелек белән кабарган.

– Минем карашым болай да сул түгел, ә турыдан, – дип, Андрей ничектер гаепле кеше төсле әйтеп куйды. Радикның нервысын чыгармас өчен, ул инде малаеның җаеннан гына тора иде.

– Турыдан ерак барып булмый, эти. Нигә син шултиклем тискәре? Үз иленең патриоты, имеш. Аларга синең ватандарлыгың бер тиен. Нинди легендар командирларны утыртып бетерделәр. Үзеңнең әйткәнең бар. Менә хәзер шуның җәзасын күрәләр.

– Мин үземне патриот санамыйм. Ә тугрылыгым алар өчен түгел, үзем өчен генә.

– Тугрылыгыңны бәяләрләр дисеңме? Уптым утыртырлар да куярлар. Аларга бит кызыл сүзләр, антлар кирәк. Ялган антлар, ялган сүзләр. Ә син кызыл сүз артына поса алмыйсың. Немецлар эшлекле, сүзләргә алданмыйлар.

– Юк, алданалар, – диде Андрей. – Соңрак үзең дә күрерсең. Ә бит фюрерга, безгә берьюлы ике фронтта сугышырга ярамый, дип әйтүче аек акыллар да булгандыр. Ә ул андыйларның башын кистергән. Ә тәлинкә ялаучыларның сүзен тыңлап, Россиягә каршы сугыш башлады. Сүзгә алдану түгелмени бу?

– Бәлки, фюрерның планы өстен чыгар? Ул чакта нәрсә?

– Белмим, әйтә алмыйм, – диде Андрей, үзен җиңелгәнгә санап һәм тавышын мескенәйтеп.

– Нәкъ менә карьеристлар немецларны харап итәчәк тә, – дип, сүзгә кушылды Клара. – Фюрер шуларның сүзен тыңлаган, чөнки үзе дә шундый сорттан булса кирәк. Немецлар үзләрен дөньяга бәхет алып килә торган «сверхчеловек» дип игълан итте. Дөнья белән алар идарә итәргә, ә бүтән халыклар кол дәрәҗәсендә яшәргә тиешләр...

– Әни, син һәрчак кирегә сукалыйсың. Ни өчен немецлар безгә каршы сугыш башлаган? Чөнки Россия үзен дөньяда әйбәт тормыш кора торган система дип тәкъдим итте. Совет кешеләре барча китапларда фәрештә кебек изге итеп сурәтләнде. Бу да шулай ук «сверхчеловек» дигән сүз инде. Ә немецларның беренчелекне бирәселәре килмәгән.

– Төп сәбәп экономикага кайтып кала, – диде Андрей, Радикның башына немецлар ниләр иңдергәнен чамалап. Шуның өчен дә Радик белән сөйләшеп утырырга, аның рәнҗетүләрен күтәрергә кирәк иде. – Ресурслары саегып бара, ә бездә кул тимәгән иксез-чиксез байлык. Капиталистларның моңа күзләре яна. Басып алып булмасмы? Шул максатка юнәлтелгән идеология булдыралар. Озак еллар буе Көнчыгышка поход девизы астында кешеләрнең миләрен эшкәртәләр...

– Алай түгел, немецларны большевикларның дөньяда социализм төзү идеясе котырткан, гыйфритне шул шешәдән чыгарган. Алар бу дөньяга яңа кан бирергә үзләрен генә сәләтле дип саный. Алдынгылыкны бирәселәре килми. Техника, фән буенча барча ачышлар диярлек немецларныкы бит. Ә Россия фән-техника буенча бер генә зур ачыш та ясый алмаган. Бөтен җирдә техниканы, фәнне, философияне, музыканы немец халкы алга җибәргән. Маркс, Энгельсны алар биргән. Шуңа күрә үзләрен законлы рәвештә «сверхчеловек» дип атаган.

Радикның тавышында кырыслык төсмере бераз кимеде, чөнки аның дәлилләре көчле иде. Инкяр итеп булмый, бар зур ачышлар диярлек чынлап та немецларныкы. Моңа каршы нинди дәлилләр китерәсең?

Бу казанышлар немецларга башка халыкларны кол итәргә хокук бирми ләбаса. Коллык заманнары үткән инде. Хәзер бүтән дәвер. Халыклар коллыкта яшәргә риза булмаячак. Хәтта немецлар җиңгән очракта да. Заман үзгәргән, заман башка.

– Җиңсәләр, чарасын табарлар, аларның башы йомры, – диде Радик.

– Патшалар ил белән без идарә итәбез дип уйлый һәм ялгыша. Ил белән заман идарә итә. Заманны исәпкә алмаган патша, нинди генә көчле булуына карамастан, иртәме, соңмы, барыбер җиңелә.

– Немецлар җиңәрме, юкмы? – дип, тамак төбе белән кеткелдәп куйды Радик. Әтисенең бу сорауны провокацион дип уйлавын белеп, ул аны шаяру формасында әйтте шикелле. Әмма ата берни булмаган кебек гади генә җавап кайтарды:

– Белмим, белмим...

– «Белмим»нең башы авыртмый инде аның, – дип куйды Радик, кәефе кырылган төстә.

– Син дә юкка баш авырттырып йөрмә, Радик, – диде Андрей.

– Үзем беләм мин, миндә эшең булмасын! – дип кычкырып җибәрде Радик. – Мин сезгә малай-шалай түгел! Үз эскәнҗәгездә күп тоттыгыз, җитәр! Үземчә яшәргә телим, миңа комачауламагыз! Сез генә түгел дөньяда!

– Әтиең сине кайгыртып әйтә, Радик, – дип арага керде Клара.

– Сез үзегезне кайгыртасыз, мине түгел! – диде уллары, үз алдында бармак яный-яный.

Ата-анасы аңа гаҗәпләнеп карады: бу аларның улымы соң, әллә башка берәүме? Кем аны шулай алыштырып куйды?..

Радик үз ягына кереп яткач та, ир белән хатын, бер-берсенә карарга базмыйча, гаепле кешеләр сыман утырды. Тәмле ризыкның бәрәкәте киткәнгә генә түгел, йөрәк парәсе кебек кадерле уллары аларның сүзен санга сукмаганга, икесенең дә күңеле нык кимсенгән иде. Әле кайчан гына алар аны үз өлешләренә тигән иң зур шатлык, бәхет саный иде. Ул ата белән ана өчен дөньядагы иң зур куаныч булды. Аның тууы һәм яшәве аларның гомерен мәгънәле, тулы итте. Үзләренә авыр вакытларда шул бала кеше күтәрә алмас кайгыларын басарга ярдәм итте, кара көннәрен яктыртты. Бала бәгырьдән

өзелеп төшә һәм гомер буе җаныңның тере кисәге булып кала бирә. Синең өчен аңардан да кадерлерәк берни дә юк. Менә шул зат үзен тудырган, үстергән эти-әнисенә каршы бара, үзенә кан һәм җан биргәннәргә дошманга караган кебек карый. Моны ничек аңларга? Ничек башка сыйдырырга кирәк? Һич мөмкин эш түгел бу. Җан кабул итми мондый хәлне. Бу нигә шулай? Ата-анасы биргән тәрбиянең начар булуыннанмы? Әллә шартлар гаепләме моңа? Дөрес, Радик үскәндә, тормыш тигез генә бармады. Бер гаепсез кешеләрне кулга алулар турында астан гына йөргән хәбәрләрне ишетте ул. Сүзләр бер төрле, ә гамәл бөтенләй икенче төрле булуын үзе күреп, татып дигәндәй белде. Менә шушы хәл аның немецлар ягына авышуына төп сәбәп булды, ахры. Ул аларда дисциплина күрде, сүз белән гамәлнең аерылмавын белде. Шулай да төп гаеп ата-анада, аны үстерүчеләрдә иде. Алар Радикны идеяле кеше итә алмады. Идеялелекне Клара кызыл сүзләр генә дип йөри иде. Үз башыңа төшкәч кенә беләсең бит: баланы яшьтән үк идеяле итәргә тырышырга кирәк икән. Кешенең үзенең бер идеясе-омтылышы булырга тиеш. Адәм баласын шул нәрсә йөртә бит инде. Идеяне баланың канына сеңдерергә кирәк. Ә Радик бер идеясез, иркә бала булып үсте. Идеясез кешенең аумакай булуы – билгеле нәрсә. Ул шунлыктан немецларны хуп күрде. Яшәү шартлары шуңа барырга мәҗбүр иттеме? Моны да исәптән төшерергә ярамый иде. Шартлар кешене кырыкка бөгә.

Яшьләрне Германиягә җыеп озаталар икән дигән хәбәрне алар алдан ук ишеткән иде. Моның өчен врач комиссияләре төзеделәр. Клара немец врачлары өчен тәрҗемәче булды. Берничә рус врачы да бар иде. Андрей да хатыны ярдәме белән шунда урнашты, чөнки эшләгән өчен паёк бирәләр иде. Эшләмәгән кеше шунда ук шик астына алына, партизаннарга ярдәм итүче булып хисаплана һәм концлагерьга озатыла иде. Немец властьлары белән сөйләшеп, Клара Радикны да почтага эшкә урнаштырды. Ул анда әйбәт кенә эшләп китте. Немецлар аны ошатты. Тел белү бик зур нәрсә шул. Тел кешеләрне бер-берсенә якынайта. Кеше газаплары белән бәйләнгән эштән читтә булу аларга бераз юаныч бирә, юкса немецлар барча канлы, пычрак эшләрне җирле латышлар һәм руслар кулы белән башкара иде. Андрейлар моны тиз сизеп алды. Иң яман эшләрнең башында немецлар тора, ә башкаручылары гел җирле сатлыкҗан мөртәтләр иде. Сатылучыларның күп булуы Адрей белән Кларaның җанын гел газаплап торды. Уллары өчен ут йотып яшәү белән беррәттән, күпләрнең немец ягына бик ансат кына чыгуы шаккаткыч иде. Ни өчен шулай үзләре теләп чыгалар? Юкса алар да ачлык кичерде һәм үлем куркынычы астында яшәде. Кларaны да, Андрейны да аерым-аерым чакырттылар, бик төшемле урыннар тәкъдим иттеләр. Шуның бәрабәренә немец подданныйлыгы алырга кыстадылар. Ләкин алар риза булмады. Ә ирле-хатынлы таныш врачлары немец тәкъдимен кабул итте. Аларга ат, олау бирелде, шуңа утырып, хуторларда медицина ярдәме күрсәтеп йөриләр иде. Бер-ике ай эчендә балда-майда йөзә башладылар. Андрейлар ач иде, аларны хәрби заказлар үтәргә көйләнгән завод-фабрика санчастена куйдылар, ләкин бертөрле медикамент та бирмәделәр. Алар, имтомчы карчыклар шикелле, төрле халык ысуллары кулланырга киңәш биреп утыручы булды. Әмма үзләре барыбер немецларга булышканлык хисе тоя иде. Бу хис аларны эчтән генә гел кимереп торды.

Нинди генә авыр шартлар булса да, барыбер чыдыйсың, актык көчкә җанны уч төбенә йомарлап дигәндәй тереклек итәсең. Барысын да шулай тиеш дип кабул итәсең, түзәсең. Әмма Радикның үз эти-әнисен дошман күрүгә

хәтле барып җитүенә чыдап булмый иде. Аның үз-үзен тотышында читтән көчләп тагылган нәрсәләр отыры күбрәк күренде. Әти-әнисе бит Радикның холык-фигылен яхшы белә, аңа тагылган нәрсәләрне сизү, белү авыр түгел иде. Аңа еш кына бүләкләр биреп кайтаралар һәм шул кичне Радик әтисенә, әнисенә бәйләнмичә калмый иде. Кызык бит, бүләк бирәләр дә аларны үзара дошманлаштыралар. Әйтерсең, Радикка бүләк бирү белән бергә әти-әнисенә басым ясарга, аларны төрлечә хәкарәтләргә мәҗбүр итәләр кебек иде. Моның күп мәртәбәләр кабатланып, системага салынуы, ниһаять, аларның гөманын раслады кебек. Радикны кемдер астан гына котырта, һәрчак әти-әнисенә басым ясап торырга боера иде. Кем булыр ул? Немецның шундый агентлары бар дип аларның колагына кергәне булды анысы. Башта, билгеле, ышанмаган иделәр, аннары ышанырга мәҗбүр булдылар. Радикны бик явыз җаннар үз кулларында тота һәм кубызларына биетә иде. Аның әти-әнисе шик астына эләккән кешеләр, әмма тотып ябарлык гаепләре дә күренми. Менә шуңа, үз карашларын кабул итмәгәнгә күрә, астан гына үч алалар. Баланы үз ата-анасын кыйнарга мәҗбүр итәләр! Моннан ары әшәкелек була алырмы? Юк, билгеле. Бәлки, әле Радикка үтерү белән дә яный торганнардыр? Әгәр безгә каршы уйда йөргән әти-әниеңне җәзаламасаң, без сине расходка чыгарырга да күп сорамабыз, дияләрдер. Вакытны үзең беләсең, йә мал, йә җан, дип тукыналардыр. Радик әйтми генә, ул тулысынча ерткычлар тырнагында иде. Ничек аны коткарырга, чынбарлыкка күзләрен ачарга? Ул бүгенге белән генә яши, алда ни буласын уйлап карамый. Тәмам башы миңгерәүләнгән. Яшь белән бәйләнгән, яшьлек юләрлегеннән килә торган шушы халәттән аны ничек аерырга? Чәчәк авыруы шикелле нәрсә бу. Яшьләр ул вакытны авырып уздырырга тиешләр. Биредә башка нәрсә. Радик психологиясенең йомшак ягын сизеп алганнар да шуның белән уйныйлар. Ул мактаганны, күпертелгән мин-минлекне ярата. Менә аның йомшак «кнопкасы». Эшендәме яисә «яшерен киңәшче»семе аны бик каты мактый. Радик, беркатлы күңел, шуларны чынга ала. Андыйлар мактаган саен күперенә, үзен бар кешеләрдән өстен күрә. Үз-үзен барларга, нәрсә эшләгәнен шәйләргә уена да килми. Ул шөһрәт дәрманы белән тулган. Зиһене томаланган. Шул сукыр килеш түбән таба тәгәри. Тәгәрәгәнен әз генә аңларга, күрергә теләми. Якын да килми. Телендә мин дә мин, башка нәрсә аның өчен әллә бар, әллә – юк. Әтисе белән әнисен дә күрми, барын да шөһрәт сөреме йоткан. Туганлык хисләре, вөҗүди якынлык, кан кардәшлектән барысы шул шөһрәткә омтылуга корбан ителгән. Кеше психологиясендә шөһрәт компоненты иң көчлеләрдән санала. Кайбер шәхесләрдә бу хис гаять көчле була. Менә Радикның шул хисен төрле бүләк, мактау ише нәрсәләр белән ризыкландыралар, үстерәләр. Шөһрәт шулай үсә, көчәйгәннән-көчәя бара. Ул шешәдән чыгарылган гыйфрит шикелле. Бер көчәеп китсә, берни белән дә санлашмый башлый. Аның үз тирәсендәге бар кешеләрне шушы хисне «тукландыру» өчен корбан итүе дә мөмкин. Бу аның өчен гади бер нәрсә булып күренә, чөнки ул үзен зур шәхес дип таный. Ул – акыл иясе, көчле ихтыярлы да, шуңа күрә бүтәннәр аның боерганын көтеп торырга һәм һәр сүзен үтәргә тиешләр дип саный. Шөһрәт хисе моның белән генә һич тә канәгатьләнә алмый әле. Аны һәр төштә, һәр көн мактап торулары кирәк. Аның дәгъвалары гаять күбәя. Таләпләре бик нык арта. Әмма ул таләпләр үзенә карата түгел, бүтәннәргә карата.

Радик отыры түзеп булмаслык булып бара иде. Өйдә ызгыш-талаш көннән-көн көчәйде...

## IX

Немецларның кадрларны психологик яктан эшкәртү оешмалары бар иде. Биредә дә үз илләрендәге кебек хәрәкәт җәелдерделәр. Беренче көннәрдә үк Латвияне Германиянең хәләл өлеше дип, элеккеге законлы җирләре дип игълан иттеләр. Тулы хуҗа булып алдылар. Хуҗаларча яңа җирне, халыкны үзләштерергә керештеләр. Кыскасы, алга карап эш йөртәләр. Әмма ышанычлы кадрлардан башка бер эш тә майтара алмыйсың. Латвиядә дә Германиягә җанытәне белән бирелгән кадрлар кирәк. Хәзер дә, киләчәктә дә. Латышлардан, руслардан, башка милләтләрдән булса, тагын да яхшы. Латышлар русларга шикләнеп карый, үз чиратында руслар да кайбер латышларны өнәп бетерми. Идарә эшендә милли каршылыкларны куллану бик үтемле ысул.

Ә Милашлар нәселенә татар каны да катнашкан. Андрейның әнисе татар, ләкин ул инде руслашып бетә язган иде. Шуңа күрә Андрей татарча бер авыз сүз белми. Ә кан тел белүгә-белмәүгә карамый, буыннан-буынга ага бирә. Кан тел кебек тиз генә бирешми, юкка чыкмый. Ул тирәндәрәк. Аны кысу-җимерүләр һәм указлар белән генә бетереп булмый. Кайчак һич көтмәгән җирдә кан үзенең холкын күрсәтеп куярга мөмкин. Гасырлар буе тыелып килгән үчме яки якты хисме, бер мәлдә хәлиткеч көчкә әверелә дә куя. Билгеле, тышкы шартлар туры килсә генә.

Немец органнары тышкы шартларны үзләре теләгәнчә булдыра ала. Алар Радик өчен шундый шартлар тудырды да. Иң элек бер бай латыш кызы белән таныштырдылар. Инга исемле зур гына борынлы, ягымлы гына кыз. Әгәр борыны зур булмаса, аны татар дип тә әйтергә мөмкин иде. Ни өчен борыны зур кызны сайлаганнар? Моның бер хикмәте бар, әлбәттә. Борыны зур кешеләр, гадәттә, секс ягына авышучан була. Ә адәм баласы өчен бу – хәлиткеч нәрсә. Секс ягына авышып, шуңа хирысланган кешенең тора-бара ихтыяры сына. Аның өчен секс иң мөһим нәрсәгә әверелә. Ашау-эчү кебек үк, ул шуңардан башка көн итә алмый. Ач кешенең уенда бары ашау гына булган кебек, моның уена да башка идеяләр керә алмый. Ә идеясез кешенең бернинди хәтәрлеге юк. Ул нәрсә кушсаң, шуны эшли. Бер эштән дә баш тартмый. Ул – чын мәгънәсендә кол. Аңа нинди дә булса эш бир, ашарына бир һәм секс бир. Аның дөньясы шуның белән түгәрәкләнә. Шул түгәрәктән ул читкә бер карыш та чыга алмый. Менә сиңа капкын әзер. Бу – иң ышанычлы һәм «осечка» бирми торган капкын. Шунысы мөһим: адәм баласы бу капкыннан үзе дә ычкынырга һич теләми. Хәтта аны коткаручылар булса да, ул риза түгел. Капкындагы кеше властьлар өчен куркыныч түгел. Ул инде зур эшләр өчен яраксыз кеше. Канатлары сындырылган, имгәтелгән, беркая да оча алмый. Шәхес буларак бернигә тормый, шәхесе шул секска сарыф ителеп бетеп бара.

Асыл егетләрне яшь чакта, акылга утырганчы, әнә шул ысул белән бөгәләр, бетерәләр.

Икенче юл да бар. Анысы – аракы белән капкынга эләктерү. Дөресрәге, аракы капкынына. Яшь вакытында адәм баласы талымсыз, чөнки әле аның акылы әйле-шәйле. Хисләре утырмаган, кайнар ташкын кебек, тән тиресе эчендә ургыла-ургыла ага. Яшь йөрәкне бер чиктән икенче чиккә ташлый. Шул мәлдә аңа аракы тәкъдим итәләр. Моның өчен үзенә аерым кешеләр була. Яшь кешене әледән-әле эчертеп торалар. Аракы – мәкерле нәрсә, ул яшь организмны тиз агулый, яулап ала. Бераздан яшь кеше аракы колына әйләнә, шунсыз яши алмый башлый. Алкоголик стадиясенә җиткерелгән кеше – шулай ук беткән

кеше. Аның башына яңа фикерләр, идеяләр килә алмый. Бүтән эшләргә инде сәләте дә, теләге дә калмаган. Хәмер капкыны йотып бетергән.

Немец органнары ихтыярлы, талантлы, үз фикере булган яшьләрне әнә шул ике капкынның берсенә каптыра, көчсезләндерә, нейтральләштерә. Эзәрлекләнә торган кеше малайларын шушы ике капкынга кандидат итеп теркиләр һәм ниятләрен әкренләп, тайпылышсыз тормышка ашыралар. Ә эзәрлекләнә торган кешенең малайлары булмаса, кызларына законсыз бала ясаттыралар. Бу эшне аерым, бозылган, әшәке егетләрдән яки ирләрдән эшләтәләр.

Милашлар эзәрлекләнүчеләр исемлегенә теркәлде, чөнки немецларга эшләүдән баш тартты. Дөрес, үзләре больницада эштә калдырылды, әмма аларга караш бик начар иде. Немецка эш башкару гына җитми икән, эшләү өстенә син күзәтчелек белән дә шөгыльләнергә тиешсең. Ягъни орган кешесе сиңа кем өстеннәндер күзәтчелек итәргә куша. Син шымчылык эшен үтәсәң һәм агентка җиткереп торсаң гына, тулы хокуклы адәм саналасың. Шунда гына сиңа ышаналар. Димәк, син Германия мәнфәгатен кайгыртасың. Әгәр агент кушканнардан баш тартсаң, димәк, син Германия өчен көч куймыйсың һәм аның тулы хокуклы гражданы да була алмыйсың. Сине инде властьлар бөтен җирдә кыерсыта. Юньле эш бирмиләр, торакның да иң начары – сиңа. Азык-төлек бүлгәндә дә, бу бик нык исәпкә алына. Кыскасы, сиңа бернинди мөмкинлек калдырылмый.

Болар барысы да астан гына эшләнә, бик яшертен генә тормышка ашырыла. Кайбер калын тиреле, уйлаудан мәхрүм кешеләр моны сизмәскә дә мөмкин. Менә сиңа бәла килде: сыерың югалды, ди. Кемнәрдер урлаган. Ә кай очракта органнар моны шул кешегә җәза бирү өчен махсус эшли. Син исә караклар эше дип йөрисең.

Немец органнары барча кешеләрне үз ятьмәсенә каптырырга тели. Берәүне дә читтә калдырмыйлар. Хәтта гарипләрне дә. Шулай итеп, бик тыгыз челтәр барлыкка китерәләр. Аннары һәркемгә, эшенә, урынына карап, күрсәтмә биреп кенә торалар. Син аны үтәми генә кара! Син бит үтәргә риза булып имза куйган! Вербовать иткән чакта, төрле сәбәпләр, дәлилләр китереп, сине ике агент кыса. Зур сүзләр сөйләп, алар сине какшата белә инде. Каты гына яныйлар да. Имза куймый кала алмыйсың. Юкса сине хыянәтчеләр рәтенә куялар, һәм син бирешәсең.

Агентлар кушкан эшне теге яки бу сәбәп белән үтәмәсәң, һич тә гафу ителми. Ике тапкыр үти алмасаң, теге яки бу яктан җәза бирәләр. Моның мең төрле ысулларын белә алар. Мәсәлән, яга торган утынга башка ис тидерә торган агу сибү яки кое суына эчәктә бабасыр үрчетә һәм шуның белән кешене аяктан ега торган дару салу... Немецлар бернидән дә чирканып тормый. Максатларына ирешү өчен, алар барлык чараларны да куллана. Бу өлкәдә «немец төгәллеге» дигән нәрсә тагын да ныграк тормышка ашырыла.

Милашларны уллары Радик аша җәзалыйлар иде. Радик эштән төн уртасында гына кайта. Һәрвакыт салмыш була. Аңа Инга да ияргән. Кыз алдында егетнең үзен күрсәтәсе килә һәм ул әти-әнисенә тиккә дә бәйләнә башлый. «Нигә сез Ингага кырын карыйсыз, ә?» – дип кычкыра. Моны ул әнисенә төбәп әйтә, әнисе дәшүдән куркып бер якка кереп поскач, әтисенә тотына... Син әнә үзең хатының белән рәхәтләнеп яшисең, ә миңа ярамыймыни? Мин дә кеше, минем дә кеше төсле яшисем килә. Нигә, әллә моңа хакым юкмы? Син әйт, бармы хакым, юкмы? Ник су каптың? Беләм мин сине, немецларны яратмыйсың...»

– Тукта! – дип, теш арасыннан кысып чыгарды әтисе сүзләрен, чөнки Инга алдында шундый сүз ычкындыру хәтәр иде.

– Нигә туктыйм? – диде Радик, идән уртасына хуҗаларча баскан килеш. – Син Инганы да өнәмисең, аны фахишә дип атыйсың.

– Ялганлама, сволочь! – дип кычкырып куйды Андрей, чыгырыннан чыгып. – Мин Инганы алай атаганым юк! Юк! Ә син артыграк эчкәнсең. Син сөйләмисең, эчкән аракың сөйли. Телең ни әйткәнне колагың ишетми...

Инга биек үкчәле туфлидән, болай да сузан буе белән стенага терәлгән килеш карап торуын белде. «Әтиеңә нигә бәйләнәсең?» – дип, ул Радикны тыярга, тынычландырырга тиеш иде ләбаса. Тик Инга аның батыраюына сокланган, горурланган төстә карый, бер сүз эндәшми. Бәлки, эченнән генә, шул кирәк аларга, дип тә торадыр әле. Өстәвенә үзе турында әйтелгән сүзләргә дә ышанды бугай ул. Радик исә әти дип тормады, үз атасын шушы сиртмә койрык Ингага сатты. Димәк, аңа Инга кадерлерәк икән. Малайлар, үсеп җитеп, хатын-кыз итәгенә каплану белән, әти-әнисен онытучан була шул.

Ата-ана эчтән, билгеле, Инганы һич тә кабул итмәде. Аздыручы, малайны адаштыручы, диделәр. Ә тыштан берни сиздермәделәр, яхшы мөгамәлә күрсәттеләр. Бигрәк тә Клара Инганың күңелен күрергә тырыша, аның белән ихлас сөйләшергә, аңлашырга тели иде. Бәлки, ул начар кыз да түгелдер. Тыңлаучандыр. Әйбәт тәрбия алган булуы да мөмкин. Радик аны бай кызы дип әйткән иде. Курляндиядә әтисенең туку фабрикасы булган. Кызыллар килгәч тартып алганнар. Хәзер әтисе үз фабрикасына кабат үзе хуҗа икән. Әмма фабриканы сатып, чит илгә китәргә дигән карарга килгән. «Нишләп?» дип сорагач, Инга «Белмим» дип кенә куйды. Клара шуннан соң үзенчә нәтиҗә чыгарды: димәк, ул немецларга ышанмый, шуңа читкә таярга уйлый... Менә бит, бер алар гына түгел, латыш капиталистлары да, әнә, немецларга ышанып бетми. Капиталист акыллы ул, күп нәрсәләрне алдан сизә.

Радик тузынды, әмма әти-әнисе тарафыннан аңа каршы тору ише бер хәрәкәт булмагач, бераз басылды. Ул Инганы үз ягына алып кереп китте дә ишеген бикләгәне ишетелеп калды.

Ә ата-ана төне буе җаннарын кая куярга, нишләргә белмәде. Яткан җирдән колакны колакка куеп, пышылдап кына сөйләштеләр.

– Бу Инга агент булмыйча, кем булсын, – диде Клара. – Радик ахмак, шуңа ышана, ә безгә – юк!

– Мин күп нәрсәгә әзер идем, әмма улым кайчан да булса мине бер хатын-кызга алыштырыр дип башыма да китермәдем, – дип, Андрей йөрәк ачысы белән карганды. – Менә син баланы кадерләп үстер. Аны син генә артык иркәләп боздың. Һәрвакыт, син акыллы, дип мактап кына тордың. Мактауга кечкенәдән күнекте, канына сеңде ул аның. Кан хәзер көчәйде һәм ул гел мактауны таләп итә. Немецлар аның салпы ягына салам кыстырып, мактап, үзләренеке итте. Мактауның фаҗигасен күрдеңме инде? Мин әйткәч ышанмыйча, һәрчак каршы килеп, ачуланырга керешә идең. Мактау – наркотик шикелле үк нәрсә ул.

– Тормышыбызның болай асты-өскә килер дип белмәдем мин. Радикны җаным кебек ярата идем, аны мактап кына торасы килә иде.

– Артык ярату фаҗигагә китерә, дип белми әйтмәгәннәр.

– Шуңа күрә мине дә үлчәп кенә яраттың, бәхетле дә итмәдең, – дип әйтеп куйды Клара. Сүзләре урынсыз булса да, күңелендә тәгаенләнгән нәрсә искәрмәстән чишелеп алды.

– Нәрсә сөйлисең син, Клара, ә? Бәхетле итмәдең, имеш. Ә син мине бәхетле иттеңме соң? Ул хакта нигә тагын бәхәсләшергә? Менә безнең уртак балабыз

турында сөйләшергә кирәк. Радик һәлак булачак һәм безне дә бетерәчәк ул. Хикмәт шунда. Без аны коткарырга бурычлы!

– Ничек итеп коткарырга, ничек? Син – ата кеше...

– Ул мине гомер буе санга сукмады, син, мактап, аны үзеңә якынайттың. Сине генә тыңлады. Хәзер дә тыңлату әмәлен тап...

– Кулымда бер корал да юк бит, Андрей. Ник шулай әйтәсең? Минем мактауга мохтаҗ түгел ул, гаиләдән киткән. Тормыш эченә кергән, әнә шул тормыштан килгән мактауны гына санлый ул. Чөнки шуның гына әһәмияте бар. Хәзер мин көчсез...

– Тукта, аның өчен син һаман да көч әле. Синең белән бераз санлаша да. Ана хакы көчле ул.

– Хәзер итәктән аера аласыңмы аны? – диде Клара, шелтәләгән төстә. – Мин ул юбкадан көчлерәк түгел инде. Ир-ат итәккә бер капланса, башын җуя инде. Бетте дигән сүз. Үзеңне хәтерлә. Беренче кичтән соң ничек итәгемә ябышып каттың. Кубарып алып булмый иде. Радик та шулай инде. Берни белән дә итәк эченнән тартып чыгарып булмаячак аны. Үзең әйткәндәй, хатын-кыз итәге бүре капкыны белән бер, аңа бер эләксәң, ычкынам димә.

– Баланың беткәнен карап торыйкмыни?

– Шулай инде, әнә немецлар бер хуторда карт белән карчыкны утка ыргытканнар, ә ике өлкән баласы карап торган. Берни эшли алмаганнар. Коткарырга тырышсаң, үзеңне аталар да үтерәләр. Әтисе ут эченнән: «Безне коткарырга маташмагыз!» – дип, балаларын кисәтергә өлгергән.

– Биредә ут-ялкын юк шикелле әле...

– Ә нәрсә соң? Улың һәр көнне исереп, бер хатын-кыз ияртеп кайта да шуның алдында безне адәм хуры итеп сүгә. Өченчекөн бәхәсләшкәндә, сиңа тибеп, мине этеп җибәрде. Бу хәл уттан ким түгел. Менә минем күңелем, эчем, аңым эчтән янып, кара көеп бетте. Синең дә күз төпләреңә кара сары күләгә булып ятты, тикмәгә түгел. Нинди калын тиреле кешесең әле югыйсә...

Кларaның бу сүзләреннән Андрей авыр итеп уфтанып кына куйды.

– Хәзер Инганы безгә каршы куйдылар. Радикны агентлар котыртса, монысы өстәп торачак, – диде Андрей. – Һәм ул шул ук вакытта Радикның агентлар биргән күрсәтмәне ничек үтәвенә шаһит та. Билгеле, Инганың үзенең аерым агенты бар, ул шуның күрсәтмәсе буенча эш итә.

– Нинди тыгыз боҗра! Ычкынып кара син моннан...

– Әйе, баланы үз ата-анасын сатарга һәм кыйнарга мәҗбүр итү – фашизмның әшәкелеге. Бу бернинди әхлакка да сыймый. Моңардан да зуррак явызлык була аламы? Һәм шушы нәрсә астан гына, бер гаилә эчендә эшләнә. Туганнар арасында эшләнә. Аңгыра Радик ник ул агентларга, булдыра алмыйм мондый эшне, дип әйтми икән? Ул бик оялчан бала иде бит, кая китте аның намусвөҗданы?

Оялчанлыкны аны хатын-кызга кушып бетерәләр икән. Инга бик тәҗрибәле күренә, ул Радикны үзенең колы итте. Колга боерык кына бир, теләсә ни эшли ул. Кол итү мөһим. Аннары адәм кулы белән әллә нинди әшәкелекләрне чирканмый эшлиләр.

– Оялчанлыгын бетерү өчен эчертәләр. Иң элек эчендәге кешелеген җимереп юкка чыгаралар. Бервакыт аны партизаннарны эзләү операциясенә җәлеп иттеләр. Ул анда берәрсен атмадымы? Кулын канга буямадымы икән? Фашистлар кешедән пычрак эшне эшләтә, гаеп, гөнаһ ясата. Гаепле кешегә әмер бирү җиңел. Әгәр алар кушканны үтәмәсә, аңа гаебен исенә төшерәләр,

пычрагын борын төбенә китереп иснәтәләр. Кеше бөгелә дә төшә. Ни боерасың, дип тора башлый... – дип, һаман бер нәрсә хакында сөйләнде Андрей.

Клара, бераз уйланып торганнан соң, телгә килде:

– Ул операция алдыннан кисәттем мин аны: немецлар синең кулыңны канга буярга тели, дидем...

– Чынлап шулай әйтә алдыңмы?

– Кайткач та, операция турында сорашып утырдым. Ул тәгаен генә әйтмәде, ләкин эш кан коюга хәтле барып җитмәгән иде шикелле.

– Үзе теләп барды микәнни?

– Нишләп, мәҗбүр иткәннәр, билгеле!

– Белмәссең, немецлардан макталасы гына килеп тора аның! Рас каты мактаулар белән агулангач...

– Бигрәк инде син, Радикны чит кеше баласы кебек күреп фикер йөртәсең.

– Чит кеше балалары безне кыйнамый, үз балабыз кыйный.

– Аны бит мәҗбүр итәләр! Нүжәли аңламыйбыз? Менә күкрәгеңә пистолет терәп мәҗбүр итсәләр, үзең нишләр идең?

– Әти-әнине кыйнарга кулым бармас иде.

– Алайса, сине атып үтерерләр иде. Синең үз башыңа төшмәгән, шуңа кырыс хөкем итәсең. Үзеңне стенага терәсәләр, йә әти-әниең, йә үзең, дисәләр... Радикны гына гаепләргә ашыкма! Нишләсен ул, йә! Аңа нибары унтугыз яшь. Аның яшисе килә...

– Юк, Клара, моны аклап булмый.

– Була, Андрей, йә, менә үзең кайсын сайлар идең?

– Белмим, әйтә алмыйм, – дип мөгрәде Андрей. – Башка сыймый бу.

– Радик, бичара, нишләсен? Ну, нишли ала ул? Ә син, Андрей, әйдә, без бетсәк тә ярый, ул яшәсен, дип әйтә алмыйсыңмыни?

– Әллә шуның бәрабәренә яшәтәчәкләр дисеңме? Тот капчыгыңны! Фашистлар, диләр аларны!

Тагын озак кына уйга чумып яттылар. Ашарга юк иде, моңарчы элеккеге запас белән тернәкләнделәр. Радикка бирелгән паёк та әйбәт кенә иде. Ләкин өч җанга җитәрлек түгел. Хәзер ул паёк та тәтемәячәк, чөнки Инга пәйда булды. Нишләргә?

– Андрей, мин немецларга эшкә керәм, – диде Клара.

– Эш өстенә шымчылык итәргә кушуларына риза булыпмы?

– Башкача ничек? Ачка үликмени? Бүтәннәр ничек, без дә шулай. Ни булса – шул. Без белгән кешеләр барысы да төрлесе төрле җиргә урнашты...

– Өч смена эшләргә дә ризамын, әмма миннән шымчылык, юк, булмый.

– Миңа нишләргә кушасың?

– Булдыра аласың икән, кер, эшлә. Яткан таш астыннан су йөрми, диләр.

– Ничек булдыра алыйм? Ачка үлмәс өчен әллә нәрсәләргә барырсың. Бәлки, частный практикага рөхсәт бирерләр, ә? Әнә, Кальнин эшли бит. Мин үз исемемә кәгазь алсам, син минем кул астында эшләүче буласың инде, ә?

Кларaның тавышы өмет белән тулы иде. Андрей аңа гаҗәпләнеп карап куйды. Бу нииндидер яңа нәрсә. Клара иренә әйтмичә генә немецлар белән элемтәгә кереп караган мәллә? Шайтан алгыры! Ирнең күңелендә шик корты кыймылдап куйды. Клара, әллә тел белгәнгә, оккупантлар белән ничектер борчак пешерә ала иде. Нәрсә бу? Чынлап та частный практика ачарга рөхсәт бирерләр дип өметләнәме?

Андрей озак кына дәшми торганнан соң:

– Мине үз җаваплылыгыңа аласың, шулаймы? Рас синең булышчың булып эшләгәч, ә? – дип әйтеп куйды.

– Минем кул астына керергә теләмисеңмени? Кара нинди горур хәерче, ә?

– Сиңа бит минем өстән күзәтчелек итәргә кушарлар?!

– Нигә, мин болай да сине күзәтү астында тотам бит, яшьрәк, чибәррәк хатынга китмәсен дип... – Клара, тавышсыз көлә-көлә, Андрейның битенә йөзен куйды. – Ризамы, ә?

– Димәк, син минем шымчым буласың инде, ә?

– Шымчымы-ниме, рөхсәт алырга кирәк, – диде Клара. – Бар шартларына риза булып. Анда күз күрер. Юкса ачка кәкрәячәкбез. Андрей, ачлыктан бик куркам мин!

– Син чынлапмыни? Шаяртасың дип торам...

– Ахмак, гомерең кыл өстендә чакта нинди шаярту ди...

Клара иренең муеныннан кочаклап алды. Андрей эндәшмәде. Ул соңгы вакытларда шикләнүчән булып беткән иде. Әллә Кларины немецлар вербовать иткәнме икән дип дә уйлады. Әмма бу уен тышка чыгарырга, хәтта үзенә әйтергә дә курыкты.

## X

Бер-ике көннән соң Радик тагын бүләкләр тотып кәефләнеп кайтты. Инга белән бергә. Ләкин бу юлы кызның йөзендә читләшкәнлек төсмерләре сизелә иде. Әллә инде Радик белән аралары салкынайганмы? Әллә бу бер битлек кенәме? Хәзер һәркемдә битлек, чын йөзне берничек тә күрмисең. Дөнья кысан булгач, адәм баласы битлек артына поса, чөнки бүтән саклану һәм гомерен саклау чарасы юк. Инга да битлек артына яшеренгәнме? Әллә кешегә хас әз генә оялчанлыгы бармы?

Ата-ана балага һәрчак өмет белән карый. Менә ул бүген әйбәтләнгәндер, элеккеге шәфкатьсезлеге беткәндер дип уйлый. Радикның да ата-анасына мөнәсәбәте яхшы якка үзгәрсә, барысы да үз урынына утырыр төсле. Кытлыкка, башка төрле түбәнлекләргә дә түзәргә була. Алары әллә ни авыр түгел. Иң авыры – үз балаң тарафыннан кыерсытылу, кимсетелү. Радикның йөзенә уйчан көлемсерәү, битенә бераз гына сәламәт алсулык йөгергән иде. Ул Инганы үз бүлмәсендә калдырып чыкты да, энисенә нәрсәдер әйтергә теләгән, шуңа җай эзләгән кебек йөренә иде. Клара кухняда, йөзенә шатлык нуры чыгарып, өстәл әзерләп йөри, Андрей аңа бик теләп булыша. Ул да улын әйбәтләнер дип өметләнә, шуңа куллары да дәртле хәрәкәтләнә иде. Ата-ана өчен рәхәт мизгел бу. Уллары эштән кайткан, хәер, бик соң инде соңын, шулай да әйбәт. Менә гаилә бергә җыелып, рәхәтләнеп чәй эчәр, сөйләшер, хәбәрләшер. Кешегә иң зур җәза – аңа сөйләшер шартлар булдырмау, сөйләшүдән тыю. Дөрес, властьлар ата-ана белән бала арасына чөй какты кагуын. Шулай да ата-ананың мәхәббәте чиксез, баланың һәр кимчелеген онытырга, аңардан күргән җәберне гафу итәргә әзер тора. Әнә алар нинди ихласлык һәм ярату белән табын әзерләп йөри. Тизрәк табынга бергә утырып сөйләшәселәре, улларын ныклап күрәселәре, аның сөйләгәннәрен тыңлыйсылары килә. Шуңа бик зарыкканнар. Радик бит андый бала түгел иде, шушы немец мәлгуньнәр килеп кенә адаштырды аны. Ул акыллы бит, исенә киләчәк, әти-әнисен санлап, олылап торачак. Аның күңеле яхшылыкта булырга тиеш. Бу аның әтәчләнү чоры, яшьлек авыруы гына. Авыруны уздырмыйча булмый инде. Һәркем башына килә торган нәрсә ул...

Табынга утырырга торганда гына, Радик бүлмәсенә кереп китте дә,

кызарынып, авызын учы белән сөртә-сөртә килеп чыкты, әнисе янына килеп басты һәм каты гына тавыш белән сүз башлады:

– Әни, мин Ингага өйләндем, – диде.

Клара, эшеннән туктап, аңа борылды.

Андрей, Радикның ачулы һәм җирәнүле карашын күрде дә, ишекне ябып, кухнядан ян бүлмәгә шылды.

– Ничек инде, бу ниткән сүз? Шушындый вакытта? – дип, Клара, лып итеп, урындыкка утырды да алъяпкычына кулларын сөрткәләде. Улының бу эшне уйламыйча эшләгәнлеге күренеп тора иде.

– Без Инга белән бер ай инде ир һәм хатын булып яшибез! – диде Радик, масайган тавыш белән. Муен төене бер өскә, бер аска хәрәкәтләнә иде.

– Чынлапмы, болай гынамы? Ныклап уйладыңмы? Бу бит авыр камыт кию, Радик! Ул камытны кияргә син әле әзер түгел шикелле. Нигә үзең теләп муеныңны камытка кертәсең? Үкенмәссеңме?

– Син риза булмассыңмыни? Нигә, сәбәп нәрсәдә? Инга ошамыймы?

– Радик, ул бик тәҗрибәле күренә, сине харап итәр кебек. Бел, көлдергән дә хатын, бөлдергән дә хатын, диләр.

– Ялгышасың, әни, Инга мине бәхетле итәм, ди. Ул андый түгел.

– Яшьли нәрсәгә ул камыт? Йә? Өзлегерсең, имгәнеп калырсың.

– Юк, мин Инганы ташламыйм, ул да мине ярата.

– Ярату юктыр анысы, инстинкт кынадыр. Аңа, бәлки, чынлап та, җенси теләген канәгатьләндереп торырдай ир генә кирәктер? Син аңа чын ир түгел, ә нервыларының киеренкелеген бетереп торучы бер корал гына булачаксың.

– Әһә, син Инганы кимсетергә телисеңме? – дип, тавышын күтәрде Радик.

– Врач буларак күзәтүемне әйтәм, Радик. Сиңа иш түгел ул, юк! Синнән олырак та...

– Өч яшькә генә, куркыныч түгел. Мин кыз кеше идем, ди.

– Синең аның өчен беренче булуың – бу миф, билгеле. Ул инде әллә ничә кулда булгандыр.

– Тукта, авызыңны чамалап ач, әни! Юкса!.. Нигә Инганы кимсетәсең?

– Мин кимсетәсе калмагандыр инде. Ул синең аша нигәдер ирешергә тели. Аңлыйсыңмы, юкмы? Бәлки, ул гестапо агентыдыр. Шул хакта уйлаганың юкмыни? Барыбызны утыртып бетерер. Безне харап итмәкче буласыңмы?

– Инга андый түгел, моны синең куркуың әйттерә.

– Кайда эшли соң ул?

– Тегү фабрикасында ниндидер мөдир, башлык...

– Әнә күрдеңме? Немецлар үзләренә яшерен хезмәт итүчене генә башлык итеп куя. Бу – аларның тайпылышсыз үтәлә торган законы. Фәкать органнарда актив эшләгән кеше генә башлык була... Үзең дә беләсең...

– Юк, Инга андый түгел, – диде Радик, ләкин тавышында ниндидер ышанып бетмәү төсмере чагылып алды, чөнки аның моны кире кага торган ныклы дәлиле юк иде. Ул Инга янына кереп китте...

Әйе, немецлар органнарга вербовать ителгән һәм аларның яшерен боерыкларын үтәп барган кешеләрне генә җайлы, төшемле урынга куя. Дөресрәге, ул кешене яхшы урын белән сатып ала. Немецларда эш урыннары кешенең сәләтенә карап бүленми, ә органнарга ничек хезмәт күрсәтүенә карап бирелә. Әйтик, жулик табигатьле, ертлач, гуҗ кеше органнарның һәр боерыгын бик яхшы үтәп бара, хәтта арттырып үти. Теләсә нинди яшерен эшләрен башкарырга булдыра. Менә шул бәндә иң югары идарәгә баш итеп

куела. Аларда бары шундый принцип гамәлдә. Кешедәге бүтән бер сәләт тә исәпкә алынмый, фәкать органнарның яшерен боерыгын карусыз үтәү генә карьера баскычы буйлап күтәрә. Карьерага омтыласың икән, талантлымы син, ачышлар ясыйсыңмы – барыбер органнарның яшерен боерыкларын үтәргә тиешсең. Ягъни, асылда, син ике төрле эш башкарасың. Беренче урында – органнар боерыгы буенча яшерен, психологик эш, фәкать шуннан соң гына син төп эшеңә хокук яулый аласың. Әгәр органнарга вербовать ителүдән баш тартсаң, сине беркем дә кешегә санамый. Син ил гражданы түгел, син эмигрант хәлендә. Сине эчке эмигрант дип йөртәләр. Сиңа юньле эш бирмиләр. Синең өчен иң юньле эш – җир казу. Шул җирдән башыңны чыгармыйлар. Азык-төлекнең дә начар сортын гына бирәләр. Торак урыны фәкать бaрактан гына була.

Радик бүлмәдән чыкты, үзе тагын да кәефләнгән иде шикелле.

– Инга син әйткәннәрнең берсе дә түгел, – диде ул, әнисе каршына килеп.

Клара алдына карап утырган җирдән башын калкытты. Чырае хәтәр чытылды, калын иреннәре ачу белән бөреште:

– Икәү сөйләшкәннәрне җиткердеңмени? Ахмак! – диде Клара һәм, өметен өзгәндәй, башын икенче якка борды. Шулай озак кына сүзсез торганнан соң, улына карап: – Нүжәли синдә әз генә булса да туганлык хисе калмады, ә? Шул калдык-постык хатынга әти-әниеңне саттың! Оятың кайда синең? Йа Хода! – дип инәлде.

– Син ни генә әйтсәң дә, мин Инганы ташламыйм, – диде Радик, нык тавыш белән. – Ул миңа яшьлеген бүләк итте...

– Нинди яшьлек, ахмак, күзеңне ачыбрак кара!

– Мин сүз бирдем, хәзер чигенмәячәкмен. Аннары, әни, сез политиканы аңламыйсыз. Инга аша мин югарыга үрләячәкмен. Элемтәләре күп аның...

– Элемтәләр барысы да юкка чыгачак. Алданып йөрмә, дип, ничә тапкыр кисәттем инде...

– Юк, сез политиканы аңламыйсыз...

– Нигә син безне шул өстерәлчеккә алыштырасың? Йә, әйт әле?

– Ул – башка, сез – башка. Нәрсәсе гаҗәп моның? Ярар, бу хакта сөйләштек инде. Мин бит сезнең өчен тырышам. Инга белән булсам, материаль яктан хәлебез дә яхшырачак. Алар байлар.

– Әйе, сиңа берни керми икән! – дип, Клара, тагын кулын селтәп, башын икенче якка борды.

– Син әти сүзләрен тәкрарлыйсың, – диде Радик, янаулы тавыш белән.

– Мин үз сүземне әйтәм, ул өстерәлчек белән бер өстәл янына утыра алмыйм, – дип кычкырды Клара.

Радикның күз аклары зурайды, борын яфраклары дерелдәргә тотынды.

– Әһә, сез әле шулаймы? – диде ул, нәрсәгә тотынырга белмичә, һавада кулларын бутады. Кинәт бер артлы урындыкны алып, идәнгә бәрде. Урындык дүрткә аерылды. Тавышка Андрей килеп керде. Радик, шуны гына көткәндәй, кинәт аңа барып ябышты: – Син бутап ятасың безнең тормышны! – дип, тегенең яңагына чалт-чолт суккалый башлады.

Клара, инәлеп кычкыра-кычкыра, ата белән улны аермакчы булып маташты. Радик аңа тибеп җибәрде, Андрейны идәнгә бөгеп салды. Башына, иңенә ботинкасы белән типкәләде. Ул исереклек белән бик нык ярсыган, нәрсә кылганын белештерми иде шикелле. Клара, Андрей янына иелеп, Радикның аякларыннан эләктерде, тегесе гөрселдәп стенага бәрелде. Аркасы белән

стенаны сыдырып төшеп, идәнгә таянды. Аның борыны гыр-гыр килә иде... Ул кинәт кенә сикереп торды да үз ягына таба атлады...

Бераздан, дөбер-шатыр килеп, Инга белән өйдән чыгып киттеләр.

Андрейның яңаклары, күз төпләре кара янып беткән иде.

– Тәмам җене котырган икән, – диде ул, өстен-башын кага-кага. – Ярый әле касыкка, бавырга типмәде. Үз башына кылана торгандыр...

– Ничек үз балаңа шулай әйтәсең, – дип каршы төште Клара, ана хисләренең үртәлүенә чыдый алмыйча.

– Аңардан барыбер игелек күрмәссең, юк!

– Немец ерткычлар харап итте баланы! – Клара елый ук башлады. Аның ирләрнекедәй киң иңе һәм калку күкрәкләре, гаҗизлек белән тулышып, дер-дер селкенә, бите буйлап тар гына юеш тасмалар сузылып төшкән иде.

– Юк, монда немец кына түгел, ул үзе дә гаепле! – диде Андрей, тонык тавыш белән.

– Ни сөйлисең, шул фашистлар гына харап итте аны. Кабахәтләр! Дөньяны ерткычлар белән тутырдылар.

– Мондый улың булганчы... Тфү!

– Радик гаепле түгел монда, түгел! Аны әнә шул өстерәлчек Инга гына аздыра. Әнә баланы ияртеп алып чыгып та китте. Берни эшли алмыйсың.

– Радик теләмәсә, алып китә алмас иде.

– Аның өчен хатын-кыз итәге бездән күпкә көчлерәк шул! Кемдә көч – шул җиңә! Безнең көч аңа тәэсир итми. Әнә бер өстерәлчек бездән көчлерәк! Уф! – Клара тагын күз яшенә буылды, бераз лышык-лышык елады да аннан ачыргаланып кычкырырга тотынды.

Андрей аны юатмады. Ул, чүпрәк юешләп, шуны битендәге авырткан җирләренә куйгалап йөрде. Клара һаман елады. Иң яраткан, җаны кебек күргән баласы бит. Ничек гарьләнмисең? Үзең табып, кадерләп үстергән затның хыянәте икеләтә авыр була икән...

Клара елый-елый тәмам йончыды. Шуннан соң гына туктады. Ата белән ана, балалары үлгәндәге кебек, кара кайгыга батып утырды. Эчләре дөрләп яна, әмма төтене күренми иде. Адәм заты өчен бала китергән кайгыдан да авыррак нәрсә юк шул...

Радик икенче, өченче, дүртенче көнне дә кайтмады. Ингаларда яшәргә булдылар микәнни? Радикның ташлап китүе һәм билгесезлек ата-ананы бик нык изә иде. Йокылары – йокы, ашаулары ашау түгел. Яшәүнең бөтенләй рәте калмады. Ни өчен шушы кадәр газаплар, түбәнлекләр кичерергә? Ә кичерми мөмкин түгел. Салкын канлы булып тумагансың икән, акыл белән генә хисләреңне тыя алмыйсың. Бәгырьгә боерык биреп булмый, ул һаман сыза да сыза. Кызган табадагы май кебек сыза ул. Үзеннән-үзе. Акылыңа һич тә буйсынмыйча.

– Радикны бер-ике айда үзе кебек зиначы итеп бетерәчәк ул өстерәлчек, – дип, кайгысыннан нишләргә белмичә бәргәләнде Клара.

– Фәхеш кеше беткән кеше инде, теләсә кемне сатарга сәләтле ул.

– Хикмәт тә шунда шул. Шәхесен җимерәләр.

– Аның шәхесе бар идеме соң? Умырткасы юк иде бит аның, – дип, Андрей үз баласы турында дөресен әйтергә тайчынмады.

– Кавырсыны нык кебек иде лә, әнә шул сиртмә койрык кына сындырды. Хатын-кыз алдында сынмаган ир-ат юк инде анысы...

– Бар, нигә булмасын? Син мине сындыра алдыңмы соң?

– Безнең алда андый мәсьәлә тормады.

– Үз кубызыңа биетергә күпме тырыштың...

– Йә, шаяртма. Әллә мин синең кубызыңа биеп тордыммы?

– Һәр шәхеснең үз дөньясы, сере булырга тиеш, – диде Андрей. – Юкса ирек фикция генә булып чыга түгелме?

– Юк, булырга тиеш түгел! Синең миннән гайре серең, дөньяң булмасын! Юк!

– Алайса, бездә шәхес иреге була алмый. Шулаймы?

– Нәрсәгә сиңа шәхес иреге? Әллә син берәр бөек кешеме, иҗади шәхесме? Сиңа тышкы ирек бирелгән, шул җиткән...

– Тышкы ирек бәрабәренә эчке ирек тартып алынган. Хатыннар тартып алды аны. Шуның өчен бездә хатын-кызга дан һәм дәрәҗә!

– Эчке ирек белән нишләмәкче буласың? Бүтән яшьрәк хатын-кызларны яратасың киләме? Бу бит азгынлык! Азып-тузып йөргән ир-ат бернигә ярамый ул. Эштә дә бернигә ирешә алмый, көче азу-тузуга исраф була. Син шуны телисеңме? Сез хатыннарга рәхмәт укып кына торырга тиешсез.

– Эчке ирекне азу-тузуга исраф итмичә, нәрсәдер уйлап чыгарырга, иҗатка чумарга була.

– Ярар, пүчтәк нәрсәләр хакында әрепләшеп, тел әрәм итмик. Ничек итеп Радикны теге сөйрәлчек тырнагыннан коткару турында уйла син.

– Котырыгы беткәч, үзе үк бизәр...

– Бизми, бизми, уйлама да. Баланы ашап бетерә ул ерткыч, бетерә. Авызын да сөртмәс. Төн йокыларым качты, бер ерткычның балаңны кимергәнен ничек карап торырга? Син менә тыныч, бер дә борчылмыйсың кебек...

– Җитте, булды. Эш турында уйларга кирәк... Теге аптекарь...

– Баланы коткармыйча торып, башым эшләми.

– Теге аптекарь немец сиңа бәйләнәме әллә? – дип, Андрей сәер генә Кларага карап куйды.

– Әһә, син дә көнләшә беләсеңмени, Ходаем? Алга китеш бар. Әйе, миңа аерым игътибар күрсәтә.

– Ирең барын белмимени?

– Беләдер, ахрысы. «Ирем бар», дигәч, бер дә гаҗәпләнмәде.

– Оккупантларга бар нәрсә дә рөхсәт ителә дип уйлыйлар, кабахәтләр!

– Бәлки, аның белән уйнап караргадыр, ә? Борыныннан тартып йөртергә...

– Ул алашага яшьләр беткәнмени? Әнә алар күпме!

– Мин дә шулай әйттем, ә ул, миңа сөйләшә белә торганы булсын, ди. Без бит хайваннар түгел, дип җибәрә.

– Кабахәт, ерткыч! – Андрейның йодрыклары төйнәлә башлады.

– Йә, йә, калай әтәчләнмә, – диде Клара, җитди итеп. – Мин аның белән уен башлап карыйм әле. Кызык, нәрсәләр сайрар икән... Кара, син әллә чынлап көнләшәсең инде?

– Юк, туктале, немецлар бик мәкерле халык, үзеңнең башыңны ашамасын.

– Соң, болай ачка үләргәмени? Тәвәккәлләмичә, бер эш тә майтара алмыйсың. Үзебез өчен бит...

– Белмим, белмим...

– Үзең тап, алайса, немецка берәр чәчбикә, мин әйләнеп тә карамас идем...

Тегеләйгә борылсаң да – стена, болайга атласаң да стена иде. Алар тикмәгә сөйләшүләрен эчтән аңлап, үзләрен эчтән тыйды. Бүтән бер сүз дә катмадылар.

## XI

Озак та үтми, Клара Радикның эшләгән җиренә барды. Эш сәгате бетеп килә иде, Радик начальнигыннан сорап чыкты да иртәрәк китте. Клара юл буе елады. Үзе бертуктаусыз: «Ничек син шулай эшли алдың?» – дип кабатлады. Радик бик ябыккан, яңаклары эчкә батып кергән, иякләренә каты төкләр чыга башлаган. Йа Хода, теге пәри кызы ничек суырган баланы! Менә бит ул ничек! Радик үзенең беткәнен мин рәхәтлек кичерәм, дип уйлый. Ә бит һәрнәрсәгә түләргә кирәк. Берни дә бушка гына бирелми. Шул рәхәтлек өчен Радик табигатьтән килгән интеллектын тәмам сарыф итү белән түли. Түлим дип уйламый ул. Алам гына дип исәпли. Шул ялган рәхәтлек аның аңын томалый, зиһенен саектыра. Физик яктан тәмам имгәтә.

Клара ипләп кенә аңлата барды, Радик исә бераз тыңлады да кинәт ачуланып кычкырып җибәрде. Ана кеше барысына да түзә инде, ул улын юмаларга кереште: «Син, Радик, нинди акыллы бала идең, ничек болай үзгәрдең соң? – диде. – Дөресен генә әйт әле, бу хәл бер сәбәпсез генә булмас. Немецлар нишләтте сине, кыйнадымы? Кыйнап үз якларына аудардымы?..» Радик озак кына дәшми барды. Анасының рәнҗүле тавышы, гозерләп соравы аны бераз йомшатты шикелле... «Беләсеңме, – диде ул, – без Петер дәдәйләргә кунакка барган идек. Кырыгынчы елның феврале иде бу. Петер дәдәйне шул төнне кулга алдылар. Ул: «Минем бер гаебем дә юк, антихристлар! Юк! Юк! Гаепсез кешеләр хакы бер килеп тотар, кеше каны җирдә ятмый! – дип карганды. – Хәтереңдәме?..» «Хәтеремдә, – диде Клара. – Апаның җан ачысы белән кычкыруы һаман да колагымда чыңлап тора...» «Менә шул чагында, – дип дәвам итте Радик, – эчемдә ниндидер җеп өзелде, һәм шул җеп аркасында гына бөтен булып торган нәрсәләр кинәт җимерелде дә төште. Шул вакытны нигәдер ачык хәтерлим. Миңа бик нык авыр булды. Петер дәдәйнең тамчы гаебе дә булмаган юкса».

Алар матур гына бер бинаның икенче катына күтәрелде. Радик ишекне ачты. Кечкенә генә ишек каты, аннан тар гына коридор, шунда бүлмәләр булса кирәк. Бернинди җиһаз-мазар юк, ниндидер ташландык квартирага кергән шикелле тәэсир кала.

Ишек тавышына, йокыдан яңа гына торып, өстенә бака ефәге төсле озын, ялтыравык халат кигән Инга чыкты. Күкрәкләре ярым ачык. Әнә шул иблис алмалары белән капкынга эләктерде дә инде ул Радикны. Чәчләре матур булып тузгыган, чынлап та пәри вәсвәсәсе бар бугай үзендә!

Радик өстен чишенде, бер бүлмәгә уздылар. Анда, стена буенда, хәрти генә диваннар тора иде. Дәшми-тынмый гына шунда утырдылар. Инганың күзләре сизгер җәнлек күзләре шикелле әле Радикка, әле Кларага сикереп йөрде. Ул нәрсәдер чамалап алды. Радикның йөзендәге икеләнү төсмере, хәрәкәтләрендәге салмаклык гаҗәпкә калдырды кебек аны. Ул Радикка, таный алмаган сыман, озак итеп карап торды. Аның янаулы карашы гүя әйтә иде: син миңа хыянәт иттеңме, син мине шулай бәяләдеңме? Кара аны, минем сине генә бөгәрлек көчем бар. Син – минеке!.. Радик аска карап бераз утырды да: «Уф, арыдым», – дип, иренеп кенә атлап, икенче бүлмәгә чыгып китте. Инга аны туктатмады. Ул, һөҗүм көткән үткен тешле бурсык кебек, бераз артка китебрәк утыра иде. Йөзе кайгыдан чытылган Клара исә, ничек сүз башларга белмичә, тезләре өстендә кул чукларын угалый иде.

– Инга, – диде Клара, бераз калтыранганрак тавыш белән. Аның, мескенләнеп, тегенең кызгану хисен кузгатасы килә иде, ләкин ул берничек

тә икейөзләнә алмый иде шул. – Зинһар, аңла, мин – ана кеше. Синдә дә ана йөрәге булырга тиеш. Радикны калдыр, үзеңнән биздер, ә? Зинһар!

Инга шуны гына көткән диярсең, – ызгыш-талашны ярата, ахры, – битендәге җыерчыклары язылгандай булды, кыяфәтенә эрелек һәм бер карыш та чигенмәү төсмере чыкты. Ул башын як-якка чайкады:

– Мин Радикны беркемгә дә бирмим, – диде. – Ул – минеке. Сез үстергәнсез, җиткергәнсез, хәзер аңа сез түгел, мин кирәк. Моның нәрсәсе аңлашылмый, нәрсәсе табигый түгел?!

– Сезгә башка ир-ат беткәнмени? Әнә алар күпме! – диде Клара, инәлүле тавыш белән.

– Мин Радиктан башканы белмим. Ул да шулай...

– Аның сәламәтлеге шәптән түгел, йөгенеп бетәр. Аннары авырыр. Сез аны кайгыртмыйсыз ич...

– Аның зарланганы юк. Ә үз сәламәтлеген һәркем үзе кайгыртырга тиеш. Чөнки аны үзеннән башка берәү дә белми. Шулаймы?

– Радик үзен кайгырта белми шул, юк.

– Белсен, аны кем тота? Йә?

– Сез аның согын эчеп бетерерсез дә ташларсыз! Мондый бәйләнеш шулай тәмамлана...

– Ул минем согымны эчә, мин – аныкын. Бергә – бер. Нәрсәсе аңлашылмый моның?

– Юк, син аның согын икеләтә эчәсең, беләм мин. Эчәрсең дә туйгач ташларсың!

– Ул минем ирем, минем милкем, ни телим, шуны эшлим. Мин дә аның милке, минем белән ни тели, шуны эшли ала.

– Юк, Радик итагатьле, ни-нәрсә теләсә, шуны эшли алмый. Ул намусына ертлач түгел!

– Сез аны белмисез, Клара ханым, аңарда ирләр эгоизмы бик көчле.

– Юк, аңарда эгоизм тамчы да юк!

– Элек сез сизмәгәнсездер. Ирләр, хатын-кыз белән кушылгач, икенче төрле ачыла. Моны алдан үзләре башка да китермәгәнчә ачыла. Радикның миңа үзе әйткәне бар...

– Инга, син чибәр, яшь, нигә үзеңә башкаларны каратмыйсың? Нигә Радикны капкынга эләктердең, ә? Берәрсе күрсәтмә бирдеме?

– Киресенчә, ул мине капкынга эләктерде, беләсегез килсә. Аңардан башка бер ир-ат та күземә күренми.

– Дөрес түгел, юк. Дөресен сөйләмисең. Нигә сез минем Радикка каныктыгыз, ә? Йөрәгенә кан сауган ананы аңлый аласызмы сез? – Клара елап җибәрүдән көчкә тыелып калды. Ул бөгелеп төште, җилкәләре калтырана иде.

– Сез һәрнәрсәне фаҗигагә әйләндерә торган зат, ахрысы, – дип, Инга ярсудан урыныннан сикереп торды һәм идән буйлап йөрергә кереште. – Нәрсәсе нормаль түгел, йә? Ике яшь кеше очрашкан, бер-берсен ошатышып кушылган. Нигә моңардан фаҗига ясарга? Мин бит Радикны элегрәк тә белә идем... Гимназиянең соңгы курсында...

– Юк, сез – тәҗрибәле хатын, Радик сезнең чираттагы корбаныгыз гына... Калдыр баламны, зинһарлап сорыйм.

– Чираттагы корбан, имеш. Алай ачуландырсагыз, Радикны кимереп үк бетерермен, сезгә сөякләре генә калыр. Корбан, имеш. Без бер-беребезне үлеп яратабыз. Мин теләсәм дә, Радик миннән китмәячәк. Ул үзе минем согымны

эчә. Беләсегез килсә, синнән башка тора алмыйм, дип, көн-төн тәкрарлый. Нәрсәсе начар моның, аңламыйм...

– Сез аның ата-анасын ташлаттырдыгыз...

– Мин көчләдемме әллә? Ул үзе бит. Ә монысы да гел кешеләрчә: кеше берсен ташламыйча, икенче тормыш башлый алмый. Радик икенче тормыш башлады. Табигать кушканча, билгеле бер яшькә җиткәч, ул сезне ташлап китәргә тиеш иде. Сез моны беләсез...

– Ләкин корбан булу рәвешендә түгел...

– Бәлки, мин аның корбаныдыр? Кем белгән аны? Хәзерге вакытта һәр адәм баласы корбан... Йә тегеләй, йә болай – барыбер корбан...

Инга, ашыга-ашыга, икенче бүлмәгә кереп китте. Бераздан йокыдан уянып җитмәгән Радикны эткәләп-төрткәләп алып чыкты.

– Әнә әниең сине алырга килгән, бар! – дип, аның аркасына учы белән бәргәләп алды.

Радик, озын керфекле күзләре белән әнисенең башыннан аягына кадәр үлчәгәндәй, ачулы карап торды, иреннәре кысылды.

– Син тагын минем тормышны җимереп йөрисеңме? – дип кычкырырга тотынды.

Улының кыяфәте үзгәрүдән Клараның коты алынды һәм ул, урыныннан торып, ишеккә таба атлады.

– Вон биредән, башка эзең булмасын!

– Әнә ул үзе сезне куа, мин түгел, мин түгел! – дия-дия, Инга Клараның колак төбендә быкылдый иде.

Радик исә, аның саен ярсып, анасына ташланды, Инга алдында үзенең батырлыгын, ир булуын күрсәтергә тырышты, янәсе, ул «маменькин сынок» түгел, ул көчле, Инга өчен дә тора алырлык...

Клара чыгып китте. Аяклары атлаганны да сизмәде. Дөньяның асты-өскә килде. Радикмы соң бу? Әллә бүтән затмы? Кем аны шулай алыштырды? Бер дә болай булыр төсле түгел иде. Әйе, Радикның нервылары тәртиптә түгел. Ул икенче категория неврастения белән авырды. Ул үзенең ни эшләгәнен, ни әйткәнен белми. Фәкать эшне эшләгәч, сүзне әйткәч кенә нишләгәнен аңлый. Ләкин эш узган була инде... Клара улын һаман гаепли алмый иде әле...

### XII

Андрей беркөнне һич көтмәгәндә танышын очратты. Ул Зорис фамилияле теш техникы иде. Милләте буенча латышмы, эстонмы, белмәссең. Зорис бер сөйләшкәндә үзен эстон дип, икенче очрашканда латыш дип таныштыра иде. Тулы алсу йөзле, киң җилкәле, бик елгыр хәрәкәтле, кырыклар тирәсендәге бу кешегә бернинди кайгы-хәсрәт, бәла-каза килмәгәндер иде кебек. Һәрвакыт шат күңелле, балаң турында сөйләп зарлана башласаң, үзең гаепле, дип тәкрарларга ярата. «Кешенең үзеннән башка бүтән бер иблис тә аңа шултикле бәла китерә алмый» дигән мәкальне әйтеп, авызны яба. Ул, хәрби шәһәрчеккә атнага ике тапкыр килеп, санчастьта теш кую белән шөгыльләнә иде. Хосусый рәвештә эшләсә дә, ничектер рөхсәт иткәннәр. Шуңа күрә «ничек ышанганнар моңа» дигән уй да башка килми калмый иде. Хәер, хәрби шәһәрчектә кавалерия частьлары урнашкан, анда яшерен нәрсә юк иде шикелле. Әмма һәр кешедән шикләнү, бар кешегә таныш нәрсәләрне дә сер итеп тоту гаять нык куелган иде. Әйтик, ике катлы казармалар янында хәрби киемле таныш түгел берәү пәйда була да, бер кызылармиячедән, бәдрәф кайда, дип сорый. Тегесе

кайда икәнен кулы белән күрсәтә. Бу хәлне политрук күзәтеп торган икән. Икенче көнне, саф алдына бастырып, бәдрәфне күрсәткән кызылармиячене бик каты «пешерәләр». Ул таныш түгел хәрби, бәлки, шпиондыр, ә син аңа серне ачкансың. Бәдрәфтә күзәтеп ятмас дисеңмени ул дошманны? Бәлки, аны халыкара империалистлар диверсия ясарга җибәргәндер? Каян беләсең, маңгаена язылмаган... Егетне үзенең иптәшләре, янәшә караватта ятучы, көнетөне бергә аралашып яшәүче дуслары тетепме-тетә генә.

Армиядә менә шундый вазгыять иде. Шундый шартларда да Зорис ничек ышаныч казанган икән соң? Бәлки, буржуаз Латвия вакытында ук русларга берәр яхшылык эшләгәндер. Зорис шикелләләр теләсә нинди эшне булдыра ала. Латвия мөстәкыйль чагында ук, анда безнең агентура эшләгән булырга тиеш. Юкса мөстәкыйль ил икенче илгә ансат кына кушыла алмас иде. Зорис та әнә шундый кешеләр белән танышкандыр һәм, алар куйган шартларга күнеп, ярдәм иткәндер, боерганны үтәгәндер. Ләкин үз энтузиазмы белән яки Советларны яратудан түгел, ә ниндидер хак бәрабәренә генә. Ул дебет-кредитны гына белә. Акчасы булса, шайтанның үзе белән дә дуслашыр һәм аңа хезмәт итәр. Андрей аны нык белмәсә дә, кешеләр белән тиз аралаша, дуслаша алуын чамалап, аңа ышанып бетмичә карый иде. Зорис берничә тапкыр Андрей белән якынаерга да маташып карады кебек. Ләкин берни дә барып чыкмады. Андрей болай да кешеләр белән бик авыр аралаша, авыр табыша. Ул гына түгел, бүтән иҗтимагый сәбәпләр дә комачаулагандыр. Әмма хәзер Андрей Зориска ниндидер өмет белән карады. Егылсаң, еланга тотынырсың, диләр. Андрейның хәле мөшкел иде. Материаль яктан гына түгел, эш буенча да. Аны кайсы акылы сизерәгән, кайсы симулянт солдатлар лазаретына бер немец врачы кул астында эшкә куйдылар. Биредә медицина белеменнән бигрәк физик көч кирәк иде. Лазаретта акылдан язган дигән диагноз белән сугышка барудан качкан немец солдатларын кыйнар өчен махсус штат тоталар. Андрей ул штатта тормаса да, ара-тирә аны да мәҗбүр итәләр. Кайчак симулянт үзе килеп ябыша, бик каты итеп суга... Андрей паёк хисабына, бары ачтан үлмәс өчен генә шунда эшләргә мәҗбүр иде. Берничә ай эшсез йөреп, тәмам чиккә терәлгәч кенә, ул бу эшкә риза булган, ләкин биредәге хәлләрне һич тә күз алдына китерә алмаган иде. Кайбер симулянтларны тимер читлекләргә ябып куялар. Бик көчле тәэсир итә торган дарулар белән укол ясыйлар. Андрейны укол кадаучы сыйфатында тоталар. Әмма сөйләшүләренә караганда, биредә авырулар һич тә симулянтка охшамаган иде. Әмма һәр милләттә яхшысы, яманы бар шул. Нинди мактаулы, дөньяны тазартабыз дип лаф орган милләт тә начарлыктан, түбәнлектән азат түгел икән.

Ә шулай да Андрей баштарак Зориска өмет белән карады. Бу үткен кешедән берәр файда күреп булмасмы дип уйлады. Тик сөйләшә-сөйләшә Зориснең өенә таба барганда, Андрей сүз сөрешеннән чамалады: бу адәм үзе Андрейдан файда күрергә тели иде.

Аның квартирасы ике бүлмәле, ләкин өйдә берәү дә юк иде. Әллә ялгызы гына яши инде? Хатын-кыз кулы сизелә дә кебек, әмма тәгаен генә белерлек түгел. Өйдә ниндидер шыксызлык бар сыман. Шәрә өстәлгә Зорис мичкә тәгәрәткән бәрәңге, бер шешә көмешкә китереп куйды. Каяндыр бер кыерчык ипи дә табылды. Шулай да бу фатир ничектер күңелгә шом сала, биредә сине эләктерергә капкын куелгандыр шикелле тоела иде. Хәер, бүгенге көндә һәр төштә капкын куелган инде.

– Кызыллар мине төпсез кәвешкә утыртты, – диде Зорис, көмешкәле стаканын ирен арасына чөңкәйтеп куйгач, тамак кыра-кыра. –Ышанычсызлар!

– Ни булды, ни булды? – Андрей сыйлаган кешенең күңелен күрер өчен генә өтәләнгәндәй сорап куйды.

– Бар алтыннарымны акчага әйләндергән идем, хутор-җир сатып алырга иде исәп, шайтан алгыры! Хатын сүзен тыңлап, харап булдым. Кызылларга ышанып, капиталдан колак кактым. Бер капчык кәгазьне хәзер стенага обой итеп ябыштырырга гына калды. Тфү, шайтан, болай беркайчан да алданганым юк иде.

– Немецлар алыштыра ди түгелме соң?

– Баручылар булган, конфискацияләп алып калганнар! Германнан ни көтәсең инде. Тфү! Син әйт әле, кызыллар кабат кайтырмы?

– Белмим, белмим... – диде Андрей, бу сорауны ишетәсен белеп һәм шуңа уйчанланып. Чын фикере беленмәсен өчен, ул йөзенә кайгы-сагыш төсмере чыгарды. Зориска гына түгел, үз улыңа да ышанып булмый бит хәзер. Ә бу немецлар турында шактый тозлы сүзләр сөйли, ә үзе гел сине күзәтә. Бәлки, алай ук күзәтмидер дә, әмма җан тәмам куркып беткән, ихтыярсыздан гел сагая, шикләнә...

– Беләсең, ләкин әйтмисең, – диде Зорис, Андрейның ихласлыгына исәп тотып.

– Белмәгәнне ничек беләм дип әйтеп булсын? – диде Андрей, тегенең ышанмавын сындырырга теләп. Шундый хәл: үзләре, стакан чәкештереп, көмешкә эчеп утыра, әмма Андрей Зориска ышанмый, Зорис – Андрейга. Зорис авыр сулап уфылдап куйды, ул Андрейны өенә алып кайтканына үкенә иде кебек. Бигрәк тә Андрей үзенең кайда эшләп маташканын әйткәч, кулын селтәде, уйланып калды. Андрей исә хуҗага ярарга тырышты: – Син үзең кайда эшлисең соң, нигә частный практика ачмыйсың? – дип сорады. – Син – мастер, сине зурларлар, – дип тә тегенең салпы ягына салам кыстырмакчы булды. Бу Зорис үзе дә кызыксынган мәсьәлә икән. Ул берничә җиргә эшкә кереп караган, әмма берсе дә төшемле түгел, аны һаман үз һөнәре тарта икән.

– Билгеле, син зур мастер бит. Немецлар, һичшиксез, бәяләрләр...

– Миндә бер тамчы да материал юк, әйттем бит, барысын да кәгазьгә әйләндергән идем. Авызын корт чаккыры! Бер-ике йөз грамм алтын, көмеш тап, частный практика ачып җибәрәбез. Син дәвалыйсың, суырасың, ә мин куям, ә?

– Кем сиңа рөхсәт итсен? – Андрей, Зорисның бер-бер тозакка эләктерергә теләвен чамалап, юри шулай әйтте.

– Анысы минем кайгы. Ну? Ышанмасаң, алтын табып бир, ни теләсәң, шуны алырсың. Хатын-кыз алкалары, йөзекләр, беләзекләр... Ну без синең белән эшләр идек.

– Немецларга ничек ышанычка кердең? – дип, Андрей күңелен баядан бирле бимазалаган сорауны бирде.

– Ничек дип, без үз җиребездә яшибез бит, – диде Зорис, бераз икеләнебрәк. – Алар латышларны үзләренеке дип исәпли. Аннары мин политикага катнашмыйм. Политика фахишә кебек, бүген болай, иртәгә тегеләй... Кызыллар инде барысы да политиклар. Аларга ипи бирмә, политика бир. Тормыш политика белән генә бармый икән...

Аның сөйләгәннәрен Андрей игътибар белән тыңлады, Зорисны немецлар вербовать иткәнме, юкмы – шуны ачыкларга теләде. Менә нәрсәдер беленде түгелме, немецларга хезмәт итәргә теләмәгән кешегә частный практика ачарга рөхсәт бирмәячәкләр. Зорис исә, рөхсәт алам, ди. Бәлки, алгандыр да. Димәк, шулай булгач...

– Ничек ышаныч казанырга, ә? – диде Андрей. – Шуның механизмын өйрәт әле миңа...

– Чынын әйтергәме? – Зорисның ачуы килә башлады. Андрейдан бер

фәтва да чыкмаслыгына ышанган саен, аның ачуы көчәя генә барган кебек иде.

– «Мин сезгә тугры хезмәт итәргә телим», дип бар, белдеңме? Немецлар шымчы булырга кушар, йөкләмә бирер. Аларын үтәсәң, тагын бирерләр. Менә шулай гына аларның ышанычын казана аласың. Бүтәнчә юл юк.

– Әгәр мин мондый эшне булдыра алмасам? – дип куйды Андрей.

– Ачка үлә башласаң, булдырырсың! – Зорис хихылдап куйды.

– Әгәр берәр иптәшем өстеннән күзәтчелек итәргә кушсалар?

– Сине саталар бит, син нигә башкаларны сатудан тайчанырга тиеш?! Синең яңагына сугалар икән, икенчесен куеп торыргамы? Кеше гел принцип белән генә яши алмый, юкса ул корбан була. Кешеләр корбан булырга теләми, ә яшәргә тели. Теләсә нинди чара-ысуллар белән, теләсә нинди эшләр башкарып. Иптәшең өстеннән күзәтчелек нәрсә ул! Һи-и! Яһүдне, коммунистны барып әйтәсең икән, шунда ук ышаныч казанасың. Исән каласың. Яки-яки! Бүтән юл юк...

Зорисның башына китеп өлгерде, бер минутка гына тормозы ычкынып торды. Шул арада авызыннан күңелендә яткан серләре дә ычкынды. Шулай да Андрей аның ялганмы, чынмы сөйләгәнен чамалый алмады. Сак булырга кирәк иде. Бу кешедән барын да көтәргә була, яки-яки – мәсьәлә әнә шулай куелган, анысын Андрей үз иңендә татып белә.

– Ә иптәшеңне ничек сатарга мөмкин? – диде Андрей, гаҗәпләнеп һәм үртәлеп.

– Син сатмыйсың икән, ул сине сата! Һаман бер балык башы! – дип куйды Зорис, кулын селтәп, элементар нәрсәне һаман аңламыйсың дигән төстә. Андрей тагын икеләнә калды: тел төбе кая таба бара бу денсезнең? Ул гамәлдә булган һәм булып торган хәлләр турында сөйли ич. Үзенең сүз сөреше белән Андрейны да бер базга илтеп батырмасмы, мәлгунь? Бу немецларда үзең кебек берәүне сатмыйча яшәп булмый микәнни? Һәркем власть органнарына яшерен хезмәт итәргә тиеш булып чыгамы? Яшерен хезмәт ул – үзең белән бергә эшләүчене, яшәүчене сату дигән сүз! Башкача мөмкин түгел микәнни? Әллә моны кешеләрне җәзалау өчен керткәннәрме? Немецлар һәр кешене җәзага тарта. Нишләп болай? Һәр кешене дошман саныйлар. Ә бит үзләре кешеләрдән башка бер эш тә эшли алмаслар иде! Фашизмның асылы шундадыр, ахрысы. Кеше дигән материалны бер тиенгә дә санамый торган.

– Син ничек ышаныч казандың соң? – диде Андрей, чираттагы стаканнан кинәт кайнарланып китеп.

– Анысы, иптәш, һәркемнең үз эше, – дип, Зорис тамак төбе белән кеткелдәп алды. – Сиңа берәү дә ул серне ачмас. Һәр кешенең үз язмышы, үз җае...

– Әйе, монысын хак әйтәсең, шайтан алгыры!

Бераз тынып, бәрәңге капкалаганнан соң, Зорис, үзенең төп максатына якынрак килергә тырышып, болай диде:

– Биредә кызыллардан подпольеда калдырылган кешеләр булырга тиеш, шулай бит? Бу беркемгә дә сер түгел. Немецларга да. Ә синең элеккеге берәр танышыңны очратканың юкмы?

– Мин подпольеда калдырылган кеше түгел микән дип уйлыйсың килә инде, ә?

Андрей шаярткан булып бармак янады. Бик хәйләкәр кеше син, Зорис, дигән төстә. Күзендә дә елмаю чаткылары күренде. Ә Зорис җитди төс-кыяфәт белән утыра. Ул да Андрейга ышанмый, аның кылларын тартып карый, серен белергә тели.

– Юк, Зорис, – диде Андрей, шик калдырмаска тырышып. – Сугыш чыкканда, мин биредә түгел, Добэледә баҗа янында идем. Гаиләм белән.

Без кайтканда, беркем дә калмаган иде. Аннары безне, хатынны да, мине дә хәрби частьтагы эшебездән чыгардылар. Эш мәсьәләсендә Кларaның сеңлесе булышмакчы иде. Чөнки ул Советлар каршында яхшы исәптә йөри. Ләкин...

– Аңлыйм, аңлыйм, – дип, Зорис тагын да җитдиләнгән төсле булды, кинәт сәрхушлыгы бетеп китте, ахрысы. – Алайса, болай: мин сиңа ун мең бирәм, син миңа ике алтын балдак тап, эшне башлап җибәрергә.

– Туктале, ул кәгазьләр белән мин нишләрмен, мине дуракка саныйсың мәллә?..

– Рус акчасы белән рус нишләргә белер.

– Минем элемтәләрем бар дип уйлыйсыңмы, Зорис? Әмма мин беркемне дә белмим. Ышансаң ышан, ышанмасаң – юк...

– Бик бетерешкәнсең, бер элемтәң дә юктыр шул, – диде Зорис, уйчанланып. – Мин сиңа котылу юлын өйрәтәм, элеккеге таныш итеп. Телисеңме? – Зорис аңа тагын да кадалыбрак карады.

Андрей ияк какты.

– Двинск урманнарында Герман атлы немец җитәкчелегендә партизан отряды бар, ди. Әйе, әйе, совет немецы. Баскын немецларны бөтенләй күралмый икән. Менә шул: ике алтын балдак өчен миннән ун мең аласың да шул якка хәрәкәт итәсең. Куркынычсыз юлны өйрәтәм. Йә? – Зорисның сәрхушлыгы беткән, күзләр үз орбитасына утырган, бәбәкләре ниндидер хәйлә белән кысылган иде.

Андрейның зиһененә кинәт бер уй китереп сукты: әгәр Зорис тәкъдименә ризалыгын бирсә, мантыйк буенча ул биредә калдырылган булып чыга түгелме? Менә ничек була икән ул үз-үзеңне сату. Сизмичә дә каласың. Ә бит тәкъдиме бик ымсындыргыч, авызын корт чаккыры!

– Исән-сау чыгарга гарантия бирәм. – Зорис, Андрейның икеләнеп калуын сизеп, шулай дип өстәде.

Андрейның үз-үзенә ачуы килде. «Ничек сизде, шайтан, минем эчемдәгене, – дип уйлады. – Чыраем, төсем уйларымны тышка белгертеп кенә тора, күрәсең».

– Нүжәли, немец немецны кырыр икән? – диде Андрей, ышанып җитмичә.

– Нинди беркатлы син, Андрей? – дип төрттерде Зорис. – Хәзер мәхшәр: немец – немецны, латыш – латышны, рус русны кыра.

– Кешеләр курчаклар урынына йөри, ә? Искитмәле хәл... – Андрей башын як-якка чайкап торды.

– Юк, син минем тәкъдимгә җавап бирмәдең. – Зорис үз максатын бер минутка да онытмый иде.

– Нәрсә дим? Мин гаилә белән бит. Аларны калдырып...

– Гаиләң белән бергә китәсең... Әйткәнемне үтим мин.

– Юк, ышана алмыйм, Зорис, – диде Андрей. – Теләсә ни уйла, әмма сүзләргә...

– Димәк, теләмисең? Шулай аңларга кирәкме синең баш тартуыңны? – Зорис әңгәмәдәшен азакка хәтле кысарга булды.

Андрейның үз хәле хәл иде: «телим», дисәң – бер нәтиҗә, ә «теләмим», дисәң, икенче нәтиҗә чыгарырга була бит.

– Ул операциядән куркам мин, иптәш Зорис, – диде Андрей.

– Телисең, әмма куркасың, шулаймы?

– Андый тәвәккәл адым ясарга теләмим, – диде Андрей, кинәт күңелендә үз-үзенә нәфрәт кузгалганын тоеп. Шушы адәм актыгына баш иеп, сүзен тыңлап утыр инде. Менә ул түбәнлек нинди була икән.

– Ә тәвәккәлләмичә берни отып булмый, Андрей! Бу – закон!

– Димәк, оттырышта җан асрарга туры килә.

– Оттырышта да ашамыйча торып булмый. Нигә аңлы рәвештә оттырасың? Отарга омтылып карарга кирәк!

– Йә мин, йә җан, дипме?..

Андрейның бу сүзләренә Зорис җавап кайтармады. Зур гына бер бәрәңгене алып әрчергә тотынды. Аннары бәрәңгесен, әрчеп, авызына капты да:

– Алайса, болай итәбез, – диде. – Минем дипломым юк. Немецлар бик формалист халык, аларны ышандыру кыен. Синең дипломың бар. Шул документ нигезендә синең исемгә частный практикага рөхсәт алабыз. Йә?

– Әй, иптәш Зорис, – диде Андрей, үкенүле тавыш белән. – Без йөреп карадык инде, әмма рөхсәт итмәделәр. Юк!

– Мин артыннан йөрсәм, рөхсәт алмый калмыйм. Ризамы?

– Ә материалны каян алабыз?

– Синең хатыныңның алтын балдаклары юкмыни? Булмыйча калмас...

– Җәл, беркөн генә базардан онга алыштырып кайтты. Юкса...

Андрейның бу сүзләреннән Зорисның йөзенә җирәнү һәм читләшү галәмәте чыкты.

– Ни өчен сезне теге частьтан кудылар? – дип сорап куйды Зорис. Ул тагын нидер гөман итте кебек.

– Нәрсәбездер ошап җитмәгәндер инде. Шайтан белсен...

– Советка да ярамагансыз, немецларга да. Сез нинди кешеләр соң?

– Яраша белми торган адәм затлары...

– Ә табигатьнең законы кырыс бит: яраша белмәгәннәр һәлак була...

– Әйе, һәлак була...

– Мин сине коткарырга телим, – диде Зорис. – Сине үз җаваплылыгыма алсам, синең исемгә частный практика эше ачарга мөмкин булачак. Материал эзләргә керешәм. Тапкач та сиңа әйтермен... Кызыллар кабат әйләнеп кайтырмы, юкмы, ә?

– Белмим, әйтә алмыйм.

– Кызыллар килсә, частный эш өчен сине гаепләячәкләр бит. Немецларга эшләгәнсең, дип...

– Әйтерләр, ябып та куярлар. Ләкин, ачка үлмәс өчен, ни дә булса эшләргә кирәк бит...

– Алар ул сәбәпне исәпкә алмаячак...

– Беләм, әмма башка чарам юк. Теләсә нишләтсеннәр...

– Димәк, син кызылларның кабат кайтуына ышанасың?..

– Белмим, дим бит, – диде Андрей, бераз тавышын күтәреп. Һәм чамалап алды: кызылларның кабат кайту-кайтмавы Зорис өчен бик тә мөһим иде. Ул хәзер шуңа карап эш йөртәчәк. Үзендә тәгаен генә фикер юк кебек. Андрей исә кызылларның кайтуына аз гына да шикләнмәде. Хәтта «немецлар Мәскәүне алган икән» дигән хәбәр шәһәр буенча телдән-телгә йөргәндә дә. Ул төгәл исәп йөртте: әгәр немецлар Мәскәүне алса, сүзне болай астан гына таратмаслар, бар дөньяга шауларлар иде. Тончыкканчы кычкырырлар иде. Авантюристлар шулай сүз белән халыкны адаштыруга бик нык исәп тота, ялган хәбәрләрне оста файдалана.

– Яшермә, ышанасың, – диде Зорис, үзенең икеләнүләрен ничек тә булса бетерергә теләп. Әгәр Андрей ышанса, аңа да теге яки бу карарга килү өчен ориентир булыр иде. Ә хәзер күңелдә икеләнү дә шикләнү генә. Ә

бит билгесезлектән дә яман нәрсә юк. Андрей ачылмый, Зорисның җанын билгесезлектә газапланырга калдыра.

– Күпме мөмкин? Белмим и всё! – дип куйды Андрей, ә үзе эчтән уйлады: бер ярты көмешкә хисабына нинди авыр газаптан котылмакчы була бу. Тот капчыгыңны! Әгәр ул үзенең ышанганын әйтсә, Зорис аны икенче көнне үк гестапога җиткерәчәк. Ул русларны болай да яратып бетерми.

– Нигә безне руслар бетермәкче була? – диде Зорис, сүзне икенчегә борып.

– Руслар сезне бетерми, сез үзегезне үзегез бетерәсез, – дип куйды Андрей.

– Ничек? Соң бит без шундый хәлгә куелган. Нишли аласың? Бар эшне экономика-политика хәл итә бит... Немецлар белән дә мөнәсәбәтләр әйбәт түгел, руслар белән тагын да начаррак...

– Советлар белән сез бәхетле булачаксыз, – диде Андрей. – Чөнки бай ил кочагына керәчәксез. Ә Германия сездән бары суыруны гына белә. Аның ресурслары юк. Германия белән сез кытлыктан чыкмаячаксыз, Россия белән байларча яшәячәксез...

– Байлык бирү хисабына алар безнең телебезне бетерә, ассимиляцияләү юлы белән руслаштыра. Бу да әйбәт түгел бит. Димәк, латышлар милләт буларак юкка чыгачак. Россиядәге греклар кебек. Тел бетте – милләт бетте...

– Юкка кайгырасың, бетми ул.

– Русларга рәхәт сөйләшүе. Бөек милләт! Ә сез үзегезне безнең урынга куеп карагыз, ә?

Алар озак бәхәсләшеп утырды. Зорис үз милләте өчен ачынып яши икән. Бу сыйфаты аңа карата ниндидер хөрмәт тә уята иде. Ә нигә Зорис Андрей белән эшләргә тели? Кызыллар килсә, менә мин немецка түгел, русларга ярдәм иттем, дип әйтер өченме? Әгәр Зорис немецларның җиңүенә ышанса, әллә кайчан аларга эшкә ялланган булыр иде. Тик менә аны хәзерге көнгә кадәр сузган. Шикләнеп, икеләнеп яткан, димәк. Кызыллар килгәч, биредә хәлләр булачак әле. Нечкә иләк аша үткәрәчәкләр. Зорис әллә аңы, әллә интуициясе белән шуны алдан сизенә шикелле.

Немецлар зур төгәллек белән җәза эшләрен алып бара. Шәһәрдәге рус милләтеннән булган һәр кеше исәпкә алынган иде. Һәр рус гаиләсе, аның нәсел-ыруы, балалары гестапо бүлегендә исәптә тора. Әгәр гаилә башлыклары немецларга яшерен хезмәт итүдән баш тарткан икән, андыйларга җәзаның иң әшәкесен кулланалар. Туганнары, балалары аша төрле җәзалар бирәләр. Туган белән туганны сугыштыралар. Икесен дә бер-берсенә каршы котырталар. Әйбер-кара өчен, квартира-бүлмә өчен тартыш китереп чыгаралар. Шул нигездә дошманлаштыралар. Хәтта ир белән хатын арасына керәләр. Хатын артыннан йөрергә берәр ертлач иргә боерык бирәләр. Бусы эш урыннарында бик шәп оештырыла. Клара эшли торган больницаның баш врачы урта яшьләрдәге немец иде. Медицина буенча белеме дә рәтле түгел, чөнки авыру исемнәрен, рецептларны бутый иде. Ул, мөгаен, ветеринар булырга тиеш, дигән фикергә килә иде Клара, чөнки бар белгәне дару дозаларын киметү иде. Биредә кешеләрне дә хайваннарга бирелә торган дарулар белән дәвалыйлар, әмма кечкенә дозаларда. Немец моны аера белә, шуңа күрә дозаларны азайта. Башта моны Клара немец саранлыгы гына дип уйлаган иде. Тора-бара баш врачның медицина буенча юньле-рәтле мәгълүматы булмавы беленде. Билгеле, ул бирегә кешеләрне дәвалау өчен куелмаган. Кешене дәвалау немецлар өчен мөһим түгел. Алар һәр авыруга әз генә ярдәм күрсәтү белән бергә, аны сынау аша уздыралар. Һәр врачка авыруның немецларга ничек каравын белү бурычы куела. Баш врач конкрет

сораулар куя, син авыруларга шул сорауларны бирәсең. Авыруын сөйләгән арада, һич көтмәгәндә, кешенең теленнән кинәт нәрсә уйлаганы ычкынуы мөмкин.

Ветеринарның бу боерыгын Клара төгәл үти, ләкин авыруларның карашларын билгеләгән графага «немецларга уңай караштa тора», дип язып бирә иде. Баш врач үз кабинетына чакырып кертә дә, Клара белән озаклап сөйләшә. Клара немецчаны ярыйсы гына белә. Балачагында немец кызлары белән уйнап үсте ул. Әмма күп нәрсәләр онытылган, шулай да аңлата да, аңлаша да ала. Ветеринар Кларага: «Әгәр немецлар кушканны төгәл үтәп барсаң, берникадәр вакыттан соң бу больницаны синең кулга тапшырам, – дип вәгъдә бирде. – Немецлар сүзләрендә нык тора. Безгә җирле кадрлар бик кирәк». Клара шунда ни әйтергә белмичә каушап калды. Ветеринар Клара тутырган карточкаларны күздән кичерде: «Нишләп барысына да «немецларга уңай карый» дип яздыгыз? – дип сорады. – Болай булуы мөмкин түгел. Уңай карамаганнар да булырга тиеш. Без моны беләбез...» «Юк, – диде Клара, – мин бары тик дөресен генә яздым, миңа каралырга килгән авырулар шундый караштa иде. Башка төрлеләре очрамады. Алайса, үземнән өстәп, «немецларга уңай карамый» дип языйммыни?..» Ветеринар кулларын селтәде, пенсне-күзлек артына яшеренгән бәбәкләре киңәебрәк китте, чиста кырылган алсу битенә җитдилек чалымнары чыкты. «Безгә өстәп язу кирәкмәс, – диде ул, һәм өстәп язуның ялгыш юлга кертүе һәм һәлакәткә китерү ихтималы булуын сурәтләргә кереште. Клара аңласын өчен, озын итеп мисаллар китереп сөйләде. Клара исә, чын уй-хисләрем йөземә чыкмасын дип, бөрешеп утырды, йөзенә ясалма елмаю чыгарды. Шулай итмичә мөмкин дә түгел. Өстәп язу кирәкми, имеш. Немецлар үзләрен «башка милләтләрдән югары» дип өстәп язган инде. Үзләрен-үзләре күтәргән, өстәп язып күтәргән. Үз-үзләрен югары күтәргән кешеләр тиранга әйләнә. Болар исә немец милләтен өстәп язып югары күтәргән дә фашистка әйләнгән. Менә бу немецның кай җире Кларанықыннан артык соң? Юк бит, юк! Бернәрсәсе дә артык түгел. Чынлап та, өстәп язу катастрофага китерүе ихтимал, дип сөйли үзе. Ә үзенең катастрофага ярдәм иткәнен белми, чөнки ул гаять көчле машинаның бер шөребе генә. Үзен югары санаган шушы «шөреп» Кларaны еш кына «тәрбияли» башлады. Начар яхшыга сабак өйрәтә иде. Юк, бу хәл юньлегә илтә алмый иде. Начар яхшыга акыл өйрәтүгә корылган тормыш нинди генә җитеш булмасын, ул – гаделсез тормыш. Ә биредә әле ачлык хөкем сөрә. Нәрсә уйлап эшли бу немецлар? Әллә аларның миләрен кара пәрдә каплаганмы? Ниндидер бер хәтәр машина төзегәннәр дә шуны хәрәкәткә китергәннәр. Барысы да шул машинаның шөрепләренә әйләнеп беткән. Эшләрен механик рәвештә уйсыз гына башкаралар...

Радикны да шулай ук «эшкәртү» бара иде. Яшерен җитәкчесе аны көтмәгәндә үзенә чакырып алды.

– Без сине хөрмәт итәбез, син безгә бик кирәкле кадр, – диде ул, бик җитди төстә. – Без синең гаилә хәлеңә дә битараф кала алмыйбыз. Гаилә тормышыңны җайга салу чаралары күрәбез. Әгәр без кушканнарны төгәл үтәп барасың икән, сезгә, Инга белән икегезгә, аерым йорт бирәчәкбез. Ә теге атнада партизаннарны эзләү рейдына барудан ник баш тарттың? Менә бит безнең «һәр боерыкны үтим» дип куйган имзаң. Нәрсә бу? Немецлар сүздә тормауны, төгәлсезлекне өнәми. Ну, ни сәбәптән бармадың? Ә? Йә?..

Агент тишеп үтәрдәй очлы күзләрен Радикка төбәде. Радик ничек акланырга белмәде. Тегене сәбәп итте, моңа сылтады. Агент берсенә дә ышанмады. Алдыйсың, сукин сын, дип, пистолетын өстәл өстенә чыгарып куйды.

Пистолет белән өстәл сугып та кычкыргач, Радик чишелде: «Кеше каны коюдан курыктым, – диде. – Әти-әни шуңардан сакланырга кушты», – дип, туганнары артына сыенды... «Әһә, сез шулаймыни әле?! – диде агент, читкәрәк карап. Аның озынча ябык йөзе тартылды, бит мускуллары хәрәкәткә килде. – Әйдә, киттек», – диде ул, ияге белән ымлап.

Алар офицерлар өчен генә ачылган ресторан-казинога килеп керде. Зал шактый зур, кечкенә сәхнәсе дә бар, анда пианино тора иде. Шул арада сәхнәгә берничә артист чыкты. Берсе пианино янына утырды. Икенчесе скрипкасын ияге астына куеп, смычогын кыллар өстенә китерде. Ә калын иңнәре ялангач, аяк йөзеннән озын күлмәк кигән хатын-кыз кулы белән ым кагуга, музыкантлар уйнарга кереште. Кирәкле тактын көтеп торган калын тавыш аларга кушылды. Хатынның ялангач иңнәре сикерергә, футбол тубы кебек күкрәкләре әле бер, әле икенче якка тәгәрәргә тотынды.

Агент Радикны ашатты, эчертте. Һәм шул эчемлек астына үзенең катгый боерыкларын тукыды. «Адәм баласы намус белән туа, аның канында нәселдән килә торган ояла белү бацилласы да ага, – диде. – Ә намуслы кеше бернигә дә тормый, чөнки ул бернинди тәвәккәл эш башкара алмый, аңлыйсыңмы? Җанында намус дигән барьер тора аңа комачаулап. Аңлашыламы? Үзеңне чын кадр, уңышка ирешә ала торган кеше итәргә теләсәң, син ул намус барьерын җиңәргә тиеш. Җиңүче, уңышларга ирешүче чын ир булырга телисеңме? Әллә сиңа боламык булып калу ошыймы? Юк, син фәкать уңышларга ирешүче кеше булырсың. Без сиңа бик зур өметләр баглыйбыз. Латвиядә җитәкчелек итү өчен безгә бирелгән һәм теләсә нинди эшкә тәвәккәл кешеләр кирәк. Сине шундый зур җитәкче эшенә әзерлибез. Әгәр без кушканны төгәл үтәсәң, билгеле. Ишетәсеңме? Синең эшлеклелек сыйфатларың безгә ошый, ләкин эшлеклелекне тагын да үстерергә кирәк. Һәм без бергә-бергә үстерәчәкбез. Ышанычың нык булсын, без җиңәчәкбез. Әгәр без канлы эшләр башкарабыз икән, бу бары тик тормышны чистарту өчен, профилактика формасында эшләнә. Немецларга һәм аларга тугрылыклыларга бөек тарих тарафыннан дөньяны пычрактан арындыру вазифасы йөкләтелгән. Без, кешелек бәхетле булсын өчен, бар пычракны көрәп бетерергә тиешбез. Без – тарихи кешеләр. Тарихи кеше булу зур нәрсә ул. Намус, оялчанлык, кешелеклелек шул эштә бик нык комачаулый, тарихи вазифаны башкарырга сиңа киртә булып тора. Комачаулык итә торган сыйфатлардан, гадәтләрдән арынырга кирәк. Тагын бер нәрсә: кешеләргә яхшылык эшләү өчен кешелексез булу сорала. Әгәр син кешелекле булсаң, бары бер-ике кешегә генә яхшылык кыла аласың. Шулай бит? Ә бары кешелексез булып кына галәм халкына яхшылык эшләргә мөмкин. Дөньяны бәхетле итүнең башка юлы юк. Була да алмый...»

Агентның озынча йөзе кирпеч кебек кызарган иде, ул Радикка кан тутырылган юан колба булып күренә башлады. Аның үзенең дә каны бик нык кайнарланды, ул, аяклары белән идәнгә тибеп, тавыш чыгаруын да сизмәде. Шуның аркасында агентка сорау бирергә йөрәге җитте:

– Бар җирләр немецлар кулына күчсә, дөньяга бәхет киләчәк, шулаймы?

Агент моңа сөенеп җавап кайтарырга ашыкты:

– Билгеле, шик булуы мөмкин түгел!

Радик бераз уйга калып торды да башында гел бимазалап торган шиген әйтеп салды:

– Ә бит большевикларның девизы да шундый: бар җирдә социализм җиңсә, дөньяга бәхет килә. Ә?

– Юк! Башыңнан чыгарып ташла бу хәсис уеңны! – диде агент, бик кискен итеп. – Ишетәсеңме? – Аның күз аклары хәтәр ялтырап китте. – Россиядә яшәп, рус социализмының нәрсә икәнен дә белмисеңме, ә? Син бик яшь шул әле. Рус социализмы дөньяны бәхетле итә алмый, юк! Чөнки рус социализмы эшчеләргә бик гуманлы карый, ә крестьяннарны кыса, изә. Ә безнең «национал-социализм» крестьяннарга барлык ирекне бирә. Аларны җиргә хуҗа итеп беркетә. Ул үз җиренә үзе хуҗа һәм шул җирдән хуҗаларча файдалана. Җирдә зур уңыш үстерә. Чөнки җиргә хуҗа кирәк, аны карау кирәк. Ә рус социализмында җирләр хуҗасыз. Аңлыйсыңмы? Җирнең хуҗасы булмаса, ул юньләп уңыш бирми. Моны үз җилкәңдә татыгансың. Россиядә беренче сортлы җирләр, ә ашарларына икмәк юк. Ни өчен? Чөнки җирнең хуҗасы юк. Россия ул табигый байлыклар хисабына гына яшәде. Дөньяда аңардан бай ил башка юктыр... Менә шуңа күрә немецлар рус халкын кытлыктан коткармакчы була. Ничек итеп? Тәртип, дисциплина урнаштырып. Җирләрне хуҗасына беркетеп...

– Алайса, нигә русларны бетерүне максат итеп куясыз?

– Юк! Чыгарып ат ул уеңны башыңнан! Менә сез руслар бит, бетерәбезме соң? Без тәрбиялибез. Әлбәттә, безнең яклы булмаганнарны эзәрлеклибез. Бу – закон. Русларда да большевиклар яклы булмаганнарны төрмәләргә япканнар. Әнә без басып алган җирләрдә күпме кеше төрмәдән котылды. Син белмисең, мин беләм... Безнең яклы русларны зур урыннарга билгеләячәкбез. Ләкин тәрбия эше алып бармыйча булмый. Руслар арасында намуслылар күп әле. Син шуны аңла: намуслы, кешелекле адәм җитәкчелек эшенә ярамый. Аңлыйсыңмы? Без немецларда гына түгел, русларда, башка халыкларда да шулай. Әйе, әйе! Чөнки җитәкче кеше политика аша эш итә. Төшенәсеңме? Бар эшләр, кешеләр фәкать политика аша гына идарә ителә. Әйтик, шул дәүләтнең политикасы хакимлек итә. Ә политикага намус, кешелеклелек, туганлык хисләре каршы килә. Шунлыктан политика ул хисләрне чыгарып ташлый, кирәксез итә... Инде бераз әлифбага төшенә башладыңмы?

– Башладым, – диде Радик.

– Әйдә, сал тагын! – дип, агент аны кыстарга кереште. Тәрбиясе үтемлерәк булсын, җанына үтсен өчен, Радикны тагын да йомшартырга кирәк дип уйлагандыр, ахрысы.

## XII

Радикның агенты да тынгысыз, һәр көнне диярлек ресторанга алып бара, сыйлый. Һаман нидер beләсе килеп, көтелмәгән сораулар бирә, җанда капшана иде. Радик нидер аңлап бетерми, чөнки зиһене өстә яткан нәрсәләрне генә белә. Ә Баурих (агентның фамилиясе шулай иде) әкрен-әкрен Радикны үзенә ияләндереп, тәмам кулына ала барды. Беренче рюмканы салып куйгач, ул Радикны мактарга тотынды: «Син бик сәләтле егет, акыллы кеше, эш урынында сине бәялиләр, – диде. – Телисеңме, сине тагын да югарырак урынга куябыз? Эш хакы да күбрәк булачак. Иң мөһиме, син безнең ышанычны аклыйсың, молодец! Начальниклар сине бик ярата. Немецлар чын эшченең кадерен белә алар. Без кызыллар кебек түгел, бездә эш беренчел, ә анда сүз беренчел. Сүзгә ышанып йөриләр дә рәтле тормыш күрмиләр. Кызыл сүз сөйлиләр, эшләргә теләмиләр. Ә без кешенең сүзенә түгел, фәкать эшенә ышанабыз. Сүз нәрсә ул?! Сүз җиңел сөйләнә, эш авыр эшләнә... Сүзләргә ышанмаганга күрә без кыска арада зур экономик уңышларга ирештек. Эш, эшнең нәтиҗәсе генә кызыксындыра безне. Аннан дисциплинаны каты куйдык. Дисциплинасыз бер юньле эш тә эшләп булмый.

Ленин «Дисциплина коллык түгел» дип әйткән. Әйе, әйе, Ленинның Клара Цеткин белән әңгәмәсен укыганым бар. Нигә исең китте?..»

– Сезнең Ленинны укыганыгыз бармыни? – Радикның күзләре зур булып ачылды.

– Без һәр талантлы кешедән акыл алабыз, талымлап тормыйбыз. Шуңа күрә немец фәне, техникасы дөньяда иң алдынгы урында. Әйе, без сүзләргә әһәмият бирмибез. Әмма бирердә башка мәсьәлә. Бу очракта кешенең карашына игътибар итмичә мөмкин түгел. Ягъни кешеләрнең безнең тәртипләрне хуплавын яки хупламавын исәпкә алмыйча булмый. Руслар – үз милләтенә, иленә фанатикларча бирелгән халык. Үзләренең зиһене кыска булуы аркасында, алар күп нәрсәләрне аңламый, яхшыны начардан аера белми. Рус һәм латыш халкын без шул нәрсәләргә өйрәтергә тиеш. Без иң элек дисциплина кертәбез, латыш һәм русларны үз көчләре белән кытлыктан чыгарачакбыз. Әйе, әйе, үз көчләрен бар куәтенә эшкә җигеп. Халыкка дисциплина кирәк. Анысы ярар, ә синең Инга белән мөнәсәбәтең ничек? – Баурих рюмкаларга тагын эчемлек салды. Радик инде шактый йомшаган иде. Ул икеле-микеле җавап бирде:

– Әти-әни аңа бик каршы, – диде һәм нидер әйтеп бетермичә туктап калды.

– Әти-әнинең ризалыгы, һичшиксез, кирәк, шунсыз ярамый, – дип куйды Баурих. – Туганлык җепләрен ныгытырга кирәк. – Ул, маңгай астыннан гына үгез кебек караган килеш, рюмкасын бушатып куйды. Әмма үзе эчкән саен айный бара кебек иде. Ә Радикның башына китте, ул аяк-кулын тоймый башлады. Үз ихтыяры беткән, ни әйтсәләр, шуны кабул күреп, бүтән кеше аны теләсә нишләтә алырлык хәлгә төшкән иде.

– Синең әти-әниең намуслы булып кылана, – дип сөйләнде Баурих. – Шулаймы?

– Әйе, шулай, – диде Радик. Ул хәзер Баурихның һәр сүзен җөпләп, шуңа нык ышанып утырырлык халәттә иде. Тулысы белән үзен сыйлаган кеше иркендә. Ул ни әйтсә, шул хак. Ул ни боерса, Радик шуны башкарырга әзер кебек иде.

– Намус – ул аяк чала торган сыйфат, әйе бит?! Эшкә зыян китерә, кешене бәхетсез итә. Әйе бит? Менә синдә дә әзрәк намус дигән нәрсә бар әле, шул сиңа киртә булырга мөмкин. Ә без сине зур начальник итеп куймакчы булабыз. Аңлыйсыңмы? Әгәр безнең сүзне үтәп торсаң...

– Үтим, Баурих әфәнде, үтим! – диде Радик. – Нәрсә үтәргә боерасыз?..

Баурих ашыкмый гына аңлатырга тотынды:

– Ингага өйләнергә әниеңнең ризалыгын ал. Ничек итепме? Менә кайтып керәсең дә, синең арканда Инга мине читләштерде, үз янына яткырмый. Әгәр бозылсам, әни, үзең гаепле буласың, диген. Мине бозылудан йә үзең сакла, йә Инга белән килеш, әни, диген. Инга мине читләштермәсен. Әниең, юк, юк, дип әйтсә, үзенә ябыш, йә Инга, йә син үзең ят, башкача чыдый алмыйм, диген... Йә, төшендеңме?

– Барып җитмәде әле, – диде Радик, авызына кабымлык каба-каба. Бу сүзләрне ишеткәч, ул айнып киткән кебек булды. Колакларым дөрес ишетмиме әллә дип каушый калды.

Баурих нидер сизенде һәм һавага чыгарга тәкъдим итте.

Тышта караңгы, тыгыз җил исә иде. Урамның җилсез, ышык ягына чыга башладылар. Баурих Радикны култыклап алды һәм колагына тукыды да тукыды:

– Инганы үзеңнеке итәсең киләме? – дип сорады.

– Килә, – диде Радик, сөенеп.

– Мин бит шуның чарасын өйрәтәм сиңа... – Баурих бая сөйләгән сүзләрен

тәфсилләп тәкрарлады. Һәр детальгә аерым тукталды, аңлатты. Радик башкарасы һәр эшне шәрехләп бирде: – Шулай итсәң, әниеңә ризалашырга ансатрак булачак. Нәрсәсе кыен моның?

Радик һаман икеләнебрәк бара иде әле.

Баурих исә кызган тимерне чүкүен белде:

– Әгәр шуны эшләмәсәң, сиңа Инга юк! – диде. – Белдеңме? Аңа кызыгучылар күп. Алар – фабрикантлар. Әгәр мин әйткәннәрне үтәмисең икән, сине начальник итеп күтәреп булмый һәм квартирадан да коры калачаксың... Ну?

– Белмим шул, – диде Радик, аның тавышы икеләнүле, карусыз иде.

Баурих тагын да ныграк үгетләргә тотынды:

– Егетме син, әллә каз тизәгеме? – диде. – Беләм, сиңа намусың комачау итә. Ул барьерны атлап үтәргә кирәк. Шунсыз уңыш килмәячәк. Намусыңны таптап уздыңмы, үзеңә дә иркен, рәхәт булып китәчәк. Әйе, әйе, мин ул мәктәпне үттем. Хәзер үземне иркен хис итәм, чөнки мин теләсә нинди эшне уйламый башкарам. Зур эшләргә тәвәккәлләп тотынам, башкарып та чыгам. Эчтән мине берни тотмый, берни комачауламый. Син намус барьерын гына атлап уз, ничек әйбәт булуын үзең дә сизәрсең. Иртәме, соңмы, сиңа ул барьер аша үтәргә туры киләчәк. Ә хәзер иң уңайлы момент. Шунсыз без, немецлар, кешеләрне чын кадр дип санамыйбыз һәм аңа җаваплы эшләр йөкли алмыйбыз. Шуны үтә! Безне тыңламасаң, синең гаепләрең җитәрлек, без аларны теркәп барабыз һәм кирәк чакта чыгарабыз. Шунда сине ни көткәнен беләсең булыр: гестапо! Гестапога бер эләктеңме, гаебең исбат ителмәсә дә, ул сине ычкындырмый. Ә синең гаепләр ярылып ята, барысы да теркәлгән...

Алар Радиклар яши торган йортка килеп җитте. Өскә карадылар, ике бүлмәдә ут яна иде әле. Димәк, йокларга ятмаганнар әле. Радик нишләргә белмәде. Баурих аны ныклап тоткан, колагына, гипнозчы кебек, һаман шул бер нәрсәне тукыды. Чынлап та Радик аның гипнозлавын тойган сыман булды. Каршы торырга ихтыяры да юк һәм гөнаһлары аны арттан кыйный, «буйсын, буйсын», дип кычкыра шикелле тоелды. Әйе, гөнаһлары бар шул, ә гөнаһларның икенче гөнаһ эшләргә этәрүе дә билгеле нәрсә. Радик шуңа каршы торырлык көч таба алмый иде.

– Бар! – диде Баурих, катгый итеп, үзе караңгыга кереп югалды.

Радик иркен сулыш алды. Баскыч күтәрмәсенә аягын куйды. Бер-ике атлады да туктады. Ул шактый айныган иде. Нишләргә? Баурих кушканнарны ничек үтәргә? Әгәр үтәмәсәң? Ә ул барыбер беләчәк һәм җәза бирәчәк. Җәзасы шул: сине урам бандитларыннан кыйнату. Бандитлар да Баурих кулында. Ул аларны азык-төлек белән тәэмин итеп тора. Моны Радик сизде инде. Бервакыт идарәдә эшли торган хезмәткәрнең күңеленә әз генә коткы салырга кушты Баурих. Тегенең колагына «Гитлерга кораллы һөҗүм булган!» дип пышылдарга һәм бу хәбәрнең аңа ничек тәэсир иткәнен күзәтергә боерды. Радик нәкъ агент кушканча эшләде. Ләкин хезмәткәр бик тыныч, йомшак тавыш белән:

– Ташла, коткы салып йөрмә монда! – диде һәм «номерың барып чыкмады», дип елмаеп торды.

Моны Баурих бурычны үти алмаганга санады, Радикны нык кына шелтәләде.

– Син безгә эшләргә теләмисең, – дип янады. Ә беркөнне эш соңрак тәмамланды. Караңгы төшкән иде. Кайтып барганда, Радикның каршысына ике әзмәвер килеп чыкты да, тәмәке сораган булып, берсе кинәт аның иягенә китереп сукты. Радик чалкан барып төшкәч, икенчесе касыгына, бавырына күн итек белән типкәләде. Бу һөҗүм, әлбәттә, турыдан-туры Баурих тарафыннан оештырылган иде.

Подъездда шулай бераз уйланып торгач, Радик тәмам айныды. Күңеленә әти-әнисе хакында кызганыч уйлар да килеп китте. Ләкин шунда ук Инганы өйгә кертмәгәне өчен әнисенә ачуы да кузгалды. Шулай да бу ачу Баурих кушканны үтәргә җитәрлек аяусызлык бирми иде. Шунлыктан Радик чигенде, ишек төбеннән авыр гына кузгалып, үзләре яшәгән өйгә таба атлады.

Инга аны бик нык ачуланып, кара коелып каршылады. Ашарга да әзерләмәгән иде. Инга да Баурих кулында икән, дигән уй Радикның миен бораулады. Әйе, ялгышмый, Инга Баурих күрсәтмәсен үти. Радик бик яхшы белә: һәр хатын-кыз аерым агентлар тарафыннан ялланган. Эштә һәр кеше агентура челтәре белән уратып алынган. Ә Баурих шул агентлардан килә торган җепләрне үз кулында тота. Бу бәхәссез иде. Ләкин нишли аласың? Ятьмәгә эләккән балык нишли ала соң?

Бурычны үтәмәгән өчен, җәза озак көттермәде. Ә аны үтәмәгәнне Баурих каян белә соң? Монысы табышмак иде. Әллә инде тыңлау аппаратлары куйганнармы? Шундый аппаратларны Япониядән күпләп китергәннәр дигәннәрен Радик ишетеп тә калган иде. Нүжәли тыңлап тордылар икән? Радикларның күршесендә, юка гына стена аша, латышлар яши иде. Әллә шуларны яллады микән Баурих? Ә нигә гаҗәпләнергә? Немец төгәллегенә сокланырга гына кала. Болар җиңәр, ахры. Шундый төгәл көйләнгән, төгәл эшли торган «механизм». Бу «механизм» дәүләтне бик көчле итә, бернинди көч тә ала алмаслык крепость итә...

Инга эндәшмәде, янына баргач, этеп үк җибәрде. Озын халатын җилфердәтеп, әйберләрен җыеп йөрде. Мендәр, юрганнарын алып, икенче бүлмәгә чыгып китте, ишекне шартлатып бикләп куйды. Радик ишек катына килде, Ингага ялынды. Гаеп миндә, дуслашыйк, диде. Тегесе ләм-мим эндәшмәде. Башка вакытта да ачуы килсә, сөйләшмәве белән үч ала иде ул.

Радик ялынды-ялынды да, үз бүлмәсенә кереп, диванга ауды. Ингага да ачуы килмәде, хәер, аңа ачулана да алмый иде ул. Менә шундый йомшаклык, бала-чагалык, хет тәгәрәпләр ела. Радик үзенең бу сыйфатын кимчелеккә саный, шуңа үртәлә, гарьләнә иде. «Ә бит әнигә кырыс була беләм, ник, алайса, башка хатын-кызлар каршында сыер тизәге кебек йомшак соң мин? Нәрсәдән килә бу бәхетсезлек? Әллә бик яшьли хатын-кыз татыганнанмы? Нилектән мин хатын-кыз колы булып киттем? Юкса әнине кыерсытырга, рәнҗетергә бер дә кыенсынмадым. Аяусызлыгым җитте, ә башка хатын-кызлар алдында эрим дә төшәм. Чүпрәк, чүпрәк! Менә мин кем!» – дип, үзен тирги дә иде.

Үзе әйтмешли, ул хәзер тулысынча курчакка әйләнеп бара. Аның белән теләсә ничек уйныйлар. Шуңа эчтән генә үз-үзен ачулана иде ул.

Инганың аны читкә тибәрүе авыр сынау булды. Ул аңардан башка яши алмый икән бит. Менә бер тәүлек кенә аерым торды, ә күңелендә күпме киеренкелек барлыкка килде. Аның өчен Инга икенче шәхескә әйләнгән ләбаса. Шайтан алгыры! Әллә шунлыктанмы, үз әнисен күралмый башлады. Ул бит аны хөрмәт итәргә тиеш. Инга аны үз анасының дошманына әйләндерде. Нишләп ул әйләндерсен? Ахмак! Юк, Инга аңардан көчлерәк кенә, бар хикмәт шунда гына. Нәкъ шул көч Радик белән идарә итә дә...

Баурих аны бүген, эшеннән бүлеп, үз идарәсенә алып китте. Билгеле, начальниклардан сорап, килешеп эшләде ул бу эшен. Немецлар дисциплина ярата. Зур начальниклар кечкенәләре белән нык санлаша, үзләренең хакларын сиздерми иде.

Гадәттәгечә, Баурих ягымлы бер абый кебек иде. Башта ул сине гел мактап

кына тора, хәлеңә керә. Хуплый, һәр гозереңне үтәргә вәгъдә бирә. Анысы безнең кулда, без аны эшлибез, борчылма, дип юата. Һәм шулай ягымлы гына әңгәмә корганда, кинәт кенә үзгәрә дә куя. Бүген дә нәкъ шулай булды.

– Теге көнне ник бурычыңны үтәмәдең, ә? – дип, кырыс тавыш белән сүз катты ул. Тавышы әллә нинди шыксыз, җанга курку сала торган иде.

– Юк, нәкъ сез өйрәткәнчә эшләдем, – диде Радик. Ләкин тавышы шактый ук ышанычсыз иде.

– Әле син мине алдамакчы да буласыңмы? – дип кычкырды Баурих һәм бик кырку рәвештә учы белән өстәлгә китереп сукты. – Көчек, мин, кирәксә, икенче төрле ысул да куллана белермен. Кадерләгәнне аңламасаң... Без сине югары бәялибез, синә зур өметләр баглыйбыз. Шуңа күрә син әти-әниең пропагандасына бирелмә, без барыбер җиңәчәкбез. Йә, әйт әле, алар безнең яклымы, түгелме? Йә, нигә шиндең?

– Белмим, кем яклыдыр, – дип, көчкә телен әйләндереп сүзен әйтә алды Радик.

– Беләсең, сукин сын, яшерәсең генә, – дип акырды Баурих. Ачудан аның аскы ирене салынып төште, селәгәе ага башлады. – Алар безнең яклы түгел бит! Мин бары тик төгәл фактларны гына кабул итәм!

– Төгәл белмим, бүген болай, иртәгә тегеләй...

– Койрык болгама, миннән котыла алмассың. Дөресен әйтмичә торып, мин сине ычкындырмыйм. Безнең яклы түгел бит, йә, әйт!

– Түгелдер, ахрысы, – диде Радик, еш-еш сулап.

– Менә бит ничек! – дип, тавышын йомшартты Баурих. – Шушы факт та аларны гестапога тапшырырга җитә.

– Юк, юк, мин берни белмим, – диде Радик, каушаудан еламсыраган тавыш белән.

– Син таныдың инде, безгә шул да җитә. Ә башкасы...

– Конкрет берни әйтмәдем...

– Хәзер чигенү юк, авызыңнан чыккан һәр сүз өчен син җавап бирәсең. Бетте...

– Группенфюрер, сез мине гафу итегез?! – диде Радик, түбәнчелекле-гозерле тавыш белән.

– Менә монысы бүтән мәсьәлә, – дип, Баурих йөзенә әз генә миһербанлылык чалымы чыгарды. – Димәк, без уртак тел таба алабыз. Шулай түгелме?

– Шулай, шулай...

– Бу миңа ошый һәм сиңа булган ышанычымны бетерми. Нигә өченчекөн партизаннар аулау рейдыннан баш тарттың? Начальнигың жалоба бирде. Мин аңардан бу хакта югарыга җиткермәвен үтендем. Син миңа моның өчен дә бурычлы, ишетәсеңме? Әти-әниеңнең исән-имин торуы өчен дә бурычлысың. Мин сиңа Инганы табып бирдем. Минем егетләр таныштырды аны синең белән... Моның өчен дә син миңа тиешле... Инга бик әйбәт кыз, ул сине бәхетле итте. Ә бәхет өчен түләргә кирәк. Дөньяда бернәрсә дә түләүсез булмый. Ә син түләргә теләмисең.

– Группенфюрер, мин түләргә әзер... – диде Радик.

– Алайса, әйдә, казинога киттек...

Бу юлы да Баурих сыйлады. Үзе исә туктаусыз үгетләвен белде:

– Әллә син, безнекеләрнең Мәскәү янында чигенгәнен ишетеп, немецлардан суындыңмы? – дия-дия тукыды Баурих. – Барысы да пүчтәк. Менә җәй генә җитсен, тагын зур һөҗүмнәр башланачак. Шунда инде немец

үзенең көчен бар Европага күрсәтәчәк. Вакыт безнең файдага эшли, безгә! Вакыт кемгә эшли, фәкать шул җиңә... Ә син нигә кыюсыз, ә? Немецлар сиңа мөмкинлек бирә, файдаланып кал. Һәрвакыт алай булмас. Форсатны кулдан ычкындырма. Ситуация шундый, икеләнеп торма, сук та ал, сук та ал! Син нәрсә, уңышка ирешүнең принцибын белмисеңме? Мин синең кебек чакта бернидән дә тайчанмадым. Менә хәзер нинди зур урында эшлим, үзең күреп торасың. Ә ахмак солдатлар анда башларын сала, мин рәхәтләнеп яшим. Бар нәрсә үз кулымда. Менә шул ул уңыш. Властьлар алдында ышаныч казану. Власть ышанычлы кадрларга барча байлыкны бирә. Минем сине дә шундый кадр итеп тәрбиялисем килә. Төшенәсеңме, мин синең өчен тырышам. Моны бәяләмәү синең тарафтан әхлаксызлык. Кара, минем ачуны китермә, юкса начар булуы бар. Дуслар булып калыйк, бер-беребезгә кирәгебез чыгар...

Баурихның өне каты иде, һәр сүзе Радикның йөрәгенә барып кадалгандай булды. Бары эчемлекнең канны кайнарлатуы һәм, баш миен томалап, дөньяны җиңел һәм әйбәт итеп күрсәтүе генә аны газаптан коткара иде шикелле. Ул инде хәмер бирә торган ясалма рәхәтлеккә күнегеп тә бара иде. Башы алга китеп уйлый алмый, ярты юлда туктап кала. Эчемлек рәхәтенә Инга бирә торган рәхәтлек тә кушылгач, дөньясы гел түгәрәкләнеп китә. Ул шулар өчен генә яши кебек тоела башлый. Радик азык-төлек өчен кайгырмый, кием-салым да проблема түгел. Инга барысын да таба. «Мин сине үлеп яратам!» ди ул, ачылып киткән вакытларында. Һәм моның буш сүзләр генә булмавын үзе тоеп тора Радик. Җирдә адәм баласына «ярату» дигән бөек шатлык бирелгән. Нигә ул шатлык кәсәсен азагына чаклы эчеп яшәмәскә? Гомер бит үлчәп кенә бирелгән, ә шатлык касәсе һаман тулып тора, табигать үзе шулай яраткан. Нигә без табигать үзе кушканны үтәмәскә тиеш әле? Дөресе шул, табигать биргән шатлык касәсеннән туйганчы эчеп, кинәнеп калырга кирәк...

Бүген Баурих кушканны үтәми калу мөмкин булмавын чамалап, Радик күбрәк эчте, катырак исерергә тырышты. Исерек килеш һәр эшне ансатрак эшләп була. Эчемлек оятны качыра, башка һәм кулларга кыюлык бирә...

Баурих бу юлы аны өенә озата бармады. Ишек төбендә көтеп торган машинасын кабызды да китеп барды. Аның кыяфәтендә бар эшне төгәл, җиренә җиткереп башкара алу горурлыгы сизелерлек дәрәҗәдә иде. Радик аңа сокланып карап калды.

Соң иде инде. Шулай да әти-әнисе әле йокларга ятмаган иде. Радик үз ачкычы белән ишекне ачып керүгә, әнисе, шатлыгыннан нишләргә белмичә, аның алдына килеп басты. Өс киемен, кулыннан алып, чөйгә элеп куйды. Радикка сүз кушты, хәлен сорашты. Ә ул эндәшмәде, авыз эченнән нәрсәдер лыгырдады, ияк какты. Тагын да исерә төшкән кебек булды, бер сүзне икенчесенә ялгый алмый торды. Радик бу юлы эшне тиз тотарга ниятләде. Әшәкелекне тизрәк эшләп котыласы килде. Ул әнисен, кулыннан тотып, бүлмәсенә алып керде, муеныннан кочаклап, диванга егып салмакчы булды. Үзе бертуктаусыз сөйләнде: «Менә син миңа, Ингага өйләнмә, дисең, Инганы кабул итмисең икән, әйдә, хәзер үзең Инга ролен үтә! Ят! Ят!» – дия-дия, әнисенең юбкасын өскә сыдыра башлады. Әнисе, шунда гына исенә килеп, улын этеп җибәрде. Радик тагын килеп ябышты, әнисе кычкырырга тотынды. Тавышка Андрей килеп керде, Радикны әнисеннән кубарып алмакчы булды. Радик аңа тибеп җибәрде. Шулай да Андрей, бар көчен туплап, улын идәнгә егып салды. Кларага китәргә кушты. Радикның торып басарга дәрманы җитмәде, йөзтүбән капланып яткан килеш тынып калды. Андрей да үз бүлмәсенә, Клара

янына кереп, ишекне эчтән бикләп куйды. Ул хатынына күтәрелеп карарга уңайсызлана. Клара исә үксеп-үксеп елый иде. Аның елавында язмышына рәнжү, иренә үпкәләү, улын каһәрләү чалымнарын күрми мөмкин түгел иде...

Шактый вакыт үткәч, ишек ачылды һәм Инганың тавышы ишетелде. Ул идәндә йоклап яткан Радикны уятырга тотынды. Инга кечкенә «Бенц» машинасы юнәткән иде. Шуның белән килгән икән. Шактый матавыклана торгач, ул Радикны торгызды, киендереп тә тормыйча, алып чыгып китте.

Баурих күрше квартиралларга шымчылар куеп чыккан иде. Ә янәшәдәге бүлмәдә үзе тыңлау аппараты белән утырды. Барысы ачык ишетелеп торды, ни сөйләшкәннәрен лентага да язып алды.

Мәкерле Баурих бу гамәле белән берничә максатына иреште. Беренчедән, ул Радикны намус барьерын үтәр өчен чирканчык алдырды. Егет хәзер оялып тормаячак. Икенчедән, Радикның әнисе белән әлегә кадәр яшәп килгән кан берлеген, туганлык җепләрен өзүгә иреште, немец органнарына ялланудан баш тарткан, ирен сатарга теләмәгән өчен, үч тә алды. Ана кешене әхлакый яктан тәмам җимерде, шулай ук Радикның моңарчы җанында көйрәп торган әхлагын бөтенләй бетерде. Хәзер ана белән бала арасында бернинди сер дә яшеренеп ята алмый, чөнки аларда бер-берсенә ышанмау хисе туды. Кешеләр бер-берсенә ышанмый башлый икән, димәк, алар дәүләт өчен куркыныч түгел. Ышанмау әнә шундый тормыш вак-төякләре аша барлыкка китерелә. Әхлак киртәләрен җимерү өчен, теләсә нинди чаралар да кулай. Әхлак тәмам җимерелеп беткәч, кешеләр битлек киеп яши башлый. Бер-береңә ышанмау битлек кияргә мәҗбүр итә. Телисеңме-теләмисеңме, битлек саклану чарасы булып та тора. Өченчедән, Баурих ата белән баланы да дошманлаштырды. Андрей хәзер ир-ат буларак та үз баласын күралмаска тиеш иде.

Әмма Радик үзе кылган явызлыгының астарын аңлаудан ерак тора иде. Бурыч үтәлдеме, ул шуңа канәгать иде. Баурих аңа башка бәйләнмәсен генә. Ул аңа ни өчен шундый әшәке бурыч йөкләгән, Радик аны уйлап, нәтиҗә ясарлык хәлдә түгел иде. Ул, гомумән, болай да ваемсыз адәм иде. Шуңа күрә немецларга да бик тиз бирелде, аларның ялганына, вәгъдәләренә ышанды.

Немецларның эчке органнары Латвия җирендәге һәр гаиләгә үтеп керү максатын куйды. Бу максатка ирешүдә иң үтемле корал, әлбәттә, куркыту иде. Куркытып, адәм баласын теләсә нинди явызлыклар кылырга мәҗбүр итеп була.

Мәсәлән, куркытып яки алтын таулары вәгъдә итеп, яшь егетне әтисе өстеннән шымчылык итәргә күндерәләр. Шиклерәк, ышанычсызрак кешенең хатынын шундый ук юл белән ире өстеннән күзәтчелек иттерәләр. Билгеле, бу максат өчен органнар чыгымнарга да бара. Әйтик, әтисе өстеннән шымчылык иткән яшь кешенең ихтыяҗларын канәгатьләндерәләр. Әгәр яшь егеткә кыз-кыркын кирәк икән, бернинди мәшәкать тудырмыйча гына, аны табып бирәләр. Алар өчен кыска сроклы ял йортлары бар, икесен бергә шунда җибәрәләр. Өйләнгән адәм булса да, мондый бүләкне аңа бик оста оештыралар, хатыны берни белми дә кала. Шулай ук ире өстеннән шымчылык иткән хатынның да кайбер хаҗәтләре үтәлә. Аңа аерым кибеттән дефицит кием-салып җибәрелә, продуктлар бирелә. Әгәр инде чит ир белән йөрергә тели икән, иренә сиздермичә генә бу эш тә оештырыла.

Немец властьлары гаиләләрне эчтән җимерү эшен әнә шулай җайга сала иде. Алар үз илләрендә дә нәкъ шулай эшләгән һәм бирердә дә әлеге сыналган механизмны файдалана иде. Шунсыз ныклы дәүләт төзеп булмый.

### XIII

Андрейны эштән чыгардылар. Кыйнап, мыскыл итеп кудылар. Моңа гаҗәпләнеп тә булмый, чөнки немецлар теләсә кемне теләсә нишләтә ала. Теләсә, урамда барган җиреннән бер исерек немец сине ата да үтерә. Беркем берни эшли алмый. Андрей исән калуына сөенде һәм моннан ары немецлардан ераграк торырга карар итте.

Шул кичне Зорис килеп чыккан иде. Андрей аңа бигүк ышанмаса да, араны өзеп тә бетерми иде. Бу юлы Зорис үзе ярдәм сорап килгән булып чыкты. Эш шунда, немецлар латышларны, русларга каршы сугышу өчен, фронтка ала башлаган, ди. Зорисны да алулары ихтимал, яше буенча да туры килә икән. Качарга урын эзли. Бер шешә көмешкә алып килгән. Андрей аның бу сүзенә дә ышанып җитмәде, үзен сынар өчен генә әйтәдер дигән фикергә килде. Тәбәнәк буйлы, зур башлы бу кешенең чын йөзен бервакытта да күреп булмый иде.

– Нишләп сыеныр җир эзләп үз милләттәшләреңә бармыйсың, ә үзегез яратып бетермәгән рус катына киләсең? – дип, Андрей аның ялганын фаш итәргә теләде.

– Хикмәт милләттә түгел, кешенең кемлегендә, – диде Зорис, бу сорауны көтеп кенә торгандай. – Латышлар әнә мөстәкыйль ил дигән булып ахмакланып йөри. Миңа да син Латвиянең патриоты түгел, дип бәйләнделәр. Армиягә алырга телиләр. Мин нишләп русларга каршы сугышыйм? Башым ике түгел лә. Әмма дураклар бар, хуторлардан яшьләрне җыеп китергәннәр. Полк төзегәннәр. Бераз өйрәтәчәкләр дә партизаннарга каршы файдаланачаклар. Латышларның хәле русларныкыннан да яманрак. Без, латышлар, сандал белән чүкеч арасында. Элек тә шулай иде, хәзер дә. Гомер бакый икеле-микеле хәлдә яшибез без. Сезгә әйбәт, сез – бөек һәм зур милләт. Иң шәбе – зур милләт булу. Зур милләт түгел икәнсең, бөтенләй булма, эч пошырып йөрмә.

– Кече милләтләрнең дә яшәргә хокукы бар...

– Вак балыкны эре балык ашый инде, хет әллә нинди хокукларың булсын. Табигать законы. Аңа каршы тору – нәтиҗәсез эш!

– Нигә үз милләтеңне алай тиз күмәсең әле?

– Йә ул үзен саклый ала торган булсын, йә бөтенләй юк булсын. Әйе, милли хис бездә дә бар. Әгәр ул хисеңне белгертсәң, сине шундук милләтче дип гаепләячәкләр. Кырыгынчы елның кышында әнә күпме кешене шуның өчен Себергә озаттылар. Бер гаепсезгә. Милли хискә бервакытта да хокук бирелми. Юк. Бер генә стройда да. Мин шулай уйлыйм. Чөнки бер генә рус әйтсенче, латыш милләте яки башка милләт яшәсен, без аларга тимик, дип. Юк, берсенең дә авызыннан чыкмый.

– Менә мин әйтәм, – диде Андрей. – Латыш һәм башка аз санлы милләтләр яшәсен, аларны ассимиляцияләргә кирәкми, дим.

– Син Латвиядә булганга күрә һәм көмешкә кызуыннан гына шулай сайрыйсың. Ә эчеңдә шовинист утыра. Билгеле, бар хикмәт дәүләт башлыкларында. Алар бар нәрсәне унификацияли, шул исәптән милләтләрне дә.

– Мин шовинист түгел, ялгышасың, – дип куйды Андрей.

– Хәзер шулай... Ну хикмәт бүтәндә. Менә немец килде, безне җәзалый, үз милләтчеләребез җәзалый, руслар килгәч, алар да шуны ук эшләячәк. Кече милләтнең хәле, әйтәм бит, бик мөшкел. Кече милләт булганчы, булмаганың артык...

– Гасырлар буе латышлар үз милләтләрен саклап көрәшкән, бер төбәккә берләшкән, ул яшәргә тиеш, – диде Андрей.

– Әйтик, аз санлы руслашып бетте ди. Шуннан нәрсә? Шул бәхет китерерме? Юк, минемчә. Бердәмлек кирәк нәрсә, әлбәттә. Ләкин бердәмлек проблемаларны хәл итмәячәк. Бердәмлек сугышлар заманы өчен файдалы. Барлык вак милләтләрне бер йодрыкка туплау өчен. Әмма сугыш заманы бервакыт үтәр бит.

– Бик еракка киттең, әйдә, бүгенге көнгә кайтыйк, – дип, Андрей сүзне икенчегә борды. – Нигә частный практика ачмыйсың?

– Ә-ә, теге көнне мин уйламыйча сөйләнгәнмен, – диде Зорис, кашларын җыерып. Калын кашлары киң маңгаенда бергә килеп кушылды да күбәләк кортына охшап китте. – Частный практика өчен, кызыллар килгәч, беләсеңме, нишләтәчәкләр?! Мин шуны уйладым. Юк, бәласеннән башаяк! – Зорис стаканына көмешкә агызды да эчеп тә куйды. Ул бик нык нервланган иде. Нигә икән? Ул да миннән шикләнә, ахрысы, дип уйлап куйды Андрей. Шуңа бик нык киеренкелек кичергән, күрәсең. Әйе, ул артыграк ачылып киткәнен хәзер генә аңлап алды, шуңа борчыла, гасабилана иде шикелле. Шикләнүе дә бигүк урынсыз түгел, ник дисәң, Клара немецча белә һәм ярыйсы гына эштә эшли.

Бу Зорис үзе бик иҗтиһатлы күренә, әнә бит бөтенесен дә исәпкә алып хәрәкәт итә. Башта немецларга ышанган булып сөйләнгән иде, хәзер бөтенләй башкача сайрый. Алга карап уй йөртә белә. Ачы тәҗрибә өйрәткән, күрәсең. Немецларның биредә калуына да ышанмый. Инде хәзердән кызыллар киләчәген сизенеп өлгергән. Адәм баласының яшәүчәнлегенә исең-акылың китәр. Тукта, кызыллар мәсьәләсендә ул Андрейны үз ягына авыштырып, аның карашын белеп, төп башына утыртмасын тагын. Кеше заты бик тиз сатыла, гаҗәпкә калырсың. Барча устав, кагыйдәләрдә, кешеләр арасында сатылу дигән нәрсә, билгеле, хөкем ителә, зур җинаять санала. Һәр кеше моны аңлый, сатылуны түбәнлек дип бәяли. Әмма кискен хәлләрдә үзе сатыла яки сата. Дөньяда сатмый һәм сатылмый торган бер генә кеше дә юк. Була да алмый.

Алар, сөйләшә-сөйләшә, кешеләр һәм политика белән бәйләнмәгән берәр эш табарга дигән фикергә килде. Немецларга эшләсәң, кызыллар килгәч, барысын да исәпкә алачак, аннан инде яхшылык көтмә.

Зорис, көндезләрен яшеренеп ятарга урын кирәк, диде. Андрей, күп уйлап тормастан, өй хуҗасының бер караңгы бүлмәсе барлыгын әйтте.

– Мин немецларга тоттырмыйм анысы, әмма үзебезнекеләрдән котылырмын димә! Немецка ярар өчен, бер тиен урынына саталар, валлаһи!

– Фәкать үзеңнекеләр генә сата, дип, французлар юкка гына әйтмәгән инде.

– Башкалардан ычкынсаң да, үзеңнекеләрдән ычкына алмыйсың, шайтан алгыры!

– Элек-электән кеше тормышы шулай корылган. Кешене иң якыннары гына саткан...

Икенче көнне, эңгер-меңгер вакытта ук торып, алар шәһәрдән унбиш чакрым ераклыктагы бер күлгә балык тотарга барды. Күл туңмаган, ике көймәдә икәүләп озын сөрәкә белән маташырга мөмкин иде. Күл буенда бер генә рәт булып, берничә йортлы авыл утыра иде. Шунда сөрәкә алып торырга дип берәүгә сугылганнар иде, сакалы нәкъ керпе кебек энәләнеп торган латыш, немецлар өч коммунистны, атып үтереп, суга ташлады, дип әйтте. Андрей белән Зорис бер-берсенә карашып алды. Бу «керпе» сөйләгәннәр чынга да охшый, әмма балыкны читкә ычкындырмас өчен, шушындый нәрсә уйлап чыгаруы да мөмкин иде. Ләкин тәвәккәлләргә базмадылар. Балыклар шул адәмнәр белән тукланадыр дигән фикер барыбер тайчандыра иде.

Шулай итеп, балык каптыру нияте дә барып чыкмады.

Зорис алтын-көмеш сатып алучы тапкан. «Бывший»лардан, ахрысы. Ул аларны онга алыштыра икән. Ригага Америкадан он килгән. Шуны Митавага да китерәләр. Ипи заводын эшләтә башладылар. Эшләүчеләргә дүрт йөз грамм ипи бирәләр. Башта Америкадан он килгәнгә Андрей ышанмады. Ничек инде, Кушма Штатлар русларның союзнигы лабаса! Әмма капиталистлар үзләре мөстәкыйль сату итә икән. Океан арты капиталистына нәрсә, бары товары гына үтсен. Кемгә сатуында – дускамы, дошмангамы – аның эше юк. Германия эшкуарлары, баксаң, икмәкне Кушма Штатлардан алып ята икән. Зорис шуны Андрейга ышандырырлык итеп төшендерде.

Ничек, каян алтын-көмеш табарга? Алтын булса, он да була. Ачка үлмәскә мөмкин. Ләкин немецларга эшкә керергә ярамый.

Зорис көз көне үк Рига белән Митава арасында, урман эчендә, немецлар еврейларны җыеп аткан дип ишеткән иде. Кай тарафта икәнен дә төгәл белә. Митавадан утыз чакрымнар чамасы ераклыкта. Анда коры елга үзәне бар. Немецлар еврейларны шунда алып чыгып аткандыр. Зорисның андый чокырларны бер-ике төштә үз күзләре белән күргәне булды. Бәлки, шунда барып карарга дыр. Хәзер кыш, куркырлык түгел. Менә анда алтын-көмешле гәүдәләр бар да бар инде.

Бу эшкә Андрей башта күнмәде. Бер төнне Зорис үзе генә шул кәсепкә китте. Тәүлек дигәндә, бер уч алтын тешләр җыеп та кайтты. Зорис Андрейны кабат үгетләде, син мәетләргә кагылмассың, бары лом һәм кәйлә белән өстәге туң катламны гына чабарсың, дип, бәгырьгә төшәрдәй булып үтенгәч, ул баш тарта алмады.

Шушы кәсеп белән алар кышны уздырды. Ике-өч ай буе тук булуның нәтиҗәсе дә күренде. Мәетләрдән алынган алтын теш һәм башка бизәнү әйберләре хисабына алар ике капчык чиста он юнәтте. Бер караганда, монда гаҗәпләнерлек нәрсә юк иде. Чыннан да, мәетләр тереләргә ярдәм итә, гомер бирә. Берәү үлә, икенче берәү көн күрә. Шайтан алгыры, бу дөньяниләр генә күрсәтми адәм баласына!

Фашистлар мәетләрне тегендә, монда, фугаслы граната шартлатып, ярны иштереп кенә күмгәләгән. Кайберләре ачык килеш ята, алар кыш буе яуган яңгырлардан һәм туңдырып җибәрүләрдән тоташ боз булып каткан. Зорис андыйларның авызларын яссы лом белән каерып ача да кесә фонареның утын шунда юнәлтә. Әгәр казналарда алтын-көмеш җемелдәсә, озын саплы келәшчәсен эшкә җигә.

Алар, җылы вакытта партизаннар белән элемтәгә керергә кирәк дигән карарга килде. Ләкин колактан колакка төрле имеш-мимешләр ишетелсә дә, конкрет берни дә табып булмый. Зорис сакал үстереп, кара күзлек һәм икенче киемнәр киеп, еш кына шәһәр уртасындагы костёл янында оеша торган базарга йөри иде. Берничә кеше белән элемтә дә урнаштырды. Ләкин үтә дә сак булганга, ул аларга ышанмый иде. Андрей да Зориска күңелен ачып бетермәде. Хәер, аның күңелендә фашистларны кыралмаудан башка нәрсә юк югын. Тик ул Зорис алдында бу хисләрен белдерергә, немецларны сүгәргә курка иде. Үз чиратында Зориста да аңа карата шик бетмәгән икән. Беркөнне, алтын коронка биреп, бик шәп көмешкә алып кайткан иде, шуның белән юанып утырганда әйтә куйды:

– Мин дә сиңа ышанып бетмим, син дә миңа ышанып җитмисең, – диде.

Андрей, ни әйтергә белми аптырап, күзен тик тасрайтып торды. Зорис хак сүзләр әйтә бит. Әмма шул ышанмаучылыкны ничек бетерергә, барьерны ничек

үтәргә? Андрей шуны белми иде. Ә тот та менә ышана башла, дип, акылың белән үз-үзеңә боерык бирсәң дә, хисләр каршы төшә кебек иде. Әшәке дөнья, фашистлар адәм затына сулыш алыр урын калдырмады!..

Андрей эндәшмичә утыргач, Зорис, кыюланып:

– Нигә миңа ышанмыйсың? – дип сорап куйды.

– Юк, син нәрсә сөйлисең, Зорис? – диде Андрей, икейөзлеләнергә мәҗбүр булып. – Әгәр мин ышанмасам, сиңа ияреп эшләп йөрер идеммени?

– Мин латыш булгангадыр инде, – диде ул Андрей сүзләрен ишетмәгән кебек. – Чынлап та, тел бер, уй бер, ахрысы, ә? Тел барьеры барыбер кала бугай! Әйе, ихлас мөнәсәбәт, ышаныч өчен бөек корал шул.

Зорисның сүзләреннән Андрей тагын аптырап калды. Ник һаман җанга үтәргә тели соң бу дип шикләнде. Әмма инде кабат икейөзләнеп, үзенең аңа ышануын сүзләр белән исбат итәргә керешмәде.

– Ярар, әйтик, руслар латышларны ассимиляцияләп бетерде ди. Шуннан нәрсә? – дип, Зорис үзенең исерек һәм шунлыктан шукланып торган күзләрен Андрейга төбәде. – Милләт бетә, димәк, дөньяда латышлар булмаган да кебек килеп чыга. Тоташ руслар гына булган, имеш. Кем ышаныр моңа? Бер генә кече милләтнең дә эзсез югаласы килми. Ә заман эзсез югалырга куша.

– Кысыр хәсрәт белән авырыйсың, Зорис! – диде Андрей. – Латыш милләтен руслар бетерми, юк. Латышлар яшәячәк. Менә күрерсең.

– Милли хиссез милләт милләт түгел инде ул!

– Милли хис – начар, авыру хис, шулай бит?!

– Милли хис – яман нәрсә, беләм, ләкин ансыз да булмый. Менә шул хис бер-беребезгә ышанырга киртә булып тора да.

– Юк, монда милли хис киртә түгел, ә безнең характерлардагы үзенчәлек киртә булып тора. Синең дә, минем дә характер шикчел.

– Үз-үзенә ышанмаганнар шикчел була...

– Ахмаклар гына үз-үзләренә нык ышана! – диде Андрей һәм көлеп җибәрде.

Зорис та аңа кушылып авызын ерды. Аның җил каклаган көрән йөзендә һәм чигәсендә чатнаган пыяладагы сызыклардай җыерчыклар пәйда булды.

Икенче төнне Зорис бер кеше ияртеп кайтты. «Курыкма, бу – ышанычлы кеше», – дип, Андрей белән таныштырды. Бунаков фамилияле чын рус иде ул. Караңгы бүлмәдә пышылдап диярлек сөйләштеләр. Бераздан Зорис чыгып китте. Алар икесе генә калды. Андрей Мәскәү, Ленинград турында сорашты. Мәскәү яныннан немецларны 400 чакрымга куганнарын ул Клара аша ишеткән иде инде. Немец баш врачы Кларага бу хакта ничектер әйткән булган. Бунаков Ленинградның бик яман хәлдә икәнен сөйләде. Төрле яктан чолгап алынган, бик каты блокадага алынган, шулай да шәһәр бирешми икән. Халык бик нык ачтан кырыла, ди. Кыш көне Ладога күле аша юл салып, машиналар йөргән, бераз гына азык-төлек кертергә мөмкинлек туган. Ләкин хәзер хәл тагын аяныч икән. Калинин урманнарындагы партизаннар ярдәмгә килеп караган каравын. Әмма немец тылында каян ресурс юнәтәсең? Мәче күз яше инде.

Шактый сөйләшеп утырдылар. Бунаков, еш кына караңгы бүлмәгә килеп, көнне йоклап уздыра иде. Андрей аны чәйгә чакыра. Сөйләшәләр, киңәшәләр. Двинск урманнарында бик зур партизан отряды бар икән. Бу хакта Андрей шулай ук ишеткән иде. Ул отряд немецларга зур куркыныч тудыра, ди, әмма эзенә төшә алмыйлар икән. Ник дисәң, Латвия белән Россия чигендә куе урманнар белән капланган гаять тирән үзәннәр сузылып китә. Бик җайлы позиция. Немецлар якын килеп караган, ләкин нык кына кырылып, кире

чигенгән, ди. «Без хәзер партизаннарга шәһәрдән – кием-салым, хуторлардан азык-төлек җыярга боерык алдык... Кушылырсыз бит?» – дип сүзен тәмамлады Бунаков. Андрей җавап бирергә ашыкмады. Бары үзенең бу эшне хуплавын белгертеп елмайгандай итте.

Бунаков киткәч, ул аның хакында уйлана калды. Шикләрен Клара белән дә бүлеште. «Нишләптер ул немецларны бик каты сүгә, – диде Андрей, тегенең ялганын шәйләгән кебек булып. Клара да уйга калды: «Белмим, белмим, бу дөньяда башым берни уйлый алмый, – дип зарланды. – Нәрсә турында гына фикер йөртсәм дә, ялгыш булып чыга. Баш миенең ориентирлары тәмам сафтан чыгып бетте. Яңаларын торгызып булмый. Чөнки дөнья бүген болай, иртәгә тегеләй – үзгәреп кенә тора. Бар нәрсә дә вакытлы гына, бүген бар, иртәгә юк. Кеше гомере дә шулай – бүген бар, иртәгә юк. Кешенең эшләре дә вакытлы гына. Тотрыклы берни дә була алмый. Без үзебез дә тузганак кебек, көчлерәк җил иссә, тузып-чәчелеп бетәрбез төсле тоела.

Кларaның сүзләрендә ачы хакыйкать ярылып ята. Бүген бернигә, беркемгә ышанып булмый. Ләкин адәм баласы кемгә булса да ышанмыйча яши алмый бит. Андрей да үзенчә, Бунаковка ышанырга кирәк дип фикер йөртте. Шуннан җанына җиңелрәк булып китте. Җанга таяныч кирәк шул.

Төн урталарында аны Клара уятты һәм колагына:

– Немец баш врачы бик бәйләнә, нишләргә инде, ә? Әнә кичә күпме продукт биреп җибәрде. Бик уңайсыз миңа, Андрей, аңлыйсыңмы? Юк, син аңламыйсың... – дип пышылдады.

– Нәрсә дип бәйләнә?

– Белмәгән булып маташмасана! Ир-ат хатын-кызга ни өчен бәйләнә?

– Соң, үзең хәл ит...

– Ничек үзем генә? Мин бит үземнеке генә түгел, синеке дә!

– Андый эшне ирләргә әйтмичә генә эшлиләр түгелме соң?

– Кинаяң урынсыз! Мин сиңа әйтмичә генә булдыра алмыйм. Юк, вөҗүдем бармый, вөҗүдем протест белдерә! Нишләргә соң миңа? Берәр сүз әйт инде... – Клара лышык-лышык елый ук башлады.

– Нәрсә әйтим соң, нәрсә? – дип үртәлде Андрей.

– Син хәлемә керергә теләмисең, читләшәсең! – Клара сүзләрен, күз яшьләренә буылып, көчкә әйтте.

– Каршы килсәң, ул мине гестапога тапшырырга мөмкин. Менә нәрсә!

– Ни өчен тапшырсын соң ул сине гестапога?

– Әнә шуның өчен! Аларның законнары үзләре белән...

Клара тамак төбеннән чинауга охшаш аваз чыгарды. Андрейның бик каты ачуы килде. Немецларга гына түгел, Кларага да. Нәрсә инде бу? Балалары бар иде, аны тартып алдылар, үзен тәмам түбәнлеккә төшерделәр, инде хатынына үреләләр. Нишләргә? Нишли генә ала соң ул? Күңелен бары рәнҗү хисе били бара, җанында чиксез нәфрәт хисе генә бәргәләнә. Шул үч, кайтарып булмый торган үч, эчтә кайный, шәхесен изә. Син юк, син бер тиен дә тормыйсың, син кеше түгел, син бары бөҗәк хәлендә генә! Бөҗәк нәрсәгә генә каршы тора ала соң?! Андрей, күкрәгеннән мәче кебек эчтән тырнаган хисләренә чыдый алмыйча, авыр сулап куйды, үзе мыш-мыш килде. Ул Кларaны ачулана башлады:

– Нигә син моны миңа әйттең, ник әйттең? Ә?

– Ә кемгә әйтим тагын? Үзем булдыра алмагач... Минем сиңа хыянәт иткәнем булмады. Ә син миңа хыянәт иткәләдең. Әйе, әйе, танма! Теге зәңгәр күзле Мария белән...

– Миңа гөнаһ өйгәч, үзеңә дә гөнаһка керергә ансатрак булыр, шулаймы? Үзеңнең гөнаһ эшлисең килеп тора кебек.

– Ник син мине шулай рәнҗетәсең? Бүтән әмәл күрмим, шуңа күрә генә! Минем каршы килүем синең өскә дә гаеп булып төшүдән куркам мин!

– Әйе, анысын аңлыйм, аңлыйм, – диде Андрей.

– Мин бит тыштан гына шулай кыланам, ә күңелем белән ул хәшәрәтне берничек тә кабул итә алмыйм.

– Ярый ла «тышың» белән генә канәгатьләнсә... Хайваннарда да ярату инстинкты була, ди.

– Юк-юк, ул хакта сүз дә булуы мөмкин түгел!

– Ә ул сине үзенеке итә алса нишләрсең? Син миннән канәгать булмыйча, мине эгоист дип тирги идең. Әгәр миндә җитешмәгән нәрсә аңарда кирәгеннән артык булса?

– Юк, мине беркем дә үзенеке итә алмый инде. Бетте!

– Мин дә сине азаккача үземнеке итә алмадым шикелле, Клара.

– Нәрсәдән чыгып шулай әйтәсең? Минем тарафтан әллә салкынлык сиздеңме, назым җитмәдеме?

– Дөресен әйткәндә, назың булмады диярлек инде...

– Авызыңнан җил алсын! Сиңа һаман җитми иде. Назымның аз булуына үзең гаепле, үзең! Син назымны арттырырга үзең тырышырга тиеш идең. Син ялкау, бернинди дә тырышлык куярга теләмисең!

– Хатын-кызда наз булмаса, аңа беркем дә ярдәм итә алмыйдыр, мөгаен...

– Хатын-кыз көне-төне эштә, мәшәкатьтә, аңарда нинди наз калсын? Наз ул күбрәк ирләрдән тора.

– Ирләр дә эшли, алайга китсә... Наз хатын-кызга табигатьтән биреләдер инде ул.

– Бар нәрсәне табигатькә йөкләү җиңел лә! Теләсә кайсы бик назлы хатынны да авыр тормыш эт хәленә төшерә! Без кичергән авырлыкларны үзең дә яхшы беләсең ич. Рәхмәт әйтегез бездә аз булса да наз калганга!..

– Юк, туктале, нигә без тел әрәм итеп пүчтәк нәрсә турында сөйләшәбез соң әле? Үзебезнең хәл турында уйлашыйк. Син ул Бунаковка ышанасыңмы, Клара? – дип, Андрей сүзне күңелен чәнчеп, борчып торган нәрсәгә бормакчы булды.

– Немецларны яманлап, безне дә шуңа кушылырга этәрәдер кебек тәэсир калды миндә. Бу провокаторлар алымы түгелме соң?

– Сиңа да шулай тоелдымы? – диде Андрей, борчылып. – Кызык! Мин дә нәкъ шуңа игътибар иттем. Нүҗәли сатар икән?

– Нигә шаккаттың? Үз улың саткан чагында, бүтәннәр хакында ничек башкача уйлап булсын?

– Менә монысын дөрес әйттең. Әйе! Әй, Радик, Радик, җаныбыз кебек күргән балабыз идең! Ничек шундый хәлгә барып җиттең? Сиңа тормыш биргән, сине якты дөньяга китергән эти-әниеңне чын дошман итеп күрәсең. Моңа син үзең генә гаепле түгел, яхшы аңлыйбыз!.. Уф, ярар, җитәр, йөрәк ярасына тоз салу юньлегә булмас.

Андрей чалкан яткан җирдән шулай сөйләнде, аннары, кулын өметсез селтәп, авыр сулады да стенага таба борылып ятты. Клара аны күпме сүзгә тартса да, Андрейдан ләм-мим бер сүз ала алмады. Аның бәгыре, уе, вөҗүде тораташка әйләнгән иде шикелле.

## XIV

Күрше хутордан олау яллап, Андрейларны озату шактый мәшәкатьле булды. Олаучы бик куркып калган иде. Сугышның үзен әле беркемнең күргәне юк, әмма куркынычы бар кешеләрнең үзәгенә кереп өлгерде. Отто үзе дә ни уйларга белмәде. Нәрсә бу, вакытлы гына берәр провокация ише нәрсәме? Әллә бик җитди хәлме? Дошманны үз җирендә тукмарбыз, дип, газета саен эре-эре хәрефләр белән язалар иде. Германиянең Россиягә басып керүе һич тә күз алдына китерә торган нәрсә түгел иде. Безгә алар ничек карар? Үз нәселләре итепме, әллә кызылларга хезмәт иткән, кызыллык идеологиясе белән бозылган кешеләргә караган кебек карарлармы? Кызылларның җәберләвен кичергән немецлар итеп караулары да бар, чөнки үзләре үк, без сезне азат итәргә киләбез, дип игълан иттеләр. Кызыллар да 1940 елда, моннан нәкъ бер ел элек, без сезне азат итәбез, дип килгән иде. Килүгә, шактый гына кешене, кулга алып, Себергә озаттылар. Болары да, азат итәбез, дип килеп, шулай эшләрме? Азат итә-итә кеше җанын кыялар, тагын бер-ике «азат итү» булса, халык та калмаячак бит! Юк, немецлар алай эшләмәс. Алдынгы халык санала бит. Алайса, нигә үз илләрендә башкача фикер йөртүчеләрне төрмәләргә утыртып бетерделәр? Тельман бит хөкүмәт әгъзасы итеп халык тарафыннан сайланып куелган булган. Шул хөкүмәт әгъзасын яла ягып гаепләгәннәр һәм таш капчыкка утыртканнар. Яла якмыйча гына гаепли алмаганнар, ник дисәң, аның бернинди дә гаебе булмаган. Хөкүмәт башына килгән Гитлер үзе берни белән санлашып тормый, башкача уйлаучыларга каршы каты террор урнаштыра... Шулай булгач, безгә, биредә яшәүче немец гаиләләренә карата да алар, белмим, миһербанлык күрсәтер микән? Үз илендәге немецларны карашлары өчен эзәрлекләгәнне, төрмәләргә тутырганны, алар безгә ничек мәрхәмәтле булсын соң? Немецлар бар яһүдләрне яһүд булганы өчен генә җәзалый, ди. Нинди галәмәт инде бу? Немецларга шундый хокук бирелгәнмени? Ник алар үзләрен бар халыклардан өстен саный? Каян килеп чыккан әкәмәт бу? Моны ничек аңларга? Мин – немец, димәк, мин бүтән милләтләрдән өстен? Нәрсәсе белән өстен? Ни өчен өстен? Юк, баш та, йөрәк тә кабул итми моны. Коточкыч гаделсезлек бу. Ул гаделсезлеккә һәркем каршы булачак. Немецлар шуны әз генә дә аңламый микәнни?..

Отто үзләренең утарына кайтып җиткәндә, кояшның болыт астында кызарып байый барганы шәйләнә иде. Шулай да якты иде әле. Болында арканланган сыерны бозавы белән абзарга керткәннәр, чөнки хәлләр бик хәвефлегә әйләнде. Элек болында куна торган сыерны хәзер кеше күзеннән яшерергә кирәк. Сыерны гына түгел, бар нәрсәне яшерергә туры килә. Кызыллар килгәндә дә шундый яшерүләр булып алган иде. Баерак кешеләр кыйммәтле әйбер-караларын җиргә дә күмгәләде.

Оттоларның исә әллә ни яшерер нәрсәләре юк. Җирләре аз, Отто үзе заводта эшли, шәһәрдә яши. Биредә аның туганнары – карт белән карчык гомер итеп ята. Авыр эшкә ярамыйлар. Отто җирне үзе кечкенә трактор белән сөрә, чәчә. Үзе заводтан китә алмаса, кеше яллап та эшләтә иде. Бер сыер, ике-өч дуңгыз асрыйлар. Карт белән карчык шуларны карап тора. Әзер курмы бирәләр, ишегалдындагы чыгырлы коедан су чыгарып салалар.

– Рита китте бит, – дип каршы алды карт Оттоны. Ул өйалды ишеге төбендә нидер эшләп маташа иде. Отто аңа якынрак килде.

– Ул квартирагыз өчен бик курыкты, – диде карт. – Анда немец частьлары

килеп, кешеләрне өйләреннән куып чыгара икән. Күрше Добэледан кайтып китешли Рита үзе әйтте.

– Алайса, миңа да ашыгырга кирәк...

– Тукта, ике активистны кулга алганнар, ди анда. Кемдер барып әйткән, имеш. Үч итеп. Сине дә көтеп кенә тормагайлары?

– Анысын көтәргә була. Кызыллар булганда, шым торганнарның хәзер канат җәюләре мөмкин.

– Син дә башлык идең бит.

– Мин, абый, кызылларны аңлый алмадым. Бик теләдем, әмма зиһенем җитмәде, – диде Отто, итек йөзендәге аксыл тузаннарны үлән йолкып сөртә-сөртә.

– Ну бит син активистлар чутында йөрдең.

– Мин эш яратам, ә кызылларга эш белән генә ярап булмый иде.

– Шуны кисәтим әле, – диде карт, калын мыегына кул очы белән орынып алып. – Хәзер болганчык чор башланачак. Әйеме?

– Ул хакта да башка килде...

– Сез шул чорда берәр җиргә яшеренеп торыгыз. Юкса...

– Немецлар шулай ук әшәке кыланыр микәнни, абый?

– Әнә яһүдләрнең барча әйберләрен алып, үзләрен каядыр озаталар икән.

– Без бит немецлар, безгә нигә куркырга, абый?..

– Сакланырга кирәк, ишетәсеңме? – диде карт, пышылдауга күчеп.

Аның мыегы иренен каплап тора, сүзләре дә мыек эченнән килә иде сыман. Күзендә – хәвефләнү, йөзендә курку, сагаю галәмәте шәйләнә иде.

– Әллә Витяны безнең янда гына тотаргамы? Ә? Рита аны үзеннән калдырмады, ахмак ул. Анда ни булмас, бирedә тыныч әле. Олы юлдан читтәрәк...

– Миңа хәзер китәргә кирәк, – диде Отто, үлән сүле чыкканчы күн итеген сөртә-сөртә.

– Караңгы төшмичә йөрмә, әйткәнне тыңла. Рита да киреләнде.

Өйалды коридоры буенча барып, өйгә керделәр. Карчык үз бүлмәсенә кереп яткан иде. Аны борчымаска булып, кухняга уздылар. Карт бәрәңге кыздырган икән. Кунаклардан калган пироглар да бар иде, шулар белән өй сырасы эчтеләр. Сүз һаман сагаю, саклану турында барды. Властьлар алмашынып тору, тормыш барышының кинәт үзгәрүе өннәрен тәмам алып бетергән иде. Теләмәсәң дә, җанда курку тора. Синең белән шул идарә итә. Эчтәге курку үзенә буйсындыра, күпме батыр булырга тырышсаң да, ул барыбер үзенекен итә.

Рита Оттога бик нык куркынып, төсе-өне беткән килеш ишек ачты. Караңгы булса да, тавышыннан шул беленде. Ә Отто ничектер бик тыныч иде. Рита тәрәзәләрне одеяллар белән томалап чыккан икән. Витя йоклый. Шуңа күрә ишек төбендә, караңгыда гына чишенеп, Отто кухняга узды. Рита шәм яндырды. Шул мәлдә өй селкенә башлады. Ике йорт аша гына олы юл иде, шуннан танклар, машиналар уза дип гөман иттеләр. Йокларга ятарга ничектер куркыныч иде. Менә хәзер өй өскә җимерелеп төшәр шикелле тоела иде.

Нишләргә, кая барырга, Витяны нишләтергә? Иң элек шул хакта сөйләшергә тотындылар. Бу болганчык вакытта кайдадыр посып яту муафыйк булыр иде, билгеле. Ләкин кая яшеренәсең? Ичмаса, баланы куркынычсыз берәр урынга качырасы иде. Әмма кая качыру турында бер карарга килә алмадылар. Рита шунда яңалык әйтте: теге кибетче еврей Эйнштейнны алып киткәннәр икән. Хатыны елап килгән булган, Отто немец бит, үз телләрендә сөйләшеп карасын әле, дип, бик үтенгән. Кич буе көтеп утырган да кайтып киткән. Иртән тагын

киләчәк, ди. «Нишләрсез икән? Аны яклап баргач, үзеңне алып калмасламы? – диде Рита. – Боларга ышаныч юк. Бер гаепсез кешене алып киткәнне, сиңа да сәбәп табарлар. Әллә бармыйсыңмы? Синең – активист, минем Ленинградтан икәнне белсәләр, дим...» «Каян белсеннәр?» – диде Отто. «Әйтүчеләр табылмас, дисеңме? Яңа властька ялагайланучылар күп булыр, – дип, Рита үзенекен куәтләде. – Яңа властьның тагын ничек ышанычын казана аласың, фәкать башка берәүне сатып кына! Башка юл юк! Властька, гомумән, кемнедер чагып кына ярап була. Бүтән мөмкинлек юк. Бердәнбер юл. Немецлар өчен дә, кызыллар өчен дә. Тормыш бер генә юл калдырган. Телисеңме-теләмисеңме. Элек-электән, борынгы заманнардан бирле кешеләр шул әмәл белән генә ышанычка керә алган. Фәкать кемне дә булса сату әмәле белән генә».

Ританың сүзләрендә, чыннан да, дөреслек бар иде. Аны исәпкә алмыйча булмый. Эйнштейнны коткарырга барып карагамы-юкмы? «Рита, син ничек уйлыйсың? – дип сорап куйды Отто. – Мин син әйткәнчә йөрергә күнегеп беттем...» «Белмим, – диде Рита. – Иртәгәгә чаклы белмим, үзеңә кара...» Оттоның уйлары ми тартмасына бөялде: нишләргә? Рита җибәрмәү ягында. Тавышыннан шул сизелеп тора. Рита сүзе белән йөргән өчен абыйсы белән апасы Оттодан риза түгел. Усал, диләр, Оттоны әнә ничек биетеп тота дип шаккаталар. Отто ни әйтергә белми. Шулай ук нык үзгәрдем микәнни дип аптырый. Сезгә карата мин әллә бераз суындыммы соң, дип сорый ул абыйсыннан. Бераз гына түгел, бик нык суындың, ди абыйсы. Апасы тагын да күбрәк дәлилләр китерергә тотына: ул сиңа түбәнсетеп карый, үзен югары тота, шуны сизмисеңме, ди. Берни сизмим, ди Отто. Ул үзе гадел табигатьле, әммаРитаның үзеннән Оттоны тәмам тартып алуын гафу итә алмый иде. Хәер, бу һәр гаиләдә була торган хәл инде.

– Витя абыйларда торып торсын, – диде Отто, ниһаять, ныклы карарга килеп.

Рита өстәлнең аргы башында мул күкрәкләре белән кырына тиеп диярлек утыра иде, башын күтәреп иренә карады. Отто чынлап әйтәме, әллә киңәш өчен генәме икәнен белергә теләде ул. Һәм белде дә. Оттоның малайны абыйларына җибәрәсе килә иде. Аның үз логикасы бар. ӘммаРитаның ихтыяры көчлерәк иде. Ул үзенең баладан азга гына аерылып торуын күзаллап карады һәм моның мөмкин түгеллеген бөтен җаны белән сизгәндәй булды.

Отто үз дәлилләрен китерергә кереште. Хуторларда куркынычсызрак булачак, диде. Качып калырга урыннар бар. Шәһәрдә кая качарга мөмкин? Юк. Яңгырлы вакытта немецлар анда бара да алмас, керергә дә куркыр. Хуторда ашау-эчү ягы да, билгеле, әйбәтрәк булачак. Алар – хосусый милекчеләр, җир сөреп, иген үстергәнне тыймаслар.

Әмма Рита барыбер дә риза түгел иде. Отто озак кына хатынына карап торды. Нигә ул аңа каршы килә соң әле? Витяны артык яратамы? Дөрес, абыйсы белән апасын өнәп бетерми анысы. Бигрәк тә аларның шапшаклыгын яратмый. Чисталыкка бик тырышып өйрәтеп тә маташты үзләрен, әмма бернигә ирешә алмады. Чигенде. Тегеләр Рита өйрәткән саен карыша гына иде шикелле. Оттоның Рита сүзен генә сүз итүен дә күтәрә алмыйлар. Ачулары килә. Ачуларын Ритага карышып чыгаралар иде. Тыштан бик тату гаилә күренсә дә, эчендә әнә шундый, астан күренми торган каршы агым бар иде.

– Рита, – диде Отто, йомшак кына. – Витя белән икегез дә утарга кайтыгыз. Аңлыйсыңмы? Анда барыбер куркынычсызрак булачак! – Ул аска карап, кайгыга батып утырган хатынының аксыл киң маңгаена карады. Акрынлап карашын аскарак шудырды: күзләре дымлы, керфек төпләре көйгән төсле

кара янып тора. Күз асларында зәңгәрсу тасма кисәкләре ябыштырып куелган сыман. Ирене кипшергән, ә ирен өстендә чак кына беленә торган соры төкләр бар. Әйе, ул бик арыган. Кайгысы да бик зур, чөнки ул барысын да йөрәгенә якын ала. Ә менә апасы Клара бөтенләй икенче төрле. Бик тыныч табигатьле. Һәр кешегә җайлаша белә. Әйбәт характерлы.Ританың холык-фигыле «үткен почмаклы»рак шул. Ләкин ул Оттоны бик ярата, назга да бай хатын. Бергә яшәгәч, назы да бик кирәкле сыйфат. Отто моны өйләнгән ир-атлар белән үзара гәпләшкәндә тагын да ныграк белде. Бернинди назы юк салкын хатыннар да була икән. Синең яныңда гел дә бүрәнә кебек ята торган...

– Рита, киреләнмә, Витя хакына үз капризларыңны куеп тор, – диде Отто бу юлы кырыс кына.

– Син немец бит, шуңа күрә безгә тимәсләр әле, – дип куйды Рита.

– Саклану зыян итмәс, Рита. Бернинди гарантия юк бит.

– Әйдә ятыйк, иртәгә күз күрер, – дип, Рита урыныннан кузгалды. Шәм тотып кухнядан чыгып килә иде, шулчак ишек шакыган тавыш ишетелде. Икесе дә куркып, кухняга кире чигенде. Сагаеп кына шаку тагын кабатланды. Бактың исә ул танышлары Стубе икән. Аңа ачмыйча булмый иде. Нәрсәгә дип килде икән? Ул бит Оттоны бер дә өнәми. Заводның профсоюз председателе булып эшләгәндә, аларның күчәр башлары һаман эләгешеп торды. Стубе какча гәүдәле, озынча чырайлы, бәрәңге борынлы, алга чыгып торган биек маңгайлы, сөйләргә маһир кеше иде. Ул, имеш, Ригада подпольедагы большевиклар әгъзасы булган. Советлар килгәч, аны заводка җаваплы эшкә җибәргәннәр. Цехларга кереп, хәл-әхвәл белешеп йөрергә ярата иде. Бигрәк тә яшьрәк хатын-кызлар янында озак туктала, нindидер шаян сүзләр әйтеп көлдерә, дәртләндерә иде.

Завод директоры йомшак булып чыкты, дип сөйләнәләр иде. Бар эшне шушы Стубе хәл иткән. Директорның йомшаклыгы характерында түгел, ә биографиясендә иде. Теге вакытта нindидер ярамый торган эшләр эшләгән, сүзләр әйткән, имеш. Шуны исенә төшергәннәр, ди. Шуңа күрә урыныннан очмас өчен артын кысып утырырга мәҗбүр булган. Бигрәк тә идән асты большевигына ничек каршы сүз әйтә алсын ул. Ә Стубе – шактый әрсез кеше. Бөтен эшкә катнаша, һәр төштә үзен белгечкә саный иде. Җыелышларда чыгыш ясаганда да дөньяга баш кеше кебек, үз-үзенә нык ышанган, алдан бар нәрсәне белеп торган сыман сөйли иде. Хәтта парторг та аңа каршы сүз кыеп әйтә алмый. Әгәр әйтә башласа, бер сүз белән артына утырырга мәҗбүр итә торган иде.

Капкачлар ясау цехында ике штамповка станогы бар иде. Шуның берсе җимерелде, һәм айлык план үтәлми калды. Моны тулысы белән Отто гаебе санадылар. Стубе шулай әйткән. Отто – баш инженер. Янәсе, ул карамаган, хәстәрен күрмәгән. Стубе киңәшмә саен Оттоны тапый башлады. Ә бит Отто турыдан-туры гаепле түгел, ә станокта эшли торган эшче гаепле иде. Ул яшь, тәҗрибәсез. Тәҗрибәле эшчеләр, Советлар килгәч, куркып, кайсы кая качып бетте. Яңа кешеләр җыярга туры килде. Алар барысы да хуторлардан килгән яшьләр иде. Өйрәтергә кеше юк, күнектерергә вакыт бирмиләр, план үтәргә кирәк. Бер нәрсә икенчесеннән килеп чыга бит. Станок белән тиешенчә эш итә белмәгән егет артык «тырышып» җибәргән дә бандажны эреткән. Һәм шуңа Отто гына гаепле булып калды. Янәсе, ул яшь эшчегә төгәл инструктаж бирмәгән. Отто үзенең моңа турыдан-туры җаваплы булмавы хакында әйтеп караса да, Стубеның ишетәсе дә килмәде. Отто зыянны түләтерләр дип тә курыккан иде, бу хакта Ритага да әйтеп куйды, чөнки хатыны һәр тиенне саный торган булып китте. Оттоны эчү мәсьәләсендә дә нык тота иде. Әмма соңыннан,

парторг түләтергә каршы чыккан, дип сөйләделәр. Стубега бирешмәгән. Элекке вакыт булса, хуҗа, һичшиксез, станокта эшләүчегә һәм цех башлыгына штраф салыр иде. Совет законнарының эшчегә карата гуманлы булуына Стубе да каршы тора алмаган. Отто мондый гуманлылыкны башка җирләрдә дә күрде. Бер яктан, моңа сөенеп караса, икенче яктан, уйга да бирелә иде. Артык гуманлылык эшченең тугарылып китеп, брак ясавына китерер дип шөбһәләнә иде. Дөрестән дә, заводта эшчеләр саны элеккеге кебек булса да, эшләп чыгару күләме шактый кимеде. Кыскасы, советларча эшли башлау белән, продукция аз эшләп чыгарыла башлады. Отто моңа бик нык аптырый, нишләргә белми иде. Тагын бер нәрсәгә исе китте аның: эшләргә яратмаучы ялкауларны Стубе бик ярата һәм җыелыш саен мактап телгә ала иде. Ялкаулар, гадәттә, сөйләргә маһир була. Җыелышта иң элек шул хөрәсән ялкаулары сөйли һәм намус белән эшләүчеләргә йә тегеләй, йә болай тибеп уза. Отто кемнең намус белән эшләгәнен, кемнең көн үтсенгә генә йөргәнен бик яхшы белә иде. Шунлыктан Стубе якын күргән ялкауларны, эштә эленке-салынкы йөрүчеләрне фаш итеп чыкты. Стубеның моңа бик ачуы килә, кайчакта, ачуын яшереп кала алмыйча, самавыр кебек кайнап чыга һәм эчендәге әйтеп ташлый иде. Димәк, хәзер эшләү мөһим түгел, ә сүз сөйләү мөһим булып чыга. Кешене эшенә карап түгел, ә сүзенә, сөйләвенә карап бәялиләр. Бу моңарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән яңа күренеш иде. Отто бу хәлне аңлый алмаудан гаҗиз: ничек инде кешене сүзенә карап бәяләргә мөмкин? Нәрсәгә китерер бу? Әмма алда нәрсә буласын уйлаганны шулай ук өнәмиләр. Ни кушсалар, шуны башкар, башкасына тыгылма. Ул хакта махсус уйлый торган кешеләр бар, алар өлешенә кермә... Уйлый торгач, Отто шундый нәтиҗә чыгара иде. Бигрәк тә Стубеның үз тирәсенә ялкау-хөрәсән, ертлачларны якынайтуына үртәлә иде ул.

Стубе социалистик ярыш оештырып йөрде. Бик зур эшкә санады ул аны. Барча бәлаләрдән коткара торган чара итеп күрде. Һәр цехка аерым социалистик йөкләмә язып бирде. Ул унҗиде пункттан тора иде. Бер пунктында, социалистик аңны арттырырга, диелгән. Бер җыелышта Стубега, нәрсә ул социалистик аң, дип сорау бирделәр. Стубе аңлатырга керешә: үз илеңне ярату, хезмәткә аңлы караш, янындагы иптәшеңә хәерхаһлы мөнәсәбәт... дип тезде генә. Бер кыю хатын шунда, минем янда хөрәсән иптәш бар, эшләргә иренә, кеше җилкәсендә утыра, мин шуңа хәерхаһ булырга тиешме, дип сорау бирде. Әйе, син аңа әйбәт карарга тиеш, диде Стубе. Аннары икенче бер чая хатын, торып, әнә барлык эшне яхшы эшләүче фәлән ни өчен сезгә ярамый, сез аны ник җыелыш саен тәнкыйтьлисез, дип сорады. Бу сораудан Стубеның битенә әз генә алсулык йөгерде. Шулай да каушап калмады, үз дәлилләрен әйтте. Аның сүзләреннән һәр кешене хезмәтенә карап түгел, ә карашларына карап бәяләү кирәклеге аңлашылды. Моны ул үзе дә сизеп алды һәм төрле аңлатмалар, искәрмәләр биргәндәй итте.

Өч айдан социалистик ярышка йомгак ясалды. Нәтиҗәләр буенча бар пункт та тулысынча үтәлгән дип әйтеп булмый иде. Стубе, цех башлыкларына басым ясап, йөкләмәләр үтәлде, дип кул куйдырды. Отто кул куюдан баш тартты, чөнки эшләп чыгару элеккеге өч айга караганда да ким иде. Бу исә Оттога каршы бик зур дәлил булды. Стубе шул фактны, күпертеп, барча төштә сөйләде. Хәтта райбашкармага махсус барып әйтте. Ул Оттоны урыныннан алу өчен йөри иде. Начальникларга яраша белми торган кешене ничек баш инженер итеп тотарга мөмкин? Бу очракта кем дә юл өстендәге ташны алып ташлау ягын карар иде. Оттоның моңа әллә ни исе дә китмәде. Әмма үзен эшеннән

төшерерләр дип тә ышанмый иде. Ник дисәң, фабрикада производствоны һәм аның процессларын аңардан яхшы белүче башка белгеч юк иде. Отто моның белән бераз горурлана да иде. Аңардан башка механизмнары рәтләп эшләмәячәк, план яначак, янәсе. Ә планны үтәмәгән өчен, башлыкларны райисполкомда тетәчәкләр. Отто шулай үз осталыгына аркаланып, Стубе канат астына посып, эшләмичә генә акча алучыларны фаш итүен белде, чөнки аңарда дөреслекне ярату хисе көчле иде. Табигатьтән килгән ул хисне эчеңдә тыеп торып булмый икән! Һәр эштә диярлек төртә дә чыга иде ул. Турыдан ерак барып булмаганы – билгеле нәрсә. Стубе Оттоны урыныннан төшерү өчен бар көчен куеп тырыша башлады. Моны сизми калу мөмкин түгел иде. Без капчыкта ятмый. Оттоны белә торган, әмма аңа каршы төшәргә яратучы бер егет эштән кайтканда, колагына гына пышылдады: «Стубе мине синең өстән язып бирергә күндермәкче булды, тик мин баш тарттым», – диде. Отто аңа берни дә әйтмәде, чөнки сүзләренә ышанып җитми иде. Шулай да Стубеның методын чамалады. Әйдә, чокчынсын, диде. Аңардан башка барыбер бер механизмны да эшләтә алмыйлар. Стубе сүзенә карап, аның мин-минлеге өчен генә заводны механиксыз калдырмаслар. Беркемнең дә башына тай типмәгән.

Әмма Оттоның өстендә болытлар куерганнан-куера барды. Ул һаман үзенең алыштыргысызлыгына нык ышанып йөри бирде. Ә куерган болытлар яшенне үзеннән-үзе китереп чыгара.

Биредә дә шулай булды. Беркөнне директор кабинетында җитәкчеләрдән генә киңәшмә җыелды. Район башкарма комитетыннан вәкил килгән иде. Башта ул сөйләде: план үтәлмәгән, айдан-айга өзелгән. Эш болай бара алмый. Сәбәбен ачыкларга кирәк. Планны тутыру өчен, ашыгыч чаралар күрү, резервлар табу бик зарури. Ә парторг бар тоткарлыкны техниканың начар эшләвеннән күрде. Директор да шуны ук куәтләде: конвейер ватылып, ничә көннәр тик торган. Консервларга азык-төлек тутыру кул белән башкарылган. Кыскасы, баш инженерның эше күренми.

Күзгә карап, барысы да шулай арттырып сөйләде. Бу ни хәл? Ни өчен шулай итәләр? Булганны булмады дип әйтәләр? Отто да бар эшкә дә өлгерә алмый, билгеле. Әнә бервакыт Украинадан томат пастасы ясарга берничә вагон помидор китергәннәр иде. Балык консерваларын томат катнаштырып чыгарырга план бирелгән иде. Әмма пешерү казаннарын көйли алмадылар. Отто берүзе өйрәнчекләр җыеп өйрәтә-өйрәтә эшләп маташты, әмма берни барып чыкмады, төп эше дә тоткарланды. Шулай итеп, тегендә дә, монда да өзеклек килеп туды, ә бар гаепне Отто өстенә өйделәр. Билгеле, ул да бөтенләй үк гаепсез түгел. Пешерү цехын бик тә җайга саласы килгән иде аның. Ә инде өч вагон помидорның череп юкка чыгуы өчен кемнедер гаепләргә кирәк иде. Юкса гамәлдә гаеплеләр берәү генә булмый, алар күп. Ләкин ни өчендер гаепне бер генә кешегә өяләр. Шуның белән эшне ябалар. Килгән зарар өчен башкача җавап бирү юк. Бу хәл, бер яктан, бик гуманлы булса, икенче яктан, экономика өчен зарарлы. Өстән, гаепле кешегә җәза бирелдеме, дип сорыйлар. Моңа җавап әзер булырга тиеш: гаепле кешегә җәза бирелде – эшеннән алынды.

Югары сыйфатлы өч вагон помидорның әрәм булуы өчен Отто бик нык борчылды, шуңа күрә баш инженер эшеннән алынганга артык көенмәде дә кебек. Вазифасыннан азат ителүен хаклы дип санады. Әмма Рита бу хәл белән һич килешмәде. Икенче көнне үк райбашкармага китте. Аңа Отто эшен яңадан карарга вәгъдә иткәннәр, юатканнар, бераз генә өркеткәннәр, күңеленә шом салганнар иде.

Күпме көтсәләр дә, Оттоның эше кабат каралмады. Аңа нокта куелган иде. Өч вагон помидорның яраксызга чыгуына чын гаеплеләр Отто артына яшереп калдырылды. Рита райбашкармага тагын барып, чын гаеплеләрне атап-атап та әйтеп карады. Тик берни дә үзгәрмәде. Карга күзен карга чукымый, дип, ахырда бу ниятеннән кире кайтты. Оттоның бәласен үз җилкәсе белән дә күтәреште. Тик Оттоның урыныннан алынуын хаклы дип санавы белән һич тә килешмәде, һәрбер хатын-кызга хас булганча, ирен астан гына котыртты да. Мин-минлегенә тиярдәй сүзләр әйтте. Син ир кеше түгел, юкка чалбар киеп йөрисең, дип тә мыскыллады. Отто исә сабыр гына тыңлап торды, намусына тия торган сүзләрне буена сеңдерде. Рита артык нык чәнчеп әйткәндә генә үзенең дәлилләрен китерә: «Болай ансат котылганга рәхмәт әйт, түләтә башласалар йә судка бирсәләр, нишләр идең?» – ди иде.

Оттога хәерхаһ булганнар соңыннан яшертен генә ирештерде: аны баш инженер эшеннән алуны Стубе бик нигезле итеп оештырган икән. Өч кешене Отто өстеннән язып бирергә күндергән. Директор шуларга нык дикъкать иткән, имеш. Өстәвенә Оттоны эшен начар башкарганга түгел, ә карашлары өчен алганнар икән. Монысына Отто һич ышанмады. Аның карашлары нинди иде соң? Ул Советларны чын күңелдән кабул итте һәм аларның һәр законы хаклы, гадел дип белә иде. Дөрес, баш инженер буларак, кайбер нәрсәләр белән килешеп тә бетмәде. Мәсәлән, әлеге дә баягы уяулык күрсәтү мәсьәләсендә. Аны начальниклар, уяулык күрсәтмисең, сукыр син, дип тирги иде. Әйбәт эшләгән кешегә карата бер сәбәпсезгә уяулык күрсәтеп, шикләнеп карарга теләми иде ул. Тора салып кешегә шикләнеп кара, имеш! Бу бит әхлакка да сыймый торгандыр. Отто, мин андый эшне булдыра алмыйм, диде. Шуннан соң аңа кырын карый башладылар.

Әйе, шайтан алгыры, чынлап та, Оттоның карашлары Советларныкына туры килеп җитмәгән икән шул. Бәлки, нәкъ менә шуның өчен аны төшергәннәрдер дә. Мөгаен, шулайдыр.

Бу мәсьәләне алар Рита белән ай буе диярлек тикшерде. Икесе өчен дә шактый каты чикләвек булды бу. Икесен дә бик нык сискәндерде, уйланырга мәҗбүр итте. «Син, – диде Рита, – беркемнән дә шикләнә белмисең. Һәркемгә ышаныч белән карыйсың. Бездә исә кешегә шикләнеп карау тойгысы патриотик тойгы санала. Аңладыңмы?..» «Юк, – диде Отто, – аңламадым. Ничек инде?» Ул тегеләй уйлап, болай уйлап карады, әмма төшенергә зиһене җитмәде. «Яңа тормыш бу, – диде Рита, – аның механизмы башкачарак. Үзең тимер механигы, әмма иҗтимагый механизмны аңларга башың җитми. Эх, сине!..»

Оттоны баш инженер эшеннән төшергәч, Стубены райбашкармага алдылар. Бер бәндә батмыйча, икенчесе күтәрелә алмый, ахрысы. Яңа тормышның тәртипләре шулайрак күзаллана иде.

*Ахыры киләсе санда*



Мөхәммәт
Мирза

# БАКЫ – КУБАРЫК ҖИЛ

ПОЭМА

*Баку – меңьеллык чал кала. Газиз әткәм Мирза Ибраһимов сугышта 18 яшендә, ике аягын югалтып, Баку госпиталендә дәваланган...*
*Баку – Бакы – тәрҗемәдә кубарылып искән җил...*
*Бакуга кыз биреп туй иттек. Бакы – кубарык җил исте, җылы ләйсән яңгыры яуды...*

Мәмәт улы Тельман Бабаев –
Баку каласының ташчысы.
Мин – Казанның бер юлаучысы...
Хозыр Ильяс булып каршыма
Килеп бастың, дип: – «Юлдашчымсың?»
Син – ятиме үткән сугышның,
Җитмеш җиде яшьлек нарасый...
Кырык бернең җәй уртасында
Сорап тормаганнар атаңнан
Ничә яшьлек ятим каласын...
Заман кырыс, котсыз замана –
кем сугышка бармый калалсын?
...Бөтен Аурупаны иңләгән
Эзләп әткәсенең каберен –
бер хәбәрсез каян табалсын?
– Нәкъ син көткән Адәм затымын,
Бабаң эзләреннән килдеңме?
Госпитальдә җан биргәннәрнең
Исемнәре бар да теркәлгән, –
Мин күчереп җиргә иңдердем...

– Мин мосафир бүген Бакуда,
Туганлашыр өчен килдек без...
Бердәм тел, динебез хакына
Җиһангир угылы Фаррухка
Никахлап кызны бирдек без...

---

Мөхәммәт МИРЗА (1953) – *шагыйрь; биш томлык «Сайланма әсәрләр», «Киек каз юлында», «Тере су», «Адәм баласы» һ.б. күпсанлы китаплар авторы. Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Туй алдыннан тәүге күкрәү –
Урамына ләйсән түгелде...
Хәзәр диңгезеннән искән җил
Изүемне ачып, күкрәгемә
Җылы кулы белән үрелде...
Йөрәгемне иркәләде Бакы –
Тәрҗемәдә – кубарылган җил...
Баку – кала, кырык өчнең көзе...
Днепрда яраланган Әткәм,
Хәзәрдә – кабаттан туган җир...
Низамидан уңга борылгач,
Мирза Ибраһимов урамы...
Йөз сиксән тугызынчы мәктәп –
Әткәм дәваланган госпиталь –
Диварында язу тора әле...

Мәмәт улы Тельман нигәдер
Кабат сорый әткәм исемен...
 – Мирза Ибраһимов – тупчы, – дим, –
Днепрда яраланган, бәгырь,
туган көне булган – унсигез...

Старшина Зиннәт – Шөгердән,
Наводкага аны өйрәтте.
тупчы Мирза фашист танкысын
күз күреме, кул сузымында
маңгаена бәреп көйрәтте...
...Өч көн, өч төн барган орышта
Тимер янып, тимер эреде.
Күкне япты канлы сөреме.
Күктән хәтта күралмадылар:
Үлеме син, әллә тереме?
...Терелеге – ярты гәүдәдә,
чәрдәкләнеп беткән аягы...
Бөтерелеп дөнья әйләнә...
Тешләп яргаланган иреннәр:
– Әшһәде Аллаһы, – дип кабатлый...

Шинеленә төреп, өстерәп,
Җәһәннәмнән алып чыктылар.
Эшелонга төяп Бакуга
озаттылар... Үтәр юл ерак,
Ни котә язмышлар чатында...
Язылганын маңгайга, сызып,
Сөртеп алып булмый кул белән.
Бакы – кубарылып искән җил
Яшәү тынын өрде тәненә
Язмышыннан узмышын теләп.

– Бу госпиталь – мәктәп әүвәле –
сугыш котырынган дүрт елда
Гарипләнгән йөз мең яугирнең,

Газраилдән йолып алынып,
Җанкайлары саклап калынган...

Дүрт яшемдә – сабый хәтере...
Әнкәм итәгенә тагылып,
Шыплап тулган палаталарда
Үз әткәмне эзләп йөргәнем
өметләнеп, бәлки, табармын,
дигәнмендер... Әмма нигәдер:
– Улым, – дип дәшүче булмады.
Әнкәм таңнан кояш батканчы
Керен юды яралыларның,
Мин йөр(е)дем көн-төн тулганып...

Төнге сменада калганда,
Мин дә куна идем биредә...
Бакы – кубарылып искән җил –
Каерып ачып тәрәзәләрне,
Тынчу палатага керүгә,
тынып кала ыңгырашулар...
Әйтерсең лә бар да савыккан:
Хәзәр диңгезенең аръягыннан
Сөткә туенган дала исен
Тансыкланып, һәркем зарыккан...

Хәзәр диңгезенең аръягы...
Бирге яктан күренми яры...
Атна, айлар үткән кәрваннар,
Җиде ятларның төяп малын,
Йолдызларга багып, юл табып...
Чүл диңгезен кичкән кәрваннар,
Хәзәр диңгезендә – көймәдә...
Бакы – кубарык җил искәндә,
Җилкәннәрен гаярь киереп...
Көткән ярларына юнәлә...
Җирнең җиде читенә җитеп,
Менеп күкнең җиде катына,
Бар хыялын чынбарлык итеп,
Хәл кадәрле тапканын төяп,
Ир гаилә-иленә ашкына...
Кайда туып, кайда торса да,
Алтыннан сараен корса да,
Җирсеп, кубарылып кайтыры –
Кендек каны тамган туф(ы)рак,
Тәкъдире – Җил каерып борса да.

Ике елда өч кат кистеләр
Чәрдәкләнеп беткән балтырын...
...Мыек та чыкмаган иде дә –
Чигәсендә чаларды төкләр...
Килде көне – илгә кайтыры...
...Кайтып бара солдат поездда,
Шпалларны саный бер көйгә...

Исәбенә чыгарлыкмыни –
Канга батып ауган яугирләр
Шпалларга салып өелгән...
Шпалларга сары шинельләр
Сары сагыш булып ягылган...
Станцага килеп җитүгә,
Ачыргаланып чиный поезд:
– Гарип солдат илен сагынган...
...Басып кала перрон ташына
Бер аякта, ике таякта...
Шпалларын санап тагы да,
Шыплап тулган гариплəр төяп,
Эшелон ашыга төньякка...
...Шпалларның югалды саны...
Санарга күчте станцаларны...
Станца саен кулсыз, аяксыз,
Күзсез яугирләрне калдыра –
Кайда,ниләр көтә аларны?

Маңгайларга язган язмышны
Сөртеп алып булмый кул белән...
Станцада калган ирләрнең
Имгәтелгән какча иңнәре
Илне күтәрәсе – ил белән...

– Илне күтәрәсе... Авыллар
Тарганмы гарасат, давылга?
Йорт курасы калган кыйшаеп,
Читәннәре сүтеп ягылган,
Капкалары тора аварга...
Капкаларга сугылган йолдыз –
Һәлак булганнарның тамгасы...
...Бер хәбәрсез югалганнарның,
Сулган гөлдәй ятим, толларның
Хәсрәтенә беркем тармасын...
Үндүрт яугир кайткан авылга...
Җитмеш йортта – үксез ятимнәр...
Җитмеш толның үткәргән көнен
Җелегенә төшеп өшеткән
Зәһәр кырлач җиле хәтерләр...
Илне күтәрәсе – йончу ил
Күтәрәмгә калган, мантымас,
дигәннәрдер... Шәһәр, авыллар,
Иңнәренә гарип ирләрнең
Тотынып, сөялеп бастылар...

– Хәбәрсезлек хәбәре ачы.
Әнкәм сулып сүнде ун елда.
Күрәчәктән буламы качып:
Бакы – кубарык җил – җыйдымы
Өереп ятимнәр йортына...
Госпитальдән бушаган мәктәп
Шыплап тулды ятимнәр белән...

Яралары – җаннарда иде...
Бакы – кубарык җил, шәт, шаһит:
Барын-югын күрдек ил белән...
Ил, дигәнем – үзебез инде,
Үксез ятимнәрнең тиңнәре...
Хәтерләрдән сызасың ничек:
Оныттырмый, тора искәртеп
Бакуның кубарык җилләре...

Мәктәп-госпитальнең бакчасы
Тоташтан каберлек иде лә...
Күзалдымда тора барчасы:
Мең чакрым аралар үтеп,
Кайдан, кемнәр эзләп килделәр...
Мин – ташчы, мин – баш архитектор,
Егерменче җиңү язында,
Сак кузгатып баскан ташларын,
Һәммәсен күчереп җирләдем,
Укып җеназасы намазын...

– Мемориал – Хәзәр ярында
Мәңгелек утының ялкыны...
...Бүтән кабатланмас, диделәр...
Җитмеш елдан кайнап кабынды
Дөнья орышының салкыны?

Мин – мосафир бүген Бакуда
Туганлашыр өчен килдек без:
Уртак тел, динебез хакына
Җиһангир угылы Фаррухка
Никахлап кызыбызны бирдек без...

Мәмәт улы Тельман Бабаев –
Җитмеш җиде яшьлек нарасый...
– Юлдашчымсың? – диеп, каршыма
Кулын сузып чыгып басты да
Түгелде – тыңламый кара син...
Орышларсыз, йә, кем торалмый,
Бакуга бер килеп кара син...
Эзләп тап та мәктәп-госпитальдә
Ятимлектә үскән баласын –
Танырсың изге Ил Агасын...
Ул – илчесе Бөек Халкының,
Ул – диндәшем минем, кардәшем...
Төзүче, ташчысы Бакуның!
Бакы – кубарык җил – бүгеннән –
Мәңгелек юлдашым, хәлдәшем.

*Казан – Баку – Казан.*
*Апрель-декабрь, 2017 ел.*



Фирдәвес
Хуҗин

# СУГЫШ КҮЛӘГӘСЕНДӘ

ПОВЕСТЬ

## Кереш

*Дөньяга яманаты таралган Суслонгер лагере 1941 елның июлендә оешып, 1943 елның ноябренә кадәр Кызыл Армия өчен пулемётчылар, артиллеристлар, танкка каршы ата торган мылтыкчылар (ПТР) әзерләү белән шөгыльләнә. Бары тик урыс булмаган халыклардан (татар, башкорт, чуваш, мари һ.б.) гына тупланган – укчы 31 һәм 46нчы номерлы запас, 47нче номерлы өйрәнү дивизиясе, 102 һәм 105нче гаубица-артиллерия бригадалары солдатлары өйрәтүләрдән соң нинди сугышчылар булып чыкканнардыр, әйтүе кыен. Еш кына, юньләп хәрби кием-салым белән дә тәэмин ителмәгән, ач-ялангач курсантлар төрле авырулардан, ачлыктан күпләп кырылалар.*

*Сугыш ветераны Муллахмәтов Мизәхмәт Муллахмәт улының сөйләвенә караганда, Салавычның сугышка кадәр колхоз рәисе булып эшләгән Габделбәр Нургалиев атлы кешесе, июль аенда ук мобилизациягә эләгеп, Суслонгер лагерена озатыла һәм кырык беренче елның салкын декабрендә шунда ачлыктан һәм суыклардан вафат була. Кайберләре коточкыч шартларга түзә алмыйча качып китә һәм хәбәрсез югала, кемнәрнедер качканда тоталар һәм алып кайтып строй алдында гыйбрәт өченгә атып үтерәләр. Командный состав, офицерларның кылануына чик-чама юк – алар балда-майда йөзә. Бары тик 1943 елның октябрендә генә мондагы хәлләр турында легендар нарком Климент Ворошиловка хәбәр килеп ирешә. Шул ай ахырында Мәскәүдән аның җитәкчелегендә югары комиссия килеп төшә. Үз күзләре белән кеше ышанмаслык күренешләрне күргән маршал, пистолетын чыгарып, строй алдында лагерь начальнигы белән берничә офицерны атып үтерә. Ноябрь ае башында лагерьны ябалар. Кызганыч ки, лагерь турында дөреслек пәрдәсе һаман ачылмаган. Бу язмам Суслонгерда күп җәфалар чиккән авылдашларым Шәйхулла, Котдус, Сәмигулла (лагерьда вафат) агайлар, күрше Ядегәр авылы кешеләре (Ядегәр – әниемнең авылы) Кашшаф, Камил, Вәгыйз, Гыйльмулла абзыйлар рухына бер дога булып барып ирешсен. Якынча мәгълүматлар буенча, лагерь корбаннарының саны ун мең кешегә җитә, диләр.*

---

Фирдәвес ХУҖИН (1955) – *журналист; «Агыла болыт илләргә», «Әлмөхәммәт тарихы», «Ун хикәя» һ.б. китаплар авторы. Алабугада яши.*

## Сугышка повестка

Җиңүнең җитмеш еллыгы якынлашкан көннәр иде. Туксан ике яшен тутырып килүче Кашшаф карт һәрчак бу бәйрәмне зур дулкынлану белән каршылый. Кырык икенче елның сентябреннән сугышка алынып, төрле фронтларда кан койган, атыш-кырылышлар тәмамлангач та, ике ел хәрби хезмәттә калдырылган карт солдат ерак үткәннәрнең һәр елын һәм аен гына түгел, һәр көнен диярлек хәтерли. Зиһененә бигрәк тә яманаты дөньяга таралган Суслонгер өйрәнү лагерьларындагы мәхшәргә тиң күренешләр бөтен ваклыклары белән сеңеп калган. Салкын окопларда ятып, өсләренә дошман «Тигр»лары сытып үтерергә омтылып килгәндә, маңгайга бәреп чыккан тирне дә сөртмичә, сулышын кысып, «ПТР»ның тәтесенә баскан чаклар, Суслонгердагы ачтан үлмәс өчен җан тартышулар белән чагыштырганда, пүчтәк кенә булган кебек. Һай, ул чаклар. Менә хәзер дә исенә төшкәндә, тәннәре чемерди, арада җитмеш елдан артык гомер озынлыгы ятса да, төшләренә кереп җәфалый. Күпме якташлары, авылдашлары иза чикте аның белән, кайберләре шунда соңгы сулышын алды. Инде тынычланырга кирәк, тормышының ахырын намазлыкта, күптән түгел гүр иясе булган хатыны Сабира рухына һәм җиде баласы белән ике дистәдән артык онык һәм оныкчыклары исәнлегенә дога кылып уздырырга дип исәпләп торганда, беркөнне оныгы Камилнең:

– Арча һәм Әтнә районы энтузиастлары Суслонгерга барып истәлек ташы һәм чардуган урнаштырганнар, – диюе кабат төн йокыларын качырды. Шушы яшенә җитеп, ниндидер ике йөз илле чакрымдагы Мари иленең Звенигов районына барып чыга алмады тәки! Ничә тапкыр талпынды югыйсә. Тик нәрсәдер тотты, күңел эчкәресендәге үзенә дә аңлашылмаган тойгы рухын богаулап, бөреләнеп килүче уй-ниятен юкка чыгара килде. Үткәннәр белән йөзгә-йөз очрашудан, аларны хәтерендә кабат яңартудан курыкты бугай. Моны үз-үзенә танырга гына теләмәде. Оныгы ирештергән хәбәр бөтен икеләнүләренә нокта куйды. Якты дөньялардан киткәнче, ничек тә ул урыннарны әйләнеп кайтырга, аз-маз өйрәнә башлаган Коръән сүрәләрен укып, шунда мәңгелек сыену урыны тапкан бәхетсезләрнең җаннарын тынычландырырга кирәк. Бәлки, үзенең дә күңеле бушаныр, бакыйлыкка да тынычланып китәр. Шул көннән соң Камилне:

– Суслонгерга алып бар! – дип тинтерәтергә кереште.

Тегесе:

– Ярар, дәү әти, җай туу белән, сәфәр чыгарбыз, – дип ышандырса да, җай дигәннәре тиз генә чыкмады. Ул арада Җиңү бәйрәмнәре генә түгел, җәй дә үтеп, сентябрь ае керде. Саргылт төскә манылган көяз каеннар, ут яфраклы усак агачлары гүзәллекләреннән теләр-теләмәс аерыла башлаган чак. Әнә шундый мәлдә авылдашлар Вәгыйз һәм Котдус абыйлары белән сугышка алганнары Кашшаф картның бүгенгедәй күз алдында. Оныгы Камил янәшәсендә җайлап урнашкач, асфальт юлдан җилдерүче машина тәгәрмәчләренең җиңелчә гүелдәве астында элекке фронтовик хатирәләренә чумды...

Колхозда эш кайный, кызу урак өсте. Басудан көнозын атлар белән иген ташыган егетләр кичке уңайда район үзәгенә илтергә олаулар әзерли. Бу инде гадәткә кергән: тәүлекнең якты вакытында – басуга, кичке мәлдә – район үзәгенә. Күбесе малай-шалайлыктан да чыгып җитмәгән үсмерләр һәм алар арасында бүген-иртәгә сугышка алынырга тиешле Кашшаф яшендәге ике-өч егет, ашлык кабул итү пунктында йөкләрен бушатып, әниләре хәстәрләгән ипи

кисәге һәм берничә салкын бәрәңге белән тамак ялгап алганнан соң, юньләп ял итәргә дә өлгермиләр, төн пәрдәсе сыегайганчы кайтырга кузгалалар. Кайтып, атларга һәм үзләренә чак кына ял биргәч, янә – басуга. Бөркөнне авыл советыннан хәбәр китерделәр: «Хәкимов, иртәгә таң белән, кирәк-яракларыңны җыйнап, хәрби комиссариатка барасы». Әнисе улының биштәренә алдан ук киптерелгән сохарилар, бәйләгән җылы оекбашлар белән йон бияләйләрен тыкты. Телогрейка бирергә дә онытмады. Кашшафның:

– Әни, син бигрәк инде, бу вакыттан кем шундый әйберләр кия, – диюенә:

– Алай димә, балам, җылы – сөякне сындырмый ул, кирәге чыга аның, – дип җавап бирде.

Ай ярым да үтмәде, Кашшаф әнисенең мең мәртәбә хаклы булуын кабат-кабат рәхмәт хисләре белән исенә төшерде. Суслонгерда аяк-куллары өшүдән әнисенең алдан күрүчәнлеге коткарып калды. Ә хәзергә аның ике авылдашы белән ат арбасына утырып, әче таң белән район үзәгенә кузгалуы. Аларны, сугышның беренче елындагыча, хатын-кызлар һәм бала-чага чыр-чуы, кемнеңдер моңланып җыр сузуы да озатып калмый. Туганнар, якыннарның саубуллашканда тыенкы гына әйткән сүзләре, исәнлек теләкләре колакка чалына. Җыр кайгысы димени. Фашист мәлгунь Идел ярына ук чыккан, «Корычкала»ны алырга ыргыла ди анда. Авылда атна саен кемгә дә булса кара пичәтле кәгазь килмичә калмый. Кашшафларны да Сталинград юнәлешенә ташларлар, мөгаен, хәерлегә булсын.

## Лагерьда

Аларны Казаннан Сталинградка түгел, күршедәге Мари Республикасының Суслонгер лагерена җибәрделәр. Тупчы, пулемётчы, танкка каршы ата торган мылтыкчыларны әзерли торган курсларга. Әүвәл мал вагоннарына төяп, Звенигов районы тимер юл станциясенә китерделәр. Әле бу юлның ахыр ноктасы булмаган, янә ун чакрым чамасы урман эчләп укыту-өйрәтү үзәге урнашкан тарафка җәяүләп атладылар. Мондагы урманнарга шаккатмалы, тирә-як тоташ тоннель хасил иткән чытырманлыклардан тора шикелле, баш түбәсендә кояш кына күк йөзе буенча озатып бара. Анда-санда күзгә землянкалар, агач бараклар чалына башлады. Кайберләре янында нининдидер кешеләр шәйләнә. Аларның килеш-килбәтләре ничектер сәер тоела, күбесенең өс-башлары теткәләнгән, йөзләрен сакал-мыек баскан. «Монда яшәүчеләр шулкадәр хәерче микәнни?» – дип уйлады Кашшаф, исе-акылы китеп. Ул әле киләчәктә үзләрен дә шундый язмыш көткәнен башына да китерми иде.

Беренче землянкалар күренгән урыннан акрынлап ачыла башлаган «коридор» торган саен киңәя барды. Инде буе ике чакрым чамасы, иңгә дә хәйран киң аланлыкка чыктылар. Хәрби лагерь дигәннәре шушыдыр инде, дип уйлады Кашшаф, биниһая дәү йомран өннәренә охшап тезелеп киткән землянкаларга карап. Моның өннәр түгеллеген араларында агач бүрәнәләрдән аннан-моннан юнып ясалган котсыз агач баракларның сураеп торуы, җир астыннан һәм шул корылмалардан күләгәләрне хәтерләткән кешеләрнең кереп-чыгып йөрүләре раслый. Тукталырга әмер яңгырады. Ике йөз кешелек төркемне станциядән лагерьга озата килгән лейтенант аларны каршылаган майорга үрә катып «честь» биргәч, шартын китереп, рапорт ясады. Тегесе ярар дигән мәгънәдә кул селтәп, аякларын аерып басты да, сөзәргә җыенган үгездәй, кайсы әле малайлыктан гына чыгып килүче, кайсы инде ир уртасы

курсантларга текәлде. Күп эчүдән йөзе шешенгән, күзләре ачулы елтырый иде аның.

– Здесь порядки жёсткие. Забудьте о мирной жизни. С утра до восхода – занятия. Валка леса, заготовка дров, отопление землянок и бараков тоже вменяются в ваши обязанности. Вас обучаем на артиллериста, «ПТР»чика и пулемётчика. Не выдержав испытаний, некоторые убегают. Их по-любому поймаем и расстреливаем перед строем. Так что заранее предупреждаю: выкиньте из головы дурную мысль. Теперь расходитесь по землянкам, после обеда пойдёте на валку леса!

Майор, сүзе беткәнен аңлатып, аркан борылды. Кашшафларның батальон командиры икән. Ул авылдашлары Вәгыйз һәм Котдус абыйлар белән бер ротага һәм хәтта бер взводка туры килде. Монысы бәхет иде, кыен чакта барыбер алар бер-берсенә терәк.

Унбиш кешегә исәпләп казылган землянкага егерме биш кешелек взводны сыйдырганнар, ә тулы бер ротаны агач баракка дыңгычлап тутырганнар. Ул кадәр халык кысан куышка сыймас та иде, шуңадыр, ятак хезмәтен үтәүче нарларны ике катлы иткәннәр. Баш астындагы мендәр урынына такта, ә матрас итеп чыршы һәм нарат ылысы җәйгәннәр. Арып кайтып, урынына ауган курсант авыр йокыга чума. Иртән хәлсезләнеп уяна. Бердән, ачлык җәфаласа, моңа начар ис, һава җитмәү өстәлә. Еш кына блиндаж дип аталучы землянкалардан, агач бараклардан төнлә җан тәслим кылган берәр бичараны күтәреп чыгалар. Бу турыда Кашшафлар лагерьга килгән көнне, алардан алда хезмәт итә башлаучылардан ишетеп белделәр. Соңыннан үзләре әлеге коточкыч күренешнең шаһиты булып тетрәнделәр. Билгеләнгән землянкага кереп урын алганчы, төшке ашка кайтып килүче зур гына төркем кешеләр якынлашканы күренде. Аларның ач яңаклы йөзләрен сакал баскан, өсләрендәге таушалган киемнәре карачкыга элгән шикелле эленеп тора. Боларның хәрбиләрме, әллә хәерчеләрме икәнен дә аерышлы түгел: кемнеңдер өстендә уңып беткән гимнастёркасы, кемдәдер гражданскидан киеп килгән өс-баш. Күбесенең үзара аралашуы татарча икән, арада чувашча һәм чирмешчә сөйләшүчеләр дә бар. Тагын нинди телдәдер, аларын Кашшаф аңламады. Командирлар урысча гына сөйләшә бугай, дип уйлады егет. Ул әле Суслонгер лагерена өйрәтүләргә урыс булмаган халыкларны гына җыюларын белми иде. Төркем яңа китерелгәннәр янына җиткәч, адымнарын акрынайтты, кайберәүләр туктап ук калды. Кызыксынып күздән кичерергә керештеләр. Аларның карашлары күбрәк яңа килгәннәрне түгел, аларның иңнәрендәге биштәрләрен капшыйлар кебек тоелды.

– Кайсы районнан буласыз? – дип сорады кырык яшьләр тирәсендәге берсе. Районның исемен ишеткәч, – ә-әә, алай икән, – дип куйды. Аннары төкерекләрен йотып: – Теш арасына кыстырырга берәр нәрсәгез юкмы соң, үтереп ашыйсы килә, – диде, кипкән иреннәрен ялмаштырып. Кыяфәте шулкадәр мескен иде бу вакытта, Кашшафның аны кызганудан йөрәге кысылды. Яшьлек диген: ике дә уйламыйча, иңендәге юл капчыгын аягы астына куеп авызын чиште һәм өстә яткан сохариларны учына сыйган кадәр алып, тартып чыгарды.

– Мә, абзый, ал, – диде ул, ихлас елмаеп. Ач яңак, каян килгән җитезлектер, шыр сөяк озын бармакларын тырпайтып, ике куллап сохариларны эләктерде һәм, шундук йөзе белән ризыкка капланып, шатыр-шотыр чәйнәргә дә кереште. Бу хәлгә аптыраган егет һәм иптәшләре исләренә килергә өлгермәделәр, әллә ничә тактадай юка, нечкә беләк өлеш сорап Кашшаф капчыгына үрелде. Авыл

малае артык гади шул, «кара көн»гә дип әнисе туплаган запасын уңга-сулга таратты. Ярый әле шулчак Котдус абыйсы килеп иңеннән тотты:

– Нишләвең бу? Күрмисеңмени мондагыларны ачтан интектергәннәрен, киләчәктә безгә дә шулар язмышы яный бит, – диде күпкә өлкән авылдашы, өметсезлек тулы аваз белән. Кашшаф айнып киткәндәй булды, капчыгына текәлеп карады, ул инде яртылаш бушап өлгергән.

– Җитте! – диде егет, сораучылардан чак аерылып.

Землянка эченә керделәр. Монда ярымкараңгылык хөкем сөрә. Яктылык, сүрән булып, бер кырыйда мунча тәрәзәсе зурлыгында уелган шакмактан гына керә, кирәк чагында чыра яндыралар. Төшке ашка барасылары юк, батальон ашханәсеннән аларга иртәгедән башлап кына баланда җибәрәчәкләр. Хәзинәдә бары белән канәгатьләнергә туры килде. Төштән соң инде яңа алынганнар белән «бабайларны» бергәләп ерактагы урман делянкасына куаладылар. Төннәрен, салкыннар башлангач, землянка һәм баракларда махсус көйләнгән «буржуйкаларны» (бигрәк тә кышларын) ягып җылытышлы. Утынны үзләре әзерлисе. Аяк астына калын кар ятканчы ашыктыралар. Әллә ничә чакрымнан биш-алты кеше чи бүрәнәне иңнәренә күтәреп лагерь ягына таба атлаганда, Кашшафның әлеге гайре табигый күренешне аңлый алмыйча, башы катты. «Нинди мәгънәсезлек бу, янәшәдә үк урман югыйсә?» – дип уйлады ул, үрсәләнеп. Ач, хәлсез курсантларның йөк күтәрмичә дә атлауларының рәте юк, бүрәнәләрен лагерь биләмәләренә кайтарып җиткергәнче, кырыкмаса-кырык мәртәбә привал ясарга туры килә. Аларны эткәләп-төрткәләп ашыктыручы кече командирлар һәм ниндидер шикле кыяфәтле, тук чырайлы елгыр адәмнәр («чыбыксыз телефон» бу затларның аерым баракта, уңай шартларда яшәп ятучы начальство куштаннары булуын кайтып җиткәнче үк белдерде) привалларны гына мөмкин кадәр кыскартырга тырышалар, һай-һулап:

– Лентяи, двигайтесь давай, – дип акырыналар. Куштаннарның күбесенең урысчасы ташка үлчим – алары вата-сындыра, бигрәк киртәгә сыймый. Шундыйлардан берсе:

– Трудна в учении, легка в баю, – дип, күп белдеклеләнеп теленә салына. Урман ешкынлыгыннан атлар кешнәвенә охшаш хырылдау булып көлү кайтавазы яңгырый.

## Баланда

Туклану урыны ачык һавада икән. Иртән тревога буенча уятылган курсантлар, землянкаларыннан чыгып, сафка тезелергә ашыкты.

– Кайда соң монда юынгычлар? – дип сорады Кашшаф янәшәсендәге иптәштән, беркемнең дә юынырга бармавын күреп:

– Юынгыч? – дип, сорауга каршы сорау бирде күршесе, шулай да ачыклык кертте, – туйганчы эчәрлек су эләксә, рәхмәт әйтерсең, юыныр өчен болганчык инеш суын ерактан махсус чаннарда ике-өч көнгә бер генә китерәләр.

Командирлар аннан-моннан барлау уздыргач, таралырга рөхсәт бирде. Һәр взвод аерым урында өстәлләр рәвешендә укмаштырылган урынга җыела. Иртәнге ашка бер кружка ком катыш кое суы белән ширпы кабыннан чак кына зуррак чиле-пешле ипи кисәге икән. Аны кабып йотканнан соң, сугыш «уены» серләренә өйрәнү башлана. Рота саен кырык биш миллиметрлы өч туп билгеләнгән. Аны җиде-сигез кеше төрле яклап эләктерәләр дә ярты сәгать дәвамында ары-бире йөгерәләр. Взвод командирлары вакыт интервалын

сәгать буенча күзәтә. Телләрен аркылы тешләрдәй булып арыган-йончыган курсантлар, «тукталырга!» дигән әмер яңгырауга, кырыйга чыгып, бушрак урынга ава, аларны икенче төркем алыштыра.

Ярты сәгать ял иткәннән соң, беренче төркемне строевойда атлап йөрергә куалыйлар. «Пичәтле» адымнар белән гадәти йөрү генә түгел, ике кешегә бер ПТР (танкка каршы ата торган мылтык) тоттыралар. Аны иңнәргә салган килеш ярты сәгать дәвамында җиңелчә генә йөгерергә кирәк. Болай да көчсез, ач курсантларның хәлсезлектән тез буыннары калтырый. Чираттагы ялга тукталганда, кайберәүләр инде җайлап утырудан узган – билгеләнгән җиргә килеп ава. Алай гына хәл керсә икән ул, ни арада узган диген ял дигәннәре – баш очында «Подъём!» боерыгы яңгырый. Тагын «кырык бишле»не ары-бире этеләп йөрүләр башлана. Кашшаф әлеге төр процедураларның һәркайсын төшке ашка кадәр өч мәртәбә үтүләрен санады. Ул – гәүдәле, таза егет, колхозда эшләгәндә, биш потлы капчыкларны да бер ыргымда җирдән җиңел генә җилкәсенә алып салганлыктан, үзендә нык талчыгу сизмәде. Ә менә гаиләле, икешәр бала атасы Котдус һәм Вәгыйз абыйлары, сулышлары кысылып, еш-еш сулый:

– Болай дәвам итсә, бер-ике айга да түзеп булмас, – диләр, кызганыч елмаеп. Хәер, елмаюга түгел, еламсырауга охшаган иде аларның кыяфәте.

Төшке ашка бер сәгать бирелә икән. Взводтан ике курсантка (курсант димәсәң, хәтере калыр: ике хәрбинең берсе өстендә өеннән киеп килгән кием) олы тас белән ярты чакрым чамасы арырак урнашкан батальон ашханәсеннән аш алып кайтырга куштылар. Берсенә Кашшаф алынды. Кулдашы да аның яшьләрендә. Алар савытларын күтәреп барып җиткәндә, башка роталардан да хәтсез генә аш-суга килүче җыелган, кечкенә чират хасил булган. Ике пар, күрәсең, нәкъ бер вакытта чиратка баскан – араларында тарткалаш та булып алды. Аларны тиз сүрелдерделәр, аш бүлеп торучыларның лейтенант погоннары такканы (хәер, аш бүлми, тәртип ягын гына күзәтә бугай), кухня ягы белән коридор арасындагы такта стена уемыннан башын тыгып:

– Хватит вам, гололобые, а то сейчас как врежу по морде! – дип бер генә акырды, «без алдарак, сез арттарак», дип чират бүлешүчеләр дәррәү тынып калды. Кашшаф ашханә хезмәткәрләренең, гади курсантлардан аермалы буларак, тук чырайлы, чиртсәң каны чыгарлык, бурлаттай кызарынган булуларына игътибар итте. Ризык әзерләү блогына ит исе дә таралган. Тик ул «учлаг» (учебный лагерь) курсантларына эләкми торгандыр, эләксә, элеп киптергән балык кебек булмаслар иде. Күрәсең, командный состав өчен аерым пешерәләр, бер уңайдан пешекчеләр дә шул ук казаннан туена булыр. Кашшаф лагерьдагы батальон һәм полкларга дип, тылдагылар авызыннан өзеп җибәрелгән төрле азык-төлек һәм итләрнең, курсантлар өстәленә куелмыйча, күбесен якындагы Мочалище авылына һәм Суслонгер базарына илтеп сатканнарын белми иде әле. Ул хәзергә иптәше белән алып килгән дәү тасларына баланда салып биргәннәрен көтә. Көл төсендәге сыекчада сыңар бәрәңге кисәкчеге дә йөзеп йөрмәгәнен күргәч, аның гаҗәпләнүенә чик-чама юк.

– Кайда соң моның ите, ярмасы? – дип сорады ул, аптырап.

– Ә син ничек уйлыйсың? – дип сорауга сорау белән җавап бирде кулдашы. – Учлаг ристаннары (әйе, ул нәкъ шулай диде) белән ашханә күселәре арасындагы аерманы күрмисеңмени?

Кашшафка гаҗизләнеп башын селкүдән башка чара калмады. Взводтагы солдатлар аларның кайтуын түземсезләнеп көткән. Һәркайсы кулына кашыгын

тоткан. Олы бер түшкә сарыкны пешереп алларына куйсаң, пычак белән кискәләп тормаслар, «ә» дигәнче, шул килеш умырырлар иде, мөгаен. Янә алтышар кешегә тәгаенләнгән табак сыман савытлар бар икән. Олы таста алып кайткан баланданы шул табакларга бүлделәр. Беравык калакларның табакка шакы-шокы бәрелеп, курсантларның кысыр шулпа чөмергәннәре генә ишетелеп торды.

– Фу, авызга алышлы түгел ич моны, – диде Кашшаф, беренче кашыгын кабу белән чыраен сытып. – Әллә әрем салып пешергәннәр тагын? – Арада хәрби хезмәткә алданрак чакырылганнар да бар. Шулардан берсе:

– Әрем түгел ул, энекәем, бәрәңге кабыгының әчесе. Тәм кертү өчен чак кына сохари оны кушалар, ул күбесенчә күгәргән була. Әнә шуларның тәме күңел кайтаргыч булып тоела да инде. Ачлыктан интекмәгән кеше боларны берничек ашый алмый. «Голод – не тётка», – ди урыс. Җан тәслим кыласың килмәсә, чөмерәсең инде.

Төшкелеккә бирелгән икмәк ике шырпы кабы зурлыгында иде. Ләчтек массаны хәтерләткән ул хикмәтне өч каптылар, ике йоттылар бугай – тиз арада бетеп тә китте.

## Бәла

– Подъём! На валку леса! – Взвод командирлары, талчыккан тәннәргә рәт кергәнче, әллә җир астыннан калкып чыктылар тагын, акыра-бакыра үз буйсынуындагыларны утырган урыннарыннан эткәләп-төрткәләп торгыза башладылар. Курсантларның буйсынмый чарасы юк, сугыш вакыты законнары буенча трибуналга бирүләре бар, физик каршылык күрсәтте, дигән сылтау белән атып үтерүләре дә ихтимал. Андый очраклар бар, диләр. Төштән соң кабат ерактагы делянкага «аркылы пычкы» белән ябалдашларын күккә терәгән агачларны аударырга киттеләр. Кемнәрдер чыршы-наратларны төптән кисеп аударса, кемнәрдер аларны ботакларыннан балта уйнатып арындыра. Алардан соң озын буйны биш-алты метрлы бүрәнәләргә тураклаучы өченче партия эшкә керешә. Кирәк кадәр запас тупланганнан соң, бераз ялга тукталалар. Аннары – кайтыр юлга. Моннан да җәфалы, бәгырьләрне суыра торган дөньяда тагын нинди шөгыль бар икән? Биредәге контингентның күпчелеге авылдан чыгып, урысчалары такы-токы булса да, алган белемнәре өч-дүрт (сирәк кенә – җиде) сыйныф белән чикләнүгә карамастан, алар бу кабахәт гамәлләрнең адәм балаларын мыскыллауга, ничек тә түбәнсетергә юнәлтелгәнлеген аңларлык хәлдә түгел иде. Лагерьга терәлеп диярлек шундый ук чыршы һәм наратлар, каен һәм имәннәр шаулап үсә. Аларга кагылдырмыйлар да. Әнә шул нәрсә җаннарны изә, чарасызлык акылдан шаштырыр чиккә җиткерә. Кырык беренче елны бу лагерьга эләккәннәргә тагын да кыенрак булган, диләр. Биш-алты чакрымнан иңнәрендә агач ташып кына калмаганнар, төннәрен аларны бүрәнәләр юнып, йорт-бараклар төзергә мәҗбүр иткәннәр, землянкалар казытканнар. Кайчагында, командирларның кәефенә карап, икенче көнне кәкре бүрәнәләрне, төзелеш өчен яраксыз, дип, кире элекке делянкаларына илттергәннәр. Кәкре булса да, утынга ярый югыйсә.

Кашшафлар арып-талып землянкаларына кайтып кергәндә, эңгер төшкән иде инде. Аларны алда зур бәла көткән икән – Вәгыйз абыйның биштәре юкка чыккан. Күпме генә эзләмәсеннәр, авылдашларының юл капчыгын тапмадылар. Сораштыруларның да файдасы тимәде. Элеккерәк килгәннәрдән

берәү әйтеп куйды шунда. Мондый хәл сирәк күренеш түгел, әледән-әле булгалап тора икән. Ачлыкка чыдый алмыйча, бәндә дигәнең урлаша, теләсә нинди адымга бара ди. Дус дигәнең дә сине авыр хәлдә калдырырга мөмкин. Вәгыйз агай:

– Сораган булсалар, сохариларымны үзем дә бирер идем, калагым белән калай кружкамны гына кайтарсыннар, – дип такмаклап елады. Алар калак һәм кружкасыз калуның мондагы шартларда ач үлемгә тиң икәнен инде аңлаганнар иде. Чөнки беркемгә аш өчен аерым тәлинкәләр каралмаган – алты кешегә бер табак. Ә кружка белән калакны өйдән алып килергә повесткада әйтелгән иде. Кашшаф якташ абыйсына ярдәм итә алмаудан өзгәләнде.

– Вәгыйз абый, бик бетерешмә син, ничек тә җаена чыгарбыз, – диде аннары, әлегә ничек җаена чыгасын күз алдына китерә алмыйча. Йокылары йокы булмады, өстәвенә бет талап җәфа чиктерә. Иртәнге подъёмга тиешенчә ял итмәүдән башлары чуен кебек. Тезелергә чыкканда, Вәгыйз абыйсы Кашшафка эндәште:

– Энем, хәлләр болай булса, хөрти бит әле, – диде ул, күзләрен сәер елтыратып. Егетнең «кабатлап әйтмәсәң дә беләм ич», дигән мәгънәдә каравын искәреп, – юк, мин биштәремне урлауларыннан гына әйтмим, – дип акланырга ашыкты. – Төнлә аз гына онытылып торган чагымда төш күрдем. Имештер, мин авылга кайтканмын. Өйгә кермәкче булам, өйалды эчтән бикле. Тартам, тартам, эндәшеп тә карыйм, һичкем чыгып ачмый. Аптырагач, абзар ягындагы тәрәзәгә барып капландым. Эчкә күз салсам, әти карт сукыр лампа яктысында итеккә олтан салып утыра. «Әти», дип кычкырам, бөтенләй ишетми, эшләвен белә. Тәки өебезгә керә алмыйча, караңгы япан кырга чыгып киттем. Шуннан салкын тиргә батып уяндым. Юньлегә түгел бу, Кашшаф энем, һай юньлегә түгел. Кашшаф мондый хорафатларга ышанмый иде, шулай да ишеткәннәреннән эченә салкын йөгерде.

– Куй әле, Вәгыйз абый, төш кенә ич бу, – дип, авылдашын тынычландырырга тырышты. – Шайтан белсен, һәр юк-барга игътибар итеп төшенкелеккә бирелсәң, тиз аягыңны сузарсың монда! – Вазгыятьне аз булса да уңай якка үзгәртергә көчсезлегеннән үзенә ачуы чыкты. Иртәнге бер кружка су һәм шырпы кисәге зурлыгындагы ипи кисәген алырга барганда, взвод командирыннан Вәгыйз абыйсы өчен кружка белән калак сорап карарга дигән уйга килде. Халыкта: «Уйланган эш – беткән эш», дисәләр дә, еш кына ул чынбарлыкка ярашмый. Кашшаф авылдашын кайгыртып калагын да, кружкасын да сорады анысы, тик взводныйдан ишеткән җавап кына артына утырырлык булды.

– Ты, чаплашка, что о себе возомнил? – дип җикерде лейтенант погоннары таккан кемсә. – Здесь вам не детский сад, а «у-ч-л-а-г!» – дип, һәр хәрефенә аерым басым ясап, каршысына ук килеп басты. Әнә күзләре белән ашардай булып Кашшафка текәлгән, ул аннан бер башка тәбәнәгрәк, астан өскә карый. Кулларын йодрыклап инде кизәнергә дә итенә бугай. «Сугып кына карасын, хөкемгә тартсалар тартырлар, берне чыраена манчыйм түлке, дип уйлады колхоз хезмәтендә чыныгып үскән егет. Аның урысчасы ярыйсы, юкка гына җиде ел укып йөрмәгән.

– А ты зачем орёшь? Ложку ведь только просил, – диде ул, явызны тынычландырырга теләп.

Әллә Кашшафның ишкәк зурлыгындагы кулларыннан шикләнде, әллә башка сәбәп, соңгы мизгелдә лейтенант, йодрыкка төйнәлгән бармакларын язып, читкәрәк китте һәм егеткә ярымборылган хәлдә:

– Сегодня вместо сна в землянке, ночью пойдёшь на наряд вне очереди, – дию белән чикләнде.

Көн артык вакыйгаларсыз: иртәдән төшкә кадәр туп сөйрәп, өйләдән соң ерак делянкага барып агач кисү һәм алып кайту белән үтте. Төшке баландага да Кашшаф, өлкәнрәк яшьтәгеләрне кызганып, бер иптәше белән үзе китте. «Әлегә кружкасы булмаса да берни түгел, ничек итеп Вәгыйз абыйны калаклы итәргә соң әле?» – дип баш ватты ул, ашханәгә барышлый. Ахырда пешекчеләрдән сорап карарга дигән фикергә килде. Безнең шикелле үк адәм балалары ич, ярдәм кулы сузмыйча калмаслар, дип тынычланырга тырышты. Мондагылардан юньле сүз ишетмәде егет, карап торышка ипле генә күренгән яшьрәгеннән ник соравына үкенде.

– Уйди отсюда, салага, и без тебя тошно. Дам я тебе сейчас ложку, врежу вот этим черпаком по лбу! – дип, кулындагы чүмечне уйнатып, яшелле-зәңгәрле тавыш белән ысылдады.

– А если я этим кулаком тебе по морде дам, – дип, йодрыгын сузарга өлгермәде, маңгае турысыннан выжылдап узган чүмечтән чак читкә тайпылып калды. Монда сүз озайтып торуның файдасыз икәнен төшенде ул, кухня ягында тыз-быз килгән унлап кешенең ике-өчләбе, эшләреннән бүленеп, аларны күзәтә башлады. Үзара бер-берсенә дә мәгънәле караш ташлап алдылар бугай. Болар җыйнаулап чыгып тәпәләп ташларга да күп сорамас. Ник болай таркау соң безнең халык, авыр чакта ярдәмгә килүне дә белмибез, дип ачынды Кашшаф. Шунда чиратта аның артында торганнардан берәү:

– Энекәш, баланданңны ал да, тизрәк моннан китү ягын кара, үзләренә аз гына каршы әйткәнне дә өнәмиләр алар, көтүләре белән чыгып «гаепле»не төя. Андый очраклар бер генә булмады инде.

Бәхете бар икән әле: Кашшафны ямьсез сүзләр белән күмеп ташлаган мәлгуньне шулчак начальниклары – кече лейтенант – ниндидер йомыш белән чакырып алды; бүре карашлы, халат җиңнәрен сызгана башлаган иптәшләре дә, ничектер, тукталып каласы итте. Шулай да арадагы берсе, таска баланда бүлгәндә:

– Мы это ещё тебе припомним, – дип, теш арасыннан сыгып чыгарды.

Вәгыйз абыйсына тиешле порция ипи кисәге куелган булса да, калагы юк. Димәк, ул баланда чөмерүдән мәхрүм калачак.

Кашшаф аңа үзенең калагын тоттырды.

– Вәгыйз абый, ал минем калакны, ал, никтер ашыйсым килми. Әче суны ашказаным да күтәрми бугай, – дигән булды, хәйләгә керешеп. Авылдашы моны гына аңламаслык түгел, карышып маташты. Шулай да бик кыстагач, ризалашты тагын. Үзара тарткалашып утырсалар, башкалар көтеп тормый – ашыга-ашыга авызларына калак арты калак озатуларын белә. Чиратлашып бер калак белән ашадылар инде. «Тамак тәмугка кертә», – дип әүвәлгеләр белмичә әйтмәгән шул, лагерьда адәм балалары тыныч тормыштагы миһербанлык, кешелеклелек сыйфатларын җуеп бетерә язганнар иде. Шулай булмаса, алар үзара киңәшеп, коточкыч бәлагә тарыган иптәшләренә ярдәм кулы сузар, аңа өлеш калдырыр иде. Кызганыч, мондый нәрсәнең эзе дә юк. Делянкага баргач, Кашшаф командирлардан һәм сакчылардан яшереп, авылдашы өчен агач кашык әмәлләргә булды. Тупас чыкса да, рәвешен китерде тәки. Нәфисрәк итәргә мөмкин иде, взвод командирларының, кайчагында ротныйның, йөренеп торулары комачаулый. Алар якынлашканны күрү белән, янәшәсендәге кулдашы тамак кыргалый һәм Кашшаф, кашык юнудан аерылып, ботак чабарга керешә.

## Җәза

Сентябрь ахырының кояшы урман артына тәгәрәүгә, землянкаларына кайтып җиттеләр. Тик Кашшафка, эчкәре үтеп, нардагы урынына сузылып ятарга язмаган булып чыкты, аны кулына винтовка тоткан солдат каршы алды.

– Тебя велено сопроводить на внеочередной наряд, – диде ул, ачусыз тавыш белән. Күрәсең, моның эше шөгыльне беренче генә башкаруы түгел. Тагын нидер әйтмәкче иде, яннарына взвод командиры лейтенант Иванов килеп басканны күреп, шып туктады.

– Пошли! – диде лейтенант, төксе генә. – Поработаешь малость на досуге, есть там такие же строптивые, как ты. Мигом собьём спесь.

Кашшафның буйсынмыйча чарасы юк. Лагерь аланлыгы янәшәсендәге тар ешкынлыкны үтеп, кечерәк аланлыкка чыктылар. Бер читтә ай яктысында кешеләр басып торганы шәйләнә. Аның кебек үк ниндидер гаепләре табылып, чираттан тыш нарядка эләгүчеләр икән. Кашшаф хезмәт иткән батальоннан гына түгел, башка батальоннардан да курсантлар бар булып чыкты. Моны алар бер-берсеннән кайсы частьтан икәнлекләрен сорашып белделәр.

– Разговорчики! – дип кычкырды капитан чинындагы офицер, – вас сюда привели камни таскать, а не болтать между собой.

Бу капитан кечерәк чиндагы берничә офицер белән бергәләп «киртәдән чыкканнар»ны җәзага тартуны үтәтү белән җитәкчелек итә икән. Башкалардан аермалы буларак, тавышында тимер чыңы сизелми – хәтта йомшак дип әйтерлек. Офицерлар арасында да төрле кеше бар, күрәсең, дип уйлады Кашшаф. Күп тә үтмәс, егет ялгышканын аңлар әле. Ә хәзергә алар өеп куелган уртача зурлыктагы ташлар таучыгына килеп орынды. Һәркайсы берәр таш күтәреп, бер-бер артлы күрсәтелгән тарафка юнәлделәр. Бер лейтенант озата бара, икенче читтән коралллы сакчы атлый. Ерак та түгел, йөз илле метрлар үтүгә, тиешле урынга килеп тә җиттеләр. Җәзага тартылучыларның беркадәр кәефләре күтәрелеп китте, болай булса, озакка китмәс, ташларны ташып бетерәбез дип шатланды алар. Тик бер нәрсә сәерсендерде – каршыларына алар шикелле үк ташлар күтәреп, нәкъ алар санындагыча алты кеше очрады. Аларны да бер офицер һәм коралллы сакчы озата бара. Кирегә буш кул белән барышлы түгел икән,читтәрәк яткан өемнән янә таш күтәреп илтешле. Аны ниндидер өченче өемгә алып барып салгач, иң беренче башлаган өем янына китерделәр. Гаҗәп хәл, ул никтер бер дә кимемәгән шикелле тоелды. Алты курсант алты таш күтәреп әүвәлге маршрутны кабатладылар – күтәргән йөкләрен аланның каршы ягындагы өемгә чыгарып салдылар. Өченче өемнән таш алгач – кабат кире маршрут, дүртенче өемне тулыландыру. Әйләнчек сарык хәрәкәтләренә охшаган шундый берничә ары-бире тугланудан соң, Кашшаф үзләре белән «җүләр» уены уйнауларын инде төшенгән иде. Җүләрләр йортында да шулай икән дип кемнәндер ишеткәне бар, аларны да, тик тотмас өчен, бер урыннан икенчесенә таш ташыталар ди. Аерма бары шунда: тегесе – бичара җаннарның дәвалану урыны, монда – курсантларны укыту-өйрәтү үзәге. Коточкыч хәл бит бу, югары командование белми микәнни соң? Иптәш Сталиннан да яшерәләрдер инде. Башкалар да эшнең нидә икәнен сизенде, күрәсең, арада чыш-пыш китте.

– Отставить! Пятнадцать минут привал, – дип әмер ирештерде һаман әле беренче өем янында басып торган капитан, тәмәке кабызып. – Уловили, голубчики, – җәзачылар башлыгы «голубчики»ны йомшак итеп әйтсә дә, бу

сүзгә мыскыллы мәгънә салган иде, – каждого, кто оказывает мало-мальское неповиновение командирам-инструкторам, ждёт суровое наказание. А теперь за работу!

Кашшаф хөр рухлы булып үсте. Кемнең кем булуына карамастан, әйтәсе сүзен кистереп алдында әйтә, кеше артыннан сөйләп йөрми. Монда, бәлки, әтисенең дә алар кечкенә чакта зимагурлыкта йөреп, шахтёр булып эшләве, авылына кайткач, балаларына тулы ирек бирүенең дә файдасы тигәндер. Менә хәзер ризасызлыгын белдерергә талпынып авызын ачты, шулай да соңгы мәлдә тыелып калды. Ахыры хәерле бетмәсен чамалады.

Аларны юкны бушка аударудан төнге икеләр тулып киткәч кенә туктаттылар. Иртәнге подъёмга башкалар белән бергә торырга тиешлекләрен искәртеп, землянкаларына һәм баракларына таралырга куштылар. Вәгыйз һәм Котдус абыйлары аның кайтуын әллә йокламыйча көткәннәр, урынына кереп ятуга, сораулар белән күмеп ташладылар. Җәелеп ачыласы килмәсә дә, өзек-төтек җавап бирде егет. Өлкәннәрне санламау була югыйсә.

– Энем, берүк сак була күр. Мондагы мәлгуньнәр башыңа җитәргә дә күп сорамас, – диде Вәгыйз абыйсы, чын күңелдән кайгырып. Авыр чакта үзенә ярдәм кулы сузган өчен аеруча якын итә ул аны хәзер. Киләчәктә Кашшафтан башка лагерь шартларында исән калуның икеле булуын авылдашлар яхшы чамалыйлар. Котдус абыйсы да үгет-нәсихәтен бирде. Әңгәмәгә шул урында янәшә нарда ятучы чуваш егете нокта куйды:

– Зиттеме инде цезгә, иртәгә тан былан торасы пар пит, йокларга пирмисез, – диде ул, татарчалатып. Кашшаф караңгыда үзалдына елмаеп куйды. Ул күп кенә чуваш һәм мариларның аның ана телендә сөйләшкәнен белә һәм акцент белән кәмәлен китереп сүз катуларына күңеле хушлана иде. Менә бу юлы да сизелерлек кырылган кәефе ачылып китте. Уң ягына борылып ятты да, бет дигән кечкенә хәшәрәтләрнең талавына карамастан, яшьлектә генә була торган тирән йокыга талды.

Өч-дүрт сәгать йоклау җитте, иртәнге тревога ишетелүгә, гәүдәсендә бернинди авырлык сизмичә сикереп торды.

## Лейтенант каныгуы

Тиешле порция икмәкне кабып куеп, бер кружка суны икегә бүлгәч, Вәгыйз абыйсыннан кичә ясап биргән кашыкның исәнме-түгелме икәнлеге белән кызыксынды.

– Үзең белән ал син аны, – диде ул. Хәзер алар калакларын землянкада калдырмыйлар иде. Запаслары кими башласа да, әлегә бар һәм аны ара-тирә капкалап куйгач, хәл кереп киткәндәй була. Үткән төндә «йокларга пирмисез пит», дип тузынып алган чуваш егете, «кырык бишле» тупны этәргә җыенганда, Кашшаф яныннан ишетелер-ишетелмәс кенә:

– Алтынны-артынны карап йөр, взводный полай гына калтырмас, – дип кисәтеп узды. Соңыннан ишетүенчә, ротада гына түгел, батальонда иң кешелексез взвод командирларының берсе икән ул. Аның каныгуына чыдый алмыйча, берничә курсант үзенә кул салган, кемнәрдер качып киткән һәм юкка чыккан. Лагерь җитәкчелеге үлем-китем күрсәткечләре буенча бу батальондагы взводның барсыннан уздыруына мөнәсәбәтле бернинди нәтиҗә ясамый микәнни соң, дип уйлады Кашшаф. Үзе чыгарган нәтиҗәдән аңа эсселе-суыклы булып китте: димәк, адәм баласын һәм физик, һәм психик

юкка чыгаруга юнәлтелгән әлеге төр алымнар биредә хуплана. Кичәге «җүләр» уены шуның бер чагылышы түгелмени? Бүген дә тупны эткәләп йөрүләр «ПТР» күтәреп йөгерүләр белән чиратлашты, өйлә туры җитте. Баланда алып кайтырга бүген бармаска булыр, буыннарга азрак ял бирергә кирәк», – дип уйлады Кашшаф, землянка янәшәсендә җайлап урнашкач күзләрен йомып. Минут та үтмәгәндер, баш түбәсендә лейтенант Ивановның тавышы ишетелде:

– За супом идти нет желания? – дия әнә.

– Нет. Сегодня пускай другие пойдут, – дип җавап бирде егет. – «Я один что ли?» – дигән сорау өстәмәкче иде, тагын тирәнгә китмәгәе дигән уйдан тыелып калды. Баландага чират буенча баралар икән, тиешле кешеләр үзләре китте. Ә болай, теләге булганнарны тыючы юк, хет көн саен ташы. Суслонгерда ничә ай тотасылары билгесез, көчне сакларга кирәк. Яңа килгәннәрдән генә түгел, элгәрерәк хәрби хезмәткә чакырылганнардан присяга алырга ашыкмаулары аңлашылмый иде. Дошман илнең үзәгенә ыргыла, Совинформбюро хәбәрләренә караганда, фронтларда хәлләр бер дә куанырлык түгел. Ә монда атарга өйрәтү түгел, кулга винтовка да тоттырганнары юк. ПТР бирәләр, ансы да патронсыз, мишень-макетлар да күзгә чалынмый. Иңнәргә таш төясәң ни дә, танкка каршы мылтык күтәреп йөгерсәң ни – аерма нуль.

Тупчылар әзерлибез диюләре нәрсә инде? Аны ары-бире эткәләп йөрүдән берни үзгәрми. Бер ай алданрак бирегә эләккәннәр дә, атып карарга туры килгәне юк, диләр. Коралны сүтеп-җыю, чистарту һәм майлау эшләренә өйрәтәләр ансы, түземлегең генә җитсен, дип фикер йөртте Кашшаф, эче пошып. Баланданы кайтарып җиткерделәр. Курсантлар дәррәү иялэнгән урыннарына утырыштылар. Һәркем калагын алып, түземсезлек белән алларына куелган савытларга өлеш салуларын көтә. Котдус, Вәгыйз, Кашшаф, чуваш егете һәм ике курсант бер өстәл артында. Вәгыйз кулында дәү агач кашык. Менә инде биш калак һәм бер кашык җамаяк белән алты авыз арасында кызу-кызу йөри башлады.

– Такое недопустимо! – дигән оран Вәгыйз агай кулындагы кашыкның читкә атылуы белән бер вакытка туры килде. Тагын шул Иванов! – Ложку не следовало потерять, теперь перебивайся как хочешь. Агач кашыктан да мәхрүм ителгән ир уртасы берни дәшмичә башын аска иде. Лейтенантның йөзендәге бер мускулы селкенми. Ул, кашыкны Вәгыйз кулыннан бәреп төшерсә дә, Кашшафка текәлгән, аның ризасызлык белдерүен көтә. «Түзәргә, ничек тә түзәргә!» – дип кабатлый эченнән Кашшаф. Ни ач булсалар да, башкалар да баланда чөмерүдән туктап, вакыйганың нинди юнәлеш алуын көтә, сагаеп әле взводныйга, әле үзсүзле татар егетенә карыйлар. Әүвәл күршедә тәгам җыючы «алтылык», аннары взводның башка курсантлары ашау темпын акрынайтты. Инде кашыкларның калай савытка бәрелеп шакылдаулары тынып ук калды бугай. Нидер булачак! Взвод командиры һәрвакыттагыча җиңүче булып калачакмы, әллә Кашшаф, кабат үзешчәнлек күрсәтеп, бу юлы катырак җәзага тартылачакмы?

– Вәгыйз абый, исең китмәсен, икебезгә бер калак җитәр, – диде Кашшаф, берни булмагандай. Лейтенантның үҗәт егетне ничек тә каршы әйттерергә теләп үрсәләнүен барсы да аңлый. Тик әлегә ул киртәгә сыймаслык бер сүз әйтмәде, ике кешегә бер калактан ашауны беркем тыя алмый. Иванов бу очракта ни кылыр икән – взвод һаман көтә.

– Говорите понятным языком, хватит каля-баля, – диде ахырда бәйләнчек

командир. Аңа ачуыннан иреннәрен чәйнәп читкә китүдән башка чара калмады. Барсы да җиңел сулап куйды. Авылдашы рәхмәт тулы карашы белән Кашшафка карый, күзеннән яше дә сытылып чыккан әнә. Башкалар да, хуплауларны белдереп, җиңелчә гүелдәшеп алды. Кемдер: «молодец, егет!» дип куйды, янәшәдә утыручы кайсыдыр якын итеп иңенә кагылды. Рәхәт булып китте Кашшафка, егермедән артык кеше арасында коллективта чак кына булса да җылылык атмосферасы тудыра алуы өчен. Һәркем ачтан үлмичә, җанын саклап калырга дип тырышкан кара урманнар арасындагы каһәрле урында золымга каршы бары бергәләп көрәшкәндә генә кеше булып калырга мөмкиндер, югыйсә аерым-аерым таптыйлар. Кечкенә өмет-сөенечләрне яралгы хәлендә үк юкка чыгарырга сәләтле лейтенант Ивановның тере өрәге торуын һәрдаим истә тотарга тиеш алар. Баланданы өч авылдаш – Кашшаф, Вәгыйз, Котдус – ике калак белән чиратлап ашадылар.

## Балык башы

Якшәмбе көнне, гадәти көннәрдән үзгә буларак, ашау рационын чак кына баеталар икән. Хәер, баету дип әйтергә ярыйдырмы – төшкелектә бирелә торган баландага, өстәп, кылчыгы-ние белән тозлы балык һәм балык башлары салалар. Ул балыкларның итен кем ашый торгандыр (анысын чамаларга мөмкин: командный состав һәм аларның куштаннары булыр), анысын курсантлар төпченеп тормый, тизрәк үз өлешен алып калырга ашыга. Тозлы суны хәтерләткән баланданы чөмереп, кылчыгын суыргалап утырганнан соң, һәркем биштәрдәге кадерле ризыгын шатырдатып чәйнәргә керешә. Гражданкада чагында эткә-мәчегә ыргытыла торган «деликатес»тан да тәмлерәк нәрсә юк бу чагында. Ләззәтләнүдән күзләр йомылган, хәтта шушы вакыт аралыгында гына булса да әйләнә-тирәдәге коточкыч чынбарлык та онытылган. Билгеле инде, балык башының ашарга яраклы җире аз. «Ач тамакка – барсы да мач», дигәндәй, курсантлар, чәйни торгач, аның яртысыннан артыгын барыбер кабып йоталар. Тозлы аштан соң үтереп тамак кибә. Шөкер, башка чагында үлчәп кенә бирелә торган кое суын бу көнне чикләү юк. Хәер, алай ук түгел икән: торымнан-торымга казылган коелар янына курсантлар чиратка тезелеп баскан, һәркемгә бер-ике кружка эчәргә рөхсәт. Чират бер кат үткәннән соң, теләгәннәр икенче әйләнешкә тезелә. Еш кына коеның төбендәге запасы төкәнеп, аннан инде ком катыш сыекча ала башлыйлар.

Якшәмбе, төштән соң, урман кисәргә йөрүләр дә юк. Һәркемгә ял бирәләр, моны икенче төрле «шәхси вакыт», диләр. Теләгән кеше өенә, туганнарына һәм якыннарына хат яза; теләгәне биштәреннән көзге кисәге һәм кайчысын (үзендә булмаса, кешедән алып) чыгарып, сакал-мыегын кыра һәм чәчен төзәтергә керешә. Бу төр хезмәтне взводтагы курсантларның берәр остарагы башкара ала, билгеле инде, нинди дә булса ризык бирү хисабына. Кемдер өстендәге киемен салып, шатыр-шотыр бет сытарга керешә. Ул хәшәрәтләрне чүпләп кенә бетерешле димени?! Учак тергезеп, кайчагында күпмедер вакыт «буржуйка» өстендә тотып, аларның чертләп коелуларын күзәтүчеләр бар. Арада хәлсез һәм хасталар күп, андыйлар землянкадагы урыннарына кереп сузылу ягын карый.

Кашшаф өйдәгеләргә хат язып салырга ниятләде. Уч төбеннән чак кына зуррак кәгазь кисәге һәм каләм юнәтеп, үзенең ике авылдашы

белән Суслонгер лагерена өйрәтүләргә билгеләнүен белгертәсе килде. Аларга укыту-өйрәтү үзәгенә китерелгән көнне үк биредәге тәртипләрнең катгыйлыгын читкә чыгармаска дигән кисәтү ясалган иде. Командирлар моны дәүләт сере дип аңлаттылар. Ә дәүләт серен чишү җинаять буларак бәяләнә. Хатларның цензура аша узып, ачып укылу ихтималы булуын әйттеләр. Моның ише өркетүләргә тамчы исе китмәде егетнең. Шулай да авыр шартлар турында җәелеп язуны башына да кертеп чыгармады. Әти-әнисен хафага саласы килмәде. Хатының зур өлешен авылдагы яңалыклар, өйдәгеләрнең хәл-әхвәлен сораштыруга багышлады, өстән-өстән генә лагерь хәлләренә тукталды: «Кадерле әтием, газиз әнием! Өйдән чыгып китүемә ике атнадан артса да, менә бүген генә – октябрь аена кергәч – сезгә беренче хатымны язып салам. Тазалыкларыгыз ничек, авырмыйсызмы? Абыйның фронттан хәбәре килмәдеме? Мин авылда чагында ук аннан хат алмаганга өч айдан арткан иде бит. Әгәр үзгәреш булса, кичекмәстән миңа белгертегез. Сеңелкәш мәктәптә укуын дәвам итәме? Өлгереше ничек? Кара аны, сеңлем, укуыңны ташлама!

Киләчәк – белемлеләр кулында. Читкә китеп, кешеләр белән тыгызрак аралаша башлагач, моның шулай икәнлеген яхшырак аңлыйсың икән. «Бөрлегән» бозауладымы инде? Бозауласа, ничәне китерде? Бүксәсе бигрәк дәү иде. Аны искә төшергәч, әнинең угыздан пешергән коймагын ашыйсы килеп китте никтер. Безне ач тоталар дип уйламагыз тагын, кунак сыенда яшәтмәсәләр дә, түзәрлек. Көннәр хәрби өйрәнүләрдә, үзебезнең хәстәрне кайгыртып уза. Командирларның: «Здесь нет мам, научись жить сам», дигән гыйбарәсенә инде күнегеп киләбез. Читкә киткәч, уллар әниләренең, ирләр хатыннарының ярдәменә мохтаҗ икәнлеге яхшырак аңлашыла икән. Сәдәф төшсә, аны тагасың; кием ертылса, ертыкны ямыйсың. Бусы – хатын-кыз вазифасы, бусы – ирләрнеке дип тору юк, барсына өйрәнергә туры килә. Хәер, әни, абый белән мине син инде кечкенәдән энә-җеп тотуның ир балалар өчен дә оят түгеллеген өйрәтеп үстердең. Моның өчен рәхмәт сиңа. Әти безгә: «Үзе егылган еламас», – дип әйтә иде һәрчак. Мондый тәрбия шулай ук дөрес булган. Әле дә хәтеремдә: сигез-тугыз яшьлек чагым иде бугай, өйгә елап кайтып кердем. Авыз-борын кан гына.

– Нәрсә булды, дөнья куптарып үкерәсең? – дип сорадың.

Шунда Түбән оч урамының миннән өч яшькә өлкәнрәк шадра Шакир малае Әхсән белән тәпәләшүемне, аның иптәш малайлар алдында сине «зимагур» дип атавы чыгырымнан чыгарды, дидем. Бу адымымны хупларсың, хәтта мине яклап Шакир абыйларга юнәлерсең, һич югы «молодец» дип аркамнан кагарсың, дип көткән идем. Ә син: «Дөрес әйткән, минем кебек читкә китеп йөрүчеләрне шулай атыйлар, – дидең. – Кыерсытучыңны бер сугуда аяктан егарлыгыңа ышансаң гына ташлан. Үзе егылган еламас, диләр, шыңшыма. Ну-ка, борыныңны сөрт!» – дип, миңа аркан борылдың. Ул чагында хәтерем калган иде. Үсә төшкәч, синең хак булуыңны аңладым. Һәрчак дөреслекне яклап яшәдең. Хәкимовларның маркасы элек-электән югары саналган, дия идең, горурланып. Әлеге хисне без – улларыңа сеңдерергә тырышуың бушка китмәде, дип әйтергә була торгандыр, әти. Һәрхәлдә, йөзеңә кызыллык китермәбез. Хуш, сау булыгыз, кадерлеләрем.

Фашист мәлгуньне оясында дөмектергәч, җиңү белән кайтып очрашканга кадәр. Улыгыз Кашшаф.

2.10.1942 ел».

## Яртысы – командирларга

Хатларны атнага бер мәртәбә Суслонгерга алып китәләр, аннан – күрсәтелгән адресатлар буенча җибәрәләр икән. Бирегә элегрәк эләккәннәр җавап хатының якынча бер айдан килүен әйттеләр. Алай булса, ноябрь җитә әле.

Көн саен лагерьдагы курсантлар янына кем дә булса килмичә калмый. Кайсының әтисе, әнисе, улының монда икәнлеген белгәч, бәрәңгесен, сохариен хәстәрләп юл капчыгына тутырган да тәпи-тәпи дистәләгән чакрымнар үткән. Кемнеңдер әби-бабасы. Соңгылары күбрәк тә, чөнки хезмәт яшендәгеләрне колхоз эшеннән бик җибәрмиләр. Гадәттә, авылдашлар мондый ерак юлга берничә кеше бергәләп чыга икән. Сугыш вакыты шул, юл тулы угры-карак. Талап, соңгы әйбереңне алып калырга да күп сорамаслар. Андый очраклар бар, диләр. «Юл газабы – гүр газабы» дип белмичә әйтмәгәннәрдер. Җылы вакытта, чана юлы төшкәнче, сәфәр чыгуның уңай ягы көн озынлыгында булса да, Суслонгерга кадәр күтәренеп ерак ара үтүләре һай ла авыр, инде күпме генә ризык алып барырга мөмкин соң? Кышкылыкта юл чыгучылар кул чанасыннан файдалана. Анда, өйдәге чамага карап, азык-төлекне мулрак төяү мөмкинлеге бар. Бер яхшының бер яманы дигәндәй, тәүлекнең якты вакыты саплам җептәй кыска булганлыктан, караңгы төшү белән, юлдагы авылларның берәрсенә тукталып, «кундырып чыгармыйсызмы?» дип йорт тәрәзәләрен чиртергә туры килә. Ара ераклыгына карап, Суслонгерга килеп җиткәнче, берничә тәүлек үтәргә мөмкин. Шуның кадәр кайтасы да бар әле.

Беркөнне, землянкалары артыннан ук башланган урман эченә кереп карарга дигән фикергә килде Кашшаф. Кыргый табигать кочагында балан, миләш, гөлҗимеш куаклары үсми калмас әле, юк чагында чәйнәр өчен аларның җимешләре дә ярап торыр. Төшке аш вакыты. Дежурныйлар батальон ашханәсеннән шулпа дип аталучы сыеклыкны кайтарып җиткергәнне көткән арада, җитешергә теләп, биш-алты сикерүдә өн-торакларының янына килеп басты. Тагын берничә адым атласа, аргы якта булачак. Шулчак колагына ниндидер ят авазлар ишетелгәндәй тоелды. Әллә тоелды гынамы? Игътибарын туплап тыңлап торды. Юк, кемнәрдер чыннан да сөйләшә. Тавышларның берсе лейтенант Ивановныкы ич. Аны уннарча кеше арасыннан да таныр иде Кашшаф. Нидер бүлешәләр кебек. Кайсыдыр ярым-йорты урысчасы белән:

– Тагда прасили сала. Ват привезли, – ди вата-сындыра.

– А почему так мало? – Бусы Иванов инде, ризасызлык белдерә торгандыр, аңа хас сыйфат. Кызыксынуы көчле иде, кемнәр икәнлеген белергә теләп, саклык белән, бәхәс барган якка үрелеп карады. Ике хәрби һәм ике граждански киемендәге кеше аяк асларына niләрдер таратып салганнар да базарда сатучы белән сатып алучы арасындагы сатулашуны хәтерләткән бәхәскә керешкәннәр. Икенче офицер – Кашшафларның рота командиры өлкән лейтенант Алексеев түгелме соң? Шул ич. Белүенчә, алай ук холыксыз түгел. Һәрхәлдә Иванов шикелле ерткычланмый. Курсантларга кизәнгәнен, ямьсезләнеп акырынганын да ишеткәне юк.

– Да ладно тебе, Иванов. Пожалей стариков, ты просил сало, они достали. Скажи спасибо, – дип, ротный Алексеев картларны яклап телгә килде.

– Товарищ старший лейтенант, не мы, а они должны сказать спасибо нам за то, что каждый месяц им разрешаем посещать своих внуков, – дип тасма телләнә лейтенант. Ротный урынында булсам, күрсәтер идем мин бу эткә! дип нәфрәтләнде егет. Мари картлары, ахрысы – киемнәре, сөйләшү рәвешләре

шуларныкына охшаган. Әйе, нәкъ шулай. Алар взводындагы ике чирмеш малаеның бабалары булырга тиеш болар. Ай саен киләләр ди. Әйтәм аны, чирмеш егетләренең өс-башлары башкаларныкыннан чиста-пөхтәлеге белән аерылып тора, яңаклары да суырылып кермәгән. Димәк, алар ачлыктан ул кадәр интекми, тик запаслары белән дә бүлешмиләр үзләре...

Кашшаф, офицерлар күзенә чалынганчы, тизрәк төшке аш бүленә торган урынга ашыкты.

## Җитмеш өч елдан соң

Кашшаф карт, хатирәләренә чумып бара торгач, йокыга оеган. Уңайлы «джип» тигез асфальттан урын юлга чыгып селкетә башлагач, күзен ачты.

– Дәү әти, уяндыңмы? – дип эндәште оныгы. – Без инде Суслонгерны уздык, хәзер кайчандыр лагерь булган җиргә якынлашабыз.

Камил, бабасының йөзенә чыккан борчылуны күреп:

– Дәү әти, аптырама бер дә, тоткан юнәлешебез дөрес. Әнә, навигатор бөтенесен күрсәтә, хәтта лагерьга ничә километр калганына кадәр билгеле. – Онык шулай дип, шофёр алдындагы панельгә урнаштырылган приборга ишарәләде. Гадәттә, алгы утыргычта йөрүне хуп күргән Камил бу юлы бабасы янәшәсендә баруны сайлады. Ул аның сәламәтлеге өчен борчыла, дулкынланулардан сакларга тырыша. Үзләре белән тынычландыргыч даруларны да мулдан алды. «Әллә шәфкать туташы ияртергәме?» – дип тә уйлаган иде дә, соңгы мизгелдә әлеге ниятеннән баш тартты – бабасының хәтерен калдырасы килмәде.

Карт фронтовик машина тәрәзәсе аша моннан җиде дистә ел элек колонна белән үткән юлларын танырга тырышып карап бара. Таныш та кебек, юк та. Баш түбәсендәге кояшны каплап үскән агачлар һаман шулар микән? Алар мине – ул чагында унсигезе генә тулып киткән малайны таныйлармы? Хәер, тешләре төшеп, чәчләре коелган, йөзен җыерчыклар каплаган картны ничек танысыннар ди. Ул агачлар киселмәсәләр дә, йөзьяшәр чиген узарлар иде. Монда яңалары үсеп чыккандыр. Кешелек дөньясы буыннарда алышынса, үсемлекләр дә яңарып тора ич. Бары хәтер генә кала. Хәтер сакланырга тиеш. Әгәр ул сакланмый икән, җирдә тереклек итүнең мәгънәсе юк.

Элек лагерь урнашкан урынны танымады Кашшаф Хәкимов. Биредә кайчандыр агач бараклар булгандыр дип уйларлык та түгел, ул корылмаларның эзләре генә шәйләнә. Землянкалардан балчык өемнәре генә калган. Терәү баганалары, түбә урынына җәелгән бүрәнәләр черек тузанына әйләнеп, туфрак астында басылганнар. Биниһая дәү мәйданны биләгән ачыклыкны төрле яклап үскән эреле-ваклы агачлар кысрыклаган. Әгәр энтузиастлар, монда сукмакны өзмичә, кирпечтән тыйнак кына һәйкәл күтәрмәсәләр һәм аның өстенә тимер каска урнаштырмасалар, бәлки, халык телендә үлем лагере дип аталучы урынны табып та булмас иде. Рәсми дәрәҗәдә Суслонгер «даны» һаман танылмады, аның күпмеңләгән корбаннарының да зур өлеше хәбәрсез югалганнар исемлегендә. Аларның җаннары моңа кадәр үзләренә сыену урыны таба алмыйча интегеп йөргәннәрдер дә менә хәзер шушы һәйкәл һәм аның янәшәсенә урнаштырылган гранит ташка килеп елышканнардыр кебек тоелды карт фронтовикка. Ташка «Суслонгерда 1941-1943 елларда ачлыктан һәм төрле авырулардан үлгәннәргә: якташлардан» дигән язулы калай беркетелгән. И-их, ул чаклар!

Оныгы Камил машина йөртүчесе белән, комачауламаска теләптер, читкәрәк киткән. Кашшаф карт хатирәләре белән япа-ялгыз. Зиһененең ерак почмагында моңа кадәр йокымсырап яткан лагерьга бәйле истәлекләре уй-хисләр дәрьясына яңа көч белән ташып чыкты.

## Ивановның этлеге

Никадәр генә саклап тотмасыннар, беркөнне Кашшаф юл капчыгыннан сохариларының соңгысын алды. Аны икегә бүлеп, зуррак өлешен Вәгыйз абыйсына тоттырды. Моңа кадәр ачыгалар иде, моннан соң ачка интегерләр, мөгаен. Бигрәк тә Вәгыйзгә кыенга килер. «Иртә уңмаган кич уңмас» дигән шикелле, Кашшафның землянкалар артындагы ешкынлыктан җыеп кергән миләш һәм баланнарын да ашый алмый. Югыйсә, октябрь кырауларыннан җиңелчә туңган җимешләр чак кына балланганнар. Кашшаф һәм Котдус, чырайларын сытып булса да, беркадәр уртлыйлар, ә Вәгыйз – юк. Бик кыстагач, бер-икене капкан иде, «булмый» дип кире төкерде. Нык ачыны организмы кабул итми икән.

Төшке аштан соң урман кисәргә барасылар. Кашшаф күреп тора: Вәгыйз абыйсының, барса да, бүрәнә күтәреп кайтырлык рәте юк. «Нишләргә соң әле?» – дип уйга калды. Ахырда Котдус абыйсына ярдәм сорап эндәшүдән башка юлын тапмады:

– Котдус абый, без синең белән миләш ашап та күпмедер түзәрбез, Вәгыйз агайны күрче, күз алдында сулып килә бит. Аз булса да, запасыңнан өлеш чыгар инде шуңа.

Котдус, кыргый табигать җимешләрен аның белән саранланмыйча бүлешкән егеткә рәхмәт йөзеннәндерме, дәшми-тынмый биштәрен ачып, ике кисәк сохари алды. Бер телемен Кашшафка, берсен Вәгыйзгә бирмәкче.

– Юк-юк, икесен дә әнә Вәгыйз абыйга бир, азрак хәл керсен.

Ир заты авылдашларына рәхмәтле иде. Елмаерга итенде. Тик йөзенә елмаю түгел, еламсырауга охшаш чалым чыкты. Урман кисүне делянканың лагерьдан өч чакрым ераклыктагысына күчерсәләр дә, барыбер ерак. Күпчелеге хәлсезлектән чак атлаган курсантлар өчен, урман кискәч, авыр бүрәнәләр күтәреп кайтуы – мең газап. Взводныйлар һәм ротныйлар кызгануны белми, өзми-куймый һаман каулый, аларның «шестёрка»лары да хуҗаларыннан калышмый. Кайту юлында әллә ничә мәртәбә ялга туктасалар да, алай гына көчләре артмый шул. Чираттагы тукталыштан соң, инде лагерьга ике-өч йөз адымнар калып барганда, Кашшаф үзеннән алда атлаучы Вәгыйзнең сөртенгәләп китүенә игътибар итте.

– Түз, чак кына түз инде, – дип эндәште ул авылдашына. – Артык көчәнмә, күтәргән атлы кылан гына. Егет иң артта, болай да бүрәнәнең юан башыннан күтәргән, Вәгыйз абыйсына биргән киңәшеннән соң, авырлыкның тагын да артуын сизде. Ярый, үзе ничек тә түзәр, башкалар гына тавыш чыгармасын.

Тавышны лейтенант Иванов чыгарды. Аларны күзәтеп баргандырмы, йөгереп килеп:

– Шире шаг! – дип, Вәгыйзгә китереп типте. Курсант аягында басып кала алмады, мәтәлеп китте.

– Ты что, мразь, косишь! – инде Иванов авыл агаена котырынып типкәләде. Кашшаф бер гаепсез кешене изгәннәрен тыныч кына күзәтсенме – юк, монысына юл куймас. Аның ымы белән кулдашлары иңнәрендәге йөкне җиргә

ташлады. Егет үзе бер сикерүдә лейтенантка барып җитеп, аны якасыннан эләктерде. Нык итеп үзенә тартты. Взводныйның гаҗәпләнүдән күзләре акайган, мондыйны башына да китермәгән, күрәсең. Ык-мык килеп, авызыннан сүз чыгара алмыйча интекте.

– В чём его вина? – сорауны Кашшаф бирде.

Тегесе дәшми генә кобурасына үрелде. Пистолетын тартып чыгарды әнә. Атачак хәзер. Үлсә дә, Хәкимов бугазлашып үләчәк. Фронттан качып, ерак тылдагы өйрәтү үзәген курсантларны җәзалауга әйләндергән урында бер ерткычка кимрәк булыр.

– Отставить! – кайсыныңдыр әмере Иванов кулындагы пистолетка көпшәсеннән ут бөркергә ирек бирмәде. Кашшаф коралны бәреп төшерергә өлгермәде. Өлкән лейтенант Алексеев икән.

– Я всё видел, лейтенант. Ты не прав. В конце концов, оставь в покое этих деревенских мужиков, – дип, ротный ары китте. Фаҗига булмый калды. Тик күпмегә? Бу юлы үчен ала алмаса да, Иванов болай гына калдырмаячак, уңайлы форсат туу белән, котырган эттәй тешен батырачак. Кашшаф моны гына аңламаслык түгел.

## Көтелмәгән кунаклар

Взводный шул көннән соң күпмегәдер тынычланып калды. Ул хәтта көтмәгәндә генә авылдан хәл белергә килгән Кашшафның бабасы белән Котдус, Вәгыйз абыйларның хатыннарына да сер бирмәде, гүяки, аларга бер катышы да юк. Кул арбасына төяп китергән әйберләрен карамады да хәтта. Гайре табигый хәл, күрәсең, ротный Алексеев, сөйләнә-сөйләнә, азык-төлек арасында актарынганда:

– Такое совсем на него не похоже, – дип гаҗәпләнүен белдерде. Ул, авылдашларның тозлап киптерелгән (бусы – Кашшаф бабасыныкы) казын һәм бәрәңгеләренең бер өлешен алу белән чикләнде. – Остальное передайте своим, – диде. «Бүләк»кә каз эләгү аның кәефен күтәргән иде.

Кашшафның октябрь башында язып салган хатын алу белән, өйдәгеләр Суслонгерга җыена башлаган. Аның нинди урын икәнлеген инде авылда белүчеләр бар икән. Егетнең әти-әнисенә колхоздан китәргә рөхсәт юк, ялынып сорагач, Котдус белән Вәгыйз абыйның хатыннарына ризалык биргәннәр тагын. Ике йөз илле чакрым араны үтәргә биш тәүлек вакыт киткән. Иртән таң сызыла башлауга, юлга кузгалалар, ялга сирәк кенә тукталып, күз бәйләнгәнче тәпили торгач, хәйранга җыела, ди. Шөкер, төн кунып чыгар өчен сугылган авылда йортына кертергә ризалашкан рәхимле бәндәләр табылып торган. Берсендә генә, эзләп-эзләп тә уңай җавап ишетмәгәч, кайсыныңдыр бакча башындагы печән чүмәләсен куышлап кереп, шунда төн уздырганнар.

Кашшаф язган хатында үзенекеләргә лагерьда аш калагының бик кадерле нәрсә икәнен сүз арасында бәян иткән иде. Харис бабасы яраткан оныгы өчен запас калак кына түгел, кружка да алып килгән. Авылдаш киленнәр дә ирләренә калак китергән – баедылар болай булгач!

– Мин патша армиясендә хезмәт иткәндә, бөтен әсбап казна исәбеннән иде: өс-башка тәгаенләнгән гимнастёрка, шинельише киемнәрне, аяктагы кирза итекне инде әйтмим дә. Чучканы хәрәмгә санаганлыктан, мөселман өммәтендәге солдатлар өчен аерым казанда хәләл иттән аш хәстәрләү дә сирәк күренеш булмады. Урыс-улак попларының кулын килеп үпсә, безне походка

полковой мулла дога кылып, хәер-фатыйхасын биреп озатты, – дип сөйләнде тәкъва карт, мондагы хәлләргә шаккатып. Учлагтагы курсантларның чуардан-чуар өс-башы, йончыган-таушалган килеш-килбәте аның ушын алган иде.

– Иң главный командирыгызга барам, – дип тузынды ул. Кашшаф белән авылдаш абзыйлар аны чак тынычландырды.

– Хәлне генә катлауландырасың, аннан бер файда юк, зыян булырга мөмкин, – дип ышандырырга тырыштылар.

– Якын арада унлап курсантны өр-яңа обмундирование белән тәэмин итәргә тиешләр, дигәнен ротный авызыннан ишеттем, – дип ялганларга мәҗбүр булды Кашшаф, үзләре өчен түгел, бабасының иминлеге өчен кайгыра башлап.

– Чынлап сөйлисеңме, балам? – дип, ихлас карашын кетер-кетер сохари кимерүче оныгына төбәде Харис карт, – теге, без китергән әйберләрне барлаган әфисәрегез турында әйтәсеңме? – Кашшаф, хәйләсе фаш ителүдән куркып, бабасына туры карамаска тырышты. Теш арасына сохари кисәге кысылган атлы кыланып, баш бармагы белән теш казнасын чистарткандай итенде. Ярый әле шулчак Котдус абыйсы ярдәмгә килде:

– Андый сүз минем колакка да чалынган иде шул, көнлек паёкны да арттырасылар икән, – диде, дөнья хәйләсен күбрәк үзләштергән агай бөтенләй арттырды. Картны ышандырдылар тәки, кирәкмәгән бәладән котылып калдылар.

Ирләр ирләр инде. Яшь ягы җитмешнең өске ягына чыкканы да, әле егермесен тутырмаган егет-җиләне дә эчке кичерешләрен тышка чыгарып селкеми, күпчелек күңел сандыгында бикләп тота. Хатын-кызның холык үзенчәлеге бөтенләй башка, аларның хисләр буасы ерылган, йөрәк ялкынын басар өчен, күзләреннән тибеп чыккан яшь тамчылары яңакларыннан тәгәри. Ир канатларын үзләреннән һәм балаларыннан аерып, кара урманнар арасына ташлаган каһәрләнгән сугышка, учлагтагы ристаннар кебек тотылучы кешелексез шартларга нәфрәтләнүдәнме, әллә инде тормыш иткән парларының тулыр-тулмас бер ай эчендә сулып-ябыгып калуларын күрүдәнме (хәер, болар бары бергәдер), Кашшафның авылдаш җиңгәчәйләре өнсез калган. Татар хатын-кызларына хас тыенкылык белән елаганда, ара-тирә «и-их» дип сулкылдап куюлары ирләренә ярдәм итә алмаудан гаҗизләнеп, тирән җан газабы кичерүләрен күрсәтә. Ирләр хатыннарын ничек юатырга белмичә аптырый.

Вәгыйз хатыны Маһруйбикәнең:

– И, җаным, нишләттеләр сине, чыкмаган җаның гына калган бит, – дип, яңагыннан сыйпавы, аның ашказаны авыруына дәва итеп кәҗә сөте эчерүләрен искә төшерүе уртакка әйләнгән хәсрәтне тагын да авырайта. Хасталык сарылыгы йөзенә типкән Вәгыйз түзмәде:

– Җә, ярар инде, насыйп итсә, монда озак тоткарламаслар, бәлки фронтка җибәрерләр әле, – дигән өн чыгарды. Монысы тагын да хәтәррәк түгелме? Фронтны, мизгел саен үлем сагалаган сугыш кырын адәм баласының котылу урынына тиңләве коточкыч хәл бит. Үзәгенә үтмәгән кеше болай беркайчан әйтмәс. Әле ишеткәннәреннән авылдашларга куркыныч булып китте. Вәгыйз ялгыш ычкындыруын үзе дә сизгән, тик инде эш узган, берничек тә кире кайтарып алып булмый. Ялганга дәвам ялгавын ачык аңласа да, ир заты хатасын төзәтер өчен:

– Әнә ич, көнлек паёкны арттырасылар, дип тә сөйлиләр, болай булгач, яшибез әле.

– Бик канә, Аллаһ рәхмәте белән шулай була күрсен берүк, – дип сөйләнде

кыз-хатыннар, ышанырга да, ышанмаска да белмичә. Күңел эчкәресендәге иң яшерен тоем аларга моның чынга ашмас теләк кенә икәнен искәртә, шулай да ышанмастайга ышанасылары килү көчлерәк. Әнә шул нәрсә яшәргә көч бирә дә инде, тәмам сынудан саклый, янәшәдә генә Зөлфирә белән Маһруйбикәнең хәлләләренә караганда да кайтышрак кыяфәтле, тере өрәккә охшашлы дистәрчә-йөзләрчә ир заты тора, көчле җил чыкса, аларны очыртып алып китәрдер төсле. Димәк, тамак кытлыгы монда күптәннән килә, вазгыятьнең уңай якка үзгәрүен гөманлау суга сәнәк белән язылган кебек, әлегә газизләре авызыннан гына ишетелә. Хәерле булсын.

Ирләр – хатыннарыннан, тегеләре – ирләреннән зур авырлык белән аерылды.

– Минем өчен дә балаларны кочаклап үп! – дип, хисләр иркенә бирелде Вәгыйз, соңгы чиктә, күз яшьләрен тыя алмыйча. Җебекләнүеннән оялыптырмы, Маһруйбикәсенең иңнәренә салынган да йөзен аның шәлъяулыгына терәгән. Бу хәл озаккарак та китте бугай, татарда моны артык нәзберекләнү дип, еш кына гаепкә саныйлар. Тик Суслонгерга мондый билгеләмә кагылмый торгандыр. Ир белән хатынның озаклап кочаклашып торуларының чын сәбәбен Кашшаф белән Вәгыйзнең үзеннән башка беркем белми. «И-их, абзыкай, нигә төшеңдә күргәннәргә шулкадәр ышанасың микән?» – дип уйлап өзгәләнде егет. Тыныч тормышта төпле һәм олпат күренгән агайның чүпрәкләнүе аны аптыраушта калдырган иде. «Ашказаны да авырта икән шул, күңел йомшаклыгы өстенә әлеге чир-сырхавы өстәлү хәлне тагын да катлауландыра инде», – дип авылдашын акларга тырышты. Хәер, Вәгыйз инде тынычланган, күзендәге яшь тамчылары да кипкән, хатынына елмая төшеп соңгы киңәшләрен бирә. Тегесе «әйе, әйе» дигән мәгънәдә башын селки, аның да талчыккан йөзенә елмаю кунган. Тик ир белән хатынның елмаюлары арасындагы аерманы Кашшафтан башка беркем сизмәде. Беренчесенеке газап белән өретелгән иде. Хәер, һәркемнең хәле хәл. Берничә минуттан ике хатын һәм бер карт ялыктыргыч озын юлга кузгалачак, бу төнне Суслонгерда кунганнан соң (кайда туры килсә, шунда), биш тәүлек туган авылларына кадәр кайтасылары бар. Ат юлы төшкәч, кул чанасына кирәк-ярак төяп, кабат килергә ниятләре бар икән.

– Аңа кадәр ничек тә түзегез инде, оланнар, – диде җитмешен тутырса да һаман әле җиргә нык басып йөрүче Харис карт. Оныгына карап эндәшсә дә, бөтенесенә карата әйтүе.

– Бабай, безнең өчен хафаланма. Ничек тә түзәрбез, – диде яңаклары сизелерлек суырылса да, яшәү дәртен җуймаган Кашшаф, күтәренке тавыш белән. Бабасы оныгын җылы карашы белән иркәләде, ул аңа үзенең яшь чагын хәтерләтә иде. Ул да шулай беркайчан күңел төшенкелеген белмәде, дошманнарына баш биргәне булмады.

Ай ярым чамасы вакыт үтәр, Харис янә Зөлфирә белән Маһруйбикәне ияртеп, ерак Суслонгерга сәфәр чыгар. Дүртенче тәүлек дигәндә, инде караңгыда (кышкы көн кыска шул), урман арасында юлларына угрылар аркылы төшәр. Чанага төялгән азык-төлекне «яхшылык» белән бирмәгәч, өч юлбасарның берсе йодрык сугышында үзләренә көчле каршылык күрсәткән картка арттан пычак белән кадар. Явызлар ашыгалар, куркышып бер-берсенә сыенган ике хатынның җанын кыеп тормыйлар, кулларына төшкән байлыкны өстерәп, урман ешлыгына кереп югалалар...

– И-их, Харис абзый, тамакларына тыгылсын иде, бирәсең калган ризыкларны, – дип елаша хатыннар, авыз-борыныннан ургылып кан бәреп чыккан, җан биреп ятучы баһадир гәүдәле карт янына тезләнеп.

Кашшаф бу хәлне сугыштан әйләнеп кайткач кына белде. Өйдәгеләр, хафага саласылары килмәгәндер инде, хатларында язмадылар. Зөлфирә белән Мәһруйбикәне дә авылда югалталар. Милиция аркылы белешә торгач, ерак районлагы НКВД бүлегенең тикшерү изоляторыннан кеше үтерүдә шикләнелүче мескен хатыннарны көчкә эзләп табалар.

Хәер, аңа хәтле вакыт үтәсе бар әле. Харис бабайның ерак юлдан арган-талчыккан хатыннарны җылы сүзләре белән канатландырырга тырышып, тизрәк кайтып җитәргә ашыктырасы бар. Кайткач та, ипкә килә алмыйча җәфаланган киленнәргә булышу йөзеннән, авыр колхоз эшенә чыгып, алмаш-тилмәш аларны алыштырасы бар. Ә хәзергә алар өчәүләп лагерь биләмәләреннән еракләша. Хатыннар әледән-әле артларына борылып карый. Кашшафның бабасы гына борылып артына күз салмый, ул моны яхшы фалга санамый. «Хуш, сау бул, бабакай», дип саубуллаша егет әүлиягә тиң бабасы белән күңеленнән. Мәңгелеккә аерылышуны күз алдына да китерми, әлбәттә. Белсәме?! Белсә?.. Гади адәм баласына алдан күрүчәнлек сәләте бирелмәгән шул. Бирелсә, тормышның кызыгы булмас иде.

## Өйрәнүләр

Бөек Октябрь революциясенең егерме биш еллыгы якынлашкан көннәрдә курсантлар арасында лагерьдагы Н-нчы укыту-өйрәтү дивизиясенең бер җыелма полкын якын арада фронтка озатасылар. Аңа кадәр присяга кабул итмәгәннәргә хәрби ант бирдерәчәкләр ди. Һаман гражданский киемнән йөрүчеләргә ашыгыч төстә гимнастёрка-чалбар, аякларына кирза итекләр бирделәр, шинель тараттылар. Обмундирование яңа түгел иде, шулай да ярап тора. Аңа кадәр махсус җиһазландырылган аерым зур баракта мунча – юыну урыны хәстәрләп, тәүлек әйләнәсе диярлек роталап-роталап юынып чыгарга мөмкинлек тудырдылар. Авылдан киткән көннәреннән бирле мунча әсәре күрмәгән Кашшаф һәм авылдашлары чистарган тәннәренең рәхәт изрәвен тоеп, беренче тапкыр тирән йокыга талды. Мунчадан кайтуларына, землянкалардагы ятакларны әйбәтләп дезинфекцияләгәннәр, тәнозын талаучы кечкенә хәшәрәтләр юкка чыккан. Бу арада ерак урман эшенә дә куаламыйлар, хәтта ашау рационын яхшырттылар: икмәк күләме ике мәртәбәгә артты, күпкә сыйфатлырак та; баландада кабыгы гына түгел, бәрәңге кисәкләре дә күренә башлады, ара-тирә кечерәк ит кисәкләре йөзгәли. Болай булгач, хәлләр үзгәрә бит, ачтан үлмәбез, шәт, дип сөенде халык. Лагерь бер төркем генералның комиссия белән киләсен көтә, ди, имеш – шуннан куркалар, янәсе. Ләкин курсантлар моны чынга алмады.

Көннәр өйрәнүләрдә уза. Күбрәк стройда пичәтле адымнар белән йөриләр. Пушкага ябышып әрле-бирле эткәләүләр, БТР күтәреп җиңелчә йөгерүләр тукталды диярлек. Лагерьга килгәннән бирле нибары ике тапкыр күзенә чалынган батальон командиры беркөнне, Кашшафлар ротасында пәйда булып, полк полигонына мишеньгә атарга барырга, дигән әмер ирештерде. Күпләр гаҗәпкә калды – ике ай хезмәттә булучыларның да мондыйны беренче ишетүе, имеш. Рота һәм взводлардагы һәр өч кешегә берәр винтовка өләштеләр, һәр курсантка – өчәр патрон. Тир-полигонда ата торган позициядән йөз илле метр ераклыкта дошман солдаты килбәтендә фанердан ясалган мишень әмәлләгәннәр. Уңайлап яткан курсант аның акрынлык белән басканын көтә. Механик ысул белән хәрәкәткә китерелгән «дошман» бөтен буена торып

басуга, бер минут эчендә бер-бер артлы өч ядрәне «күкрәк» турысындагы түгәрәкләргә туры китерүчеләр сирәк булды. Кашшафның ике атканы «сөт»кә китте, соңгы ядрәсе шулай да «сигезле» түгәрәкне тиште. «Котырган» кушаматлы комбатның үзен тыныч тотуына аны якыннан белүчеләр аптырады. Холыксызланган, нишләгәнен белештермәгән комбат (кырык беренче елда лагерьдан качкан ике дезертирны строй алдында пистолеттан атып үтергән, диләр) үзеннән түбәнрәк чиндагыларны кыйнап-имгәтеп ташларга да күп сорамый иде. Аның аек чагын сирәк күрәләр. Бүген салмаганга охшый: даими аракы чөмерүдән кызарып торган шешенке йөзе күксел-саргылт төскә кергән. Курсантларның «икеле»гә бәяләрлек ату күнекмәләрен чыраен сытып күзәткәннән соң, ротный Алексеевны янына чакырып китерде. Тегесе, әнә, честь биргәннән соң үрә катып тора.

– Вы продолжайте, старший лейтенант. Я, пожалуй, пойду. Надо подготовиться к приезду высоких гостей, – дип, әллә ротныена, әллә үз-үзенә сөйләнде.

Алексеев:

– Есть, так точно, есть, – дип, ярарга тырышып кабатлавын белә. Ниһаять, майор китеп барды. Мәскәү комиссиясен каршыларга әзерләнү өчен түгел, баш төзәтергә. Командирларның мөгамәләсе уңай якка үзгәрүе, ашауның яхшыруы әнә нәрсәгә бәйләнгән икән. Димәк, таралган чыш-пыш дөрескә чыга. Хәер, офицерлар инде моны яшереп тә тормый, курсантлар алдында ачык текст белән сөйләшәләр.

Комиссия дигәннәре килсә генә ярар иде, дип, чын күңеленнән теләде Кашшаф, бу турыда ишеткәч. Ничек тә берәр югары чин янына үтеп, биредәге хәлләрне сөйләр: «Ышанмагыз боларга, монда барысы да ялган!» – дип кычкырыр иде. Комиссияне көтүнең җитди сәбәбе бар – егет үзен утлы күмер өстендә йөргәндәй хис итә, комиссия әгъзаларына лагерьдагы хәлләрне аңлаткач (ул алар белән очрашып сөйләшәчәгенә тамчы да шикләнми), үзен фронтка җибәрүләрен гозерләп сорар – каршы килмәсләр әле, ял йортына түгел, сугышка ашкына ич.

Полигоннан арып кайтып, нардагы урынына сузылып яткач, Кашшаф үзендә канәгатьлек сизде. Бу – хәрби хезмәткә чакырылганнан бирле, күңелендә туган беренче зур канәгатьлек. Йокыга оеп барганда, баш миендә соңгы уе сызылып узды – лагерь оешканнан бирле, елдан артык вакыт эчендә үзәктән бер тикшерүченең килеп карамавы гаҗәп хәл... Аннары тагын ниндидер уй калкырга талпынды, тик туып өлгерә алмады, йокы кочагында эреп, төшләр дөньясына кереп адашты ул.

Алтынчы ноябрь таңында, йокыдан торып, көндәлек процедураларны үткәннән соң (соңгы атнада ашатуны яхшырту белән беррәттән, ике-өч көнгә бер юынгычта юынуны көн саенга әйләндергәннәр иде), стройда барлау уздырганда, рота командиры курсантларга плацта полк күләмендә тезелү булачагын, анда хәрби ант кабул иттерәчәкләрен әйтте. Ант бирүчеләр Ватанга һәм бөек Сталинга тугрылыкларын полк командиры подполковник Дьяченко белән лагерь начальнигы полковник Чистоплюев каршында белдерәчәк. Курсантлар, аптырап, бер-берсенә караштылар, җиңелчә гүелдәшү йөгереп узды.

– Разговорчики, – диде ротный Алексеев, каты кычкырмаса да, нык тавыш белән. – Есть курсанты, находящиеся здесь по три месяца и более, их срочно отправляем в составе сводного полка на фронт. Вопросы будут?

Сорау бирүчеләр юк иде. Кәефләр кырылган. Ничек була соң әле бу,

офицерлар авызыннан: Мәскәү кешесе килә дигән сүз чыккач, шуңа өметләнгәннәр иде. Югары нәчәлство бернинди киртәгә сыймаслык тәртипсезлекләрне ачыклап, гаеплеләрне җавапка тартыр, шартлар яхшырыр, дип өметләнгәннәр иде. Берсе дә булмас микәнни? Курсантлар арасында лагерь башлыгы һәм полк командирлары гына түгел, комбатларга кадәр балда-майда йөзәләр, дигән сүзләр йөри. Учлагтагылар өчен җибәрелгән өр-яңа шинель һәм гимнастёркаларны (хәтта кайры туннар) ниндидер шикле адәмнәрнең Мочалище, Суслонгер базарларында сатып торуларын еш күрәләр, ди. Хәтта полковник Чистоплюев яхшы токымлы этенә каймаклы беленгә кадәр ашата, имеш. Әлегә имеш-мимеш булып таралган сүзләр чыннан да дөрескә чыгачак. Кремльгә кадәр барып ишетелгәч, маршал Климент Ворошилов үзе, пистолетын чыгарып, строй алдында берничә зур чиндагы офицерны атып үтерәчәк. Шул хәлләрдән соң ике атна үтәр-үтмәс, Суслонгер лагере яшәүдән туктаячак. Хәер, болар хакында Кашшаф Хәкимов һәм исән калган учлаг «ристаннары» бик соңлап беләчәк. Ә хәзергә чиләнүләр дәвам итә.

### Кабат элекке тәртипләр

Ике көн эчендә дивизиядәге полкларның һәркайсында полковниклар, подполковниклар хәрби ант кабул иттереп бетерде. Батальоннардан тиз арада сайлап алып, җыелма полк тупладылар һәм Суслонгерның үзенә озаттылар. Аннан – Сталинград юнәлешенә. Идел буендагы башбирмәс бу кала астына фашистларның фельдмаршал Паулюс җитәкчелегендәге гаять зур группировкасы чолганышта калган, ди, совет гаскәрләре менә-менә һөҗүмгә күчәчәк. Моның өчен җанлы көчләр катастрофик рәвештә җитешми икән. Аннан-моннан өйрәтелгән, ачлыктан чак җан тәслим кылмыйча калган кичәге курсантлардан нинди сугышчылар чыгар, анысы комсоставны кызыксындырмый. Сугыш дигән утлы аждаһаның туймас тамагы һаман җаннар сорый, миллионлаган җаннар.

Кашшафлар взводындагы егерме биш кешедән ай ярым чамасы вакыт эчендә өч курсант ачлыктан һәм төрле авырулардан вафат булды, тагын дүртесен (шулар арасында алдарак телгә алынган ике мари егете дә бар) җыелма полк составына керттеләр. Землянкада, яңа положение килгәнче, аларның саны хәзер унсигез. Урын иркенәйгәч, сулар һава арткан кебек. Тик мондый иркенлек озакка бармастыр.

Урын тарлыгына ияләнергә мөмкин, ачлыкка ияләнеп булмый. Учлагта ашау-эчүне тиешле нормада бирсәләр дә, полкны фронтка озату белән, бар да элекке эзенә төште: иртәнге ашка кечкенә ләчтек икмәк кисәге белән бер кружка су, төшкелеккә баланда, кичке якта янә такы-токы. Моның белән ерак китә алмассың. Саклап тотканга гына авылдан китергән запаслары бар. Анысы төкәнгәч, ни хәл итәрләр? Авылдашларга артык кашык булып, чуваш егете дә өстәлде. Элегрәк бертуган апасы хәл белергә килеп ризык запасы калдырса да, инде озак вакыт янында беркем күренми. Ачыга мескен. Өч авылдаш кичкелектә «буржуйка» өстендә ике бәрәңгене урталай бүлеп пешергәннән соң, ашарга әзерләнгәндә, Кашшаф Борисның (чувашның исеме шулай) йотлыгып карап торуын искәрде. Ачыгучылар күп, аңа инде ияләнделәр. Кашшаф шулай да үз өлешен тыныч кына кабып куя алмаслыгын аңлады.

– Абзыйлар, бу кисәкне Бориска бирикче, – диде ул, тегеләрнең ризалашуына ышанып җитмичә. Авылдашлар беравык карашып торганнан соң, ярар инде,

сиңа «юк» дип әйтү барыбер файдасыз, дигән мәгънәдә кул селтәделәр. Борисның күзләре яшьләнде:

– Татарлар, чувашлар – пез пер тамырдан пит, төркиләр, – дип сөйләнде, – авыр чакта терәк пулыйк. – Ярдәм итүләре өчен, үзенә ризык китергәч, һичшиксез, өч авылдаш белән бүлешәчәгенә ышандырырга тырышып сөйләнде.

– Күп лыгырдама, ашавыңны бел, әйдә, анысын өеңнән ризык китергәч, бүлешерсең, – дип, Котдус абыйлары Борисның кулына ярты бәрәңгегә өстәп бер кисәк сохари тоттырды.

Мәскәү комиссиясенең килмәве билгеле булу белән, офицерларның башбаштаклыгы тагын башланды. Акыру-бакыруларына түзәр идең, беркөнне Алексеев белән Иванов ротадагы өйрәнүләрнең вакытлыча туктатылуын, бүген-иртәгә кыш башлануы көтелгәнлектән, курсантлар батальонлап, полклап утын әзерләргә җәлеп ителәсен әйттеләр. Болай да кырылган кәефләре тагын да төште. Көненә бер мәртәбә иңнәргә бүрәнә күтәреп кайтуы үзәккә үткәнче, көнозын урман кисеп һәм ташып ничек түзәрбез, дип уфтанды курсантлар.

Якындагы делянкадан булса да, урман егып ташуның авырлыгын шахтада көнозын кәйлә белән күмер чабучыныкы белән генә чагыштырырга буладыр. Татар кешесе элек-электән иң авыр эшләргә тартылган: читкә китеп, лашманчылыкка ялланган, забойга төшеп күмер чапкан. Хезмәтнең һәр икесе куркыныч. Лашманчылыкта өстеңә агач төшеп үтерү куркынычы янаса, җир асты тирәнлегендә терәү баганаларының сынуы яки метан газы шартлавы күпләрне харап иткән. Кашшафның әтисе үзенең шахтада, штрек ишелеп, ташкүмер кантарлары астында калуын сөйләгәне бар. Инде исән калуга өмете өзелгәндә, ярый әле коткаручылар табып алган. Бер аягы гомерлеккә чатан калса да, башы исән. Алар бәхетенәдер инде. «Бер яманның – бер яхшысы» дигәндәй, гарип аягы аны сугышка алынудан коткарды. Югыйсә, ике улы кебек ул да ут эченә озатылыр иде. Урман кисәргә барганда, Кашшаф шуларны искә төшерде.

Урман эче пычкы, балта тавышларыннан шау-гөр, чаж-чож килә, боларга агачны егар алдыннан кулларына пычкы тотканнарның «бойся!» дип кычкыруы һәм куе ябалдашлы озын агачларның гөрселдәп авуы өстәлә. «Бойся!» – янәшәдәгеләрнең, искәрмичә, кинәт агач астында калып сытылмавы өчен кирәк. Агачларны тиешле озынлыкта кискәләп, лагерь биләмәләренә ташу бер чакрымнан артмаса да, курсантлар көненә арлы-бирле өч кенә хут ясарга өлгерә. Баланданың егәре шуннан артыкка (хәер, нинди егәр турында сүз булырга мөмкин) җитми. Командирларның һәм «шестёрка»ларның эткәләп-төрткәләп акырынулары да ярдәм итми. Ноябрь көне ярый әле кыска, кеше дигәнең техника түгел – аның җаны бар.

Биш көн кышка утын запасы әзерләп чиләнгәннән соң, алтынчы көнне курсантларның күбесе тәмам хәлсезләнеп, иңнәрендә бүрәнә күтәреп кайта алмас чиккә җитте. Яшьләр әлегә түзә, өлкәннәрнең хәле хөрти: атлап барган җирдән сөртенеп, егылып китүчеләр бар. «Ач рацион»га (курсантлар лагерь рационын ачы шаяртып шулай атый) запасыңда булган бер кисәк сохари һәм бәрәңгене өстәп кенә (кайберләрдә анысы да юк) әлләни хәл керми шул. Командирлар батальон һәм роталарда бер көн булса да ял бирмичә, вазгыятьне җайлап булмасын аңлады бугай. Алтынчы көнне көч-хәл белән ике хут ясаганнан соң, иртәгесенгә ял игълан иттеләр. Моңа төшке аштан соң «яңа» курсантлар килүе дә сәбәп булды. Аларны урнаштыру байтак

вакытны алды. Бу көнне стройга тезеп кичке барлау да уздырмадылар. Иртәнге барлауда батальонның өченче ротасыннан ике солдатның юкка чыгуы билгеле булды. Плацка аерым роталап кына тезмичә, бөтен батальонны бастырдылар. Дулкынланудан бите тимгелләнеп чыккан, калтыранган куллары белән кесәсеннән кулъяулыгын чыгарып, әледән-әле тирләгән йөзен сөрткәләүче комбат строй каршында туктаусыз йөренә. Тавышы гасаби:

– Дезертиров всё равно поймаем, приведём сюда и я самолично с ними расправлюсь! – дип кычкыра ул. – Чтоб впредь остальным было неповадно.

Качучыларны табып кайтарганчы, плацтан таралырга беркемгә рөхсәт юк. Рота һәм взвод командирларыннан, «шестёрка»лардан тупланган зур гына төркем, берничәгә бүленеп, төрле якка таралышты. «Шестёрка»ларны әнә нәрсә өчен файдаланалар икән. Этләр дә иярткәннәр. Дезертирларны эзләү өчен монда махсус этләр дә тотыла, дип сөйләгәннәр иде, шул дөрескә чыкты. Менә хәзер Кашшаф үз күзләре белән күрде. «Ял иттек, болай булгач, – дип уйлады ул. – Плацтан таралырга рөхсәт бирмичә торулары качып китүчеләргә карата тирән нәфрәт хисе тудырыр өчен эшләнә булыр».

Күзәтчелек итәргә калдырылган кайбер взводныйларның һәм рота командирының башта эткәләп, аннары типкәләп йөртүенә карамастан, кайбер хәлсезрәкләр җиргә утыра башлады. Андыйлар артканнан артты. Командирларның сукранудан тамаклары карлыкты. Ахырда, файдасызлыгын күреп, кулларын селтәделәр. Кар катыш яңгыр ява башлады. Кешеләр туңа, эчләренә суык үтте. Бер-берсенә елышып, җылынырга телиләр. Моның файдасы аз, чыланган өс-баш белән җылынырсың, бар.

Каядыр еракта, артыннан эз калдырып, күккә ракета чөелде. Шуннан соң бер сәгать вакыт үткәндерме, эзләүче төркемнәр плацка җыелды. Комбат туңган-өшәнгән гавам алдында кыска гына нотык тотты:

– Дезертиры при задержании оказали сопротивление и, во избежание жертв, были уничтожены, – дип аңлатты. Майорның тавышы ышанычсыз чыкты. Әллә алдаша. Мөгаен, шулайдыр. Дөресен сөйләсә, тавышы чыңлап торыр, үзен җиңүче кыяфәтендә тотар иде. Аннары качып китүчеләргә каян корал килсен ди? Эзәрлекләүчеләргә кусәк белән каршылык күрсәтсәләр генә инде. Ышандырмый. Этләр иярткән кораллы таза бәндәләргә хәлсез ике качкынны зарарсызландыру берни тормый. Кашшаф күңеленең бер почмагында үзенә дә аңлашылмаган сәер тойгы уянуын сизде. Бу тойгы качу белән бәйле. «Карале, – ди шайтан котыртыгы, – бик яманга китсә, андый вариант та бар икән (соңгы вакытта занятиеләрдә, урман кискән чагында еш кына кемнеңдер карашы белән үзен бораулавын тоеп, сискәнеп борыла. Лейтенант Ивановның ашыгып читкә каравын искәреп өлгерә – ниндидер этлек уйлый булыр). Юк, юк, миргә язмаганны. Хәкимовлар нәселенә андый түбәнлек төс түгел. Искәрмәгәндә һөҗүм ясамаса, аңа гына бирешмәслек рәте бар аның. Авылдашларын ташлап калдырыруны да егетлек дип булмый, аларның киләчәк язмышы нинди юнәлеш алыр?» Лагерьга килгән иң беренче көннәре исенә төште. Ул чагында өч курсантның качу очрагы турында сөйләгәннәр иде, аларны да каршылык күрсәткәнгә атканнар, имеш. Андый хәлләр кабатланып тора, ди. Эзәрлекләүчеләр дезертирлар эзенә төшәдерме-юкмы, анысы караңгы. Атып үтерүләре дә алар намусында калсын.

– Разойтись по своим жилищам! – ораны яңгырады. Майорның әмере Кашшафны чынбарлыкка кайтарды. – После обеда объявляется активный отдых.

Яңа килгәннәр төшкелеккә алып кайткан баланданы ашаудан баш тартты.

– Фу-у, авызга алышлы түгел ич моны, – диде арадан берсе, мишәрчәләп. Взводның элекке составыннан кайберәүләр елмаешып баш чайкады. Котдус агай, биштәрләреннән үзләре белән алып килгән өй сыен бөкләп утыручы егетләргә карап, киңәшен бирде:

– Егетләр, запасларыгызны саграк тотыгыз. Сез мондагы шартларны белмисез. Ачыгасыларыгыз алда әле. Әче баланданы тавык шулпасыннан ким күрмәссез.

Туклыклылыгы булмаса да, җылы баланданы күбрәк чөмергәч (ашамаганнар өлеше дә тия ич), тәннәренә җылы йөгерде. Һавалар бозылганнан бирле, землянкада тукланалар. Эчтә кеше күплектән, тынчу. Шулай да бәрәңге пешерергә, кием киптерергә буржуйкага ягып җибәрделәр. Тагын да тынчурак булып китте – вентиляция хезмәтен үтәүче бердәнбер төннек кенә һаваны җилләтеп бетерә алмый. Төшке аштан соң, өлкәнрәкләр генә түгел, Кашшаф яшендәгеләр дә, атна дәвамында эшләп ватылган гәүдәләренә ял бирергә теләп, нарларына сузылып ятты. Яңа килгәннәр әлегә ачлыктан интекмәгән, энергияләре ташып тора.

– Цез ял итегез, – дип, мишәр малае иптәшләрен ияртеп землянкадан чыкты.

## Иванов һөҗүме

Соңгы атнада ташыган бүрәнәләрне ике көн дәвамында роталарында кисү һәм яру белән шөгыльләнделәр (элек ташыган агачлар кисеп-ярылып күптән әрдәнәләргә өелгән). Монысына гына түзәрлек, чи бүрәнәне иңнәрдә чакрымнардан ташу түгел инде. Лашманчылыкка башка кумаслар, кышка җитәрлек запас туплангандыр дип уйлаганнар иде, алай булып чыкмады. Полк командирларының әмере – батальоннарда, комбатларныкы роталарда курсантларга ирештерелде. Аның әйтүенчә, тагын өч көн буена урман кисүдә алны-ялны белмичә эшләргә тиешләр икән. Югыйсә, кыш узган елгы шикелле зәмһәрир килсә, ягулык запасы җитмәс дип шикләнәләр. Бу хәбәр күпләрнең котын алды – ничек чыдарлар? Болай да аякларын чак сөйрәп йөриләр. Өстәвенә, соңгы көннәрдә, төбе тишелгәндәй, яңгыр катыш кар бөтен күк йөзен иңләп ява. Тора-бара ул бозга әйләнде. Аяк асты тайгакланды. Юньле хуҗа этен урамга чыгармаслык, дип тормадылар, курсантларны якындагы делянкага куаладылар. Эшләгәннәре эш булмады, командирлары каһәрләве астында көч-хәл белән лагерьга ике хут ясый алдылар: берсен – төшкә кадәр, икенчесен – төштән соң. Икенче көнне урман егу турында уйларлык та түгел, кая ул – бүрәнә күтәреп кайту. Суытып җибәргәнлектән, җир өсте бозланган, җитмәсә хәйран гына кар да төшкән. Саклык белән генә атламасаң, егылып имгәнүең дә ерак йөрмәс. Командование моны гына аңламаслык түгел. Тик тотмас өчен, кичә ташыганны түмәркәләргә тураттылар. Түмәркәләр пүләннәргә әйләндерелде.

Һавалар ачылу белән, курсантларны кабат ике-өч көнгә урман егарга җәлеп итәселәрен белдереп, ротныйлар һәм взвод командирлары яңадан өйрәнүләрне башлап җибәрде. Бу юлы өйрәнүләр картада алган аз-маз теоретик күнекмәләрне практикада гамәлгә ашыруга кайтып кала: ротадан һәр взвод аерым отделениеләргә бүленеп, лагерьдан чама белән өч чакрымнар еракльктагы Н ноктасын эзләп табарга тиеш. Кайсы отделение билгеләнгән объектка алданрак чыга – шул җиңүче. Кулларга корал тоттыру юк. Отделение командирларына гына берәр компас өләшенгән. Шуның ярдәмендә

сержантлардан юнәлешне дөрес билгеләп, үз кул астындагыларны мөмкин кадәр тизрәк хәрәкәт иттерү сорала. Сержантлар да курсант паёгында, аларның да көч-егәре чамалы. Нинди тиз хәрәкәт итү турында сүз булырга мөмкин?!

Землянкадан чыгып, ачыклыкны үткәч, взвод өчкә аерылып, урман ешлыгына таралды. Капитаннар отделениесе сул флангка туры килде. Хәрәкәтләнү акрынлык белән бара. Ашыгудан файда юк, саксызлык күрсәтеп, берәр агачка орыну җитә, өсләренә шундук мул булып йомшак кар коела, шунлыктан эзгә-эз диярлек басып атлыйлар. Кулына компас тотып алда барган сержантка чыгышлары белән Брянски якларыннан булган ике мордва егете ияргән, алардан соң мари, авылдашлар Котдус белән Вәгыйз уртада, алар артында – Кашшаф һәм төркем ахырын Борис төгәлли. Дүрт-биш минут үтмәгәндер, отделение командирының сукранулы авазы ишетелде:

– Ватык компас биргән бит җә, хайвани зат, – дип, лейтенант Ивановны татарчалап-урысчалап төрләндерде.

– Хәзер кирәкле юнәлешне ничек билгелибез инде? – ди әнә, аптырап, – кире кайтудан да мәгънә юк. Ничек туры китерәсең аны, күптән без чыгарга тиешле Н ноктасына китеп баргандыр. – Сержант чын-чынлап пошаманда. Аны аңларга була, төркем өчен ул җаваплы. Карурманда адашып йөрүләре дә бар. Курсантлар бер-берсенә карашып тик тора. Төпле киңәш бирүче күренми. Кашшафның башында кинәт бер уй сызылып үтте: «Иванов компасның ватыклыгын белеп биргәнме, әллә белмичәме? Башкалар бу хакта уйлап та карамый анысы. Ә менә аның өчен бу бик мөһим – төбендә берәр төрле этлек ятуы мөмкин. Ә нигә, дошманыңа һөҗүм оештырыр өчен, моннан да уңай вакытны кайда туры китерәсең тагын? Җиң-итәкләрне җыештырып йөрергә кирәк», – дип фикер йөртте ул.

Бүтәннәргә шик-шөбһәләрен белдерү көлке тоелыр иде, шунлыктан күңелдәгесен авылдашларына да әйтмәде. Аңласа, Борис кына аңлар. Аңа гына ишетелерлек итеп ни-нәрсә уйлавын чиште. Чуваш егетендә мантыйкый фикерләү җитәрлек. Тегесен-монысын хәтер иләге аша уздыруы булгандырмы, азиатларныкына тартым күзләрен кыса төшеп, беравык дәшми торгач:

– Беләсеңме, азер турырга кирәк. Ивановтан барсын кутарга була, – дигән нәтиҗә ясады.

Котдус белән Вәгыйзнең сугышка кадәр урман эшләрендә йөрүләре ярап куйды, алар арада иң өлкәне дә. Кайбер билгеләргә карап, юнәлешне якынча ачыклый алалар икән. Әйтик, агачның төньякка караган ягы мүкләнеп-яшелләнеп тора, ди. Карта буенча табылырга тиешле объект төньяк-көнчыгышта. Чамалап, шул тарафка барып карарга дигән фикергә килделәр. Сержант ике агайга да үзе янына күчеп басарга кушты. Билгеләргә карый-карый озак барды алар. Инде вакыт буенча исәпләгәндә, күптән билгеләнгән объектка барып җитәргә тиешләр, тик менә таба гына алмыйлар. Адаштылар микәнни? Бу турыда әлегә авыз ачып сорау бирүче юк. Ансыз да аңлашыла: ул күпләрнең карашына язылган. Арыганнар иде. Отделение командиры биш минутлык ял белдерде. Бераз утырып хәл җыяр өчен, колач җитмәслек агач төбендә өелеп торган чыбык-чабык өемен сайладылар. Өстендәге карын каккалап төшергәч, тезелешеп утырырлык булды тагын.

– Җә, нишлибез инде, – ди командир. Аның югалып калуы йөзенә чыккан. Барысына да оят иде. Взводның башка сугышчылары, ротадагы бүтән взводлар алдында оят. Һәркемгә: «Ватык компас биргәннәр, шуңа күрә куелган бурычны үти алмадык», – дип аңлатып йөреп булмый ич. Хәзер инде

табарга тиешле ноктаны эзләүнең кирәге бармы икән? Бәлки, килгән юлдан лагерьга кире кайту дөресрәктер? Сержант шундый карар кабул иткән булып чыкты. Аның «кайтабыз!» дигән әмере яңгырады. Кашшаф иптәшләренең арган-талчыккан кыяфәтенә күз салды. Иреннәр ачулы кысылган. Мөгаен, лейтенант Ивановка ачулыдыр алар бу минутта. Тик торуны белмәс Борис, әллә эчке кичерешләр тәэсиренә бирелеп, куллары белән «шарт та шорт» китереп, чыбык сындыргалый. Ул кинәт пружинадай атылып аягына торып басты.

– Нарса пу? – ди, әле генә җайлап утырган урынына карап. Аның кыяфәте сәер, еш-еш сулыш ала. Башкалар да, ни булганын белергә теләп, урыныннан купты. Чуваш егете тирәсенә җыелыштылар. – Ана, курасызмы? Ана! – ди ул, никтер һаман нәрсә турында сүз алып баруына ачыклык кертмичә.

Кашшаф Борисның бармагы төртеп күрсәткән тарафка күз салды – анда чыбык-чабык арасыннан кеше аяк бармаклары тырпаеп күренә түгелме соң? Әллә ялгышамы? Күзләрен уч төбе белән угалап янә карады. Инде шиге калмады: өем астында ниндидер шәрә аяк шәйләнә. Сержант кушуы буенча, чыбыкларны як-якка араладылар. Күз алдына килеп баскан күренештән чәчләр үрә торырлык: анадан тума чишендерелгән ике мәет, йөзләрендә үлем ачысы катып калган. Аларның үз үлеме белән үлмәүләре аермачык. Ниндидер тупас предмет белән сугудан, баш капкачлары ярылып, эчкә таба изелеп кергән, кырыйдан миләре күренә.

Бәхетсезләр берничә көн элек өченче ротадан качучылар булырга мөмкин. Аларны танучы булмагач, анык әйтүе кыен. Кем булсалар да, бичараларны кызганудан күзләргә яшь тыгыла. Кемдер күңеле болганып укшырга керешге, кайсыдыр йөрәгенә чыдый алмыйча, катлы-катлы сүгенеп тынычланырга тырышты. Боларның, лагерь шартларына түзмичә, дезертирлыкка китүчеләр икәненә шик юк. Бәс, шулай икән, командирларга бу турыда кайтып әйтүнең аңлау табуына өметләнү беркатлылык булыр иде. Ә менә үзләренә зыяны тиюе бар. «Куелган бурычны үтәмичә, нишләп тиешсез урында иснәнеп йөрисез?» – дип бәйләнүләре бик мөмкин. Кашшаф комбатның «при задержании оказали сопротивление» дигән сүзләрен искә төшерде. Боларның өченче рота курсантлары булуына тамчы да шикләнми ул. Әгәр башка рота һәм батальоннардан кичәле-бүгенле генә качучылар булса, ишетелми калмас иде. Мәетләрне үз күзләре белән күргәч, егет эзәрлекләү төркеменең кешелексез гамәл кылуына тагын бер кат инанды – бичараларны лагерьга алып кайтып мәшәкатьләнмәгәннәр, куып тоткан урыннарында бәреп үтергәннәр. Анадан тума шәрә калдырулары нигә хаҗәттер? Танымасыннар өчен тырышканнар, күрәсең.

Төркем башлыгы үлекләрне, башка вакытта килгән очракта, эзләп табарга ансат булсын дип, якын-тирәдәге куак вә яшь туйраларны сындыргалап капларга кушты.

– Кешечә җир куенына иңдерергә кирәктер ич аларны, ерткыч-җәнлекләр өзгәләп бетермәсен, – ди.

Аның күрсәтмәсен үтәр өчен, курсантлар хәрәкәткә килде. Нәкъ шул мизгелдә ату тавышы яңгырады. Кашшаф борылган уңайга чигәсе яныннан гына нәрсәнеңдер «выжт» итеп узып китүен абайлады. Моның ни аңлатканына төшенгәнче, бая гына төбенә утырып хәл җыйган колач җитмәслек агачка «тык-к» итеп кадалган тавыш ишетелде. Кайсыдыр аларга ут ачканмы? Әнә, анда баскан урынында катып калган сержантның чырае көлдәй агарган, ядрә аның борын төбендә генә кәүсәне тишеп кергән. Кашшафның үзенә дә үлемнән

чак калуы хәзер генә барып җитте, әгәр ул урыныннан чак кына кузгалган булса, кургаш агачка түгел, аның чигәсенә тишеп керер иде.

– Ложись! – дип кычкырды Борис, икенче мизгелдә җиргә сузылып ятып, ул үзе белән Кашшафны да, җиңеннән тартып, аска сөйрәде. Ярый өлгерде, икенче мәртәбә аттылар. – Я его заметил, вот он – совсем рядом! – дип, чуваш егете шәрран ярды. Ешкынлыктан ут ачучыны башкалар да абайлап алды. Алар шулай ук сузылып ятты, тик әлегә беркем аягына басып, ул якка ташланмый, күрәләтә кемнең үлемгә барасы килсен? Кашшаф белән Борис бер-берсенә карашып баш кактылар һәм кинәт аякларына калкынып, мәкерле дошман ягына ыргылдылар. Такы-токы ашап, ярты көн урманда адашып йөргән егетләрнең әлләни кызулар чамасы юк. Кашшаф хәлсезлектән һәм нерв киеренкелегеннән тез буыннарының калтырануын сизде. Әллә инде аякларын тагып куйганнар, башка чаклардагыча, бөгелгәндә, пружинадай киерелеп гәүдәне алга этмиләр, киресенчә, гәүдә аякларны өстери бугай. Ул иң алда, аннан ике-өч адым арттарак Борис йөгерә. Кашшаф үзләренә һөҗүм оештыручының ешкынлыктан чыгып, аңа пистолеттан төзәвен күрде. Бу – лейтенант Иванов иде. Аның шикләнүе дөрескә чыкты, мәкерле зат уңайлы форсат тууын көткән. Хәзер ул атачак. Бу юлы, һичшиксез, тидерер, чөнки аларның арасы биш-алты метрдан артмый. Кашшафның лейтенант тәтегә баскан мизгелдә, кинәт аска ташланып, ядрәдән котылу ихтималы юк түгел анысы. Тик андый очракта аңа тәгаенләнгән үлем «күчтәнәче» бер гаепсез Борисны харап итәчәк. Нишләп әле чуваш егете Иванов белән Кашшаф арасындагы «разборка» өчен гомере белән түләргә тиеш, ди. «Сау бул, якты дөнья, хушыгыз, әти-әни, туганнар!» булды Кашшафның соңгы уе. Егет тәненең бөтен күзәнәкләре белән Ивановның тәтегә басканын тойды кебек. «Чык» иткән тавыш ишетелде – ату авазы яңгырамады, пистолет осечка биргән иде. «Аучы»ның югалып калуы йөзенә чыккан, ул янә тәтегә басты. Тик файдасыз, корал тагын атмады. Менә Иванов, борылып, инде качарга маташа. Ике кешегә каршы тора алмаячагын чамалый торгандыр. Моңа юл куярга ярамый иде. Әгәр явызны ычкындырсаң, соңыннан берничек аның һөҗүм оештыруын дәлилләп булмаячак. Шушы уй Кашшафка көч өстәде, ул күкрәгеннән чыккан җан авазы белән «ах» орып, дошманының өстенә сикерде. Качучы, бәлки, тайпылып өлгергән булыр иде, аны әллә кыргый кычкыру каушатты – сөртенеп алды. Һәм бу аның алдагы язмышын хәл итте, ул өермәдәй ябырылган масса авырлыгына түзмичә, аяк астына тәгәрәде. Инде Кашшафның кочагыннан ычкынырга теләп чәбәләнә. Борис ярдәмгә өлгерде, икәүләп явызның кулларын боргычладылар. Отделение сугышчылары белән сержант та килеп җитте.

– Вы? – дип гаҗәпләнде кече командир, Ивановны күргәч. – По инструкции вы должны встретить нас в точке Н. Вместо этого, нас преследуете, более того – устраиваете вооружённое нападение. Как это понимать? Впрочем, вроде становится ясно, почему всучил сломанный компас.

Сорау бирелгән, сержант җавап көтә. Бүре карашы белән үзен чорнап алган сугышчыларны күздән кичергәч, взводный нидер аңлатуны үзе өчен түбәнлек санады булса кирәк.

## Вәгыйзнең үлеме

Рота командиры өлкән лейтенант Алексеев взводныйны якламады. Батальондагы бүтән роталардан нәкъ менә Ивановның үзешчәнлеге аркасында артка калулары аның ачуын чыгарган иде булса кирәк.

Курсантлар арасында йөргән сүзләргә караганда, һәр ротада комбатның үз стукачлары бар, Алексеев ротасында ул – Иванов. Алексеев аны өнәп бетерми, кодрәтеннән килсә, бер көн тотмас иде, ләкин түзмичә кая барасың...

Шулай да Кашшафларның взвод командирын алыштырдылар. Сидоренко фамилияле лейтенантны куйдылар. «Башкалардан яхшылыгы белән аерылып тора», дип мактарлыгы булмаса да, Иванов кебек миһербансыз да түгел бугай. Ә Ивановны комбат батальон ашханәсенә мөдир итеп күчергән икән, икенче көнне взводтан төшкелеккә баланда алып кайтырга барган дежурныйлар лейтенантның аш-су блогында үз тәртипләрен урнаштырып, акырынуын ишеткәннәр.

Кашшаф, Ивановны кулга алгач, зур бәладән котылдым, дип сөенгән иде – явызны хөкемгә тартмадылар, һаман иректә. Алай гына да түгел, солдатлар өлешен рәхәтләнеп талардай урында ул хәзер. Хәер, андагыларның берсе дә намуслылык белән аерылып тормый. Югыйсә, курсантларны ачка интектермәсләр иде. Монысы инде башка тема. Шунысы бәхәссез: әлегә Кашшафның гомеренә турыдан-туры куркыныч янамый.

Ноябрь ахыры җитте. Ай ярым элек Кашшафның бабасы һәм авылдаш хатыннар китергән запасларның соңгысын кабып куйганга да атна үткәндер. Чана юлы күптәннән төште, авылдан хәл белергә килүчеләр генә күренми. Җае чыкмыйдыр инде, колхоз бит, теләсә кайчан чыгып китә алмыйсың. Кашшаф, Котдус һәм Вәгыйзнең үзара сүзләре күбрәк шул турыда. Алар, бүген килерләр, бүген булмаса, иртәгә, кул чанасы тарткан килеш талчыккан йөзләрендә елмаю балкытып каршыларында пәйда булырлар, дип гөман кылдылар. Көн арты көн үтсә дә, уйлаганнары чынга ашмады. Моңа кадәр, аз-маз запаслары барында, түзәрлек булган икән. Ачыгалар хәзер. Беркемнән бернинди ярдәм көтәр чама юк. Борисның апасына өметләнгәннәр иде, ул да никтер күренми. Чуваш егете, сезнең алда миңа уңайсыз, дип аклана үзе, тик аннан ни файда. Исәпләделәр: әгәр апасы азык-төлек китерсә, бер өлешен командирларга биргәннән соң, дүрт кеше өчен ун көнгә җиткерерлек рәт булачак. Бу – ун көн буена ачтан үлмичә җан асрый алачаклар дигән сүз! Аннары берәр җай чыгар әле. Бәлки, фронтка озатырлар. Ротаның кайбер взводларында ачтан үлүчеләр бар инде: икенче взводтагы бер удмурт егете әүвәл тәмам ябыгып, бетәште, аннары гөбедәй шешенеп, йөри алмас хәлгә килде. Ике айдан артык учлагта хезмәт итү вакытында янына беркемнең хәл белергә килгәнен күрмәделәр. Гаеп түгел, биш йөз чакрымдагы авылларыннан килсәләр дә, ун көннән артык атлый торгач, алган ризыкларының бер өлеше юлда ашалып бетәр, калган өлешенең яртысын комсостав тартып алса, бирергә ни калыр иде соң? Кайтасы да бар, ул якка да азык кирәк – тамакны алдап булмый. Нәтиҗәдә, андый еракльктан ары-бире тугланунын мәгънәсе калмый. Дүртенче взводтагы мордва егете дә ачтан шешенеп үлде. Кашшафның октябрь аенда ук урманга берничә хут ясап миләш, балан (ярый әле өлгерде – соңыннан якын-тирәдә аларның берсе дә калмады) җыюлары ярап куйды, менә хәзер шуларны аз-маз уртлап, ачлыктан боручы буш корсакларын алдарга тырышалар. Әчегә саруы кайнагач, Вәгыйзнең хәле катлаулырак, миләш белән баланны авызына якын да китерә алмый. Күз алдында сулып бара бичара. Кашшаф, аптырагач, буржуйка өстендә кар эретеп, аның суында төрле агач кайрылары кайнатып эчерә үзенә. Файдасы юк диярлек. Лагерьда полк лазаретлары бар. Аларның исеме генә. Чынлыкта хасталарны дәвалау белән аларда беркем шөгыльләнми. Авырулар, дистрофиклар анда акрын үлемгә дучар ителгән. Кайсыбер көннәрне

икешәр-өчәр мәет чыгарып, күмү командасының учлаг зиратындагы алдан казып куелган чокырларга илтеп күмүләренең шаһите булалар. Шуңа күрә Кашшаф Котдус абыйсы һәм Борис белән киңәшеп, «лазаретка җибәрә торган авыруларыгыз бармы?» дип землянкаларына кергән санинструкторны «юк», дип чыгарды. Авырулар юк икән, урында ятучылар да булырга тиеш түгел (андыйларны кичекмәстән лазаретка озаталар). Иртәнге һәм кичке барлауда катнашу, стройда «пичәтле» адымнар белән йөрү, занятиеләрне калдырмау – бер-ике көннән Вәгыйз боларның берсен дә башкара алмаячак. Аннары инде сорап тормаячаклар, авылдашларын яшәү белән үлем арасындагы соңгы пункт ролен үтәүче урынга алып китәчәкләр. Нишләргә соң әле, дип баш ватты Кашшаф. Тик бер төпле фикергә килә алмады.

Икенче көнне Вәгыйз абыйсы стройга иртәнге барлауга чыга алмады. Бусы инде куркыныч иде, авылдашның язмышы хәл ителгән дип санарга була. Әллә вакытны сузу өчен, взвод командиры лейтенант Сидоренко белән сөйләшеп карарга микән? Абзыкайны лазаретка озатуны бер-ике көнгә кичектерергә ризалатып булмасмы? Моның өчен Кашшаф алдашуга барды; авылдашлар юлда инде, бүген-иртәгә килеп җитәргә тиешләр, дип, взводныйны ышандырды. Башка чарасы юк иде аның. Бәлки, ул арада бабасы җиңгәчәйләр белән алар хозурына килеп басар. Һәрхәлдә, егет моңа бик өметләнә. Лейтенантка, хәлләренә керсә, күчтәнәчләрне мулдан бирергә вәгъдә итте.

Бер көн үтте. Икенче көннең киче якынлашып килә. Вәгыйзнең хәле тагын да авырайды. Ул инде, Кашшаф ничек кенә кыстамасын, көндезге баландасын ашарга да тормады. Иртәгә иртә белән санитарлар аны лазаретка күчерәчәкләр. Лейтенант Сидоренко вакланмады, Кашшафка «алдадың», дип тә бәйләнмәде. Бәлки, ул егетнең якташын коткару өчен шундый адымга баруын аңлагандыр.

Тышта декабрь салкыны. Землянкада, «буржуйка» янып торганлыктан, җылы. «Бүтән утын өстәмәскәдер», дип уйлады взвод буенча кизү торучы Кашшаф. Ул, аның чираты булмаса да, кизүлек итүне үзенә сорап алды. Барыбер йоклый алмый, Вәгыйз абыйсын коткара алмавына өзгәләнә. Өченче аен биредә хезмәттә саналса да, лагерьда тудырылган шартларның адәм балаларына карата шулкадәр кешелексез булуын һаман акылы сыйдырып бетерә алмый, моның төбендә нинди сер ята икән, дип уйлана. Рядовой составка урыс булмаган халыкларны гына алалар. Фронтка җибәргәнче, урыс теленә өйрәтү өчен, дисәләр дә, чынлыкта, командирларның үзара урысча сөйләшегез, дигән әреннән башка бернинди өйрәтү юк... Егетнең уйларын Вәгыйз абыйсының ыңгырашып саташуы бүлде. Бүген ул ешрак бутала. Авылны, хатыны белән балаларын телгә ала, әтисенең исемен әйтеп: «ишекне ач»! дип кычкырды. Әнә, бу юлы ниндидер ризык сорый, «ит», диюе бугай. И-их, болай азапланырлар идемени алар кешечә тукландырсалар! Котдус абыйсы да йокламаган икән, акрын гына эндәште:

– Энем, безне шулай берәм-берәм ачтан үтереп бетерерләр микәнни?

Нәрсә әйтсен соң моңа каршы Кашшаф. Ул да башка камырдан түгел, авылдан чыккан. Аңа да артыгы мәгълүм түгел. Әмма шунсы бәхәссез: моның төбендә аңлашылмый торган иблис мәкере ята. Алар буыны өчен ул ачылмаган сер булып калырга мөмкин. Килер вакыт, сер пәрдәсе алыныр, бәлки, без капчыкта ятмый, диләр бит. Анысы инде киләчәк эше. Ә хәзер? Хәзергә Котдус абыйсы аннан җавап көтә. Яшь булса да, җиде сыйныф белеме өчен укымышлыга саный ул аны.

– Котдус абый, алай гына үтереп бетерә алмаслар. Күп ич без. Беребез китсә,

аның урынына икенчебез, өченчебез килә, – дип сөйли башлады Кашшаф. Аннары аның башына: нишләп мин кызыл коммунист шикелле сөйләнәм соң әле, мондый җавап көтәмени ул, дигән уй килде. – Мондагы хәлләр турында Мәскәүдә белмиләрдер, дип уйлыйм мин. Әгәр белсәләр, килеп тәртип урнаштырырлар иде. «Сүз иясе белән йөрми», диләр. Иртәме-соңмы, барыбер тиешле җиренә барып ирешер, шуннан соң җаваплы кешеләре җәзасын да алыр. Миңа калса, башкача була да алмый торгандыр.

– Рәхмәт, туганай! Сүзләрең күңелемә май булып ятты. Югыйсә мондагы башбаштаклыкны күреп йөрәк елый. Кызык та, кызганыч та булган бер нәрсә сөйлим әле, – диде Котдус агай, җанланып. – Син өченче ротадан безнең районның күрше авылдан Хәмит атлы ир затын белә идең микән? Безнең елгылар тирәсе. – Кашшафның «әйе», диюен ишеткәч, Котдус дәвам итте. – Шул Хәмит, Суслонгерга эләккәч, дүрт айдан артык фронтка китә алмыйча җәфаланган, буй кыска тегенең, метр ярымнан чак кына артык. Җитмәсә, болай да ябык нәрсәкәй, ачлыктан гел үсмер бала кебек кенә калган. Без килгәнче, сентябрь башында оештырып фронтка озатылган җыелма полкка эләгәсе булган, стройга тезелгән җирдән полк командиры «буең кыска», дип, ошатмыйча калдырткан моны. Икенче мәртәбә – инде без монда чагында – оештырылган фронтка озатуда тагын калдырырлар дип куркып, буйчанрак күренер өчен, аягы астына түмәркә кисәге куеп баскан. Үткән шулай стройда икенче рәткә басып. Соңыннан «пичәтле» адымнар белән плац аша барганда, полкны кабул иткән югары чиндагы офицерлар иң арттан атлаучы кечкенә буйлы сугышчыны күреп бик гаҗәпләнгәннәр. Полк командиры калдырмакчы да булган, соңгы мәлдә Хәмитнең нинди хәйләгә баруын белгәннән соң көлгән дә: «Ладно, возьмём уж его, будет служить при штабе», дигән.

Әңгәмәгә Борис кушылды. Аны да йокы алмый, күрәсең. Вәгыйзнең үлем хәленә килеп җитүендә күпмедер дәрәҗәдә үзен гаепле саный ул – «килми бит!» дип, апасының лагерьга һаман килмәвенә өзгәләнеп сөйләнүен Кашшаф соңгы көннәрдә еш ишетә. Авылдашлар өлешенә керүе өчен вөҗдан газабы кичерә булыр. Борисның:

– Ашханада Иванов килганнан бирлы часто эчү оештыралар икан, – диюе игътибарын җәлеп итмәгән иде. – Мәҗлес барышында сөяк-санак, азык калдыкларын тышка тәрәзәне ачып кына ыргыталар, – дип дәвам итүенә сагаеп колак салды. Ыргыткан калдыклардан ач курсантларның кайчагында ит кисәкләренә кадәр табып алуларын ишеткәч, күңелендә нindидер өмет чаткысы кабынуын тойды. «Бәхет елмаеп, берәр юньле ризык юнәтә алсак, шуның ярдәмендә Вәгыйз абыйны терниәкләндереп җибәрә алмабызмы әле?» дигән хыялый уй туды башында. Ул – табиб түгел. Авылдашына хәзер беркем ярдәм итә алмаячагын, аңарда инде кире кайтара алмаслык процесслар башлануын белми иде шул. Аңа хәзергесе кадерле. Борисның:

– Буген кайсынындыр туган кунын байрам италар бугай, – диюен ишетүгә, Кашшаф аягына ук торып басты.

– Нишләп монда ятабыз соң әле без, әйдә киттек! – диде ул, кайнарланып. Борис никтер урыныннан кузгалырга ашыкмады. Ятуын белә. Башка чагында бер әйтү белән ярдәм итәргә ашыга иде, ни булган моңа, дип уйлады Кашшаф, сәерсенеп.

– Син ашыгасын. Уйларга кирак, – ди әнә чуваш. – Калдыкларны ташлагач, исырыклар тышкы якка чыга. Тамакы да тарта инды. Ансы быр хал, алар бит чылбырдан этларны ычкындыра. Этлардан талата курсантларны. Шулай кызык таба. Бер кеше да качып котыла алмый. Шуна анда баручы хазыр аз,

– дип ачыклык кертте Борис, ашыкмавының сәбәбен аңлатып. Барам дигән җиреңнән бармассың. Сөйләнүдән нинди мәгънә соң, дигән шикелле Кашшаф кулын селтәде.

– Этларга каршы быр юлын былам да инды, – диде шулчак Борис, икеләнүле тавыш белән.

– Нинди юл ул, әйт, сузма! – Кашшафның сабырсызлануы тавышына чыкты.

– Уска бушлат или телогрейка киясын, кулга чолгау урыйсын. Шунда ук дау кадак урнаштырасын. Эт уска ташлангач, кулны алга суз – ул аны кабачак. Авызга кадак кадалган эт башка тешлами, чинап кача.

Әнә ничек. Усал этләргә каршы торуның әллә нинди юлларын белә бу. Сынап карарга ярыйдыр моны. Авылдан алып килгән телогрейкасы исән әле, кадактан күп нәрсә юк. Портянка-чолгау проблема түгел. Барырга, дигән уйга килделәр.

Караңгылыкка чумган землянка һәм бараклардан аермалы буларак, батальон ашханәсенең тәрәзәләре электр уты яктысыннан гөлт иткән. Яктылыкны ашханәләр һәм полк штаблары өчен махсус көйләнгән танк моторларын эшләтеп алалар. Командный состав яши бeлә, дип уйлап куйды Кашшаф, күңел эчкәресендә баш калкыткан ачу хисен басарга тырышып. Офицерлар өчен торакларда да шундый ук ысул белән ильич лампалары кабызыла.

Әллә киләсе кеше инде килеп киткән, әллә Борис әйткәнчә, этләрдән талатудан куркалар – ашханә тирәсендә җан әсәре күренми. Эчтән җыр сузганнары ишетелә, ул әледән-әле кемнәрнеңдер кычкырып куюы, сүгенү авазлары белән аралаша. Кашшаф ярымкараңгыда сөяк-санак табып булыр микән, дип юкка борчылган. Юллары уңар кебек: ачылмалы зур тәрәзәдән төшкән саран яктылыкта шул турыда ук кар өстендә чәчелеп яткан ниндидер әйберләр шәйләнә. Егетләр килгән шәпкә шунда ташланды. Исерекләр ыргыткан калдыклар икәнлегенә шик юк: ике-өч кенә кабып куелган ипи телемнәре, ярып пешерелгән бәрәңге яркалары, тозлы кыяр калдыклары, аннан-моннан гына кимерелгән берничә сөяк кисәге, хәтта итен каезлап алганнан калган каз түшкәсенең скелетына кадәр бар иде монда.

– Кара, нәрсә таптым, – диде Кашшаф акрын тавыш белән, табылдыгын Бориска күрсәтеп. Алар үзләре белән биштәр алганнар иде, тапкан бер нәрсәләрен шунда җыялар. Кашшаф түзмәде, каз скелетының батынкы урыннарында калган ит кисәкләрен куптарып ала башлады. – Мә, син дә сыйлан, – диде, иптәшенең, авызына бер-бер артлы ике кисәк озатты. Юньләп ит ризыгы күрмәгәннәренә тиздән өч ай тула шул инде. Онытылып барган тәмнең рәхәтләндергеч ләззәтен озаклап сузарга чама юк, теләсә кайсы мизгелдә «хуҗалар»ның килеп чыгу куркынычы бар. Курсантлар тыелып кала алмады, каз «түшкәсен» икесе ике яктан тотып урталай сындырдылар. Һәркайсы үз өлешенә тешләрен батырды. Яшь, таза тешләр өчен нәрсә соң ул йорт кошының юка һәм йомшак сөяге – аз-маз калган ите белән алары да тураклана. Бермәл кышкы һавада егетләрнең шатыр-шотыр китереп чәйнәүләре генә ишетелеп торды. Алар бу шөгыльләренә шулкадәр нык бирелгән иде, хәтта ике хәрбинең яннарына килеп басканнарын искәрмәделәр.

– Ба-а, тут оказывается не только мы гостим, – дип эндәшүгә сискәнеп киттеләр. Комбат ич бу! Димәк, эчтә сыйланучыларның берсе шул. Егетләр аптырашта. Үзләрен ничек тотарга белмиләр. Карак хәлендәме алар хәзер, әллә чүплектә азык эзләп казынучы саилчеләрме?

– Иванов, – дип кычкырды яхшы ук кызмачаланып өлгергән майор, ачык калдырылган ишек ягына борылып. – Поди-ка сюда.

Егетләр ниндидер күңелсезлек килеп чыгасын сизенде, тизрәк моннан таю ягын карарга кирәк. Тик ничек? Комбат болай гына җибәрергә охшамаган. Кашшафның дошманы лейтенант Ивановны чакырмас иде. Ивановка ул арада кем әйткәндер – чыгып та җитте. Кул фонаре тоткан.

– Ты что говорил тогда про собак, на любителей халявной еды натравливаешь? – дип сорады аннан майор.

Тегесенең «Так точно!» дигән җавабын ишеткәч:

– Ну что ж, давай посмотрим, – дип, көндәлек тормыш ыгы-зыгысы турында сүз баргандай гына әйтеп куйды.

Фонарь белән яктыртып, Иванов, калдыклар эзләп килүчеләрнең элек үз буйсынуындагы взвод сугышчылары икәнлеген танығач, ифрат сөенде. Шатлануын яшереп тормады:

– На этот раз от меня не уйдешь! – диде Кашшафка, теш арасыннан сыгып чыгарып.

– Эттан талаталар хазыр, качарга кирак, – бусы дустына гына ишетелерлек итеп Борисның әйтүе.

«Бер, ике, өч», дип санадылар да икесе берьюлы землянкалары урнашкан якка ташландылар. Артта әче итеп сызгыру ишетелде. «Фас!» дип кычкырдылар. Этләрнең усал ырылдап үзләре артыннан ыргылуын сизде Кашшаф. Эшләр харап, болай булгач. Йөгергән уңайга алдан әзерләнгән чолгауны кесәсеннән тартып чыгарды. Икенче кулы буш түгел, анысында азык калдыклары салынган биштәр. Ташлап калдырырга кызганды, ул әле һаман андагы калдык-постык белән Вәгыйз абыйсын аягына бастырырга өметләнә иде. Шул харап итте дә, чолгаулы кулы белән телогрейкасының түшеннән кадакны тартып алырга өлгермәде, кисәк тукталып, өстенә сикергән овчаркага таба борылуына, дәү гәүдәле җанвар бөтен авырлыгы белән аңа килеп бәрелде. Дөресрәге – кулындагы биштәренә. Кашшаф та, эт тә бер масса булып кар өстенә тәгәрәделәр. Каяндыр укыганы бар: эт талаганда битне каплап йөзтүбән ятарга кушалар. Овчарканың юл капчыгына туры килүе аны берничә секундка булса да коткарып калды. Күз кырые белән генә Бориска ташланган этнең чолгау уралган кулдан кабып алуын күреп өлгерде, икенче мизгелдә колагына чинау авазы чалынды. Дустының алдан сөйләшенеп куйган планы барып чыкты, димәк. Этләр икәү генә булган ахры, башкалары күренми.

– Бар, син, кач! – дип кычкырды Кашшаф. – Землянкадан иптәшләрне алып килергә тырыш!

Борисның иптәшен калдырып китәргә исәбе юк иде бугай. Шулай да тыңлады, берничек ярдәм итә алмаячагын аңлагандыр, күрәсең. Моңа ашханә янында гына торып калмыйча, фонарь утын аларга юнәлткән төркем якынлашуы да сәбәп булгандыр. Кемне-кемне, Кашшаф Хәкимовны эт тырнагыннан коткаруга Иванов юл куймаячак. Комбат, ашханә мөдире, тагын берничә мәҗлестәш күңелле гөрелдәшеп кар өстендә адәм баласы белән шул адәм баласының күп меңләгән еллардан бирле дүрт аяклы дусты саналган җан иясе әүмәкләшкән урынга якынлаштылар. Тик бу – кеше белән этнең өйрәнү өчен үзара дус, тату әүмәкләшә торган очрагы түгел, монда аларның бугазга-бугаз килеп алыша торган урыны. Бериш явыз бәндәләр, шәхси рәхәтлекләрен канәгатьләндерер өчен, икенче берәүләрне коточкыч шартларга куйганнар һәм менә хәзер ерткыч хәленә китереп, борынгы заманнардагы кыргый инстинктын кузгаткан эт-бүрене, ачлыкка чыдый алмыйча, яннарына килгән шул мескенгә өстергәннәр. Кайсы өстен чыгар?

– Ну ты даёшь, Иванов, – дип сөйләнде майор, кәефләнүдән кулларын угалап. – Наслышан о твоих проказах, но не подумал, что дойдёт до такой степени.

Бу чагында инде эт биштәрне туздырып-умыргалап ташлаган һәм Кашшаф өстенә сикереп, аның беләге турысыннан телогрейкасын капкан, чалкан әйләндерергә теләп ары-бире тарткалый иде. Егет моны яхшы аңлый, әгәр җанвар аркан әйләндерсә, беттең – бугазыңнан бер генә кабачак. Ничек кенә иптәшләре килеп җиткәнче сакланырга соң?! Фонарьдан төшкән яктылык тасмасы, тегендә-монда уйнаклап, овчарканы тагын да ярсыта бугай, ул ачулы ырылдап җиңне умыра. Күрәсең, Иванов этләрне ничек котыртырга икәнен яхшы белә.

– Товарищ майор, у меня с этим курсантом особые счёты. Пускай собака загрызёт до смерти? – диюен Кашшаф ишетте дә бугай, ишетмәде дә. Ул барлык акыл һәм ихтыярын эткә бирешмәүгә туплаган.

Бу чагында котырынган эт аны аркасына әйләндерде. Тик бугазыннан кабарга өлгермәде, кайсыныңдыр саллы күсәге сыртына килеп төште. Эт чиный-чиный читкә ыргылды.

– Кто такие? – бусы майор тавышы.

Нәрсә булуын әлегә аңышып өлгермәгән Кашшаф йөзеннән кулларын алды. Ниндидер кешеләр басып тора. Ивановның кул фонаре инде аларны яктырта. Алар взводының курсантлары. Кай арада килеп җиткәннәр әле болар, Борис землянкаларына кайтып җитәрлек вакыт та узмады ич. Аны шатлык биләп алды. Ярый өлгерделәр. Берничә секундка соңарсалар да, ул исән калмас иде. Иң алдан Борис белән мишәр егете Газиз басып тора. Алар янәшәсендә Котдус абыйсы, аннан соң мордвалылар һәм башкорт Мортаза, арттарак удмурт Сергей да күзгә чалынды кебек. Бөтенесе уннан артадыр. Нужа дилбегәсен бергә җигелеп тартканлыктан, барыбер авырлык килгәндә ташламыйлар, рәхмәт инде. Кашшафның күзләре яшьләнде. Ул яткан җиреннән торып утырды, шулай да аягына басарга ашыкмый. Сорау бирелгән. Комбат һәм аның яраннары җавап көтә. Тынлык озаккарак сузылды. Арада Газиз кыюрак булып чыкты (моны Кашшаф бер генә искәрмәде), телгә килде:

– Мы, товарищ майор, бойцы из взвода лейтенанта Сидоренко и пришли выручить своего товарища от неминуемой гибели, – дип, беркадәр мишәрчәрәк акцент белән шартлатып җавап бирде.

– Откуда взял, что твой товарищ погибает? – диде комбат, чын-чынлап гаҗәпләнеп.

– У нас в землянке от голода его односельчанин умирает, и мы знали, что он со своим другом отправился в поисках остатков пищи в сторону столовой. Всему батальону известно как издевается лейтенант Иванов над курсантами пришедшими к помойной яме в надежде найти что-нибудь съедобное, натравливает собак на них.

Комбат мондый ук тапкыр һәм тәвәккәл җавапны көтмәгән иде булса кирәк. Беравык ни әйтергә белмичә торды. Аннары ниндидер катгый карарга килде. Тавышына боеру тоны иңдереп:

– Заберите своего товарища и возвращайтесь в свою землянку! – дигән әмер ирештерде. Үзенекеләргә: – Пошли за мной! – өне чыгарып, ашханә ягына атлады. Иванов нәрсәдер исенә төшерергә теләп авызын ачкан иде, – отстань! – дип кул гына селтәде.

Кашшафны иптәшләре күтәреп торгызды. Котдус абыйсы, Борис, Газиз,

Мортаза һәм башка хезмәттәшләре бер-бер артлы килеп кочакладылар. Сөйләүләренчә, землянкага кемнеңдер кайтуын көтеп тормаганнар, бәла буласын алдан сизенеп, ярдәмгә ашыкканнар. Газиз, Котдус абыйларына төртеп күрсәтеп:

– Әнә, аңа әйт рәхмәтеңне. Сез цыгып китүгә үк: «Әйдә, артларыннан барыйк», дип безне тыкырдата башлады, – диде.

Землянкаларына кайткач, «буржуйкага» кабат утын өстәделәр. Алган тәэсирләрдән күпләрне йокы алмады. Кашшаф төнозын саташып яткан Вәгыйз абыйсының баш очыннан китмәде. Таң алдыннан авылдашы аның кулларында соңгы сулышын алды...

## Мәңгелеккә күчү

Кашшаф карт, авыр уйларыннан арынырга теләп, башын чайкады. Вәгыйз агайның үлеменә җитмеш өч елдан артык вакыт узса да, үзләре өч ай чамасы иза чиккән землянкалары янында (урынын ялгыштырмаса – шул) аның уй-кичерешләре кабат яңарды. Авылдашлары артыннан ачтан үләргә үзләренә дә чират җиткән иде, ярый инде соңгы чиктә Борисның апасы ризык төяп килеп җитте. Аны өч кешегә өч атнага җиткерделәр. Декабрь ае ахырында өчесе дә фронтка озатылучы җыелма полкка эләкте. Әнә шул үлүдән коткарды. Җиңү язы җитеп, янә бер елдан туган авылына кайткач, Кашшаф Котдус абыйсының сугыштан әйләнеп кайтмаганын белде. Тугрылыклы чуваш дусты Борисның аннан соңгы язмышы аңа билгесез. Котдус абыйсы һәм Борис белән, яраланып госпитальгә эләккәч, юллары аерылды. Хат алышмадылар. Хәер, андый буталчыкта кая ди инде хатлар алышу. Кызганыч, әлбәттә. Кирәк иде. Менә хәзер, гомер кышы капка какканда гына, элекке фронтовик моны аңлагандай булды. Бу тормышта бер генә яшибез ләбаса. «Дөньяда без кунак кына», дип юкка әйтмиләрдер. Кашшаф Хәкимов Борисны беркайчан да эзләтеп карамавына чын-чынлап үкенү хисе кичерде. Авылларына әйләнеп кайту белән, оныгына элекке дустының аннан соңгы язмышын теләсә ничек ачыкларга кушачагын күңеленә беркетте. Ул соңгы елларда яшәү мәгънәсе турында еш уйлана. Унынчы дистәсен ваклап килә. Сугыштан кайткач, төпкә җигелеп колхоз йөген тартты. Әүвәл кырчылык бригадасын җитәкләде, читтән торып авыл хуҗалыгы институтын тәмамлады. Авылдашлар, ышаныч күрсәтеп, күмәк хуҗалык җитәкчесе итеп сайладылар. Утыз ел рәислек итү дәверендә аны арттагылар рәтеннән районда алдынгылыкка чыгарды. Пенсия яшенә җиткәч тә, биш ел эшләде әле. Буталыш заманы башланып, илнең асты-өскә килгәч, ул һәм аның кебекләр көнне төнгә ялгап дистә еллар дәвамында тир түгеп тудырганны елгыр адәмнәр кыска вакыт эчендә уңга-сулга таратып бетерде. Күпчелек гавам ярык тагарак янында калды. Мондый оятсызлык югары пост биләүчеләрнең дәшми-тынмый (әллә хуплаулары?) күзәтүе астында дәвам иткән буталыш чарасыз итте. Шуның өчен кан койдымыни алар, шуның өчен коммунизм таңы аттырабыз дип тырыштымы? Соңгысының чынга ашмас хыял гына икәнлегенә Кашшаф Хәкимов күптән төшенгән иде. Тик СССР дип аталучы гаять зур илнең ничек тиз арада таралып бетүен аңлый алмыйча башы катты. Соңыннан ул озак вакытлар, кыйбласын югалткан кеше кебек, үз-үзен кая куярга белмичә йөрде. Хатыны Сабира мәчеткә барып карарга киңәш итте, урыны оҗмахта булсын. Ни гаҗәп, дин йортында Кашшаф агай күңеленә ниндидер рәхәтлек таралып, тынычланып калуын сизде. «Күптән монда киләсе калган», – дип уйлады, үкенү хисе кичереп. Өйлә намазларына

нибары өч-дүрт, ә җомганыкына, күп дигәндә, ун-унике кеше җыела икән. Алары да өлкән яшьтәгеләр. Арада иң карты – туксанны узганы – ул. Җитмеш, сиксән яшьлекләр бар. Иң яшь дигәне дә алтмышны тутырган инде. Димәк, дингә аз тартыла халык. Күбрәк тормыш артыннан куа. Ә тормышның узгынчы гына, «ә» дигәнче үтеп киткәнлеген аңлар өчен, нәкъ менә монда килергә кирәк икән. Хәзер хәтере юк инде, аять-сүрәләрне дә исендә калдыра алмый. Ике еллап йөрү дәверендә нибары өч сүрә ятлый алды. Мәчет имамы:

– Бер дә аптырамагыз, Кашшаф абзый, ниятләвегез дөрес булсын. Җитешеп намазга бастыгыз ич. Аллаһ кабул кылыр, иншалла, – дип юаткан була. Бәлки, шулайдыр да. Карт фронтовик Суслонгерда ачлыктан һәм авырулардан вафат булганнар рухына намаз уку уе белән дә килгән иде. Шуңа, әзерлеген алдан күрде. Ислам йоласы кушканча, үзе белән алып килгән комганына суын салып, тәһарәт алганнан соң, кыйбла ягына карап намазлыгын җәйде һәм догасын башлау хәстәренә кереште. Шофёры белән оныгы Камил аның шул чагына туры килде. Бер-берсенә карашкач, «комачауламыйк», дип, тагын кире борылдылар. Берничә минуттан соң нәрсә буласын белсәләр, борылып китү түгел, аларны моннан куптарып алып та булмас иде дә бит. Күрәчәккә шулай язылгандыр инде. Хәер, бар да Аллаһ кулында!

Кашшаф агай намазын:

– Илаһи ният кылдым, – дип башлады һәм кемнәргә багышлавын күз алдына китергәннән соң, «Фатиха» сүрәсен укырга кереште. – Әгуузү билләәһи минәш-шәйтанир-раҗим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. – Хәтерендә шулчак яңарган Котдус абыйсының йөз чалымы догасының сүзләрен оныттырды.

«И-их, – дип өзгәләнде карт, – хәзрәт тә, намаз укыганда, башыгызга чит фикер кертмәгез, дип әйтә. Нишләп игътибарымны башкага юнәлтәм соң әле мин», һәм ул, тагын фикерен бер ноктага туплап, зиһенен эшкә җигәргә тырышты. – Әл-хәмдүлилләһи раббил-гааләмиин. Әр-рахмәә-нир-рахиим. – Янә онытты. Кашшаф агайның үз-үзенә ачуы килде. Элегрәк дингә киләсем калган, яшьрәк чакта өйрәнгәннәр онытылмый ул. Менә бит, намаз укырга ният иттем, ә үзем хыял диңгезендә йөзәм, дип пошынды. Күз алдына кабат Вәгыйзнең сурәте килеп басты. «Чү, ул исән түгелме соң? Әнә ич, землянка ишегеннән чыгып килә. Нидер әйтә дә бугай. Юк, сөйләшми икән, кулын изәп, үзе артыннан ияреpгә чакыра. Бармыйча булмый инде, берәр төрле ярдәм кирәктер». Элекке фронтовикның кинәт күзләре томаланып, дөнья караңгылыкка чумды. Колакларында әче сызгыру барлыкка килде. Әллә нинди сәер халәттә сизде ул үзен. Намазлык өстендә утырган җиреннән, җаны гәүдәсен калдырып чыга кебек. Никтер ул бернинди курку хисе кичермәде. Сызгыру дәвам итте, көчәйгәннән көчәеп, соңгы ноктасына җитте дигәндә, өзелеп, тып-тын булып калды. Алда нурлар чәчеп торган иксез-чиксез иркенлек ачылды. Кашшаф картның тәненнән аерылган җаны шул чиксезлеккә омтылды.

Камил шофёры белән әйләнеп килгәндә, бабасының сәҗдәгә оеган җиреннән тынсыз калган гәүдәсен күреп, тораташтай катып калды. Болай булыр дип башына да китермәгән иде ул. Адәм баласының соңгы сулышын кайда һәм кайчан аласын Аллаһтан башка беркем белми шул. Фанилыктагы ахыргы тукталышына ашкынган икән бахыр.

Авылына алып кайткач, икенче көнне, Кашшаф агайның җәсәден сугыш ветераннарына тиешле хөрмәтләүләр белән зиратта хатыны Сабира янәшәсенә җирләделәр.



# Таһир Шәмсуаров

## ҖЫРЫ БАРНЫҢ – ЧИКСЕЗ ГОМЕРЕ!

### Хәтер кыры

Көтәләр, дип, башка язмам инде,
Мин елармын, ахры, тын гына.
Солдат хатыннары китеп бара,
Ирен эзләп хәтер кырына.

Әниләрнең кара чәчләренә
Хәсрәт-бәсләр иртә кундылар.
Бүгенгедәй, кайтып керер, диеп,
Ишек бикләмичә кундылар.

Соңгы каһарманнар басып тора,
Иртәгәне уйлап тартынам.
Җиңү мәйданына килми калса,
Кирәк булмас бару артыннан.

Тик батырлык янәшәдән атлар,
Тезелешеп узар күп еллар.
Һәйкәл яннарында, чәчәк тотып,
Солдат балалары торырлар.

Онытырлар, диеп, уйламагыз,
Җир төренгәч язгы бер ямьгә. –
Ап-ак чәчле солдат улларының
Оныклары килер бәйрәмгә!

Солдат хатыннары китеп бара,
Ирен эзләп хәтер кырына.
Мин бу хакта бүтән язмам инде,
Бер елармын, ахры, тын гына...

Таһир ШӘМСУАРОВ (1954) – *шагыйрь; «Җанлы шәм», «Яратудан тора җир шары», «Ярату белән» һ.б. китаплар авторы. Лениногорскида яши.*

## Бер бит кәгазь

Өстәлемдә ап-ак кәгазь ята,
Белү кирәк аның кадерен.
Мин Җәлилгә бер бит сузар идем,
Язсын өчен үлмәс шигырен.

Гади кәгазь азмы шагыйрьләргә
Мәңгелеккә якты юл ярган?
Кәгазь – хәтер, Бөек Кол Галинең
«Йосыф – Зөләйха»сын кайтарган!

Кәгазь тотсам, Такташ искә төшә –
Замананың моңлы шагыйре!
Ни гаҗәптер, киткәч арта төшә
Шагыйрьләрнең җирдә кадере!

Ә урамда күбәләк кар ява,
Бизәк булып куна талларга.
Җаннар күбәләктәй очканлыкны
Шагыйрь җаны кирәк аңларга.

Актан торган бу дөньяга баккач,
Күзләр чагылмавы икеле.
Ак кәгазьгә төшкән шигырь – энҗе,
Киләчәккә илче шикелле.

Шигырьләргә богау салынмавын
Кайсы хәким, әйтче, тыймаган?
Язу – бездән, ә илһамы исә –
Тиңсез бүләк иңә Ходайдан!

Өстәлләрдә сөттәй кәгазь ята,
Белү тиеш аның кадерен.
Мин Туфанга бер бит сузар идем,
Язар өчен үлмәс шигырен...

## Билгесез солдат

Тол хатыннар көтте, күпме ана
Олы юлдан күзен алмады.
Миллионлаган сабый кабереңне
Әтинеке диеп санады.

Син танкта яндың, суда баттың,
Фашистларның бирдең кирәген.
Кем булса да, соңгы сулышкача
Ватан белән иде йөрәгең.

Мәрмәр һәйкәл, якты истәлекләр
Яңаралар кабат хәтердә.
Яу кырыннан гүя эндәшәсең:
«Улларыңны, Ватан, хәтерлә!»

Онытмадык, солдат: хәбәрсезләр
Мәңгелек ут булып яналар.
Сазлыклардан, урман эчләреннән
Оныкларың эзләп табалар...

Күрәсеңме, әнә, бер минутка
Тыгыз сафлар тынып калалар.
Аурупа буйлап яшьле күзләр
Кызыл кәнәферләр салалар.

Миллионлаган ятим кабереңне
Әтинеке, диеп, санады.
Тол хатыннар көтте, күпме ана
Кайтуыңны күрә алмады!

Бүгенгеләр барыр сукмакларын
Синең үрнәгеңдә билгели.
Син билгесез солдат саналсаң да,
Батырлыгың илгә билгеле!

## «Шөгер» җырына мәдхия

Мәңгелеккә илтер юллама син,
Таулар сыман горур башыбыз.
Кайданлыкны әгәр сорасалар,
«Шөгер» җырын көйли башлыйбыз.

Мәгърур таулар – Урал итәкләре,
Шул итәккә үстек ябышып.
Юк, без читтә озак торалмадык,
Кайтып төштек моңга сабышып.

Без бәхетле җирдә, торган саен
Төп нигезнең арта кадере.
Җыры барның – күңел күтәренке,
Җыры барның – чиксез гомере!

Кырык өчтә, сугыш барган мәлдә,
Хәтерләргә төшә тагын да.
Кара алтын бирдең, һәрбер өйгә
Кара кәгазь килгән чагында.

Ә җәйләрен илнең амбарларын
Икмәк белән тутыра бу кырлар.
Йорт аралаш батыр яши бездә,
Адым саен очрый шагыйрьләр.

Синең матурлыкны сөйләгәндә,
Ышанмаучылар да бар, туган.
Тальян гармун җанын тыя алмый,
Аңлый алмый монда тумаган!

Жыры барның – килер язлары бар,
Борынгыдан килгән сүз рас ул.
Киләчәккә нурлы капка ачкан,
Гасырлардан килгән мирас ул!

Шушма белән таңда саубуллашып
Кузгалабыз ерак юлга без.
Сәхнәләрдән сине җырлаганда,
Чишмә суын эчеп чыгабыз!

Аягүрә басып тыңлыйм сине,
Утыралмыйм тик бер урында.
Үзем җырлыйм, үзем шигырь язам
Синең бөеклегең турында!

Мәңгелеккә илткән юллама син,
Таулар сыман горур башыбыз.
Газиз халкым белән кушылачак
«Шөгер» җырын көйли башлыйбыз!

## Солдат хатыны

Рядовой да түгел, генерал да,
Погонның да юктыр алтыны.
Җиңү, дибез икән, иң беренче,
Сиңа рәхмәт, солдат хатыны.

Итәк тулы бала белән калдың,
Сыңар валчык кайчак капмадың.
Ирең илгә тугры булган сыман,
Иргә тугрылылык сакладың.

Синең хатың дошман пулясыннан,
Ядрәләрдән, ышан, саклады.
Ватан, диеп, синең исем белән,
Дзотларны ярың каплады.

– Бездә бар да әйбәт! – дидең һәрчак.
Авыр, диеп, кем соң сөйләсен?!
Хат ташучы керсә, курка идең,
Кара кәгазь генә килмәсен.

Язалмадың, юкса сабыйларың
Ипекәйне төштә күрделәр.
Бер уч бодай өчен хатыннарны
Себерләргә азмы сөрделәр?!

Салкын мендәр генә сөйли ала
Яшәү кыенлыгын ир-атсыз.
«Әтисе!» – дип каршы алдың аны,
Атлый алмаса да таяксыз!

Кайберләре һаман көтә әле,
Тәрәз чиртер, диеп, бәгырен.
Бүгенгеләр, беләбезме икән,
Солдат хатынының кадерен!

Рядовой да түгел, генерал да,
Погонның да юктыр алтыны.
Җиңү, дибез икән, иң беренче,
Сиңа рәхмәт, солдат хатыны!



Тәлгат
Галиуллин

# ТАТАР ӘРЕМЕ

ХИКӘЯ

*Яшь әремнәр, уйдык-уйдык булып,*
*Ызан буйларына тезелгән.*
*Сәлам биреп кенә китим, дисәм,*
*Кочып алды алар тearемнән.*
*И әремнәр – туган нигез гаме!*
*Тыйнак та сез, әрсез, ярсу да...*
*Елыйсылар килә үкси-үкси,*
*Тезләнепләр сезнең каршыда.*
Сания Әхмәтҗанова

Кояш нурларын юксындырган, күзгә күңелсез көннәрнең берсе иде. Иртәдән кеше гомеренең ифрат кыскалыгын, безнең белән киңәшеп тә тормыйча, тиз узып китүен искә-ятькә төшергәндәй, туктаусыз вак пыскак яңгыр сибәли. Каударланып, абына-сөртенә ашыгып барыр җирем, зарыгып, ямансулап көтеп торган кешем булмаса да, автобус тукталышына титаклыйсы килми. Җиңел машинада, ян тәрәзәдән терсәкне чыгарып йөрүгә мөкиббән китүе белән яшь, көнче, шаян каләмдәшләренең теленә эләккән дустым Мөхәммәт Мәһдиевнең, «форсат чыкканда, мөмкинлегең булганда, хатыныңның «юк акчаны әрәм-шәрәм итеп, бушка туздырып йөрисең, дип фырылдавына да исең китмичә, борыныңны тиешле югарылыкта тотып, таксида гына йөрергә тырыш», дигән васыятен үтәү өчен генә түгел иде машина чакыруым. Аның башка җитди сәбәбе дә бар иде. Хикмәт шунда: улларым үсеп җитте, оныкларым тупылдатып җиргә басып йөриләр, кешенекеннән кайтыш җире булмаган хәләл җефетем янымда, пинсәмне вакытында китерәләр, дөньям түгәрәк, дип, сөенеп, авызны җыя алмыйчарак йөргән бер мәлдә, «туктале, син, кем малай, артыгын сикерәсең, бәхет ул, ташбака кебек, акрын гына, сиздермичә генә яшәүне ярата», дигәндәй, Ходай Тәгалә яраткан пәйгамбәрләре Әюб белән Ибраһимга җитди сынаулар җибәргән мисле, миңа да бер-бер артлы диярлек, гавам телендә паралич, тыйб фәнендә инсульт дигән зәхмәтен җибәрмәсенме?

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН (1938) – *язучы, тәнкыйтьче; филология фәннәре докторы, Татарстанның һәм Россиянең атказанган фән эшлеклесе. «Сәет Сакманов» роман-трилогиясе, «Замана балалары», «Дәгьва», «Мәһдиев йолдызлыгы» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Үземнең танырга «кыюлыгым» җитмәсә дә, гөнаһларым җыелган булгандыр инде күрәсең. Мин үтәсе язмыш булгандыр. Дөрес, ошбу хәтәр авыру төп яшәү чыганагыма – телемә кыңгырау салмады, кырау төшермәде кебек. Мәгәр чакырган җиргә чыгып йөгерүләрне киметергә туры килеп, хөкүмәтнең юл йөртү чараларына керү-чыгулары кыенрак була башлагач, машиналы якыннарым кәҗәләнгәндә, такси белән йөри башладым.

Янтавына шакмаклар ясалган, түбәсенә чакыру саннары язылган дүрт көпчәкле араба хуҗалары белән аралашу үзе бер дөнья икән. Беришесе акча ягын гына каера, барыр юлыңны белмәсәң, 500 метр араны 10 чакрымга сузарга мөмкин, артык комсызлыкка бирелмәгәннәре, үзе, гаиләсе турында гәп корырга ярата, өченчеләре олы сәясәткә кереп китеп, президентларга, патшаларга бәя биреп алырга да күп сорамый...

Түләүле машина чакыруның күңелне нурландырган ягы шул: телефон трүбкәңне куярга өлгермисең, аргы яктан, күптәнге яхшы танышыңны хәтерләткән тавышлы хатынмы, кызмы сиңа, «фәлән-фәлән нумерлы машина сезне баскыч төбегездә көтеп тора. Хәерле юл сезгә! Сау-сәламәт булыгыз!» – дигән теләкләрен дә юллый.

Шундый итагатьле мөнәсәбәттән җылыга тарган балавыз кебек эреми калуың да җиңел түгел. Ә бит тышына «Ашыгыч ярдәм», дип, ат тешләре кебек эре хәрефләр белән язылган тыйб машинасын сәгатьләр буена көткән вакытлар да булгалады.

Ул көнне кай тарафларга барганымны, күкрәккә кулымны куеп, өздереп әйтә алмыйм. Иң еш һәм теләп барган җирем Язучылар берлеге булганга, Мөштәри хәзрәт исемен йөрткән урамны «бәхетле» иткәнмендер дигән җитди шигем бар. Чакырган арабамның бик тиз килеп сылануын тәгаен хәтерлим. Гадәттә, мин ярдәмче дустым – кул таягымны урнаштырырга җайлырак, дип, икенче рәткә өстенлек биргәнгә, бу юлы да шул арткы утыргычка кереп урнашкач, йөртүче белән әүвәл татарча исәнләшәм. Җавапны үзгә телдә алсам, монда хәлләр шул тирәдәрәк икән, дип, барыр ноктамны кабатлыйм да шыпырт кына тәрәзәдән карап утырам. Бу юлы сәламемә, исемен соравыма «исәнмесез» һәм «Адель» дигән җавапны алу күңелемне эретеп җибәргәндәй булды. Укытучы кауме, ягъни мәсәлән, мин, белемен күрсәтмичә түзәме соң инде? Адель түгел, Гаделдер инде дөресе, «Тапшырылмаган хатлар» авторы Гадел Кутуй турында ишеткәнегез бардыр, шәт? Йөртүчем, минем якка борылып:

– Может, дөресе Гаделдер. Мин Адельга күнеккән инде. Сез әйткән китапны укыганым юк, адашның язганы белән, Аллаһ кушса, танышырмын әле, Ул исән түгелдер инде...

– Ул – соңгы сугыш батыры. Җиңүгә бик аз көннәр калгач һәлак була.

Шул кыска гына аралашу мизгелендә йөртүчемә, мишәрең әйтмешли, дикъкать беләнрәк бактым. Сырган коңгырт куртка кигән, симез күренмәсә дә, тулы гәүдәле, кыска киселгән кара чәчле, ияккә таба очланыбрак киткән түгәрәк битле ир-егетнең минем белән килешүе, бәхәскә кереп тормавы аркасындамы шунда, үзенә нисбәтән, әйткәнемчә, җылы мөнәсәбәт уятты. Җитмәсә, сүзчән ир-егеттән икән үзе. Рус, татар, тагын башка бер лөгать кәлимәләрен аралаштырып өстәп куйды.

– Абый, минем телемнән көлмәгез инде. Мин бит ярым татар, ярым үзбәк.

– Соң, без бит бер уртак – төрки тамырдан чыккан халык балалары, телләребез якын. Күтәренке рух, пафос белән өстәп тә куйдым:

– Төркиләр, якут-саха белән чувашлардан башкалар, һәммәсе мөселманнар.

– Әтием үзбәк булып, яшьлегем шунда узгач, миңа үзбәк теле якынрак.

Миңа Адель-Гаделнең ошбу искәртүе җитә калды. Сүз ташкынын ерып ук җибәрде.

– Үзбәкләр – күптәнге, мәдәниятле халык. Сез беләсезме икән, Американы Колумб түгел, ә үзбәк сәяхәтчесе Әмир әкә дигән кеше ачкан.

Йөртүчем, ак, тигез тешләрен алдындагы көзгедә ялтыратып:

– Ишеткәнем юк, – дип куйды, битараф кына. Аның, урыс әйтмешли, миңа «до лампочки», дип, сиздерүе кебек аңладым минем мәзәккә мөнәсәбәтен.

Ул юк-бар сүзем өчен төрттерепме, әллә мине «яктыга» чыгару нияте беләнме:

– Сез укыган кеше күренәсез, үзбәкчә берәр сүз беләсезме соң?

– «Нан», «Һоп мәйле» кебек бар төрки дөнья белгәннәрне хәтерлим һәм бөек шагыйрегез Алишер Нәвои иҗаты белән бераз танышлыгым бар.

Бохарада фәнни очрашулардан соң, чәй-мәй мәҗлесендә үзбәк галимнәре үзләре үк сөйләгән бер-ике мәзәк хәтердә калган. Шуларның берсе – Бохара ханлыгы чоры белән бәйле. Кайсыдыр хөкемдарның сарае алдындагы мәйданчыкка көннәрдән бер көнне бик күп гади халык җыелган имди. Аларның кычкыруына, гөр килеп шаулашуына уянган, тынгы бирмәгән өчен җене чыккан хан, чуар халатын кия-кия, ачулы тавыш белән вәзиреннән сорый икән: «Ниткән тавыш, халык ник шаулый, нәрсә җитми тагын аларга»? Үзе дә югалып калган вәзир, гаепле кешедәй, күз карашын паласка төшереп:

– Нан сорыйлар, бөегем, – дип аңлата.

– Әмир, ач халыкка ипи бирергә боерган дип уйласаң, бик нык ялгышасың, егетем. Ул чуалышларга, кан коешлы инкыйлабларга алып килгән мәсьәләне бик «җиңел» хәл итә.

– Менә ахмаклар. Нан кирәк аларга. Нигә пылау йә мантый гына ашамыйлар, – дигән ачыкламыш килеп ирешә вәзирнең оялудан кызыл төскә кергән колагына.

Гадел, кулыннан машина рулен ычкындырмыйча гына, рәхәтләнеп көлде дә үзе дә шул ук ханлык турында бер сөйләкне исенә төшереп алды.

– Мин ишеткәне дә соңгы Бохара ханы белән бәйле. Бераз оятсызрактыр да инде шунда, – дип төртелеп калды. Сүзнең ни-нәрсә турында барганын чамалап, егеткә ярдәм иткәндәй:

– Әйдә, сөйлә, күңелеңдә калмасын. Татарлар «А» хәрефен әйтсәң, «Б»сын да рәнҗетмә, диләр. «Монда ят кеше, бигрәк тә хатын-кыз юк, без икәү генә», дип тә өстәүне мәгъкуль күрдем.

– Ярый алайса. Кыскача гына болай («короче», диелде). Өйләнә торгач, ханның хатыннары бишкә җитә. Шәригать кануннары буенча, ир-ат ничә хатын алса да, аларның берсен дә матди яктан рәнҗетмәскә, тигез күрергә тиеш. Хан үз сараенда һәркайсына аерым-аерым затлы бүлмәләр эшләтә, шымчыларын куярга да онытмый.

– Соң ул аларның һәммәсенең күңелләрен күрергә ничек өлгергән, каян көч алган, әле бит хөкүмәт мәшәкатьләре дә җитәрлек, – дим, үземчә ханның «авыр хәленә» теләктәшлек белдереп.

– Күп хатынлы булуның да уңай ягын тапкан хан. Юкка гына яшьрәк чакта чит илләрдә белем эстәп йөрмәгәндер.

– Соң, уңай ягы, маңгайдагы мөгез кебек, алга чыгып, ерактан күренеп тора. Оҗмахта яши. Бер көнне берсе янында куна, икенче көнне икенчесе кырында пәйда була...

– Юк шул, бу четерекле төенне ул башкачарак чишә. Биш хатыны да «бүген хуҗа теге себеркесе түшәгендә эреп ята», дип, бәхетлене каһәрләп, ялгызлыкларына зарланып, төнбоеклар кебек, күз йоммыйча, үз сәгатьләрен көтеп яталар. Ә хан үз бүлмәсенә кичке ашны китертеп, сөяк кимереп, бикләнеп, җәелеп ятып, йокы симертә. Тик аны, ара-тирә, пылау ашамыйча, нан сорап, «аңсыз» халык кына уята.

Без шулай мәзәкләр сөйләп, үзебезне юаткан көннәрдә татар теле олы тарихында иң авыр, кысынкы, аянычлы мизгелләрен кичерә иде. Тел гелән авырткан тешне кармалап торган шикелле, бу мәүзугны әйләнеп үтеп булмады. Ярым үзбәк-татар егетеннән берәр нәрсә торган шикелле, «телебез белән дуслыгыгыз ни дәрәҗәдә», дип сорап куйдым.

– Үзбәкстаннан Казанга күчеп килүебезгә шактый вакыт үткән булса да, татар теле мине кочагына алырга бик ашыкмый әле. Сүз байлыгым бик чамалы, ипи-тозлык кына дисәң дә ярый. Үзбәк, татар лөгатьләрен бутыйм-бутыйм да, боткадан тозлы кәбестәгә – русчага күчәм.

Еш яңгырый торган җырдагыча, әйтергәме икән, әйтмәскәме икән, дип, икеләнебрәк торды да, чамалавымча, милләттәшләремә, шул исәптән миңа да төрттеребрәк аңлатмасын бирде.

– Миңа утырып йөргән татарларның бик сирәге сезнең кебек татарча сөйләшерлек иделәр. Күбесе телегезне, гафу, телебезне әллә белмиләр, әллә куркалармы инде. Татарча ватып-җимереп сөйләшүемнән үзем оялам. Ул бит минем икенче, яһүдиләр күзлегеннән караганда, беренче туган телем.

Ни өчен икәнен чамаласам да, түбәндәге фикерен үз авызыннан ишетәсем килде.

– Хикмәт нәрсәдә?

– Әнием – килеп чыгышы, нәсел-нәсәбе ягыннан Кукмара төбәге баласы. Әтием үзбәк иде, – диде.

Шул мәлдә Урта Азиядә дә, башка кыйтгаларда да үз дәрәҗәләрен югары тота белгән Кукмара кызлары белән, бер хакым булмаса да, масаеп аласым килде. Сүз кая да ким-хур булып калмау турында бармый. Әдәбиятыбызга, сәнгатебезгә ничаклы затлы шәхесләрне тудырып, үстереп биргәннәр шул төбәк чибәрләре. Тел очында торган мисаллары да саллы. Дөнья әдәбиятына Чыңгыз Айтматовны бүләк иткән Нәгыймә апабыз да шул яктан. Атаклы җырчыбыз Ринат Ибраһимовның әнисе Асыл апа да шул төбәктән. Бүген дә атаклы милли итекләре белән генә дан тотмый икән Кукмара. Агымдагы сүз сәнгатебезгә дә Фоат Галимуллин, Газинур Морат, Рифә Рахман кебек талантларын җибәреп тора. Белүемчә, алар, туган яклары белән горурланып, хәлдин килгәнчә, хаерһак кылып яшиләр.

– Әниең ул якларга ничек барып чыккан соң, күптәннән Үзбәкстанда яшиме? – дигән сорауның тел очымнан «очып чыгып» китүе табигый иде.

– Әнием шунда туган. Аның әти-әнисе, 1917 елгы революциядән соң, 30нчы елларда хәлле кешеләрне кыерсыту башлангач, Себергә озатылудан качып, шул якның ерак бер кышлагына барып сыенганнар. Дөньялар бераз тынычлангач, Әндиҗанга күчкәннәр. Әнием шунда туып, сугыштан соң, пединститутны тәмамлап, бер үзбәк егетен – минем әтиемне бәхетле иткән.

Машинабыз кызыл утка туктау сәбәпле, минем якка борылып, елмаеп:

– Мин шул мәхәббәт җимеше, – дип куйды.

Ике тугандаш халыкның җан җылысын, яшәү дәртен алган, сүзчән ир-егет миңа ифрат ягымлы, кешелекле күренде. Ияккә очлана килгән бите татарныкы

булса, өлгергән карлыгандай кара, елгыр, читләре кысыграк хәйләкәр күзләре үзбәкнеке иде.

– Сез Казанда күптәннән яшисезме инде?

Кемгәдер ачыласы килепме, әллә фани дөньяда шактый яшәгәнлегемне сатып торган чыраем ышаныч уяттымы, өздереп әйтә алмыйм, ул үз тормышларын бәйнә-бәйнә бәян итеп китте.

– Әтием үзбәк, дигән идем. Әниемне яратып кадерләгәнгәме, күбрәк аның аркасындадыр, «татарлар белемле, укыган халык», дип яшәде. Казанга күчеп килүебез дә әти аркасында булды.

– Ничек алай инде ул? Үзбәк карты сезне Казанга алып килсен ди. Әниең туганнарын барлап, әтиеңне дә үзе белән иярткәндер.

– Дөрес әйтәсез! Әнием сезнең, хәзер инде безнең Татарстаныбызга, берничә тапкыр кайтып килгәние. Бу юлы безне бу якка әти, ягъни Самат карт, алып кайтты.

– Кызык! – дип кенә әйтеп кала алдым, чөнки егетем, көттереп интектермичә, сүзен дәвам итте.

– Бу якларга безне әтинең авыр чире юллады.

– Әллә мине эзләп тапкан шикелле, аны да инсульт аяктан ектымы?

– Юк, хет анысыннан Аллам саклады. Үзбәкләрнең яраткан ризыклары шашлык, пылау, манты, гомумән, кыздырылган ит ише ашамлыкларга җылы мөнәсәбәте нәтиҗәсендә әтием ашказанын имгәткән булып чыкты.

– Нәрсә дигән сүз була инде ул?

– Эчем авырта, тамактан ризык үтми, дип зарланып йөри башлагач, әни аны, җилтерәтеп, докторларга алып китте. Табиблар соңгы стадиядәге рак чирен таптылар әтинең ашказанында. Үзенә сиздермичә генә, әнинең колагына, дөньялыкта өч-дүрт айлык гомере калган, дигәннәр. Әни, аларга ышанмыйчарак, әтине Татарстан докторларына күрсәтергә булган.

Мин, гаҗәпләнүемне яшерә алмыйча:

– Сәер, медицина сездә дә берүк дәрәҗәдәдер инде ул. Совет чорында да игътибар сезгә күбрәк булды. Хәзер инде мөмкинлек офыкларыгыз бермәбер киңәйде. Болытлы көнне елмаеп кояш чыккандай, язмыш көтмәгәндә, уйламаганда, үзләренә сугышсыз-корбансыз тулы мөстәкыйльлек бүләк иткәч, үзбәкләр, казахлар, гомумән, Урта Азия халкы һаваланып киттеләр, әлифбаны кул арбасы белән тартып килеп, «әлпи-тиси»гә өйрәткән, аң-белем алуда ярдәм иткән татарларга өстән-аска, биектән, тилгән чебешкә баккан мисле түбәнсетеп карый башладылар. Уртада кысылып калган татар халкы капкынга эләккән җанвар кебек тыпырчына, бер яктан да һич югында информацион ярдәм дә юк мөселман кардәшләрдән.

СССР заманында төрки галимнәр, язучылар үзара аралашып, мәш килеп яши идек. Хәзер андый элемтәләр калмады диярлек.

Егетем ихтыярымнан башка бәреп чыккан моң-зарымны, яшь түгүемне тыныч кына тыңлап барды да:

– Мин гади кеше. Югары белемем булса да, олы сәясәттән хәбәрдар түгелмен. Урыслар «не копенгаген», диләрме әле? Минем өлкәм түгел. Ике халык баласы буларак, үзбәкне дә, татарны да бер үк дәрәҗәдә зурлыйм, якын күрәм, ярдәм итешеп, дус яшәүләрен телим. Чөнки ике канатымда да олы тарихлы, бөек халыклар фәрештәләре утыра.

Үзен «мин гади кеше» дип тәкъдим итеп, чытыкланса да, аның шактый әзерлекле, күп нәрсәдән хәбәрдар егет икәнлеген аңлау өчен фәрештә – мәлик

булуның кирәге юк иде. Мин шуңа гаҗәпләнергә дә өлгермәдем, ул йомгакны сүтүен дәвам итте.

– Гомеремнең яртысы үзбәк илендә үтте, калган өлешен монда уздырырга ниятлим. Язган булса.

Кечкенә генә күл буе үрен менгәннән соң, шик-шөбһәгә урын калдырмаслык итеп, өстәп куйды:

– Татарстанга, аерым алганда, Кукмара белән Казанга без рәхмәтле дә, бурычлы да.

Машинабыз исә, безнең гәпләшүгә исе дә китмичә, инде тигез юлны көпчәкләре белән сыйпавын дәвам итте. Ә сүзебез әле, чүпрәгә тарган камыр кебек, «күпереп» кенә килә иде.

– Әтинең авыр чире аеруча әнине тәшвишкә (нәкъ шул сүзне әйтте, күрәсең, ул үзбәккә дә кергән) салды.

Мондый очракларда әйтелә торган сөаль үзеннән-үзе, куркытылган кош мисле, «пырхылдап» очып чыкты.

– Әниеңнең борчылуы табигый хәлдер. Гомерләре бергә узган.

– Әйе шул. Әнием күз алдында картайды, битләре салынып төште, күз төпләре күмер белән буягандай каралды, йөрүе салмакланды.

– Еллар да үзен сиздерә торгандыр, – дип кенә сүзгә кысыла алдым.

– Әнием терекөмеш кебек хәрәкәтчән, шуның өстенә, этидән аермалы буларак, көрәшче рухлы шәхес.

Әти язмышына ризалашкан, даруларга да, киңәшләргә дә кулын селтәгән иде, әнинең «Казанга барып киңәшеп, күренеп кайтыйк», диюенә дә, «мин беркая да бармыйм, менланы чакырып укытам да якты дөнья белән үз аңымда чакта саубуллашып калам», дип, үзенекендә торды. Әнием башлаган эшен, гамәлен ярты юлда калдыра торган кеше түгел. Беренче мәлне аңа чит кеше итеп, кырынрак караган күрше-күлән, хәтта ташны тишеп чыгардай чая үзбәк хатыннары белән дә җитәкчелек итә, юнәлеш биреп тора башлады. Әти белән сатулашканның икенче көнендә, бер ләм-мим сүз әйтмичә, каядыр барып кайтып, бераздан, бусаганы атлап керүгә, «минем туганнар янына кайтып, кешечә саубуллашып киләбез, иртәгә оча торган Ташкент-Казан самолётына дүрт билет алдым, үзебезгә һәм Гадел белән Нәзирәгә». Әти ягына борылып: «Барасың килмәсә, мә билетыңны, теләсәң нишләт. Кирелегеңне җиңә алмасаң, тапшырып кайт, акчасы үзеңә булыр, мин балалар белән очармын», диде. Әтинең артка чигенерлек чамасы тавык кетәге хәтле генә калган, дөресе, ул камалышка эләккән немец генералы фон Паулюс хәлендә иде.

Хамраевлар (ул фамилиясен дә әйткән иде) гаиләсенең кайгысы минем борчылуга әйләнгән иде инде. Пырдымсызланып, сорап куйганымны да сизми калдым.

– Шуннан, Казанга очтыгызмы?

– Әлбәттә. Әтинең билетын тапшырып йөри алмавы, үзе генә өебездә утырып калмавы якты көн кебек ачык иде. Билетын кире кайтару мәшәкатьләренә караганда, очкычка утырып сәфәр тотуы җиңелрәк бит. Әни сүздә, бигрәк тә чит кешеләр, таныш-белеш алдында, этине хуҗа итеп, олылап яшәсә дә, чынлыкта тәртә башы аның кулында иде.

– Казанга килеп төшкәч, кая бардыгыз инде? Кунакханәгә урнаштыгызмы?

– Юк. Машина яллап, Кукмарага киттек. Безне каршы алган, ахыр бик якын иткән ерак туганыбыз Зөфәр Гарипов җирле бульнистә хирург булып эшли икән. Әнием, аның белән элемтәгә кереп, барысын да алдан сөйләшеп куйган.

Кучтәнәчләрен дә алырга онытмаган. Зөфәр абый ифрат ярдәмчел, җитмәсә, халык медицинасын таный торган доктор булып чыкты.

– Бар анализларны тапшырып, Казанда урын юнәткәнче, үзем дәвалап карыйм әле, диде.

Им-том да, күрәзәче-шаманлык та түгел иде аның бу гамәле. Бергәләп ак кыр әремен җыеп кайтып, азрак киптереп, шуны кайнатып, суытып, төнәтмәнең ярты стаканын этигә иртән ач карынга эчерү, кичен, йокы алдыннан, шул ук процедураны янәдән кабатлау иде аның бар сые. Ун көн дәвам итте шул гамәлен.

Кыргый әрем ярдәм иттеме, химиянең файдасы тидеме, әллә энинең тырышлыгы, Татарстанда җылы кабул итү ракны өркеттеме, әйтә алмыйм, әмма нәтиҗәсе үзен озак көттермәде, өч-дүрт айдан якты дөнья белән саубуллашасы Әбүзәр карт тагын ун ел, яраткан ризыкларыннан баш тартмыйча яшәде. Җитмәсә, Татарстаннан бер кочак ак әрем күтәреп кайтты һәм таныш-белешенә, «бездә бар нәрсә дә җитешә, тик менә шундый үзе ачы, үзе шифалы үлән генә үсми», дип, ак әремегезне ду килеп мактап йөрде.

Гадел, алда машиналар күбәеп киткәч, бераз тынып торды да яңа бер табышмак әйтеп куйды.

– Татар иле безгә янә гаҗәп, бәяләп бетергесез бер яхшылык эшләде.

– Әрем суы тагын берәрегезне савыктырдымы әллә?

Минем кинаяле соравыма ул җитди итеп җавап бирде.

– Кем белә инде. Бәлки, әремнең дә файдасы тигәндер, чөнки, этигә кушылып, хатыным да төнәтмәне эчкәләде. Татарстан һавасы килештеме, табибларыгыз белемлерәкме, әйтә алмыйм.

Җан тартмаса, кан тарта, дигәндәй, мәркәзегезне яраттык һәм хатыным белән монда күченеп килергә булдык. Үзебез алырга өлгергән фатирыбызны, машинабызны сатып, абый-энеләрдән бурычка алып, «малосемейка» дип йөртелгән кечтеки генә бүлмәчек юнәттек. Хатыным, белеме буенча шәфкать туташы, эшкә тиз урнашты. Миңа, авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаган инженерга, шәһәр шартларында иң кулае автобус йөртүче булып чыкты, бераздан төшемлерәк эшкә, таксига күчтем.

– Туып-үскән ягыгыз сагындырмыймы соң? Анда җылы, салкын кар бураннары дуламый, җиләк-җимеш арзан. Юкка гына, ач-үксезләр, заманында «Ташкент – город хлебный», дип, авыз суларын корытмаганнардыр? Кыйммәтле кышкы туннарга да акча сарыф итәсе түгел.

– Ул хәтлесе дөрес. Җиләк-җимеш, алма, хөрмә, кавын, карбызише нигъмәтләр очсыз булса да, анда хезмәт хакына түләү юк дәрәҗәсендә, гомумән, сәмәнне кулга төшерүе бик авыр. Тырышып эшләсәң дә, «сынауны уза алмадың», дип куып чыгаралар, ахыр чиктә, кулыңа бер торпедо кавын тоттыралар да, башка бу якта буталып йөрмәссең инде, дип, капкага чаклы ук «зурлап», озатып куялар.

Сүзчән егетемнең озын итеп сөйләве, Урта Азиядә яшәүче кавемнәрнең бер үзенчәлеге, һавалар салкынга авышкан саен, сүзләр авыздан кысылыбрак чыга икән, азга гына тукталып торып, үзен эзләмиләрме, ашыгыч заказ юкмы, дип, теге юмарт тавышлы кизү ханымга шалтыратып алды да фикерен җөпләп китте.

– Тәмле-томлы нигъмәтләргә иркенлек булса да, үзбәкләрнең җиләк-җимешкә исләре китми. Алар, минем эти шикелле, күбрәк кыздырылган, пешерелгән итле ризыкларга, тәнгә сихәтле дәрт өстәүче яшел чәйгә өстенлек бирәләр. Сез дә бит, әнә, без килеп шифалы файдасын ачканчы, әремгә сәлам

да бирмәгәнсез, – дип, Гаделем, ак тигез тешләрен күрсәтеп, кеткелдәп көлеп куйды һәм сүз кәлимәсен дәвам иттерде.

– Казан атаклы югары уку йортлары, дөньякүләм танылган галимнәр, Тукай, Исхакый кебек бөтен төрки дөньясының якты йолдызлары (мин шаккатып, чак телемнең яртысын тешләп өзмәдем) белән данлыклы. Сез әйткәнгә өстәп, урысның икенче мәкале дә барын онытмыйк: «не единым хлебом сыт человек». Адәм баласының җаны да азыкка мохтаҗ (янә телем чүт-чүт исән калды). Минем шулай, соңарып килгән яз шикелле, көтеп алган нарасыйларыма белемне Казанда бирәсем килә.

Гаделем тышкы сөйләмен – монологын әтисе халкына хас тантана белән диярлек тәмамлады.

– Аларны, укуларын тәмамлагач, дәү әниләрен биргән изге җиргә хезмәт иттерәсем килә!

Мин инде күптәннән машинаны үземнән азат итәргә тиеш идем, мәгәр могҗизаның сере ачылмыйча, селкенәсе дә килми. Җитди итеп уйласаң, бәяләсәң, миңа ни пычагыма кирәк инде кемнәрнеңдер хәл-әхвәлләре, кыланышлары? Шулай да, түзә алмыйча, сорауны кабатладым.

– Соң, могҗиза дигәнегез нәрсә була инде?

Егетем, иренмичә, чын үзбәкләрчә, сүзләренә буш кулы белән булыша-булыша бәян итте:

– Минем шикелле үк метис, ярым үзбәк, ярым уйгур кызы Нәзирә белән егерме ел гаилә булып яшәдек. Балдан ычкына алмаган чебеннәр кебек яратышып көн иттек. Тик дөньябызның бер чите кыелып төште. Болытлар куерды. Гаиләбез таркалу ноктасына килеп җитте.

Урта Азия халыкларының кинаялап, озын-озаклап сөйләргә яратуын белгәнгә, мин, кигәвен тешләгән ат кебек, пырдымсызланып, Гаделне бүлдерергә җөрьәт иттем.

– Яратып өйләнешкәч, рәхәтләнеп, балалар сөеп, кавын артыннан ләпәшкә белән яшел чәй эчеп, җимертеп яшисе дә яшисе иде. Могҗиза дигәнең лотереяга затлы машина отудыр әле. Мәхәббәтегезгә томау төштеме, дисәм?

– Бөтен фаҗигабез бала шатлыгын татый алмауда булды шул. Кая гына барып төртелмәдек, нинди генә шифаханәләрдә дәваланмадык. Файдасы тимәде. «Ирлегең юктыр, күршеңне чакыр, булышсын», дип, үземнән ачыктан-ачык көлә башладылар. Үзбәкләр нәсел дәвамчысы булмаган гаиләләрне кунакка чакырмыйлар, үзләре дә килмиләр. Чума яисә тиф авырулы йорттан шикләнгән кебек, әйләнеп узалар. Баласыз гаиләләргә шундый кырыс мөнәсәбәт Казанга күчеп килүебезне тизләткәндер дә инде. Монда безне белмиләр, «үзебез өчен яшибез», дип шомартып та булыр иде. Кыскасы, без диңгездәге кораблар шикелле, як-якка таралышу яисә кеше баласын алу чигенә килеп терәлгән идек.

Мин, машина ишеген ачып, бер аягымны чыгарып:

– Йә, могҗизаңны әйт, исәп-хисапны ясыйк та, мин киттем, синең һәр минутың кадерле, Гадел дус, – дим.

– Могҗиза шул. Казанда яши башлавыбызга ике еллап вакыт узуга, 39 яшьлек хатыным ике бала: бер кыз, бер малай алып кайтты. Нәзирәм: «күңелем болгана, укшыта», диюгә, үзен өрмәгән җиргә дә утыртмадым, «минем ханбикәм», дип кенә йөрттем. Аллага шөкер, шатланып бетә алмыйбыз, тансыклап алган ризык тәмле була, диләрме әле? Җәмил белән Әминәм Казанны бик яраттылар. Җәен Үзбәкстанга алып барсак та, тизрәк үзебезгә кайтыйк, дип кыбырсыйлар. Инде өченче сыйныфта укыйлар.

Татар теленең, димәк, бөтен кавемнең киләчәге кыл өстендә эленеп торган көннәрдә шул сорауның биреләчәген алдан сизенеп, егетем:

– Хатыным татарчаны миннән яхшырак белә, балаларыбызга да татар, үзбәк телләрен өйрәтергә тырыша. Быел менә машина сатып алдык. Яңа ук булмаса да, үзебезнеке, – дип, рулен, тәрәзә төбен иркәләп, сыйпап куйды.

Аралашуның озаккарак киткәнен аңласам да, Кукмара ягы кызының язмышы белән кызыксынмый булдыра алмадым. Гомеремдә күрмәгән, улының бәясенә, кылган гамәлләренә караганда, булдыклы ханым күңелгә якын булып өлгергән иде. Тирән тамырларыбызда уртак кан аккангадыр инде. Үзеңнеке – үзәктә, кешенеке – кештәктә, дип белми әйтмиләрдер.

– Әтиеңнең вафатыннан соң, әниең монда, сезнең янга кайткандыр инде?

– Үзебездән дә артык тансыклап алган оныкларын якын итеп, «балаларның балалары балдан татлы», дигән әйтемегезне кабатларга яратса да, «әтиегез монда күмелде, мин аны ташлап китә алмыйм», ди. Татар хатыннары никахлы ирләренә, исән чакта гына түгел, үлгәч тә тугрылыклы калалар, дип ишеткән идем, дөрес икән. Икенче яктан, аның бит әле миннән башка өч җитлеккән баласы, оныклары бар. Барысы да Үзбәкстанда яшиләр. Аларга, бик теләсәләр дә, Татарстанга кайтып урнашу, тормышларын көйләп җибәрү җиңел булмаячак. Дөресрәге, хәзер бөтенләй мөмкин түгел. Без гасыр башындарак күченеп, урнашып кала алдык.

Мин, аны бүлдереп:

– Ярый, егетем. Синең белән аралашуы бик кызыклы да, гыйбрәтле дә булды, балаларыгызга, үзегезгә бәхетле тормыш телим! Әниеңә, фәлән-фәлән абыйдан, дип сәлам әйт!

Күкрәк кесәмнән ике йөзәр сумлыкны чыгарып, Гаделгә суздым. 160 сум тиеш идем. Йөртүчем, минем якка борылып, татар йөзен балкытып, үзбәк күзен уйнатып, җәһәт кенә, акчаның берсен суырып алды да:

– Шунысы җиткән, абый, – диде.

Мин аптыраудан югалып ук калдым.

Егетнең ихластан әйткәнен тавышының тембрыннан ук сизеп, «алай яхшы түгел бит инде ул», дип мыгырдансам да, инде Казанныкы булып киткән Үзбәкстан егетен рәнҗетмәскә булдым. Ни генә әйтсәң дә, туган җиремдә үскән үлән, табибларыбызның яхшы мөнәсәбәте бер үзбәк картының фани дөньядагы гомерен озайткан, улына ике нарасый бүләк иткән. Нәселе Кукмарага барып тоташкан әнисе – Зәйнәп апабыз да татар хатыннарының намусына тап төшермәгән. Ниһаять, татар әреме өчен горурлыгым шул чаклы көчле иде, 60 сум өчен вакланып тормаска булдым. Сибгат Хәким әйтмешли, горурлык хисе, аяк бармакларымнан өскә күтәрелеп, йөрәк аша узып, күз яшемнең тамчыларын энҗеләде. Менә шундый икән ул татар әреме. Без аның кадерен генә белмибез! Татарныкы булып калган соңгы «таянычыбыз» түгелме соң ул безнең?



Лилия
Гыйбадуллина

# АННАРЫ – МӘҢГЕЛЕК САГЫНУ...

* * *

Барлыгымны беләм. Барлыгымда –
Булмышымда әрем чәчкә ата.
Йолдыз тынын күмеп, таңнар ата,
Карлыгачлар оясына кайта.

Җил тузына, төссез тузаннарны
Кыек өсләреннән куар булып.
Күк имәнеп яңгыр җебен суза
Кара җиргә, үксеп елар булып.

Булмышымда – җирге тормышымда
Зәңгәр пәрдәләрдә көн чайкала.
Таш юлларга аяк терәп, төнгә керә,
Өр-яңадан төсен җуеп һәрбер кала.

Минем булмышымда-сулышымда
Өермәдәй дулый сүз бураны.
Бишек җыры булып тамчы тама,
Курай итә җилләр һәр кураны.

Еллар кайта, битлекләрен салып,
Көзгеләрне сара соры төсләр.
Хәнҗәр хыялында чынга аша
Кызыл шәфәкъ, кара-кучкыл кичләр.

Булмышымда мизгел өне сеңә
Һәр адымга, җырга, кайтавазга.
...Гавам карашыннан качып кына,
Әрем чәчкә ата һәрбер язда.

Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА – *шагыйрә; «Мин бәхетне күрәм!..», «Тынлык кайтавазы», «Кайту» исемле китаплар авторы, «Белла» халыкара әдәби премия лауреаты. Чаллыда яши.*

## Соң инде…

Соң инде, җырлама. Җырыңны
Аңламас бу җирдә берәү дә.
Өстеңә үз шәүләң егылыр чигеңдә,
Кирәкми, ябышма терәүгә.

Моңыннан ваз кичкән сандугач!
Терәтер булыпмы вакытны,
Туктатыр булыпмы чиргүне,
Кыйблаңа шулкадәр ашыктың?!

Соң инде. Кыелган өметләр,
Югалган моңдашлар, ишләрең.
Ник саклап калмадың? Аларны,
Җырыңны якларлык нишләдең?

Ялгызың торасың юлларның
Төенгә чуалган чатында.
Малың да, җаның да юк синең,
Юк синең атың да, хакың да…

Теләнмә ятлардан мәрхәмәт,
Җырыңны калкан ит шәүләңә.
Җырыңда үткәнең яктырак,
Җырыңда сагышың шәйләнә…

Әмма соң. Артык соң. Җырлама!
Җаның да, җырың да ялангач.
Син кайсы орышның яугире,
Моңыннан ваз кичкән сандугач?..

* * *

Вакыт кәүсәсендә яңа буын,
Яңа уем, яңа кешесезлек.
Мин синеңме углың, газиз токым?
Үксезлекнең богауларын өзеп,
Кочаклыйсы килә безгә язган
Нигез ташын, кайтып ят яклардан.
Без генәме сагынудан сызган?
Без генәме җанын канатмаган?..

Иртәләре хыял тулы җирнең,
Өзелергә тора чылбырлары.
Мең гасырлык вакыт кабыгында
Кем җырлары анда? Кем еллары?

Яңа кешесезлек, яңа буын
Китеп бара, таптап нигез ташын.
Мин синеңме углың, газиз токым?
Эндәшмисең. Бәлки, шулай яхшы…

Таныйсыңмы мине, мин таң булып,
Хыял булып, бер уянган идем.
Уем булып вакыт кәүсәсенә,
Җырың булып, бер уелган идем.

Хәтер – туфрак. Шул туфракны
Таптап китә, гөл утырта, оя кора,
Иген игә, сата, зират итә…
Уза тора, бары да туза тора.

Яңа кешесезлек, яңа буын…
Бу туфракта инде яңа уен.
«Мин – мин түгел, мин монда булмадым!» –
Вакыт кәүсәсендә яңа уем.

## Буран гына

Оча. Зынҗырларын өзәр булып оча дөнья
Бәгыремә. Хәерлегә булсын.
Кан куесы, әйдә, ташып тулсын.
Ни кылсаң да, ни уйсаң да көн күзенә,
Тугры дөнья. Тыныңдагы
Төтен тәме булып сеңә бара
Һәр сүзеңә, үз-үзеңә.

Оча шәһәр, оча йортлар, елмаюлар…
Күз иярмәс тизлек белән туза күңел.
Китүчеләр көлә-көлә күккә аша,
Килгәннәре елый-елый килә торыр.

Әнә, икәү, карап бураннарга,
Ут кабыза үзәгемдә. Оча дөнья.
Оча дөнья, оча канатланып,
Оча дөнья буран кочагына!

Шул икәүне иркәлисем килә,
Үзем булып, иркә сүзем белән.
Алар талчыкканнар юкса җирдә
Буран гына, буран гына гелән…

* * *

Тәрәзәңне ачтың.
Иңнәреңнән
Каерылып очты канатларың.
Очты алар кысан мәңгелеккә.
Мин һичкайчан сине яратмадым.

Карап калдың томырылып, ник очмадың?
Очар өчен бер талпыну җитә.
Юлын җуйган бер мосафир булып,
Япа-ялгыз киттем синсезлеккә.

Качып киттем, ачык калды тәрзәң.
Ак күлмәгең калды сиңа кунып.
Сызылып калды урам, сызлап калды,
Канатсызлыгыңны аклар булып.

...Канатларың ап-ак иде – җилләр
Ак кар итеп кенә тараткандыр.
Мин һаман да синсезлектән барам.
Мин һичкайчан сине яратмадым.

## Яшәү

Ә яшәү дигәнең – җир һәм күк арасын
Тырышып, тырмашып икегә яру ул...
Аннары – мәңгелек ярату,
Мәңгелек табыну.

Бербөтен мизгелне, ипине урталай бүлгән күк,
Каерып икегә кисү ул,
Тынлыкта тончыккан мәлләрдә,
Җил булып исү ул.

Бербөтен сөюне, җитмәс дип чигенә,
Үткәнгә чигенә-чигенә икегә аеру,
Аннары – кояшсыз иртәләр,
Аннары – мәңгелек сагыну…

Бербөтен хыялны акка да, карага телгәләү,
Бербөтен өметне тураклау, бүлгәләү
Ул – Яшәү дигәнең…
Һәр бәндә умырып каера
Үзенә бүленеп биргәнен…

Юкса, бик гади барысы да.
Бу яшәү – бербөтен ипи ул.
Җир һәм күк арасын, агын һәм карасын
Бер итеп дөньядан үтү ул…

## Кайту

Кабат күзгә. Кыштыр-кыштыр көйгә.
Үзем – Үлмәсбикә кортка гүя.
Җылы оек кирәк, җылы өйләр...
Калын киен, йөрәгеңне сакла,
Урамнарда инде җилле, диләр...

Һәрбер җиле таныш, юкса, җирнең,
Һәрбер җөе таныш яраларның.
Күргәнем бар тәннән җан киткәнен,
Җирдә яңа кеше яралганын.

Һәрбер исе таныш, һәрбер хисе.
Бар ымнары таныш, бар сыннары.
...Бер йорт аша сиртмә кое иде,
Күперләре иде асылмалы...

Салкыны да таныш, ялкыны да,
Янган чак та булды, ялган чак та,
Караңгыга качар мәлләрем дә,
Тәрәзләргә ут ягылган чакта.

Мең сукмакта адашканым булды,
Кайтыр юлны кабат бер эзләргә.
Инде күптән такта кагылса да,
Җирдәге иң газиз тәрәзләргә.

Аклы-каралы бу дөнья йөзе
Мең төсләргә керде. Минем хакка.
Хак дигәнем нахак булды кайчак
Һәм хакыйкать булды иң зур хата.

Кайта-кайта кабат бу күзләргә,
Кыштыр-кыштыр, Үлмәсбикә кебек,
Мин үзем дә, кара күзләр булып,
Йөргәләрмен төшегезгә кереп.

# ЛИЛИЯ ГЫЙБАДУЛЛИНА. ШИГЪРИЯТ

Лилия Гыйбадуллина – яшь буын шагыйрьләр арасында иң талантлылардан. Фәлсәфилекне тирән психологизм белән кушу юлын тапкан – гаҗәеп тәэсирле һәм төрлечә укыла торган шигъри энҗеләр иҗат итә. Текст төзелешендә охшаш яңгырашлы авазлар кабатлануына корылган алымнарны күпләп куллана – сихерле аһәң тудыра. Татар поэзиясен үстерә торган сыйфатлар болар.

Зур, өлгергән шагыйрьләр иҗатында гына күзәтелә торган сыйфат – төрле юнәлеш-агымнарда яза ала, бер иҗат сукмагы белән чикләнми. Журналда тәкъдим ителгән шигырьләр арасында да шушы төрлелек күзгә ташлана.

Беренче шигырь «...Барлыгымны беләм...» – сызлану (экзистенциализм) фәлсәфәсе, якты сагыш, нечкә моң. Бер-берсенә тәңгәл, катлаулы эчтәлек белән форманың эчтәлек-фикер ягын аерып карыйк. Лирик герой яшәеш һәм тормыш, кеше гомере турында сөйли. Чынбарлыкта тормыш бар (әрем чәчкә ата), ул гаять матур (таңнар, карлыгачлар, яңгыр җебе, зәңгәр пәрдәләр һ.б.), тик кеше гомере тиз үтә – вакытлы («Булмышымда мизгел өне сеңә»). Әмма яшәү мәңгелек, һәр вакытлы гомердә кабатлана («Әрем чәчкә ата һәрбер язда»). Дүртенче строфа фәлсәфәне шәхсиләштерә, лирик герой – иҗат кешесе булып төгәлләшә һәм тагын бер мөһим фикер күренә: кыска гомернең мәгънәсе – тормыш матурлыгын күрүдә, яшәешкә бала – яңа гомер бүләк итүдә («Бишек җыры булып тамчы тама»), шушы матурлыкны җырга әйләндерүдә («Курай итә җилләр һәр кураны»)! Шул фәлсәфәне дәвам итүнең төрле мөмкинлекләр төене калдырылган, ачкыч билгеләнмәгән. Әйтик, әремнең «Гавам карашыннан качып кына» чәчәк атуы шундыйлардан, һәркем үзенчә укый ала торган яңа фикерләргә алып чыга. Шигырь күп укылышлы, күпмәгънәле.

Еш кына яңгыраш охшашлыгын ассызыклаган (аллитерация, ассонанс), кабатлауга нигезләнгән фигуралар (эчке рифма һ.б.) төрлечә укылышка юл күрсәткән төеннәргә (ачкычка түгел) әйләнә: *җил тузына, төссез тузаннарны; булмышымда – җирге тормышымда; сара соры* төсләр һ.б.

Кайчак камил шигырь структурасында кабатлауларның артык булуы да күзгә ташлана. Мәсәлән, беренче ике строфадагы *«Барлыгымны беләм. Барлыгымда – / Булмышымда әрем чәчкә ата» «барлыгымда»* сүзен икенче тапкыр кабатланганда алыштырасы килә (көй «*тормышымда*» сүзен сорый). Көйне боза торган тагын бер кимчелек – 10/10 үлчәмендә язылган шигырьгә өченче строфада 12/12 үлчәме килеп керү. *«Таш юлларга аяк терәп, төнгә керә, / Өр-яңадан төсен җуеп һәрбер кала» юлларын шунда ук 10/10 га кайтарасы килә («Таш юлларга туктап, төнгә керә, / Үзен-төсен җуеп һәрбер кала»*, әйтик). Чөнки текст – сөйләм шигыре түгел, көйләм шигыре. Дөрес, әгәр мондый тайпылыш әсәрнең фикер-идеясе тупланган урында булса, ул акланыр иде. Әмма мин андый мөмкинлек күрмәдем (бәлки, ялгышамдыр...).

Икенче булып килгән «Соң инде...» шигырендә дә 9/9 үлчәмен ярып, беренче строфаның өченче юлында 12 иҗек санала. Бу юлдагы «чигендә» сүзен алып ташлаганда, мәгънә дә артык үзгәрми, көй дә саклана. Яки «...Вакыт кәүсәсендә...» шигырендә 6нчы строфадагы беренче-икенче, 7нче строфадагы өченче юллар белән дә шулай. Әйтик: *«Хәтер – туфрак. Шул туфракны / Таптап китә, гөл утырта, оя кора» тезмәсен «Хәтер – туфрак. Шул туфракны* ***кеше*** */ Таптап китә, гөл****ле*** *оя кора»*, дип үзгәртәсе килә.

«Соң инде...» шигыре – бөтенләй үзгә, ул символларга нигезләнгән. Шигырь мәгънәләргә гаять бай, тәэсирле, символларны уку юллары күрсәтелмәү аны төрлечә аңлауга китерә. Шигырь лирик геройның – асылыннан, талантыннан, максатына барудан... ваз кичкән кешегә риторик эндәше формасында язылган. Риторик эндәш кичерешләрне соң чиккә җиткереп көчәйтә, лирик геройның сызлануы белән кушыла. Җыр, сандугач, чирү, кыйбла, ятлар, шәүлә – текст эчендә автор символларына әйләнә. Укылыш мөмкинлекләре шулкадәр күп, ул гомумкешелек проблемасыннан – конкрет-тарихи проблемага кадәр аралыкны колачлый.

Мәсәлән, хәзерге ситуациядә аны ниндидер башка кыйблаларга йөз тотып, туган телен якламаган татар кешесе фаҗигасе буларак та карарга мөмкин, гәрчә болай уку өчен детальләр ассызыклап күрсәтелмәсә дә. Кайбер укылыш юлларын күрсәтеп-калкытыбрак кую, ачкыч бирү отышлы булыр иде. Моның өчен кабатланган сүз-образларның санын киметеп, нәкъ менә мотивлаштырып кабатлау да җитә. Башка алымнары да бар.

«...Вакыт кәүсәсендә...» – күпмедер яшәгәннәрнең фәлсәфәсе, һәр кеше күпмедер яшәгәннән соң килә торган нәтиҗә! Әмма шулай ук символларга корылган бу текст, фәлсәфәдән бигрәк, гражданлык лирикасы үрнәге кебек укыла. «Мин синеңме углың, газиз токым?» соравы кабатлану лирик геройның, иң беренче чиратта, милләткә эндәшүе һәм аның бер вәкиле кебек чыгыш ясавы турында сөйли. Бу укылыш нигез ташы, җыр, таң (шунда ук XX йөз башы шигъриятендәге таң символы белән интертекстуаль бәйләнеш урнаша) кебек ассоциатив образлар ярдәмендә тирәнәйтелә. Нәтиҗәдә, яңа буындагы кешелексезлек түгел, бәлки милләтнең әйдаманнары, аның өчен янган «кешеләре» булмау эчтәлеген ала. Сүзләрнең төгәл һәм матур сайланышы, аларның текст эчендә уйландырырлык мәгънәләр тупланмасына әйләнүе, сүз уеннары (уем-уен; хәтерне таптау-нигез ташын таптау һ.б.), риторик сорауларның кичерешләрне киеренкеләндерүе – шигырьнең камиллеген һәм укылышын тәэмин иткән хасиятләр. Иң соңгы строфа текст контекстында фаҗигале укыла – татар милләтенең тарих барышында юкка чыкканлыгын раслаган «уем» «вакыт кәүсәсенә» уела. Г.Исхакыйның «Инкыйраз...»ыннан килә торган фикер-кисәтү Л.Гыйбадуллина иҗатында тагын бер кат үзенчәлекле яңгыраш ала һәм XXI гасыр татар шигъриятендә гражданлык лирикасының үзгәрүенә (совет чорындагы – яшерен эчтәлек тә, үзгәртеп корулар чорының декларатив-ачык фикер белдерүе дә түгел инде) дәлил булып та килә. Шагыйрәнең осталыгын күрсәтеп, алдарак хасил ителгән уем-уен күчешләре укылышны шәхси яссылыкка күчерергә, гомере узып баручы лирик геройның шәхси кичерешләре, үткән тормышыннан, эш-гамәлләреннән канәгатьсезлеге, милләт язмышына нисбәтле мин дә үз өлешемне җитәрлек кертә алмаганмындыр, дип сызлануы кебек шәрехләргә дә юл калдыра.

Ассоциативлык, милли дөнья сурәтендә таныш образ-детальләрне сайлый белү, шигырьләргә кат-кат әйләнеп кайтып, аларның серенә төшенергә теләү тудыра. «Кайту»да да шулай. Күз символы шәхси яссылыкта – кеше гомеренең көзе буларак та, иҗтимагый кимәлдә – җәмгыятьтә туңлык дәвере башлануга да ишарә ясый. Текстта беренче, шәхси укылыш варианты калкытып куелган, икенче укылышка *«Урамнарда инде җилле, диләр...»* юллары ачкыч бирә, ялган чак – янган чак; тәрәзләргә ут ягылган вакыт, хакыйкатьнең хата булуы кебек детальләр аны көчәйтеп киләләр. Әмма шушы ике эчтәлек янында өченче – милли дөнья сурәте калка, Үлмәсбикә образы тирәсенә берәм-берәм җылы оек, сиртмәле кое, асылмалы күпер, такта кагылган газиз тәрәзәләр – җыелып, татар тормышының үткәнен сагыну, сызлану хасил итә. Шушы контекстта Үлмәсбикә – милләт символы, милләт анасы булып төгәлләшә дә, шигырь якты өмет белән сугарыла, татар халкының мәңгелек кыйммәтләре җуелмас, дип раслый. Шәхси яссылыкта ул кешенең киләчәк буыннар хәтерендә, сынында, уенда яшәячәген *(«йөргәләрмен төшегезгә кереп»)* якты өмет итеп күтәрә. Журнал вариантында булмаган, әмма шигырьнең әле генә укучы кулына килеп кергән «Кайту» җыентыгындагы вариантында тагын ике строфа бар. Алар инде иҗтимагый укылышны калкыталар, *«Кабат көзләр кайта, / Мин өзелеп көттем бу кайтуны»* юлларында көзнең – яз килүгә адым булуы, көз узганнан соң, яз киләчәгенә ышаныч белдереп яңгырый. Һәр кеше әлеге текстта үз шигырен – үз эчтәлеген таба.

Барлык шигырьләре турында фикер әйтәсе килә... Татар шигъриятендә мәхәббәт турында «...Тәрәзәңне ачтың...»дагы кебек көчле сызлану җырын күрсәтү дә авыр. Шагыйрь һәр шигырьгә кеше һәм кешелек язмышын сыйдыра, романнарда аңлатылырлык фаҗигаләрне туплый белә. Фәлсәфи лирика, мәхәббәт лирикасы, гражданлык лирикасы булсын – бөтенләй үзгә югарылыкта яңгырый. Болай яза алган Лилия Гыйбадуллина – зур шагыйрәбез булып җитешкән инде! Ак юллар аңа.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы*



Гомәр
Даутов

# ГЕНЕРАЛ

хикәя

**1**

Аның генерал дәрәҗәсенә ирешү юлы озак булды. Бу юл исә биш яшь чагында ике үпкәсенә дә салкын тиюдән башланды. Фашизмны җиңеп, галәмгә кеше очырып, дөньядагы иң зур армия тотарга куәте җиткән СССР империясенең үз эчендәге иксез-чиксез киңлекләрне яуларга, юллар салып, газ кертеп, халкының тормышын җиңеләйтергә әллә көче җитмәде, әллә теләге булмады. Шунлыктан, биш яшьлек Гамир авыл советы өстәлендә үлем белән көрәшеп ятты. Ашыгыч ярдәм машинасы язгы көпшәк карны һәм җебегән җирне үтә алмыйча туктап калды. Аңа каршы малайны кочаклаган әнисен утыртып, бозлы су тулган чокыр-чакырдан сикергәләп, җиргә тиярдәй булып агылган кургаш болытларга кара төтен ата-ата, «Беларусь» тракторы кузгалды.

Стена акшарлары кубып төшкән, тәрәзә ярыкларыннан җил өргән район больницасында алар айдан артык яттылар. Өйгә озатканда, врач ханым сакланырга, җылы киенергә, вакытында килеп тикшеренеп торырга дигән таләпләрнең бик озын исемлеген бирде. Алар гаять төгәл үтәлделәр: өч кат ыштан гадәти күренешкә әйләнде, эчкән дару һәм алган уколларның исәбе-хисабы юк иде. Малай физкультурага йөрмәде, чак кына төчкерсә дә, укырга җибәрмәделәр, урамга чыкмады. Китаплар – авыл китапханәсе мөмкинлек бирә алган кадәр китаплар – аның төп юанычына әйләнде. Менә шул китаплар һәм күпне күргән, тәрбияле һәм авыл фельдшеры булган акыллы хатынның әтисенә биргән киңәшләре олы юлның башлангычы булды бугай. «Яңа сауган сөткә бал болгатып эчегез көн саен, – диде фельдшер, – һәм спорт белән шөгыльләнсен».

Гамир үсештә иптәшләреннән бик калыша иде. Мәктәптә һәм сирәк-мирәк урамда уйнау бәхете тәтегәндә дә, ул иптәшләренең кыерсыту объектына әверелде. Елап кайткач, абыйлы малайларга кызыга, нишләргә, болардан ничек үч алырга дип озак уйлана, хыялында үзен көчле, берсеннән дә курыкмаучы итеп күрә иде.

Рус мәкале ничек ди: «Сәламәт тәндә, сәламәт рух» диме? Ә менә

---

Гомәр ДАУТОВ (1967) – *КФУның Алабуга институты татар филологиясе кафедрасы мөдире, доцент, филология фәннәре кандидаты. Вакытлы матбугатта чыккан күпсанлы тәнкыйть мәкаләләре авторы. Чаллыда яши.*

кытайлар: «Сәламәт рух сәламәт тән тудыра», – диләр. Гамир кытайларның бу сүзен белми иде әле, әмма фельдшерның «спорт» дигән сүзенә тешетырнагы белән ябышты. Әйе, менә ул юл – шөгыльләнергә һәм көчле булырга. Ләкин нидән башларга! Бу мәсьәләдә авылда мәгълүмати ачлык. Спортзал юк, спорт түгәрәкләре турында сүз дә юк, әмма бөтен малайларның кумиры булган, озын буйлы, киң җилкәле, педучилище тәмамлап кайтып физкультура укытучы абыйлары бар. Ул көн саен чаңгыда йөри. Димәк, чаңгыдан башларга.

Ничек итсә итте, ләкин ботинкалы чаңгы алдырды. Көн саен шуды. Башта авыл тирәсендә, аннары кырларга чыкты, биш чакрым ераклыктагы урманга ук тәвәккәлләде. Кара тиргә батып, тыны кысылудан күз аллары караңгыланганчы, алдында торган көчле кеше образын куып җитәм дип чапты.

Җәй көне турник ясады, тимер-томырлар җыеп, күтәрә торган штанга оештырды, киндер капчыкка тыгызлап салам тутырды да боксёр грушасы элеп куйды. Спорт белән шөгыльләнүендә эзлеклелек тә, методика да, система да юк иде – ул бары чапты, күтәрелде, салам тутырган капчыкны төйде. Ләкин хәрәкәт һәм, мөгаен, әтисе тарафыннан кырыс контрольгә алынган, көн саен яңа сауган сөткә бер кашык бал болгатып эчү үзенекен итте: сигезенчедә укыганда, ул бөтен сыйныфташ малайларын да бәргәләп чыкты. Шул вакыттан катгый бер фикерне үзләштерде: нәрсәгә дә булса ирешәсең килә икән, эшләргә, үзең тырышырга, хәрәкәт итәргә кирәк.

Физик үсеш белән янәшә рухы да чарланды, ул максатчан, үзенә дә, тирә-юньдәгеләргә дә кырыс һәм таләпчән булып формалашты. Иптәшләрен куып җитү түгел, инде узып китсә дә, үзен камилләштерүдә, торган саен яңа биеклекләргә омтылуда ул туктый алмады, камилләшүнең яңадан-яңа юлларын эзләде. «Физкультура и Спорт», «Спортивная жизнь России» кебек журналлар яздырып ала башлады. Күнекмәләр даими һәм юнәлешле төс алды, ул хәзер бокс һәм самбо, дзюдо кебек көрәш төрләренең техникасын, аларны дөрес куллана белүгә басым ясады. Элеккеге елак һәм һәркемгә куркып карый торган ямьсез үрдәк бәбкәсе урынына, гәүдәгә зур булмаса да, нык бәдәнле, какча, әмма тире астында тимердәй мускуллар тырпылдап торган егет үсеп чыкты. Күз карашы бәяләүчән, төбәп, сөзеп карый, кичке якларда әтәчләнә башлаган егетләр, каршыларына Гамир килеп басуга, һәр мизгелдә каршылык күрсәтергә, йодрыкларын эшкә җигәргә әзер торган сугышчы күреп, шунда ук тынычланалар иде.

Армияне көтеп алды. Повестка килгәндә, яңа гына төзелгән авыл мәктәбенең спортзалында яшьләрне волейболга өйрәтә иде.

Гаҗәп, армиянең мәгънәсез, әмма тәртипле тормышы аңа ошады. Ул бер әйберне ныгытып аңлады: монда буйсынырга һәм буйсындырырга кирәк икән.

Төрле милләт вәкилләре очрады. Чечен һәм ингушлар белән, яшәр өчен дус булсаң да, аларның кызып китүчән-импульсив холыклары сагайтты. Белорусларның үз йөзләрен саклап калыр өчен күп кенә чигенешләргә баруы, украиннарның сержант лычкосын алыр өчен дә җан бирергә әзер торулары ят иде аңа. Гамир үзенекен бирмәде, кешенекенә кызыкмады, шуңа күрә замполит аны үз итте, чеченнар «Гамирҗан» дип йөрттеләр.

Монда бер кагыйдә катгый – армиядә гражданкадагы кебек ошый-ошамый дип тормыйлар, кирәк – кирәк түгелдән чыгалар.

Ул офицер булырга карар кылды. Әтисенең куркытуларына, әнисенең күз яшьләренә бирешмичә, хәрби училищега гариза язды.

**2**

Бу бригадага командир итеп ул полковник дәрәҗәсендә билгеләнде. Аның кандидатурасын караган комиссиядә утырган генерал-полковник уңга борылды:

– Татардан башка кеше юкмыни?

– Юк шул! – Ярдәмче катгый иде. – Куеп карадык, тыныч, тынчу җир, барысы да запойга китә. Именно татар кирәк.

Кушияк уңга борылды:

– Протоколга кертегез, Абдуллинны часть командиры итеп, – бераз паузадан соң өстәде, – генерал дәрәҗәсе бирмичә генә билгеләргә.

– Генералсыз булмый. – Ярдәмче сүзгә кушылмакчы иде...

– Була! – Генерал-полковник авыр сулап урыныннан кузгалды. – Татар бит ул, алар генералсыз да үзләренекен эшлиләр...

Килеп төшкәч тә хәлләрнең начар гына түгел, коточкыч икәнен аңлады. Мондый шартларда гаиләңне үзең белән йөртү күз алдына китергесез нужа булыр иде. Бәләкәй уллары Әмир һәм Камилне җитәкләп авыл капкасында басып калган хәләлкәе Халисә белән аралары көннән-көн, елдан-ел ерагая барды.

Илнең нәкъ үзәгендә булганлыктан, бригада чит илләргә әледән-әле мускуллар күрсәтеп алу максатыннан үткәрелгән өйрәнүләрдә катнашмый, конкрет максат һәм бурычлар өчен түгел, гомум гаскәр саны өчен генә тотыла, шуңа күрә аңа башкала игътибар итми. Бармы – бар! Кирәге чыкса, эндәшербез. Шуңа күрә офицерлар эчә, солдат үз ирегенә куелган, аның бар максаты бүген нидер урлап сатып, тамак туйдыру. «Дедовщина» чәчәк ата. Әмма гаҗәп, барлы-юклы тәртип, көндәлек тормышның агымы әнә шул дедовщина аркасында. Чөнки офицер килеп күрсәтмә бирә дә югала, үтәлешен яшьләрне мәҗбүр итеп һәм эшләтеп, өлкән чакырылыштагы солдатлар тәэмин итә.

Урнашып алуга, Гамир өлкән офицерлар белән бер атна эчте. Моны махсус эшләде, шул вакыт эчендә кемнең кем булуын, нәрсәгә сәләтле икәнлеген ачыклады. Нәкъ бер атнадан, иртәнге киңәшмәдә, штаб начальнигын, тыл һәм строевой хезмәт, автомобиль хезмәте командирларын аек, астан сөзеп караучы, һәр каршылыкны кичекмәстән сындырырга әзер Гамир каршылады. Шешенгән, авызларыннан үлгән мәче исләре килеп торган хәрбиләр, башларын да күтәрергә иренеп, кирәк булганга һәм нидер хәл итәргә түгел, ә болай, гадәт буенча гына, түгәрәк өстәл артына кереп урнашуга, Гамир кискен торып басты:

– Офицер иптәшләр! – Тавышы бугаздан, кыргый дуамаллык белән яңгырады, гаскәриләр кинәт айнып, үзләре дә сизмичә, торып бастылар, – Офицер иптәшләр, бүгеннән эшли башлыйбыз һәм Ватанга хезмәт итәбез!!!

Бригада берьюлы тузгытылган умарта күченә дә, таяк тыгып болгаткан кырмыска оясына да охшаган иде. Иң кирәкле документларын таба алмаган штаб начальнигына төбәлгән пистолетлы кулын вакытында тотып калдылар. Автоколонна начальнигы, төн йокысын онытып, машиналар янында кунды. Батальон һәм рота командирлары казармада яши башлады. Солдатларны хәрби осталыкка өйрәтү программасының үтәлеше Гамирның шәхси контроле астында башкарылды.

Шома гына бармады. Гамир өстеннән башкалага жалобалар китте, прокуратура килде, янаулар да күренгәләде. Гамир кара көйде, ябыкты, ләкин күзләрендәге үҗәтлек, тавышындагы тимер чыңы артканнан-артты. Аны тәүлекнең теләсә кайсы вакытында автопаркта, ашханәдә, казармада күрергә мөмкин иде. Частьта дисциплина, тәртип урнашты, күрсәткечләр

яхшырды. Ләкин иң яхшы күрсәткеч дигәндә: командирның хезмәтен танып – дембельләрнең аның белән саубуллашып китә башлавы һәм Гамирга генерал дәрәҗәсе бирелү булды.

Солдатлар аны үз итеп «батя» яки «Бату хан» дип йөрттеләр. Гамир очраклы рәвештә «батя» сүзенең Бату исеменнән ялган икәнен укып белгәч, бик гаҗәпләнгән иде. Димәк, тарих дәресләрендә язылганча, бернинди татар изүе булмаган, чөнки иң якын кешегә иң баш колонизатор исеме белән эндәшмәсләр иде. Димәк, Бату хан зур һәм дус гаиләнең хуҗасы – хөрмәт ителгән хуҗасы булган.

«Берәү үлми – берәү көн күрми», дигән кебек, берәүләр хезмәтне тәмамлый, икенчеләре башлый. Бүген яшь солдатларның ант итү тантанасы. Генерал, сәгатенә күз ташлады да, ярдәмчеләрен ияртеп, часть ишегалдындагы трибунага таба кузгалды. Солдатлар рота-рота булып тезелгән. Әлегә ирекле торалар, офицерлар тыз-быз чабыша. Кинәт шул тирәдә чуалган берничә хатын һәм ир-ат, яшүсмерләр күзенә чалынды. Аңлашыла, әти-әниләр, туган-тумача җыелган, ләкин иртәрәк бит әле, алар территориягә ант башланыр алдыннан гына кертелергә тиеш.

– Иптәш полковник, – дип, урынбасарына җикеренде Гамир, – нишләп ишегалдында чит кешеләр йөри? Ханым, – дип мөрәҗәгать итте ул плацка ашыгучы хатынга, – сез кая барасыз?

Хатын борылды, генералның кырыс тавышына исе китмичә, мөлаем елмайды.

– Халисә! – Генерал әүвәл югалып калудан, фуражкасын салды, аннан яңадан киде. – Син! Син ничек монда?

Хатын янә елмайды.

– Исәнме, Гамир. Улыбыз монда хезмәт итә, бүген присяга бирә.

– Кем? Әмирме? Ул монда! – Генерал хисләрендә буталды, ыкы-мыкы килде,  нәрсә генә әйтсә дә, җавап гайре табигый булачак иде.

...Алар аерылышканда, Гамир олы улына өч тәгәрмәчле велосипед бүләк итеп калдырган иде. Шул малай хәзер солдатмы? Велосипеды кайда?..

Ә Халисә һаман елмайды:

– Әйе, монда. Әнә, кече улың, Камил белән килдек, Казаннан өч егет бу частьта...

Гамир хатыны күрсәткән тарафка борылды да имәнеп китте, анда аңа училищега кадәр булган яшьлеге карап тора иде.

– Исәнмесез?! – Камил генералга үзе кулын сузды. Шул ук бәяләүчән караш, шул ук физик ныклык, буйга гына калкурак. Гамир алгарак чыгып торган җилкәләргә, колак яфракларының имгәнгәнлегенә игътибар итте. Димәк, йә ирекле, йә классик көрәш белән шөгыльләнә. Исәнләшкәндә уң кулына, бармак төпләрендәге төзәлеп килүче характерлы яраларга күз төшереп өлгерде. Мондый эзләр сугышкан чакта көндәшенең тешенә бәрелүдән кала.

Кич белән ашханәнең «вип» залында дүртәү бик озак утырдылар. Хатыны белән улларын кунакханәгә урнаштырганнан соң, баскыч төбендәге эскәмиягә чыгып утырды.

### 3

Әфганда иде ул вакытта Гамир, разведка ротасының командиры. Аңа гаскәр һәм зур күләмле хәрби йөк үтәчәк юлның куркынычсызлыгын тикшерергә дигән бурыч куйдылар. Уттай яндырган кояш астында унбиш чакрымлап җир

баргач, Гамирны кинәт нидер борчый башлады. Колакны ярырлык сәер тынлык иде моның сәбәбе. Ротаны туктатып, солдатлары бераз тын алгач, кирегә борылырга мәҗбүр булды һәм йөрәкне сирәк, әмма тирән итеп тибәргә мәҗбүр иткән беренче ату тавышы яңгырады. Нәкъ вакытында, алдагы калкулыкка барып җитмичә туктаткан булып чыкты ротасын. Анда күпсанлы әфганлылар уңайлы позициядә көткән булган аларны.

Вакытында туктаган булсалар да, үзебезнең төп көчләргә ара ерак. Болай да шактый йөгергән егетләр йончыдылар, мышнап төштеләр. Тар уйсулык буйлап йөгергәндә, Гамир команда бирде:

– Беренче һәм икенче отделениеләрнең пулемётчылары, минем янга!

Кулы белән зур валуннарга таба күрсәтте:

– Менә сезнең позиция! Дошманны шушында тоткарлыйсыз! Сез бер сәгать торырга тиеш, аннан чигенәсез...

Лимонка, гранаталарын, пистолетын отделение командирына бирде дә, сержантның күзләренә карамаска тырышып, рота артыннан йөгерде. Белә иде, унике кеше бер сәгать буе каплап тора алмаячак, аларны ярты сәгатьтән, күп дигәндә, кырык минуттан юк итәчәкләр, ләкин төп көчләр — туксан кеше, исән калачак.

Минималь югалтулар белән бурычны үтәгән өчен Гамирны бүләкләделәр һәм вакытыннан алда майор дәрәҗәсе бирделәр. Әйе, сугыш кагыйдәләре буенча ул дөрес эшләде: ун солдатны корбан итеп, туксанын саклап калды. Ләкин генерал бүген уйда: ә бит ун солдат, ул ун кеше – кемнәрнеңдер бала-а-сы!

Менә, Әмир, аның улы, бүген илгә хезмәт итәргә ант бирде, кем ул хәзер: баламы, солдатмы? Гамир өчен ул бала, ә командиры буларак, солдатмы? Ул аны да беренче отделение белән башкаларның чигенүен сакларга калдырырга тиешме? Булдыра аламы?

Сигаретын үкчә белән басып сүндерде дә урыныннан торды. Авыр торды, авыр атлап машинасына таба кузгалды, нәрсәдер ияргән кебек. Артына борылды – берни дә юк. Кузгалды, юк, нәрсәдер, ниндидер йөк иярә. Акыллы кеше буларак аңлады, буй җиткән уллары белән очрашкач, бер хакыйкатькә төшенгән икән: аңа – солдат, кемгәдер – бала. Ә арттан ияргән йөк һәр сугышчан хәрбинең соңарып булса да килә торган мәңгелек соравы – хаклы идеме ул теге чакта?

***

Кунакханә каршындагы эскәмиядә бөтен язмышын күз алдыннан кичергәнче утырырга риза иде Гамир. Ләкин көтелмәгән, дөресрәге, генералның үсеш юлында тавышсыз-тынсыз югалып калган яшьлек мәхәббәте Халисәне, газиз уллары Әмир белән Камилне иртәгә ул тагын югалтырга мөмкин.

Генерал бу төнне кунакханәдә кунып калды.



Наталья
Харлампьева

# ҖАН ЯКТЫСЫН ЯУДЫРА

## Хатын-кыз монологы

Мин – ут.
Мин төнлә йолдыздай балкыйм.
Мин – җилдә янган учак һәм
Мичтәге тыңлаучан ялкын.

Мин – ут.
Кешеләргә җылы бирәм.
Аларны яныма дәшеп,
Бер табында күрештерәм.

Мин – ут.
Син күңелемне күрергә
Бик ашыкма.Үтә авыр
Җан үзәгемә керергә.

Мине
Көчсез итү, түбәнсетү
Хокуклары бирәүгә дә
Бирелмәгән... җанны сүтү...

Мин – ут.
Чын күңелдән килешәм мин:
Бары ихлас елмаюың
Яктысына бирешәм мин.

---

Наталья ХАРЛАМПЬЕВА – *Саха (Якутия) Республикасының халык шагыйре, прозаик, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе. Якутия Язучылар берлеге рәисе. Егермедән артык китап, шул исәптән татар телендә дөнья күргән «Күзге яңгырлар» шигъри җыентыгы авторы. Якутск шәһәрендә яши.*

* * *

Төннәрен дә, көннәрен дә
Кулымда каләм ныкка,
Үзгәрми ышаначакмын
Гаделлек, яхшылыкка.

Бу инану ярдәм итсен,
Юк әле уфтанасы.
Явызлык авызлыкланып,
Ахырда булсын җиһанда
Яктылык тантанасы!

* * *

Минем бәхетле булмавым –
Бәхетем каралыгы,
Маллы-мөлкәтле булмавым –
Кесәм бичаралыгы.
Гел уңыш явып тормавы –
Ул тышкы кыяфәтем...
Болар кемгәдер китерә
Дөньяның зур афәтен:
Комсыз, саран адәмнәрнең
Тормышын нурландыра,
Тонык тәрәзәләренә
Җан яктысын яудыра.

Бәхетем ярлы булса да,
Ул нур тарата;
Акчасыз да күңелемдә
Һәрчак таң ата.
Уңышлар ерак качса да,
Өметем ныклы;
Тормыштан сөенеп атлыйм,
Уйламыйм юкны.
Бу хәләтем комсызларны
Сагышка сала:
Соры көннәре тагын да
Караңгылана.

* * *

Сары яңгыр аша атлыйм,
Яфрак алтыны буйлап...
Юк, атламыйм, гүя очам,
Канат кагам, дип, уйлап;
Күзге агачлык өстендә
Кояштай нурлы җиһанны
Җан-тәнем белән сулап.

Син, яныма килми генә:
«Син бүген ябь-яшь, – дисең, –
Барыр юлың ап-ачык, һәм
Юк-барга китми исең...

Бәхетне, кулыннан алып,
Һавада җиләсеңме?
Син, чынлап та, һаман шулай
Булыр, дип, беләсеңме?..»

Сөмсерем коелып китте...
Булачак тормышымны
Әллә юкка яктылыкка
Бәйләргә тырыштыммы?..
Бар да бетте, өмет сүнде,
Шатлыгым очты ерак.
Аны, яман сүз ыргытты,
Вак-вак кисәккә турап...

Сары яңгыр аша йөрдем,
Яфрак алтыны буйлап,
Күңелемдә урын алган
Сары сагышны уйлап...

Бу караңгы агачлыкта
Адашып, һушымнан язып,
Һәм бер җылы сүз юллап.

* * *

Белмим, нигәдер,
Сүнгәчтен учак,
Өем катына
Килдең син берчак.

Ә язмыш-учак
Салды канатын.
Җил буйлап көлне
Үзең тараттың.

Сер итеп саклыйк
Без үткән юлны,

Читләр кермәсен... –
Buласы булды.

Көннәр артыннан
Көннәр атлады.
Учак урынын
Үлән каплады.

Ишегалдымнан
Кит әле торып...
Шул үләннәрне
Таптаудан курык.

* * *

Әгәр шагыйрь намуслы һәм туры булса,
Вөҗданы кәгазьдәй чиста, коры булса,
Хакимият шаукымыннан ерак качар,
Өстәвенә, иман – барыр юлы булса.

Әгәр шагыйрь иркәләнсә күкләр белән,
Юлына һәрчак түшәлсә кызыл келәм,
«Бу җирдә бәхет юк!» дигән фикер ачар,
Башы тулыр җыен юк-бар чүпләр белән.

* * *

Бу кичнең карашы усал.
Кара күзләр яктысында
Җан уттан дагалана.
Һавага сорау эленгән.
Кемдер мине узып китте
Ашыга-кабалана.

*Якутчадан* **Ленар ШӘЕХ** *тәрҗемәсе*



Рифкать
Хуҗи

# КАРТ КЫЗ

ЮМОРИСТИК ХИКӘЯ

*Чәчәк кебек яшь чакларында Казан «Мехавае», «Житен комбинаты»нда зарарлы авыр хезмәттә интегеп, кияүгә чыга алмый калу гына түгел, сәламәтлекләрен дә югалткан татар авылы кызларына.*

Исемем... Хәер, карт кызларның исемнәре дә, җисемнәре дә кемне кызыксындырсын соң – йөз-кыяфәтеңдә яшеңне исбатлаучы бер генә нәрсә дә калмагач! Ә миңа нибары утыз гына бит әле!

...Бәлки соңгы тапкыр бәхетемне сынап каравымдыр бу – быел да көньякка путёвка алдым. Өч ел инде рәттән шулай туган көнемә үземә-үзем бүләк ясыйм – затлы тун тектерәм дә Кара диңгезгә путёвка алам. Гомер көзләрең түгел, инде кышларың якынлашып килгәндә, күңел җәй җылысын тансыклый. Җәен миңа кем күз салсын ул ял йортларында – ә кышын ир-егетләрнең күзе йөзеңнән битәр, беренче чиратта, затлы туныңны күреп ала. Туннар чынлап та зерә шәп минем. Эксклюзив!

Кем соң әле син шулкадәр кияүгә чыгарга азапланучы карт кыз, дисезме?! Казан мехаваеның әнә шул затлы туннар тегү өчен тире эшкәртү цехы башлыгы.

...Менә хәзер ял акчаларын алам да – әллү Кара диңгезгә!

...Әһә, сез генә җитмәгән идегез – тагын практикантлар. КХТИдан. Минем цехта – ир-ат кына. Берсе дә әлләкем түгел. Җилкәңә затлы тун менеп кунаклаганчы, күпме тиреңне тамдыра да күпме көчеңне ала ул тире дигәнең! Үзе сасы, җитмәсә. Шуңа да монда эшләргә атлыгып торучылар юк. Менә шул безнең мужикларга хәтле үзләренчә атый КХТИны – «камера хранения тупых инженеров», әле «инженер»ны «идиот»ка да алыштыралар. Соң, шушында эшләр өчен биш ел институтта укып йөрсен инде башында акылы булган кеше!

Рифкать ХУҖИ (Рифкать Хуҗиәхмәтов, 1958) – *галим, прозаик, Казан милли-тикшеренү технология университеты доценты. Казанда яши.*

Хәер, башка елларда нәкъ шундый керделе-чыктылы егетләр килә иде практикага. Ә бу юлы алдымда өч хур кызы басып тора! Җәлләп куйдым үзләрен. Тыштан ялтырасалар да, башларында боларның да азрак җитеп бетми микән әллә?

Юк, үзләре дөрес сукалый.

– Кәттә факультетларга эләгү өчен, безнең кебек авыл кызларының калын кесәле этиләре юк – ә тире эшкәртергә ашкынып торучы бик күренеп тормый, – ди беренчесе.

– Дипломсыз кияүгә чыгу да кыенлаша бара, – дип җөпли икенчесе.

...Һай, бар иде бит минем дә алар кебек чибәр чаклар! Хәзер акчам да бар. Күңел генә гомер буе шул студент халкыннан көнләшә! Торырга урыннары, ашарга ипиләре юк – ә үзләре һәрвакыт шат-көләч, елмаеп кына яшиләр. Шул җилбәзәк-күбәләк кызлар егетләрнең иң асылларын эләктереп кала да инде.

– Их кызлар! Минем дә кияүгә чыгасы килә бит, карт кыз булып калдым ич инде! Әйдәгез, болай итәбез, мин сезгә булышам, сез – миңа! Курсовойларыгызны конструкторлар бюросында эшләтеп бирәм үзегезгә. Ә сез миңа шул ир-егетләрнең хет берсенең генә булса да башын әйләндерергә булышырсыз.

– И-и-и апа, була ул! Институтта укучы бар кызның максаты шул бит – мөмкин кадәр күбрәк егетнең башын әйләндерү дә араларыннан иң шәбен үзеңә яр итү!

– Үзебез белгәнне сезгә дә рәхәтләнеп өйрәтербез, апа! Төс-битне рәткә китерү пүчтәк кенә хәзерге заманда, тик менә сезнең габаритлар гына...

– Тукта, дускаем, – дип сүзгә кушыла өченчесе, – фигурагызны тәртипкә китерүнең бик гади ысулы бар. Теләсәгез – бер айда билегез безнекеннән дә нечкәрәк булачак!

– Теләмимме соң?!

– Тик моны бары тик безнең тулай торакта гына тормышка ашырырга була, апа!

– Мин барысына да риза!

– Киттек тулай торакка! Бездә хәзер заочникларның кышкы сессиясе. Пенсионер студентларга хәтле бар анда – ата – улны, ана кызны белми торган чак!

...Көньякка – ял итү урынына... общагага киттем!

Дөрес әйткән кызлар – монда шыр сөяккә калырсың. Ничекме? Чәй эчәргә дип утырган идек – студент халкы кереп тулды бүлмәләренә – үзебезгә бер стакан чәй белән ярты печенье кисәге генә тәтеде.

– Менә шул инде төз булуның сере! – дип көлә кызлар.

Егет халкы ашаган ризыгыгызны түгел, кигән киемегезне күрә. Шуңа да тәмле ризык урынына матур күлмәк ала кызлар. Ашауга килгәндә... Кухня плитәсендә кемнең чәйнек-кәчтрүле тәмле исләр чыгарып кайный – кичен шуның бүлмәсенә җыела общага халкы.

Ахмак... минем шушы гади хакыйкатьне аңларга баш җитмәгән!

Монда диета саклауның хаҗәте юк. Җаның ни тели, шуны аша, барыбер күп тәтеми. Минем кебек өендә бикләнеп ятучы ялгызлар өчен генә ашау тормышта бердәнбер ләззәт булып кала түгелме соң? Күтәреп кайтасың сумка тутырып май, казылык, тегесен-монысын, утырасың иң якын дустың

– телевизор каршына һәм... көч-хәл белән күтәреп кайтканнарыңның җиңел генә корсакка кереп утырганын сизми дә каласың!

Яши башладык шулай общагада...

Кызлар җиң сызганып миннән хатын-кыз заты әвәләргә кереште. Алия – имиджмейкер, төс-бит тә, чәч тә аның кулында. Айгөл – тренер, фигура өчен җаваплы. Алинә – психолог һәм лингвист.

Иртәнге сәгать биштә Айгөл төртеп уята. Казансуга йөгереп барабыз, кар белән ышкынып юынабыз. Кайткач үтереп ашыйсы килә, ә суыткыч буш! Шуннан эстафета Алиягә тапшырыла. Анысы минем йөз-битне рәткә кертергә маташа. Аннары төшке аш. Дөресрәге – төшке чәй, аш атнага бер-ике тапкыр гына эләгә. Янә Алия – йоглар гимнастикасы, медитация. Аннары Алинәгә чират җитә.

– You do speak on English?

– Yes! – инглиз телен өйрәнәбез шулай.

Аннары теоретик дәрес. «Ир-егетләрнең башын әйләндерүнең мең дә бер ысулы!»

Кичен – дискотека, бакчада йөрү яки теннис.

Дискотекада кемдер артымда «корова» дип ычкындырды. Түздем – чөнки ул хаклы. Соңыннан белдем – Алия алар белән кул сугышкан. Озакламый бу апагызны танымассыз әле, дигән.

Эх, кызкайларым-чибәркәйләрем! Шул егетләрнең борынына чиртсәкме... Теге эксклюзив туннар гардеробы – сезнеке!

Шулай итеп, ике атналап общагада яшәдем. Гомерлек хыялым тормышка ашты, күңелем булды, дөньям түгәрәкләнде! Практиканы шул ук режимда минем фатирда дәвам иттек. Фигураны коррекцияләү тизлеге дә шул ук калды – тәүлегенә минус бер кило...

Экспериментның, әй лә – практиканың соңгы шимбәсен «Икс» көне дип билгеләдек. Башта теге егетләр белән алыш-биреш ясарга тулай торакка барабыз... төнге клуб яки стриптиз-барны яуларга ук кыюлык җитеп бетмәс-бетүен... Карарбыз!

Соңгы сугышка әзерләнгән кебек җыенабыз. Билгеләнгән сәгать сукты. Ярты көн чәчтарашханәдә утырдык. Макияж – урынында, барысы да эксклюзив, аякта каюлы кара читекләр. Кызлар туннарның үзенә ошаганын сайлый: берсе чәшке, берсе төлке, берсе аснықы. Алар барысы да үз кулларым белән иләгән иң яхшы тиреләрдән тегелгән... Булды бугай – төялдек тә минем «Jeep» машинасына, әйдә тулай торакка.

Шимбә бит – дискотека көне. Вахтада комендант үзе – танымады кызларны. Алинәбез аның колагына «лапша элә» – Америкадан кунакка кайткан апасы Алинә сеңелкәшенең ничек яшәгәнен күреп чыгарга тели икән.

– This hostel or prison – you prevent encounter with my sister? – Бусы инде мин – сценарий буенча – үземнең ризасызлыгымны белдерәм – ниткән «ярамый» ул – сеңелкәшем белән очрашумы?!

Озын-озын коридор. Алда мин – бизнес-леди, имеш! Ян-ягымда һәм артта – кызлар. Нәкъ менә тән сакчыларым! Каты басып атлаган аяк тавышларыбыздан бөтен ишекләр ачылып бетте диярлек.

Һәй, ул ләззәтле минутлар! Барысы да сиңа гаҗәпләнеп баккан. «Кемнәр булыр бу?» – дип баш ваталар, күрәсең!

Коридорның нәкъ урта бер җирендә шып туктадым – тик бусы сценарий буенча түгел.

– Ни булды? – дип пышылдый «тән сакчыларым». Китап-кәгазьләргә төртенеп, каршыма бер заочник килә – башы инде пеләшләнә башлаган, өстендә шактый тузган спорт костюмы.

Миңа бәрелә язып, ул да туктап калды. Күзләр очрашты, ул гаепле сыман миңа елмайды. Кайда күргән идем соң бу кадәр ягымлы йөзне?

– Посторонись, дядя! – дип боерды кызлар.

Процесс дәвам итте, маршрут – дискотека залы. Килеп кердек. Ярым караңгы булса да, безне күргәч, җенләнеп сикеренүләреннән туктадылар, музыка да акрынайды. Алинә күзе белән теге егетләрнең берсен эзләп тапты да бармагы белән үзенә чакырып китерде.

– You do learn me? – дим тегеңә, таныйсыңмы мине янәсе.

– No! – дип инглизчә җавап кайтарды теге.

Алинә татарчага күчте:

– Син оттырдың, егет!

Студент халкын гаҗәпләндердек егетләреннән үч алып! Ә башка ир-атның күзе төшәрлек булып «җитештем» микән соң?

Киттек иң шәп ресторанга. Монда инде затлы тун белән ир-ат халкының күзен кыздыра алмассың! Башкача алдырырга кирәк. Уйлап таптык бит тәки! Бу юлы мин Казанга килгән эшмәкәр фин татары, имеш. Эшем буенча берничә тапкыр Финляндиядә булганым бар. «Moi! Hyvästi!» кебек исәнләшү – саубуллашу сүзләре дә истә калган. Кереп утырдык. Өстә – затлы күлмәк, башта – яулык. Чәй, җиләк-җимеш китерттек, дога кылып, чәй белән сыйланырга керештек. Мин татарча акцент белән сөйләшәм, ара-тирә фин сүзләрен кыстырып куям. Кызыксынып карауларын сизеп торабыз. «Авыл кызлары дисәң – ресторанда утырырлык маялары юк аларның, кем икән болар?» – диләр бугай. Тәки түзмәде берсе, зур алтын тәресен ялтыратып каршыбызга килеп басты. Минем янга түгел, минем кызлар янына килгәнен белсәм дә, «Мине күрер микән, миңа сүз катармы икән?» дип, дөп-дөп тибә йөрәк.

Кызлар каршында бөтерелепме-бөтерелә бу.

– Менә, чит илдән кунакка кайткан апабызга Казанны күрсәтеп йөрибез әле, – диде тегеләр.

Шул сүзләрдән соң Алтын тәре миңа борылды – масаюы йөзенә чыккан. Аның турында ни уйлаганымны әйтергә авызны ачкан идем – этикет кагыйдәләрен бозу була бит – айның унбишенче кичәсендәге кебек балкып татарча сүз каттым үзенә.

Масаю шундук юкка чыкты, йөзе чалшайды тегенең.

– По-нашему не сечёт что ли? – дип китеп тә барды.

Җүнлерәк ир-ат игътибар итәрлек дәрәҗәдә үк түгел икәнмен, ни кызганыч!

Шулай дип уйларга да өлгермәдем... бер татар егете каршыма килеп тә басты.

– Гафу итегез, баядан бирле сүз катарга кыймыйча, рәхәтләнеп үзебезчә сөйләшкәнегезне тыңлап утырам. Сер булмаса, кайсы яклардан буласыз? – ди.

Чүт кенә мехавайдан дип әйтеп ташламадым. Бая гына общагада үземне күкнең җиденче катында кебек хис иткән идем, ә менә монда аның сигезенчесенә күтәрелдем.

Егет үзе – эшмәкәр, Казанга беренче килүе икән. Кем икәнемне әйтсәм, көлеп китеп барыр төсле тоелды. Бу ләззәтнең мөмкин кадәр озаккарак сузылуын теләдем:

– Тамперpredан. Мин дә Казанда беренче тапкыр, – дим.

...Бу әкәмәт төн алдан уйланылган сценарий буенча дәвам итте. Тик... шундый асыл егетне алдау оятыннан битләрем генә бертуктаусыз янды.

Иртәгесен иртүк шалтыратып гафу үтендем үзеннән, дөресен әйтеп бирдем.

– Казан мехаваенда тире иләүче мин – кияүгә чыга алмый интеккән карт кыз!

Әкият төне тәмам – ничек мыскылласа да түзәрмен. Тик, төшемме бу, өнемме?

– Синдәй туташны гомер буе эзлим, – ди.

Шундый сүзләрдән соң тагын ни көтәм мин, дивана! Үзем дә белмим. Менә хәзер кызларым янына барып киләм дә, иртәгедән янә үз урыныма – сасы тире цехына!..

Общага янына килеп туктавым гына булды, каршымда ... һаман шул кичәге заочник! Тик бүген ул затлы кайры туннан, башы гына яланбаш. Колаклары шуңа кызарган.

– Зөһрә, синме бу?! Беренче тапкыр күргәндә, «ялгыштым» дип уйлаган идем. Кичә янә күргәч аңладым – ялгышмаганмын.

Кем бу? Каян белә мине?

Тукта, күңелемнең иң ерак почмагында ничәмә-ничә еллар нәкъ менә шушылай елмаеп басып торучы... УЛ үзе түгелме соң?

Мин бит сине гомерем буе көттем. Шулай дип бөтен дөньяга сөрән саласым килде. Тик авыздан бер сүз чыкмый, баскан урынымда катып калдым.

– Исеңдәме, сигезенче класс... Болгарда үзешчәннәр конкурсы. Икебез ике авылдан бер үк җырны өйрәнеп килгән булып чыктык. Шуңа аны парлап башкардык:


> Исеңдәме, дустым, таныштык без икәү,
> Җылы яктан кошлар кайтканда...

...Таһир-ы-ым! – авыздан пышылдап кына чыкты сүзләрем. Ничек шулчак бәхетемнән шашып, кочагына ташланмыйча кала алдым икән? Ә ул артка куйган кулын алга чыгарды...

Дөньяда – аклык-пакьлек, Таһирның кулында – җете кызыл розалар бәйләме!

Миңа күк капусы а-ч-ы-л-д-ы-ы-ы-ы!!!

Ә тәрәзәдән безне үземнең кызлар гына түгел, бөтен тулай торак күзәтеп тора иде...



*Абдулла Алишның сугышка китәр алдыннан төшкән рәсеме.
Хатыны Рокыя, балалары Алмаз һәм Айваз белән. 1941 ел.*



*Җәлилчеләрнең берсе – Фәрит Солтанбәков укучылар белән очрашуда.*




*Язучыларның Г.Тукай клубында (Бауман ур., 19) Җиңү бәйрәме. Мөнбәрдә – КПССның Татарстан Өлкә комитеты секретаре М.Ф.Вәлиев. Президиумда: В.Нуруллин, С.Хәким, Г.Ахунов, А.Шамов, Т.Журавлёв, Р.Ишморат, Н.Арслан, генерал Ф.Булатов, М.Мусин.*



*Муса Җәлилнең хатыны Әминә ханым Казанга килгәч.*
*Уңнан сулга: Венера Ихсанова, Риза Ишморат, Әминә Җәлилова.*

*Сәхифәне* **Равил ФӘЙЗУЛЛИН** *әзерләде.*



Гөлфия
Солтанова

# ФАКЕЛ

хикәя

Урал тау итәгендә, ямьле Дим буенда, бер-берсеннән чакрым-чакрым ярым гына ераклыкта урнашкан дүрт авылны берьюлы бәхет басты: авыллары бөтен кырлары, яланнары, урманнары, болыннары белән нефть ятмалары өстендә утыра икән. Кара алтыннан аларга да өлеш чыгачак, димәк! Озак та үтмәс, хәзинәне җир куеныннан суыртып ала да башларлар, авыл кешеләренә керемле эш булыр, кулга ишелеп акча керер, дип татлы хыяллар белән яшәде ул көннәрдә акчага тилмергән авыл кешеләре.

Шул авылларның берсе булган Суыксу халкын, нефть табылудан бигрәк, авыллары янындагы калкулыкка урнаштырылган факел сөендерде. Җилдә дә, яңгырда да, буранда да, карда да сүнми торган бу «учакта» нәрсә янганын белмәсәләр дә, караңгы төннәрдә авыл урамын яп-якты итеп тотучы ул ут, беркатлы авыл кешесенә цивилизациянең бер могҗизасы булып тоелды. Әйтерсең лә факел аларга караңгылыктан якты юл ачкан да утыз йорты булган Суыксу халкын матур киләчәккә әйди.

Шушы шатлыклы көннәрнең берсендә факеллы Суыксу авылына килен булып төшкән Мөнирә дә бәхетнең югары катында иде. Авылның иң чибәр егете, иң оста гармунчысы – Минискә кияүгә чыкты. Ничек шулай өздереп, моңлы итеп көй чыгарырга өйрәнде икән аның Минисе баянда! Бер-ике тапкыр үзе дә уйнарга өйрәнергә талпынып карады. Кая ул! Көй чыгару түгел, гармунны күтәреп тору да кулыннан килерлек эш түгеллеген аңлады. Күптән түгел генә армиядән кайткан Минис гармунын бик сагынган иде, үз туенда да кулыннан төшермәде «дустын». Өйләнешкән парларның туен кунакка алу алар ягында якын туганнарның изге бурычы санала. Менә инде дүртенче туйлары. Башка гармунчылар да бар барын өстәл артында, әмма һаман Минис уйный. Җиренә җиткереп, һәр көйнең борылышларына телен эзләп таба гармунның.

Туйга дип атап кайтмаса да, туйчылар арасында хуҗаларның ерак Үзбәкстанда яшәүче кызлары Динә дә бар. Биш ел буе кызу кояш астында мамык җыеп, үзбәк кызлары кыяфәте кергән үзенә.

– Динә апа, сагындырадыр чит җирләрдә, – дип сүз катты аңа Мөнирә, халык ишегалдына биергә чыгып киткәч.

– Башта авыр булды, хәзер күнегелде кебек. Үзем генә түгел бит, татарлар бик күп анда. Аралашып, кунакларга йөрешеп яшибез. Үзегез нишләргә уйлыйсыз соң туйлардан соң? Авылда каласызмы?

– Белгән дә, сөйләшкән дә юк әле ул турыда. Армиядән кайтып, бер-ике ел эшләсә дә ярый иде Минискә, юк бит, өйләнәсе итте менә.

– Әйдәгез минем белән, монда колхозда хезмәт көненә йөргәнче, акча эшләрсез.

«Минискә генә әйтә күрмәсен бу тәкъдимен, бер дә сагышланып, сагынып чит җирләрдә яшисе килми әле», – дип, эчтән генә пошынып куйды Мөнирә.

– Минис өч ел хезмәт итеп кайтты, китү яклы түгелдер у-ул, – дип, сузыбрак уен җөпләп куйды.

Китү яклы булып чыкты шул Минисе. Нефть бораулаганны көтеп ятканчы, күп итеп акча эшләп кайтып, зур өй салу иде аның хыялы.

Һәм менә алар Үзбәкстанның мамык җыючылар шәһәрчеге Гөлбостанда. Килеп урнашуларына инде өч айлап вакыт үтте. Мөнирә, көн дә вахта машинасына утырып, Динә апасы белән мамык җыярга китә, Минис, гармунын уйнап, барактагы бүлмәләрендә кала. Электрикларга монда әлегә мохтаҗлык юк икән, башка җирдән эш табалмый, тәки моңаеп гармун тарта. Әле күптән түгел генә бик матур булып тоелган көйләр Мөнирәнең ачуын чыгара башлады. И дулады, и дулады ул, беркөнне, эштән арып кайткач, иренә:

– Нинди бетмәгән моңлану бу? Җитте, эш эзлә! Мин бәбиләгәч, акча каян алырбыз соң?

Терсәкне тешләп булмаган кебек, Минисне гармуныннан тиз генә аера алмаячагын аңлый иде Мөнирә. Алай да җае чыкты әле тагын.

Әлсерәп эштән кайтып керсә, авырып эшкә бармый калган Динә апасы белән сөйгәне терәлешеп үк утырганнар да, берсе уйный, икенчесе шахта көен җырлый. Аны күрүгә шып туктадылар үзләре. Динә үз бүлмәсенә ашыкты, Минисе баянын өстәлгә куйды. Чыгырыннан чыкты Мөнирә. Баянны өстәл өстеннән сөйрәп төшерде дә аяклары белән типкәли-таптый башлады.

– Менә сиңа шахта көе, менә сиңа бию көе, – дип, такмаклый-такмаклый изде ул гармунны. Әле ярый Динә апасының Минисне эләктерергә дип авылга кайтуын да, инде кырыенда яшәп ятучы яшьләрнең тормышын бозарга дип ятьмәләр кора башлавын да белми Мөнирә.

Хатыныннан моны ук көтмәгән иде ире.

– Тинтәкләнә инде әйдә, баян беткәнмени дөньяда! – дип, бүлмәдән үк чыгып китү ягын карады.

Баяны да, хатыны да бик жәл-жәлен, гаеп үзендә. Үзбәкләр – аны, ул үзбәкләрне якын итә алмады шул. Кайтып китәргә кирәк. Әнә дусты Илдус та хатында чакырып яза. Нефть бораулаучылар нәкъ алар авылы янында вышкаларын көйләп яталар икән. Күп кеше буровойга эшкә дә урнаша башлаган, акча да яхшы төшә ди! Безнең төшкә дә кермәгәнне, дип тынычландырды ул үзен, кояштан качып арык буенда күләгәдә утырганда.

Поездан төшкәч тә тәгәрмәч тавышы текелдәде әле Мөнирәнең колагында. Озын юл да, баян белән килеп чыккан хәлләр дә талчыктырган иде аны. Минис кайту турында сүз кузгатуга, ул юлга җыена да башлады. Эшләгән акчасы билетка, әз-мәз күчтәнәчкә генә җитте. Әйе, биргәннәр ди хәйләкәр үзбәкләр меңәр чакрым юл узып бәхет эзләп йөрүчеләргә өеп акча. Җүнле эш булса,

үзләреннән артмас иде әле! «Агыйделнең аръягында – бер инәгә бер дөя, барсаң чуртым да юк», – дия иде мәрхүм әтиләре. Дөресе шул булып чыкты. Ярар бәхетләрен «нефтькә чумып» эзләп карарлар инде болай булгач. Исеректән айнымаган авылдашлары Газул да шунда эшләп йөри ди бит, кәгазь акча гына өләшә ди авыл әбиләренә хәер итеп.

Туган якның тансык һавасын сулагач, татлы чишмә суын кайнатып чәй эчкәч, Мөнирә үз хәленә кайткан кебек булды. Тәненең һәр күзәнәге язылып китте, ял итте. Ярый әле әзгә генә булса да читкә чыгып кერделәр, кайчан татыр иде ул әйтеп аңлатып булмый торган рәхәтне – туган як назын!

– Миниснең баяны кайда соң? Сатып кайттыгызмы әллә? – дип, каенанасы сорау оештырмаган булса, бу рәхәт әллә күпмегә сузыласы иде, булмады. Дөресен ишеткәч, әллә малаен, әллә өч сарык түшкәсе сатып алынган баянны кызганып, каенана дулап та карады соң! Бергә тора алмаячаклары көн кебек ачык иде: хәзер үк, чемоданнарын бушатканчы ук, каенананың күз алдыннан югалырга – чыгып китәргә кирәк.

Шулай эшләделәр дә: ике тәрәзәсе, нефтьчеләрнең вагоннары, эрелеваклы тракторлары, машиналары урнашкан яланга таба карап торган салам түбәле кечкенә өйгә урнаштылар. Хуҗасы, Галиматтәй, аяклары йөрмәс булгач, малайларына күченгән икән. Ике бала табып, аларны үстергәнче, шушы өйдә яшәрбез, дип уена да китермәде Мөнирә ул вакытта. Минисе нефтяник булып күп акча эшләр дә, өр-яңа зур матур өй салып керербез, дип хыялланды. «Өметсез шайтан», ди бит халык. Шундый матур өметләр белән, Минис башта буровойда электрик булып эшләде, аннары авыллары янындагы нефть качалкалары участогына оператор-обходщик булып урнашты. Мөнирә бик каршы булса да, акча бераз җыелгач, яхшы мотоцикл алып җибәрде. Хезмәт хакын алырга район үзәгенә барырга, бер качалкадан икенчесенә йөрергә дә, юллар өзелгәнче, менә дигән транспорт чарасы иде тимер ат.

Оператор эше үзе эшләмәгән кешегә генә җайлы тоела иде. Берүзең тәүлек буе кизү торып кара син! Качалкаларның һәрберсен сменага ике-өч тапкыр карап-җайлап торырга кирәк, кәгазьгә теркәп барырга. Әле ярый, әнисе, әтисеннән калган җиз телле кыңгыраулы тальянын китереп бирде. Шуны уйнап юанып ала бушаган арада. Будкадан ерак түгел урнашкан озын тимер морҗа очында факел дөрләп яна. Дөресрәге, нефть эзләгәндә табылган табигый газны шулай яндыралар. Факел бер дә сүнмәгәнгәме, караңгы төннәрдә ул бер иптәш кебек Минискә: учак тавышы күңелгә тынычлык иңдерә.

Көянтәләрен әле бер, әле икенче якка авыштырып, качалкалар эшләп утыра. Урал тавы итәкләрендә җәйрәп яткан кырларда йөзләгән качалка тәүлек буе армый-талмый җирнең маен суыра.

Инде менә берничә көн элек, җир бораулый торган зур вышканы, егып, кызыл битле тау башына сөйрәтеп алып менеп киттеләр. Вышканы тартып менгән дүрт трактор тауның кызыл битендә тирән сырлар калдырды. Тау тикле тауларга да тынгылык бетте: кара алтынны инде аларны актарып эзли башлыйсылары ди. Ничә гасырлар буе, горурлыкларын җуймыйча, адәм баласының төрле кыланмышларына түзеп, күзәтеп торган таулар нишләр дә, бәреп чыккан саф сулы чишмәләре нишләр?! Менә бүген дә шундый кысыр уйларыннан, борчуларыннан арына алмый йөрде Минис. Ярый әле калкулыкта урнашкан будкасыннан авыллары уч төбендәге кебек күренеп тора, уйлары шунда күчә. Таң атканчы ук аларның кечкенә өй тәрәзәләрендә ут алына:

Мөнирә шулай балалары уянганчы эшен бетереп куярга күнеккән, бик уңган хатын. Иске өйне дә курчак өе ясап куйды, бөтен җирдә чисталык, пөхтәлек. Балалар да ялт иткән! Табын тулы үзе әзерләгән ризык, ике көнгә бер хуш исле ипи сала! Кемдер аның шикелле хатын турында хыяллана гына ала, ә Минаснең – чынлыкта шундый.

– Керергә ярыймы? – дигән калын, карлыккан тавышка Минис сискәнеп китте. Смена беткәндә кем йөри инде дигән уй йөгерде аның башыннан. Ризалык та алып тормыйча, агач сәкенең кырыена килеп утырган таныш булмаган ир-ат, дәшми-нитми, чепи күзләре белән будка эчен айкады. Әйткән иде аңа Мөнирәсе, кырыеңда пычак булса да тот, япан кырда кем йөрмәс, дип. Юк шул, курка белмибез шул ир-ат халкы, дип үзен битәрләп алды Минис, эчтән генә. Алай да, кыюланып:

– Ни йомыш, знакум? – дип соравына сорау белән сүз катты.

– Төнлә шикле кешеләр күзеңә чалынмадымы?

– Юк шул, беркемне дә күрмәдем. Бер-бер хәл бармы әллә?

– Юк, юк, берни дә юк. Борчыган өчен ачуланма!

Ничек кисәк кергән булса, шулай ук чыгып та китте. Минис будка тәрәзәсеннән караганда, көтмәгән кунакның уйсулыкка таба атлаган шәүләсе инде югалып бара иде. Бераздан, кояш күтәрелә башлагач, тынчу будкасыннан һавага чыкты. Кайтып киткәнче, җәяүләп кенә чираттагы обходны ясарга кирәк. Калкулыкта урнашкан качалкага якынайганда, еракта бүрәнәләр төягән ике дәү йөк машинасының әкрен генә районга чыгучы юлдан китеп барганын шәйләп алды. Электр баганаларын күчерүчеләрдер, дигән уй белән, ашыкмый гына чыклы үлән өстеннән атлады ул.

Кояш шактый җылыта ук башлады. Аның яктысында факел ялкыны югалыбрак калган. Дим өстеннән күтәрелгән зәңгәрсу томан инде елгадан аерылган, рәхәт салкынлык биреп һавага таралган. Сменаны тапшыру – эшнең иң рәхәт чагы. Алда ике көн ял көтә. Районга барып, буралык делянка белешәсе булыр бүген, дип план корып куйды Минис, мотоциклын кабызганда.

Өенә кайтып, юынып, ашарга гына утырган иде, ишектән папкасын култык астына кыстырган участковый Латыйп килеп керде. Нинди йомыш белән йөрүен дә әйтмәс борын, Миниснең дә, Мөнирәнең дә эчләрен ут басты.

– Кемнәргә сатып җибәрдең яңа электр баганаларын? – дип, төксе генә сүз башлады участковый.

Шушы сорау белән ике ай буе үзен тинтерәтәчәкләрен белми иде әле Минис. Тау башына электр линиясе сузар өчен китерелгән яңа баганалар турында сүз барганын аңлады ул. Ләкин үзен кайчан, кемгә, ничек итеп шул баганаларны сатуда гаепләүләрен аңлый алмады. Соңгы арада булган вакыйгаларны берәм-берәм күз алдыннан кичерде, изоляторның каты сәкесендә төннәр уздырганда. Бергә эшләүче егетләрнең: «Өй саласың бар, чумара баганалар кирәкмиме?» – дигән тәкъдимнәреннән башка, бер генә нәрсә өзеп ала алмады Минис көннәр бәйләменнән. Авыл башында урнашкан төп йортларының бәрәңге бакчасы буена өч айлап элек китереп аударылган өч иске баганадан башка, бер генә үзен гаепләрлек кырын эш тапмады ул. Әле аларын да аласы килмәгән иде, әнисе бик үгетләгәч, агачлары әйбәт, дигәч кенә, кеше күзенә ташланып тормасын, дип, кычыткан арасына бушаттырган иде.

«Яхшы ниятле» хезмәттәшләренең инде күптән, электр линияләре

сузучыларның башлыклары белән бер булып, яңа баганаларны искергәннәр дип астан гына сатып ятулары да; көтелмәгән кунакның шул хезмәттәшләренә акча бирергә дип килүе дә; таң белән районга таба китүче ике машинаның, калган бүрәнәләрне райпо рәисенең биек коймалы ишегалды уртасына илтеп аударулары да аңа караңгы иде. Тотыла-нитә калсалар, гаеп эчкерсез Минискә төшсен дип, аңа ике-өч багана төртергә аларга «зуррак» абыйлары кушкан иде. Хезмәттәшләре дә, таң алдыннан будкага кереп чыккан көтелмәгән кунак та Минискә каршы сөйләде судта.

Сорау алган саен, шаһитләр бар, диделәр, гаебен танып, кул куярга куштылар, ул һаман юк, диде. Ике ай буе җелеген суырдылар Миниснең. Үзен – җир итеп, тикшерүчене нефть суыручы качалка итеп хис итте ул. Үзе, хатыны, балаларының киләчәге өчен курку хисе, факел ялкыны кебек, бөтен эчен биләп алып, сүнмәс булды. Менә кызганып утыр син таш кыялы тауларны, чишмәләрне. Нәрсәләр күрергә язган икән аның газиз башкаена, бер гаепсезгә!

Ниһаять, суд көнен билгеләделәр. Судья Минискә ике генә сорау бирде: «Гражданка Әхмәтова Мәрфуга сезнең әниегезме? Аның бакча буендагы баганаларны сез үзегезгә дип алдыгызмы?»

«Әйе», – димичә, нәрсә дисен инде Минис. «Кара эшләре» өчен Минис биш елга ирегеннән мәхрүм ителде. Суд залыннан иренең кулларына богау салып алып чыгып киткәндә, Миңниса түзмәде:


– Кеше үтерүче түгел бит ул! Аның бер гаебе дә ю-юк! Мунча булса да кереп китсен инде, – дип ачыргаланып кычкырып елап җибәрде...

Аерылу ачысына чыдый алмыйча, нахакка гомерлеккә рәнҗетелгән Минисен, үзен, балаларын, чәлпәрәмә килгән бәхетле көннәрен кызганып, үртәлеп, юл буе елады да елады Мөнирә. Кылган явызлыклары өчен җәзага тартсалар бер хәл, бер гаепсезгә яшь гомерен төрмәдә әрәмгә уздырырга язган Минисенә. Бигрәк нечкә күңелле, явызлыкның нәрсә икәнлеген дә белми торган кеше бит ул.

Авылларына кайтып җиткәндә, тирә-якка караңгылык иңә башлагангамы, Мөнирәнең туктаусыз елаудан шешенгән күзләре, ирексездән, бер файдасызга көне-төне янып утырган калкулыктагы факелга төште. Минисенең акча табам дип, өй салам, дип, янып-көеп эшләп йөрүләрен, тырышуларын шушы факелга охшатып куйды ул. Әрәмгә булды, Гөлбостаннан кайтулары да, мотоцикл алулары да... Барысы да, әйтерсең, бер мизгелдә янып юкка чыкты. Рәнҗү катыш ачу уты гына җанны каралтып көйдерә, әйтерсең лә факел, әйтерсең лә сүнми торган факел...

*Лаеш районы*
*Имәнкискә авылы*

# ТУГАН ЯК МОҢЫ...



Булат Вәликә улы Сөләйманов иҗат эшенә әдәбиятта, аеруча шигърияттә, җанлану, кеше күңеленең бөтен тирәнлеген ачарга омтылыш белән характерланган 1960 елларда килә. Шигырьләрендә – тынгысыз рухы, яралы җаны, туган туфрагына булган бетмәс-төкәнмәс мәхәббәте; прозасында – Себер киңлекләре, яралы язмышлар; публицистикасында туган халкын иректә, бай итеп күрергә теләге чагылыш таба.

Ул 1938 елның маенда Төмән өлкәсенең Вагай районы Сопра авылында дөньяга килә. Әтисе – Вәликә (Вәлиулла) Хәлиулла улы гасыр башында туган, Бөек Ватан сугышында катнашкан кеше, әнисе – Әтия Яка (Яхыя) кызы – икесе дә чыгышлары буенча төп Себер татарлары, гомер буйларына колхозда эшләп тормыш кичергәннәр, сигез бала тәрбияләп үстергәннәр. Булачак шагыйрьнең балачагы сугыш һәм сугыштан соңгы елларга туры килә. 1946 елда беренче сыйныфка укырга кергән Булатка ноябрь аеннан, киеп барыр киеме булмау сәбәпле, мәктәпне калдырып торырга туры килә, шулай да 1954 елда җидееллык мәктәпне тәмамлый; авылда төрле эшләр башкара, соңрак аңа Салехардта йөкче, Омскида маляр, бетон коючы булып эшләргә туры килә. Белем алу теләге аны яңадан райондагы Карагай мәктәбенә кайтара: монда китапханәче булып урнаша, үзлегеннән әзерләнеп, биш-алты яшькә кечерәк укучылар белән бергә имтиханнар тапшыра, 1961 елда кулына өлгергәнлек аттестаты ала. Шул ук елны ул, Казанга барып, эшкә урнаша, маляр-штукатурчы булып эшли. Теләге – университетта уку. 1962 елда Казан университетының филология бүлегенә укырга керә, ләкин аннан китәргә мәҗбүр була. 1967 елда, читтән торып, А.М.Горький исемендәге Әдәбият институтында укый башлый. Ул елларда аңа Фрунзеда (хәзерге Бишкек), Сургутта, Бакуда төрле эшләрдә булырга туры килә. Тормыш офыклары шулай киңәя. Әдәбият институтын 1974 елда тәмамлый һәм шул ук елда туган якларына кайтып, Себернең нефть чыга торган районнарының берсе булган Түбән Вартага эшкә китә. 1976 елда, Төмән өлкә язучылар оешмасы чакыруы буенча, матур әдәбиятны пропагандалау бүлегендә әдәби хезмәткәр булып эшкә урнаша, ләкин, авыруы сәбәпле, эштән китәргә туры килә. Шул елдан Б.Сөләйманов тулысынча әдәбият белән генә шөгыльләнә башлый.

1984 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

Б.Сөләймановның беренче шигырьләре 1959 елдан Тубыл шәһәрендә татар телендә чыгып килгән «Ленин юлы» газетасы битләрендә дөнья күрә, башлангыч әсәрләренә беренче бәя дә әлеге газета битләрендә басыла: аның авторы – бу елларда Тубыл дәүләт педагогия институтының татар бүлегендә эшләгән Гомәр Саттаров булуы да әһәмиятле. *(«Себер егете шигырьләре – «Совет мәктәбе» журналында» // «Ленин юлы». – 1962. – №62 (734). –23май.)*

1960 еллардан «Совет әдәбияты» («Казан утлары»), «Ялкын» журналларында аның шигырьләре басыла башлый. 1970 елда «Беренче карлыгачлар» исемле күмәк җыентыкта шагыйрьнең 23 шигыре, «Идел» альманахында (1976) шигырь цикллары чыга. Аерым шигырьләре, русчага тәрҗемә ителеп, «Юность», «Сибирские огни» журналларында, үзәк нәшриятларда чыккан күмәк җыентыкларда да еш басыла. 1975 елда «Юность» журналы үткәргән конкурс лауреаты исеменә лаек булуы да аның иҗаты киң катлау укучылар арасында танылуына дәлил булып тора. 1980 елда Татарстан китап нәшриятында шагыйрьнең беренче «Таңнар фонтаны» исемле мөстәкыйль шигырь җыентыгы дөнья күрә. Китапка кереш сүзне шигъриятебезнең аксакалы Сибгат ага Хәким яза.

«Кытыршы, ритм өзелә, басым үз урынында түгел, сүзләр дә колакны ерта, ләкин Себер киңлеге, Себер җиренең (кайчандыр төрки халыклар яшәгән җирнең) ниндидер аһәңнәре шул шигырьләрдә ачык сизелеп китә. Эпиклык, басынкылык, салмаклык. Шигырьнең биографиясе зур булса, ул техник кимчелекләреннән арынachak, – ди олы шагыйрь. – Сирәк, аз яза, ләкин хәзер ул үзенә бик нык ышанып яза, әле җәелеп, бирелеп, чумып эшлисе көннәре алда... Булат Сөләйманов Себер татарлары арасыннан әдәбиятта хәзергә фәкать үзе генә икәнлеген беркайчан да онытмас, җаваплылык хисе аны олы юлга алып чыга», – дип яза С.Хәким, яшь шагыйрь иҗатына олы өметләр баглап. *(Хәким С. Үз аһәңе, үз җирлеге // Б.Сөләйманов. Таңнар фонтаны. Кереш сүз. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1980. – Б.3.)*

Автор хезмәтенең беренче җимеше, горурлыгы була бу китап. Юка гына җыентыкта шагыйрьнең дөньяга карашы, уйланулары, рухи дөньясы чагылыш тапкан. Үзе исән чагында авторның икенче китабы – «Ак метеор» (1988) да басылып, укучылар карамагына тапшырылырга өлгерде. Бу китапка кереш мәкаләсен – «Туган туфрагына гашыйк шагыйрь» исеме астында, Р.Даутов яза.

1980 елда язган автобиографиясендә шагыйрь үзе: «Бүгенге көндә нәшриятка «Җирсү» исемле шигырьләр җыентыгы әзерләдем һәм «Иртеш дулкыннары» дигән шартлы исем астында яңа китап өстендә эшләп торам», – дип яза. Ләкин шагыйрьгә бу хыялларын тормышка ашырырга, яңа китапларын күрергә насыйп булмый. Моның бер сәбәбе – аның иҗтимагый-сәяси эшчәнлеккә шактый актив кереп китүендә, дип әйтсәк тә ялгышмабыз. 80нче еллар ахырында илебездәге мәгълүм үзгәрешләр халыкны әкренләп уятып, милли хәрәкәтнең башлануына китерде. Татар милләтенең асыл уллары үз халкының нинди аяныч хәлдә калуын, инде юкка чыгу хәленә килүен аңлап, милли-мәдәни хәрәкәтне әйдәделәр. «Үзгәртеп кору» дип аталган тарихи-сәяси форсаттан файдаланып, шагыйрь һәм көрәшче тәкъдире арасында сайлый торгач, Б.Сөләйманов та үзен һәм үзенең шагыйрь язмышын корбан итәргә, йокыдан арына алмаган халкын үзе җитәкләргә көч таба. Шул максаттан, өлкә матбугатында халыкка мөрәҗәгать итеп, берничә мәкалә белән дә чыга. «Тел булмаса – халык булмый», «Себер татарлары – без кем?» мәкаләләре шагыйрьнең туган халкының бүгенге халәте, тарихи үткәне, киләчәге хакында уйлануларын чагылдыра. Әлеге мәкаләләр ихлас күңелдән, халыкны кузгатырга теләп, уйланырга чакырып язылган.

Шагыйрьне якташлары, замандашлары, туры сүзле, кискен холыклы кеше иде, дип искә ала. Милли хәрәкәт башында торучы лидер буларак та, ул бик күпләр өчен җайсыз кеше була, чөнки чигенүне, компромисска баруны һич кенә дә кабул итә алмый.

Әдәби эшчәнлегенең башлангыч чорында ук шагыйрь үз иҗатының һәм иҗтимагый эшчәнлегенең кредосын төгәл билгели:

*Мин төп себер татарымын чыгышым белән,*
*Гомер сөргән монда минем бабаларым.*
*Чал Иртышның үзе кебек, борынгыдан*
*Яшәп килә монда татар балалары.*
*Мин килмешәк түгел монда, туган җирем,*
*Гомерлеккә сине ташлап китә алмам.*
*Җирнең тарту көчен җиңдем, и Себерем,*
*Ләкин синең тарту көчең җиңә алмам.*

Б.Сөләйманов себер татарларының бу якларда җирле халык, туган җирләре – ата-бабалары туфрагы булуына басым ясый. Иҗатының соңгы елларында аеруча актуальләшкән әлеге мәсьәлә халыкның үзбилгеләнүе, тарихи үткәнен өйрәнүгә, телен һәм мәдәниятен сакларга омтылыш буларак тагын да көчлерәк, куәтлерәк яңгыраш ала: *«Әйтмәгез, Себерем хакында, / Үткәндә каргалган җир булган. / Каргалса-каргалсын, ул минем / Туган җир, и туган...»*

Б.Сөләйманов иҗатының асылы – туган җиренең образлы сурәтен тудыруда билгеләнә. Шагыйрьнең биографиясе, яшәү урыны башка каләм осталарыннан аерылып тора. Әсәрләрендә урын алган татар авыллары исемнәре – Сопра (шагыйрьнең

туган авылы исеме, Вагай районы), Бәеш, Рәнцек, Киндерле – себер географиясен тудыруда катнашкан топослар гына түгел, ә татар халкының ераклардан килгән тарихын саклаучы төрки атамалар буларак кыйммәтле. Шигъриятендә эреле-ваклы шәһәр, елга, күл исемнәре дә әдәби топос рәвешен ала, көчле позициядә шигырь атамаларына чыгарып, шагыйрь үзәктә яшәүче татар укучысы өчен ят булган яшәү ареалы, үз язмышында эз калдырган дөнья киңлеге белән таныштыра. «Тобол», «Түбән Варта», «Обьта боз киткәндә», «Самотлорда җәй уртасы», «Төньяк. Тундра», «Салехардка килгәч» шигырьләрендәге атамалар, җансыз топос булудан туктап, җыелма образ – шагыйрьнең кадерле туган җире сыйфатында конкретлаша, символик мәгънәгә ия була башлый.

Шагыйрь иҗатында дөнья сурәте дә гомумтатар әдәби үрнәкләреннән үзгә, үзенчәлекле:

*Чишмәләрең, елгаларың – терекөмеш.*
*Урманыңда Еш кызлары яши, имеш,*
*Кырлар буйлап тәгәрмәчләр*
*тык-тык үтә,*
*Гүя алар миңа шуны*
*хәбәр итә:*
*Күрәсеңме, саргаешып бетте кырлар,*
*Туган якка кайтуыңны көтә-көтә!»*

Сөләйманов иҗатының башлангыч чорында чагылыш тапкан дөнья сурәте себер топосы белән аеруча тыгыз бәйле. Кышкы себер картинасы традицион формада тудырыла: гадәттәгечә, ул салкын, буранлы, кар көртләре астында калган, башка төбәк халкына аңлашылып бетмәгән дөнья төсендә сурәтләнә: *«Караңгылык хакимлеге, / Иксез – чиксез кар иле бу...», шулай ук «Ник очрасын хет бер агач. / Яңа туган бала кебек, / Бу кар иле – шыр ялангач» («Төньяк. Тундра»). «Очсыз-кырыйсыз кар даласы», «буш киңлекләр», «усал җилләр», «кургаш күк»* сурәтләре Себер җиренең караңгы, җансыз ягын чагылдыралар. Шагыйрьнең башлангыч чор иҗатына хас бу образлылык «Түбән Варта» шигырендә, шушы караңгылыкны җиңеп, яңа шәһәрләр төзүче, нефть чыгаручы кешеләрнең героик образын тудыру өчен антитеза буларак файдаланыла.

1970 еллар ахырына Б.Сөләйманов иҗатында табигать күренешләре, пейзаж шушы җирдә яшәгән геройның күңел кичерешләрен ачуга хезмәт итә башлый. Шагыйрь иҗатындагы лирик «мин» субъективлык белән характерланып, сентименталь башлангычны көчәйтә. Себер ландшафтында кыш картинасы да «яктыра», шигырь юлларыннан көлтә-көлтә яктылык сирпелә башлый: *«Челтәр-челтәр ап-ак карлар ява, / Ап-ак карлар күкнең иңендә»* («Белсәм иде») һ.б.

Шагыйрьнең пейзаж лирикасында тайга төп образ булып тора. Күп очракта ул туган як, туган җир символы гына түгел, ә шунда яшәгән бөтен тереклекнең җыелма образы буларак гәүдәләнә. Тайга, күчерелмә мәгънә алып, дөнья сурәте тудыруга турыдан-туры катнаша. Пейзаж лирикасында лирик геройның соклану, сагыну кебек хис-кичерешләр белән тәгәлләштерелгән туган як табигатенә мәхәббәте чагыла. Күп очракта бу традицион хис туган җиреннән читтә яшәргә мәҗбүр булган лирик герой кичерешен күрсәтә: *«Мин дә китәм. / Ниләр көтә мине / Туган җирдән читтә, еракта. / Бүген тагын күз яшьләре күрдем / Торып калган ялгыз яфракта».* («Кыр казлары үтте каңгылдашып»).

Туган ягын сагыну тойгысы белән сугарылган әсәрләрендә дә тайга образы лирик геройны туган иле белән бәйләп торучы үзәк топос буларак тәкъдим ителә. Автор, «туган нигезем», «туган йортым», «бишегем», «бабаларым яткан җир» кебек гыйбарәләрне кулланып, һәр кеше өчен изге булган кыйммәтләрне ача. Мондый характердагы шигырьләр укучы күңелендә психологизм остасы Ә.Еникинең «Туган туфрак», «Җиз кыңгырау» әсәрләренә аваздаш хисләр тудыра.

Б.Сөләйманов иҗатында пространстволар каршылыгы еш очрый. «Үзенеке» булган Себер башка урын хронотобына каршы куела. Бу җәһәттән караганда, «Себер – Казан»

оппозициясе кызыклы: *«И Казаным! / Туган анам кебек, кочагыңа ал син гомергә. / Ярсып чапкан / Минем чал Иртышым / Кушылып аксын синең Иделгә»*.

Шагыйрь иҗатында Казанга багышланган шигырьләр бер циклны тәшкил итә. «Казанга», «Иделдә», «Күптәнме җәй иде Казанда», «Күренми шул Себер Казаннан», «Казаннан китәр алдыннан», «Казанда яз» әсәрләре шундыйлардан. Б.Сөләймановта Казанга тартылу, аны шигърият мәркәзе итеп тану мотивы еш яңгырый. «Тукай кабере янында», «Мин ялгызым йөрим урамда...» әсәрләрендә татар халкының бөек шагыйре Г.Тукай шәхесе һәм иҗатына мәхәббәт авторның Казанга мөнәсәбәтен ачуга хезмәт итә.

Б.Сөләйманов әсәрләрен системалы рәвештә кабул иткәндә, Себер – Казан образлары оппозициядә түгел, ә лирик геройның күңел кичерешләрен гәүдәләндерүче гомуми хронотоп буларак сурәтләнә. Лирик «мин»нең туган ягын сагыну хисе себер төбәгенең поэтик чагылышы – болан баласы образы – аша оеша: *«Күренми шул Себер Казаннан, / Анда карлар, җилләр уйныйдыр, / Ә тайгада болан баласы / Адашкан да ялгыз елыйдыр. / Шулайдыр ул минем хәлләр дә. / Эзләремне карлар көридер. / Адашкан да тайга эчендә, / Бала чагым елап йөридер»*.

Шагыйрь иҗатында ел фасыллары үзгәрешенең кабатланмас төсләре, колориты аша да үзенчәлекле дөнья сурәте тудырыла: *«Сары сулар / Сары туфрак монда / Бөтен дөнья гүя сап-сары. / Бәлки, / Туган якны сагынганга, / Сары булып / Күренәдер миңа нибары»*.

Аз сандагы гражданлык лирикасы үрнәкләре шагыйрь әдәби мирасында аерылып тора. Б.Сөләйманов иҗатының икенче этабында (1970-1980 еллар) фәлсәфи һәм гражданлык мотивлары көчле яңгырый. Бу чор әсәрләрендә яшәү мәгънәсе хакындагы гамьнәр «үткән-бүгенге-киләчәк» оппозициясендә яктыртыла. Гомеренең соңгы елларында үзен милли көрәшкә багышлаган шагыйрь милләтнең үзбилгеләнүе хакында көчле публицистик мәкаләләр белән чыгыш ясый, регионда милли белем бирү системасын тергезү мәсьәләсен бөтен кискенлеге белән күтәрүчеләрнең берсе дә ул була. Б.Сөләймановның Г.Тукай, М.Җәлилгә багышланган шигырьләре шагыйрьнең әлеге көрәш юлындагы уйлануларын һәм теләк-омтылышларын сәнгатьчә гәүдәләндерүгә хезмәт итә:

*Җилләр сыман йөри,*
*Илләр буйлап,*
*Безнең хакта күпме ялганнар.*
*Татарлар бит*
*Фашист балтасына*
*Баш имгән өчен ауганнар.*
*Без иреккә бары*
*Омтылганбыз,*
*Омтылмаган беркем зур данга.*
*Изелгән дә,*
*Киселгән дә булган,*
*Җиңелмәгән ләкин дошманга.*
*Туган ил өчен без яуга кергән,*
*Кергән сыман атлар*
*бәйгегә.*
*«Татар илен сатмый», – дип язылган*
*Төрмә ташларына мәңгегә.*

Шулай итеп, Булат Сөләйманов иҗаты бүгенге көндә хаклы рәвештә «Себер гимны» булып яңгырый.

**Флёра СӘЙФУЛЛИНА,**
*КФУ профессоры*

# ЯЗМЫШ СЫНАУЛАРЫНА БИРЕШМИЧӘ

Бу вакыйгаларны кичергән Барый Галиев Теләче районы Балыклы авылында туып үсә. Аның узган язмыш юлы сикәлтәле һәм бик тә катлаулы... Шулай да ул һәрвакыт кешеләргә булган хөрмәт хисен югалтмый, дөньяны яратуыннан туктамый. Исеме акланганнан соң, озак еллар мәктәптә балаларны балта осталыгы серләренә өйрәтә. Бүгенге көндә лаеклы ялда, балалары белән Теләче районының Алан авылында көн итә.

Материал тулысынча аның сөйләве буенча язылды.

Ямьле яз көнендә Барый карт ихатасына яшь кенә кыз белән бер егет килеп керде. Алан урта мәктәбенең 11 нче сыйныф укучылары икән. «Соңгы кыңгырау» бәйрәменә мәктәптән чакыру кәгазе китергәннәр. Итагатьлелек саклап, бераз сөйләшеп тордылар. Аннан чакыру турында кабат искәртеп, саубуллашып китеп тә бардылар. Карт аларны капка төбенә кадәр озата чыкты. Яшьләргә сокланып карап калды. Их, яшьлек, яшьлек! Иң матур, иң рәхәт вакытлар... Әйе... Ул да шушы Алан мәктәбендә укыды бит. Аның да яшь вакытлары, изге хыяллары бар иде. Тик сугыш дигән аждаһа бөтен хыялларны чәлпәрәмә китерде.

Барый урта мәктәпне 1939 елда тәмамлады. Районда алдынгы мәктәпләрнең берсе иде бу. Директор Нур Шәфиевич Сафиуллин, фәннәрне яхшы укыту белән генә канәгатьләнмичә, сыйныфтан тыш чаралар оештыруга да зур игътибар бирә белде. Барый иң актив укучылар рәтендә булды. Түгәрәктә мандолина уйнау серләренә төшенде. Гармунда уйнарга инде кечкенәдән үк өйрәнгән иде. Мәктәптәге бер генә кичә дә аннан башка үтмәде. Мәктәптә үткәрелгән төз ату ярышларында да иң яхшы атучылардан саналды. Шуңа да егетләрчә горурлык белән күкрәгендә «Отличный стрелок» һәм ПВХО (противовоздушная и химическая оборона) билгесен йөртте. Сигезенче сыйныфтан ук үзенең алга таба кая барасын, кем булачагын ачык күз алдына китерә иде. Ул хәрби офицер булачак! Барый үзен шуңа әзерләде. Хәрби темага китаплар укыды, төрле походларда катнашты, күренекле хәрби җитәкчеләрнең тормыш юлын өйрәнде. Егетнең активлыгын тиз күреп алдылар. Унынчыда укыганда, партиягә кандидат итеп кабул ителде.

Мәктәп тә артта калды. Көзге чакыру башлангач, Теләчегә килеп, хәрби комиссар Васильевка үзенең хыяллары турында сөйләп бирде. Бу вакытта армиягә китү өчен мөмкинлек чыкмады. Өч ай партия райкомында статист булып эшләгәннән соң, ноябрьдә Орлов хәрби пехота училищесына юллама тапшырдылар. Егетнең башы күккә тия язган иде ул вакытта. Гади авыл малае – хәрби офицер!

Бу юлның бик катлаулы буласын, алда озакка сузылган сугыш михнәтләре, чит җирләрдәге әсирлек, илгә кайткач күрәчәк хурлыклы газаплар – боларның берсен дә күз алдына китермәде Барый ул вакытта.

Әнисе Барыйны юлга әзерли башлады. Ә ул, әтисенә ияреп, колхозның атларын карашырга барды. Аның да ярты гомере әтисе белән шушы атлар арасында үтте бит. Хуҗалыкта алтмышка якын ат бар. Барый һәрберсенең исемен, холкын белә. Алар арасында яраткан чаптары – җиңел сөякле Йолдыз кашка! Ничек инде аларны күрмичә, саубуллашмыйча китәсең, ди. Әле тагын кайчан кайтыла?!

Менә ат базары. Зур капканы ачып, эчкә үттеләр. Моңа кадәр тыныч кына печән чемченеп яткан малкайлар, хуҗалар килгәнне күреп, пошкырып сәлам бирделәр, урыннарында тыныч кына тора алмыйча, тыпырдап биеп алдылар. Ата белән ул, артык сөйләшмичә генә, атлар астындагы сайгакларны себереп җыештырдылар. Иң аргы башка кертеп өелгән печән кибәненнән йолкып, утлыкларга азык салып

чыктылар. Кайтып китәр алдыннан Барый Йолдыз янына тукталды. Чаптар егетнең күңелендә нинди уйлар кайнаганын белми иде шул. Ул егет белән шаярырга маташты. Гадәт буенча, хуҗасының кесәсеннән шикәр шакмагы, ипи кисәге эзләде, пинжәкнең җиңнәренә, түшенә кагылды. Беренче тапкыр Барый «китү» сүзенең чын мәгънәсен шушында аңлады. Бугазына кайнар төер утырды.

...Орёл пехота училищесындагы курсантлар арасында төрле милләт вәкилләре бар иде. Бәхеткә, татарлар да шактый икән. Взвод командиры Хатыйп Галимов та күрше Сауш авылыннан булып чыкты. Арча педучилищесын бетереп килгән. Мирсәет Заһидуллин – Бөгелмәдән. Алар Барыйның иң якын дусларына әйләнделәр.

Авылда эшләп үскән Барыйга училищеда уку артык кыен булмады. Зачётларны, ату нормаларын «яхшы» билгеләренә тапшырып килде, шушында партия сафларына кабул ителде.

Сугыш башлану турындагы хәбәрне Барый туган авылында ишетте. Ике ел уку дәверендә беренче тапкыр ялга җибәрелгән курсант куш атнасын да тутыра алмыйча, 23 июнь көнне училищега китеп барды. Юлда барганда ук, Тула шәһәренә җитәрәк, аларның эшелонын бомбага тоттылар. Тәүге тапкыр егетнең фашистлар белән очрашуы шушында булды. Сугыш китергән канлы вәхшәтне, беренче үлемне, кул-аяклары бомба ярчыкларыннан теткәләнеп беткән хатын-кызларны, балаларны күреп тетрәнде, гаҗизләнде.

Сугыш училище тормышына да кырыс үзгәрешләр кертте. Барлык өйрәнүләр урманда, лагерьда үткәрелә башлады. Укыту срогын кыскартып, июнь ахырында барлык курсантларга лейтенант дәрәҗәсе биреп, фронтның төрле участокларына тараттылар.

Мценск шәһәре янында яңа дивизия туплана башлаган икән. Барыйны шушы 51 нче Перескоп армиясе составына кергән 271 нче дивизиянең 176 нчы полкына транспорт ротасы командиры итеп билгеләделәр. Дивизия тупланып беткәч, көньяк фронтка – Кырымга җибәрделәр. Юлда ук эшелон дистәләрчә тапкыр бомбага тотылды. Аеруча Джанкой станциясе янында булган канлы сугышлар йөрәккә сеңеп калды. Сугышның беренче айларына иң авыр, иң күп югалтулар туры килеп, совет армиясе бөтен фронт буйлап чигенде. Джанкой, Алупка, Алушта шәһәрләре немецлар кулында калды. Алушта шәһәре янында Барыйлар полкы да тулысынча тар-мар ителде. Полк командиры полковник Рогозянов (азәрбайҗан, заманында Казанда укыган, татарча яхшы белә) җитәкчелегендәге командирлар төркеме полкның документларын яндырырга, байракны яшерергә дигән карарга килде. Бу авыр миссияне башкаруда Барый да катнашты. Полкның исән калган кешеләре, командирларының соңгы боерыгы буенча ике-өч кешелек төркемнәргә таркалып, таулар аша Севастопольгә чыгу өчен хәрәкәт итәргә тиеш булды. Барый җитәкләгән төркем – хәрби техник Василий Игушин (белорус) һәм мал табибы Алексей Кудрин карта буенча үзләренең кайда икәнлекләрен ачыклаганнан соң, юлга кузгалдылар. Бер авылга кереп, хәрби форманы калдырып, гади киемнәргә алыштырып чыктылар. Барый үзенең офицер киемен һәм документларын юк итте. Бары тик бүрек эченә тегелгән партбилетын гына калдырды.

Юлда барганда, алар партизаннар белән очраштылар. Отряд бары коммунистлардан гына тора. Аларның командиры белән сөйләшкәннән соң, Барый да партизаннар янында калырга булды. Иптәшләре генә партиядә булмаганлыктан, партизаннар отрядында кала алмый. Дуслары Василий һәм Алексей командирларыннан аерылырга теләмәүләрен әйткәч, Барый да фикереннән кире кайтты. Ни күрсәк тә, бергә күрербез, дип юлга кузгалдылар. Партизаннар командиры аларга үзенең бер үтенечен җиткерде: «Әгәр дә, Севастопольгә барып җитә алсагыз, Чапаевская урамындагы егерме икенче номерлы йортны табып, әниемә исән икәнлегемне хәбәр итегезче...»

Бу үтенечне үти алмадылар, Севастопольгә барып җитәрәк, өч егетне дә әсирлеккә төшерделәр...

Шушы авыр хатирәләрне яңартып утырганда, Барыйның кулына бер умарта корты килеп кунды. Күп бал җыеп арыган идеме, әллә сусызлыктан әлсерәп төшүе булдымы – умарта корты, йөгерештән килгән чабышчы шикелле, бөтен гәүдәсе белән сулап торды да, үз юлы белән очып китте. Әйе, бу дөньяда һәрбер җан иясенең үз юлы бар шул. Табигать бар тереклекне үзенчә ирекле итеп яраткан. Бар җан иясенә ирек кирәк, ирек...

Әсирләрне, мылтык түтәләре белән төрткәләп, авылга таба куаладылар. Бу Кырым татарлары яши торган Өскет авылы булып чыкты. Авылны бүлеп, көчле елга агып ята. Барый, озак уйлап тормыйча, суга сикерде. Немецлар бу хәлне көтмәгән иде булса кирәк. Алар, мылтыкларын төзәп ата башлаганчы, көчле су ташкыны егетне дошманнарыннан ерагайтты. Партбилет белән бүрек тә дулкыннар арасында юкка чыкты. Әмма качып котылырга язмаган икән. Елганың алдагы борылышында фрицлар, мондагы ыгы-зыгыны күреп, иптәшләренә ярдәмгә ташландылар. Барыйны, тотып алып, калын олтанлы итекләре белән типкәләп, иптәшләре янына алып килделәр. Өчесен дә нindидер таш стена янына тезеп куйдылар. Немец капитаны (гаупман) авылдан мулла чакыртты. Бөтенесе дә үлем якынлашканын аңлый иде. Ни могҗиза, бу юлы үлем аларны читләтеп үтте. Офицер белән мулла арасында булган сөйләшүдән Барый бары: «Бигрәк яшь бит. Малай гына әле», – кебек сүзләрнең мәгънәсенә төшенә алды.

Шуннан бер атна буе аларны салкын подвалда тоттылар. Сорау алулар көнаралаш кабатланды. Барый үзенең офицер икәнен дә, коммунист булуын да яшерде. Фамилиясен үзгәртеп, Вәлиев дип яздырды һәм сугыш беткәнче шушы фамилия белән йөрде. Суга төшкәч, энәсеннән-җебенә кадәр чыланган Барыйның чалбарлары да, сырмасы да шыкраеп катты. Салкын тиеп, аяк һәм кул буыннары киемнәргә сыймаслык дәрәҗәдә шеште, урыныннан да кузгала алмас булды. Берничә көннән әсирләрне лагерьга озату өчен конвоирлар килде. Үз аяклары белән атлый алмаганнарны юлда ук атып калдырдылар. Иптәшләренә рәхмәт, Барыйны, ике яктан култыклап, күтәреп диярлек йөрделәр. Казакъ егете Рәхимов, Балык Бистәсе районы Күгәрчен авылыннан Миңлебаев иң авыр вакытта да аны ташламадылар. Лагерьда да йә ипи кисәгеннән, йә үзләренең баландаларыннан өлеш чыгардылар. Аягына басарлык хәлгә килгәч, Барый да иптәшләре белән эшкә йөри башлады. (Эшкә йөрмәүчеләргә бер грамм да икмәк бирелми.)

Бервакыт аларны Бахчасарай шәһәреннән Херсонга җәяүләп алып киттеләр. Башта җиде йөзгә якын кешене өчәрләп колоннага тезделәр. Алдан-арттан овчаркалы солдатлар озата барды. Ике тәүлек ашарга-эчәргә бирми интектерделәр. Бервакыт колонна чөгендер басуы кырыеннан үтә башлады. Берничә әсир белән Барый да татлы ризык эләктереп чыкты. Алардан күреп, тагын бер төркем басуга ташланды. Фашистлар, котырып, автоматлардан ата башладылар. Чөгендер басуында дистәләгән кеше ятып калды.

Авыллар аша үткәндә, җирле халык әсирләрне кызгана, ярдәм итәргә тырыша иде. Алар колоннаның кайчан үтәсен ничек белгәннәрдер, ләкин һәрвакыт токкыннарны алдан әзерләнеп каршы алалар. Хатын-кызлар йә сало кисәге алып килә, йә ипи кыерчыгын кесәгә сала. Немецлар моңа сүз әйтми. Әсирләрне ашату проблемасын шулай хәл итәргә күнеккән булганнардыр, күрәсең. Тукталыш болында яки киңрәк бер тигезлектә оештырыла. Халык белән очрашуга берәмләп кенә чыгаралар. Ачлык тәмугка кертә, диләр бит. Барый да, үз порциясен ялмап куйгач, икенче «рейска» чыгарга батырчылык итте. Читтән күзәтеп торучы немец солдаты, озын гәүдәле чандыр татар егетен чамалап калган, күрәсең, шунда ук үзенең овчаркасын өстерде. Минут эчендә бозау кадәр эт гимнастёркадан эләктереп алды да хәлсез Барыйны болгап та ыргытты. Ярый әле тешләмәде, бөтенләй бугазлап ташламады, ләкин торырга да ирек бирмәде. Барый торып кына баса, эт ырылдап җиңнән яки итәктән каптырып ала да җиргә кабат егып сала. Немец солдатлары, мәзәк ясап, әсирне чолгап алдылар, шарык-шорык көлешеп, этне кабат-кабат өстерделәр.

...Барый калтырый башлаган куллары белән күз яшьләрен сөртеп алды. Тамак төбенә килеп бөялгән төерне йотып җибәрде. Әйе, егуын күп ектылар, ләкин сындыра, тормышка, яшәешкә, кешеләргә булган мәхәббәтен сүндерә, үтерә алмадылар.

Гомере бетмәгәч, Бахчасарай, Херсон, Симферополь, Николаевск шәһәрләрендәге хәрби лагерьлар тормышының барлык «рәхәтлек»ләрен дә татырга туры килде аңа. Ә күпме кеше шушы тимерчыбык киртә эчендә ятып калды?! Күпме гөнаһсыз җан кыелды монда?! Николаевскида Барыйны төрле эшләргә йөрттеләр. Бервакыт иптәшләре аша шәһәр кешеләре белән бәйләнешкә кереп, качарга булды. Алдан сөйләшенгәнчә, үлек чыгаручылар аны, мәетләр белән бер арбага төяп, зур чокырга

ташлады. Егет көнне мәетләр арасында уздырды. Өстенә дистәләрчә кеше гәүдәләре ташланганлыктан, әздән генә үзе дә теге дөньяга китеп бармады ул. Төнлә Шура исемле рус хатыны һәм аның энесе Алексей, чокырга төшеп, мәетләр арасыннан татар егетен актарып алдылар һәм бау белән тартып чыгардылар. Ике атнага якын ул шушы шәфкатьле гаиләдә яшәде. Алар, шәһәр читендәге зират янында, Рыбная урамындагы кечкенә генә йортта көн итә. Ләкин кемнеңдер немецларга җиткерүе нәтиҗәсендә, ул кабат лагерьга эләкте.

1943 ел башларында бер төркем әсирләрне Польшага озаттылар, алар арасында Барый да бар иде. Башта Радом шәһәрендәге, аннан Едлино станциясе янындагы лагерьга күчерделәр. «Идел-Урал» легионы турында ул беренче тапкыр шушында ишетте. Сталинград янында җиңелгәннән соң, фашистларның тактикасы нык үзгәреп, алар Совет Армиясе солдатларының әсирлеккә эләккәннәренә, большевиклар коллыгыннан коткаруны вәгъдә итеп, милли дәүләтчелек төзергә мөмкинлек тудырачакларына ышандырырга тотындылар. Шушы максаттан, рус булмаган милләт вәкилләрен «Идел-Урал» легионына туплауны башлап җибәрделәр.

Билгеле, күпчелек әсирләр немецларның бу эшчәнлеген провокацион, ялган алым икәнлеген яхшы аңлый. Ә үзебезнең үк татар әсирләре, немец формасы киеп, легионга язылырга өндәп йөри башлагач, күпләр гаҗәпләнеп калды. Каршы чыгучылар, аларны сатлыкҗанлыкта гаепләүчеләр, турыдан-туры йөзләренә бәреп, «хаин» дип әйтүчеләр дә булды. Тора-бара мәсьәләгә ачыклык керде. Бараклар кырыенда ачык сәхнә ясалып, концертлар куя башладылар. Татарларның концерт труппалары туган ил, туган тел турында шигырьләр укыды, халык күңеленә үтеп керә алырлык җырлар башкарды. Шушы туган ил турында җырлар тыңлаганнан соң, тоткыннарның йөзләре яктырып китте, йөрәкләргә яңа кан йөгерде, алга таба яшәүгә өмет уянды. «Кием алыштыру гына әле ул сатылу дигән сүз түгел. Киегез киемен, алыгыз коралын. Аннан намусыгыз кушканча эш итәрсез. Болай, башыгызны иеп, палач балтасына таба атлыйсыз. Ә беләсезме бу лагерьда безнең кебекләрнең йөзәрләп, меңәрләп һәлак булганын?! Шуннан үзегез уйлап карагыз инде. Татар халык мәкален онытмагыз, «ятып калганчы, атып кал!» Бу сүзләр Барыйның күңелендә әле дә яңгырап тора. Бераз соңрак аңа бу эшне оештыруда төп рольне Җәлил җитәкләгән «каршылык» группасы уйнавы мәгълүм булды. Әйе, Барый – дошман өнендә бүгенге көндә бөтен дөньяга танылган татар шагыйре Муса Җәлилнең шигырьләрен тыңлаган кеше.

Җәлилчеләр алар лагеренда берничә тапкыр булды. Легионерларга караш үзгәрде. 1943 елда Барый да легионга керде. Аларны, немецлар белән аралаштырып, каравылга куйдылар, төрле объектларны сакларга йөрттеләр. Берничә айдан өченче батальонның көнчыгыш фронтка озатылуы, аларның үз араларындагы немецларны юк итеп, үзебезнекеләр ягына чыгуы ишетелде. Вакыт үткән саен, немецлар легионерларга ышанычын югалта барды, таләпләр кырысланды, һәркемне күзәтә, тикшерә бардылар. Озак та үтмәде, өч батальонны Франциягә озаттылар. Барый да шунда иде. Көньяк Франциядәге Ле-Пюи шәһәренә килеп урнаштылар. Хәлләренең мөшкел булуына карамастан, немецлар легионерларны фронтка җибәрергә шикләнделәр, төрле өйрәнү эшләренә генә йөрттеләр.

Франциядә яшәүче рус эмигранты аша француз партизаннары белән бәйләнеш булдырылды. 1944 елның маенда капитан Хаҗи Галиев җитәкчелегендә сиксәнләп легионер француз партизаннары белән кушылды. Барый да партизан булып китте. Яңа чыкканнардан өч взвод оешты. Беренче взвод командиры итеп – Барый, икенче взводка башкорт егете Мәхмүт билгеләнде. Отряд белән полковник Люзеш җитәкчелек итте. Партизаннар Франциянең күп кенә шәһәрләрен һәм авылларын фашистлардан коткарды. Шундый шәһәрләрнең берсе Уссельне азат иткәндә, Барый взводы җитмеш дүрт немец солдатын әсирлеккә төшерде. Уссель шәһәрен азат итү хөрмәтенә зур банкет оештырылды. Бу бәйрәмдә татарлардан ике егет – рота командиры капитан Хаҗи Галиев белән Барый да катнашты. Люзеш татар егетләрен хөрмәт итә иде. Барыйны үзенең егерме яшьлек кызы белән таныштырды хәтта.

Маймак, Марат, Сантанжел шәһәрләре, партизаннар көче белән, дошманнан чистартылды. Франция хөкүмәте офицерларга ул чор өчен шактый зур суммада хезмәт хакы да түли башлады. Лимож шәһәрен азат итүдә күрсәткән батырлыгы өчен

Барыйны Франциянең көмеш ордены белән бүләкләделәр. Шәһәрне алганнан соң, отряд белән фотога төштеләр. Барысы да – француз партизаннары символына әйләнгән береткалардан, шортиктан, аякларда – калын табанлы ботинкалар.

Немецлар Франциядән тулысынча куып чыгарылды. Советлар иле фашизмны җиңде. Туган җиргә, илгә кайту мәсьәләсе алга килеп басты. Татар егетләренең булдыклылыгына инанган полковник Люзеш берничә тапкыр Барый һәм Хаҗига Франциядә калырга тәкъдим ясады. Егетләр баш тартты. Туган җир бик сагындырган иде шул. Илчелеккә барып сөйләшкәннән соң, Уссель шәһәре янындагы җыю пунктына килделәр. Кемнәр генә юк иде монда. Хатын-кызлар, балалар, хәрбиләр... Араларыннан Франциядә калучылар да булды. Инде кайтырга дип тезелгәч тә, берничә кеше, колоннадан чыгып, калучылар ягына басты.

Юл буе Хаҗи Галиев, Бөгелмә егете Вазыйх һәм Барый, гел бергә булып, киләчәккә планнар корып, изге хыяллар белән кайттылар.

Менә алар үзләре сугышта яулап алган кораллары белән, француз партизаннары формасыннан Германиянең Франкфурт шәһәренә аяк бастылар. Монда аларны чекистлар каршылады. Коралларны шундук җыйнап алдылар. Француз хөкүмәте биргән күкрәкләрдәге бүләкләр дә йолкып алынды. Берничә көн ябулы баракларда торганнан соң, товар вагоннарына төяп, этап белән Коми АССРга алып киттеләр. Ике айлап вакыт юлда үтте. Меңнәрчә чакрым газаплы юл узганнан соң, состав Котлас станциясендә туктап калды. Хаҗи һәм Вазыйх белән Барый шунда аерылышты. Аны Абезь шәһәренә алып килделәр. Элекке әсирләрне фильтрацион лагерь аша уздыру башланды. Үзе кичергән, күргән вакыйгаларны бөртекләп сөйләп бирергә туры килде. Тикшерү аны гаепсез дип тапты. «Спецпереселенец» дигән ярлык белән иреккә чыгардылар, ләкин шулай да еракка китәргә ярамый иде. Ул балта остасы булып эшкә урнашты. Василий Князев исемле рус егете аны агач эшенең барлык серләренә өйрәтте. Заманында үзе Мәскәүдә Кремльдә столяр булып эшләгән. Сәяси тоткын булып йөри. Монда бер-береңнән, нәрсә өчен хөкем ителдең, дип сорау юк. Кирәк дип таба икән, кеше үзе сөйли. Еллар буе бергә эшләп тә, иптәшеңнең кем икәнлеген белмәскә мөмкинсең. Василий белән икесе урындыклар, өстәлләр ясадылар. Башка легионерларны тагын да еракка озатканда, белгеч буларак, Барый лагерьда калды. Шушы һөнәре, хезмәтне яратуы тагын күп мәртәбәләр ачлыктан, үлемнән саклап калды әле егетне. 1947 елда аның кулына чиста документ тоттырдылар, өйгә кайтырга рөхсәт бирделәр. Шулай итеп, хәбәрсез югалган дип саналган Барый алты елдан соң туган авылы Балыклыга кайтып керде. Ул югында авыл да үзгәргән икән, һай үзгәргән. Сугыш авылны да нык картайткан... Барый, туган-тумачаларын күреп чыкканнан соң, кичләтеп, урам буйлап атлады. Мишә ярларын урап менде, ферма яныннан үткәндә, атлар торагына да сугылырга итте. Күңелендә балачак хатирәләре яңарды. Менә таныш сукмак. Абзар кырыенда су ташу өчен җайлап зур кисмәк утыртылган шул ук арба тора. Шул ук шыгырдап ачылучы капка, шул ук балачактан таныш абзар исе. Тик Барый эшләгәндә тулып торган абзар бушап калган, ул вакыттагы атларның яртысы да юк. Булганнары да шулкадәр ябык, эчләре-эчкә ябышкан, үтәли күренеп тора. Егет аранлык арасыннан Йолдыз кашканы эзләде, ләкин таба алмады. Бары соңыннан гына Йолдыз һәм аның кебек дистәләрчә башка атларның фронтка озатылуын ишетте ул. Арчага илтеп, вагоннарга төяп җибәргәннәр икән. Аларның алдагы язмышы берәүгә дә билгеле түгел иде инде...

Бераздан Барый колхозда эшли башлады. Нәрсә генә булса да, тормыш алып барырга, яшәргә кирәк иде. Кышка керделәр. Замананың авырлыгына карамастан, яшьлек үзенекен итә икән. Авылда кичке уеннар, аулак өйләр яңарды. Гармунда яхшы уйнаучы Барый бу кичәләрнең түрендә булды.

Беркөнне авылга чегәннәр килүе турында хәбәр таралды. Йортларга кереп күрәзәлек итеп тә йөриләр икән. Гаҗилә апаларда кызлар аулак өй ясаган көнне багучылар арасыннан 16-17 яшьлек бер чибәр чегән кызы да кичке уенга эләкте. Кызлар – кызлар инде, һәрберсе үзенең киләчәк язмышы турында сораштыра башлады, егетләре, булачак ирләре белән кызыксынып, багучыны сырып алдылар. Тик араларында ник берсе русча белсен. Шуңа барысы да Барыйга ябырылды.

– Син русча яхшы беләсең бит, әйдә, безгә тәрҗемәче бул. Тик серләребезне сакларга сүз бир.

Кап-кара толымлы, кара күзле чегән кызы, тәҗрибәле юраучылар кебек, кызларны аерым-аерым чаршау артына алып кереп, күрәзәлек итә башлады. Барый бераз шомартып, кызларның күңеленә хуш килерлек итеп, юрау сүзләрен җиткерә торды. Самими җанлы авыл кызлары чын күңелдән киләчәк матур язмышларын уйлап, сөйгәннәре белән озак та үтми кавышачакларына инанып, тарала тордылар.

– Әйдә, батыр егет, хәзер синең язмышың турында сөйләп бирәм – дип, чегән кызы сихри шомырт кара күзләрен Барыйга төбәде. – Алда озын һәм авыр юл күренә. Күргәнеңә караганда, күрәселәрең тагын да яманрак булырга охшый. Язмышың сиңа зур каршылыклар әзерләгән. Шунысы сөенечле: син боларның барысын да җиңәчәксең, ерак юлдан исән-сау кайтырсың. Үзең яхшы белгән кызга өйләнерсең. Бер малаең, ике кызың булыр. Иптәшең белән бергә байлыкта һәм муллыкта бәхетле озын гомер кичерерсез. Бу авылда яшәмәссез, – дип тәмамлады үзенең сүзен.

Барый моны бары шаяру итеп кенә кабул итте. Их, кем уйлаган аны ул вакытта, чегән кызы әйткән һәрбер сүзнең рас киләсен, кем уйлаган...

Көннәр үтә торды. Тормыш мәшәкатьләре белән чегәннәр дә онытылды. Барый көн дә колхоз эшенә йөри, бригада белән җимерек торакларны яңарталар, фермаларны ремонтлыйлар. Ел ахырында, артык зурдан купмыйча гына, күрше Алан авылыннан укытучы Мәрьям белән никах укытып, гаилә корып җибәрделәр. Егет кызны күптән белә иде, сигезенче сыйныфка кадәр бергә укыдылар, бер партада утырдылар.

Авыл кешесенә хас булган йөз төрле мәшәкать белән чабып йөргәндә, Барыйны кинәт кенә Теләчегә чакырттылар. Икенче көнне сак астына алып, Казанга – «Черек күл» дип йөртелә торган НКВД төрмәсенә алып киттеләр. Легионерлар эшен кабат тикшерә башлаганнар икән. Башта Барыйга ничек пленга төшүе, әсирлектәге тормышы турында тәфсилләп язып бирергә куштылар. Аннан сорау алу башланды. Бу хәл 1948 елның көзеннән 1949 елның апреленә кадәр дәвам итте. Беренче айларда эшне Горшков фамилияле яшь кенә лейтенант алып барды. Сораулар һаман да бер үк, бишун тапкыр кабатлана:

– Ни өчен әсир төштең? Син – офицер, коммунист, нишләп «Соңгы патронны үзең өчен саклау» турындагы приказны үтәмәдең? Синең белән тагын кемнәр бар иде?

Мондый вакытларда Барый да аннан:

– Сиңа хәзер ничә яшь? Приказ биреп кенә бүген үз-үзеңә пуля җибәрә алыр идеңме? Чын сугышны күргәнең бармы, аның ни икәнен беләсеңме? – дип сорый иде. – Ике кешегә бер мылтык биреп, немец танкына каршы җибәрелгән солдатны, әсир төшкән өчен, сатлыкҗанга саныйсыз. Безнең дүртенче армияне җитәкчеләр немецларга саттылар, анда 500 меңнән артык кеше бар иде. Шушы 500 меңне дә сатлыкка санаргамы? Без үзебезнекеләргә каршы корал күтәрмәдек. Шул соңгы чиктә үзебезнең маңгаебызга пуля җибәрә алмаганга гаепләсәгез генә инде. Лейтенант хаксызлыгын үзе дә аңлый иде, күрәсең. Шуңа күрә артык җәбер-золым күрсәтмәде. Ләкин ул – кечкенә кеше, өстән кушканны үтәргә, приказга буйсынырга тиеш. Тикшерү озакка сузылып та, гаепләрлек дәлилләр табылмагач, эшне башкага бирделәр. Монысы – майор. Тикшерү бүлеге начальнигы. Моның белән кешечә сөйләшү мөмкин түгел. Телендә гел мыскыллы сүзләр.

– Сатлыкҗаннар, фашист ялчылары. Төрмәдә черетәчәкмен мин сезне.

Янаулар буш булып чыкмады. Барыйны 58нче статья буенча атарга хөкем иттеләр. Ләкин, бәхеткә, яшь булуын исәпкә алып, атуны егерме биш ел төрмә белән алыштырдылар. Әлеге статья буенча хөкем ителүчеләрне «пересыльный» пунктка җыйдылар. Бу – яманаты халык теленә кергән «Плэтән» төрмәсе булып чыкты. «Кара козгын»нар көн саен яңа тоткыннарны ташып кына тора икән. Озак та үтмәде, аларны Колымага озаттылар.

Ә өйдәгеләр, Барый турында бернинди дә хәбәр ала алмыйча, кара кайгыда, ут йотып яшәделәр. Авылда калган беренче сабыен көтүче хатыны Мәрьямнең тормышы 180 градуска үзгәрде дә куйды.

Иң авыры юлда бару булгандыр, мөгаен. Товар вагоннары тоткыннар белән шыплап

тулган. Ашарга начар, су бөтенләй юк диярлек. Көндезләрен сулыш алуы да авырлаша. Бу газапларга түзә алмыйча, шактый кеше юлда ук дөнья белән саубуллашты. 1949 елның июнь-июль айлары юлда үтте. Поезддан төшкәч, аларны Охота диңгезе буендагы Ванино портына китерделәр. Моннан «Дзержинский» исемендәге теплоходка төяп, Магаданга озаттылар. Җыелу пунктында бераз торганнан соң, Колыма елгасы буена урнашкан Сусуман шәһәренә җибәрделәр. Аннан биш йөзләп кешене сак астында «Фролыч» исемле алтын приискасына алып киттеләр. Килүчеләрне мәйданга тезеп, һөнәрләренә карап, төрле отрядларга бүлә башладылар. Балта осталары төркемендә Барый берүзе булып чыкты. Мондый һөнәр иясенә лагерьда ихтыяҗ зур икән. Ул белгечләр өчен булган аерым баракка урнашты. Монда медик, повар һәм мастерлар тора. Барысы да сәяси тоткыннар, озак срокка хөкем ителгәннәр. Беренче көнне үк яңа килүчене чолгап алып, сугыш, илдә булган башка вакыйгалар турында сораштыра башладылар. Барый үзенең әсирлектә булуын, Франциядә партизан отрядында сугышып йөрүен, монда ничек килеп эләгүен сөйләде.

Километрларга сузылган мәңгелек туң җир. Кешеләр шуны кәйлә, лом белән чокып, 2-3 метр тирәнлеккә төшәләр (алтын комына җиткәнче). Бу кыш көне эшләнә. Яз җиткәч, шушы меңләгән чокырга динамит урнаштырыла һәм бөтенесе берьюлы шартлатыла. Актарылып ташланган ком-таш кисәкләренең өске өлешен бульдозерлар чистартып чыга. Аста калган катламны, вагонеткаларга төяп, алты метр биеклектәге бункерларга меңгереп бушаталар. Моннан ташлы ком улак аша үтә. Шушы вакытта басым белән су җибәрелә. Алтын комы, улак төбенә җәелгән йонлы тукымага эләгеп, утырып кала. Эрерәк алтын «самородок»ларын һәм таш кисәкләрен аста күзәтеп торучы эшчеләр «бутырка» белән ике сортка аерып тора. Вакыт-вакыт өч-дүрт килограммлы «самородок»лар да очрап куя. Билгеле бер вакыттан соң, улакка җәелгән полотноны алып, алтын комын коялар. Аннан, балчык чүлмәкләргә тутырып, кислота белән эшкәртәләр. Чистарып калган алтын агач тартмаларда Магаданга озатыла...

Ашарга мул бирәләр. Су дуңгызы ите, селёдка, икмәк өстәлдән өзелми. Сугыш чорында американлылардан кергән сало, күкәй порошогы да алтын чыгаручылар авызына еш эләгә. Беренчедән, хезмәт бик авыр, хәлсез кеше алтын юу эшен башкара алмас иде. Икенчедән, бу эш ил өчен бик табышлы. Араларында булган экономист: «Дальстройның бер көне СССРны бер атна туйдырып торырга җитә», – дип әйтә торган иде. Алга таба эшләгән өчен тоткыннарның махсус счётына акча да күчерә башладылар. Зонадагыларга бер грамм алтын комы юып тапшырган өчен – ике сум, ә ирektәгеләргә дүрт сум хезмәт хакы яздылар. Ләкин кырыс климат, ирексез яшәү рәвеше, цинга авыруы меңнәрчә кешене вакытсыз теге дөньяга алып китә торды. Бу якларда кыш аеруча салкын була. Температура еш кына илле градустан да түбән төшә. Бараклар беләктән аз гына юанрак агачлардан салынган. Уртада – тимер мичкәдән ясалган мич. Ул, көне-төне янып торуга карамастан, бүлмәне җылыта алмый. Стеналар берничә сантиметр калынлыгындагы боз белән каплана. Шушында, ике яруслы нарларда, калын чалбардан һәм сырмадан йөзләрчә тоткын төн үткәрә. Иртән тагын шул ук эш, тагын җир вату, тагын ком-таш чыгару...

Ике ел узганнан соң, Барыйны прииска начальнигы Авраам Моисеевич Непомнящий үзенә чакыртты. Аның күтәреп куелган йорты бар икән. Шуны торырлык итәргә кирәк. Барый берничә иптәше белән өйне эшләп чыкты. Тәрәзә-ишекләр куйдылар, идән-түшәмнәрен кыстылар, бурасын мүкләп-чутлап, яшәрлек хәлгә китерделәр, соңыннан хәтта мичен дә үзләре чыгардылар. Боларның осталыгын күреп, Авраам Моисеевич өй өчен җиһазларга да заказ бирде. Буфет, кәнәфи, ачылмалы өстәл прииска хуҗасының күңеленә хуш килде. Моннан соң Барыйны казу эшләренә йөртмәделәр. Ул тулысынча столярлыкка күчте.

1953 елның язы якынлашты. Тоткынлыкта үткән бишенче яз иде бу. Шундый көннәрнең берсендә аңа бер төш керде. Төсле төш. Имеш, алар җир астыннан тоннель казыйлар икән. Инде казылган өлеше дә шактый. Менә ул тоннель буйлап алга таба атлый. Еракта-еракта алсу яктылык күренде. Барый шул яктылыкка таба йөгерә башлады. Озак та үтмәде, чәчәкле якты аланга килеп чыкты. Бөтен дөнья ямь-яшел. Күктә кояш көлә, кошлар сайрый. Алан кырыенда җыйнак кына өй тора. Аяклары

үзеннән-үзе шушы өйгә таба алып китте. Йортның ишеген ачып, түргә узды. Аның каршында яшь бала күтәргән мөлаем гына бер хатын пәйда булды. Стена кырыенда агач эше өчен верстак куелган, өстендә фуганка ята.

– Абый, балама уйнар өчен струг йомычкасы юнып кына бирче әле, – ди яшь хатын. Барый фуганканы алып, агач өстеннән йөртә башлый. Шундый җиңел, шома бара. Алкаланып, бөтерелеп, агач йомычкасы сыдырыла. Барый аны хатынга сузды.

– Рәхмәт, – диде ханым, елмаеп. Төшенең шушы урынында уянып китте. Күргән тәэсирләреннән айный алмыйча, озак кына уйланып ятты.

– Егетләр, берничә көннән мин илгә кайтып китәчәкмен. Күңелем шулай сизә, менә күрерсез, – диде ул иптәшләренә. Алар моңа көлеп кенә карады.

Смена бетәр алдыннан цех начальнигы Шпаков Барыйны үз янына чакырып алды да: «Борис, по секрету скажу, ты скоро уедешь. Только пока никому не говори об этом», – диде. Төшен кайтуга юраса да, күңеле белән азат ителүне көтсә дә, чын мәгънәсендә хыялының тормышка ашуына тиз генә ышанып җитә алмады Барый. Ике көннән аңа эш коралларын тапшырырга куштылар. Башта самолёт белән Магаданга, аннан пароход белән Ванинога озаттылар. 1953 елның маенда ул Уфада иде инде. Бу вакытта Башкортстанда аның белән бергә әсирлектә булганнарны яңа «җыя» гына башлаганнар икән. Барыйны шуларны тану өчен алып килгәннәр булып чыкты.

Гали Рәхимов белән күзгә-күз очрашу оештырдылар (әсирлектә ул Гали Белый булып йөри). Алар бер-берсен таныдылар һәм аны яшермәделәр дә. Галине әле яңа гына кулга алганнар. Тикшерү эшен алып баручы следователь – Советлар Союзы Герое. Сугышны үз җилкәсендә татыган кеше. Солдатларның хәлен аңлый, сорауларын да иплә бирә. Барый Галинең намуслы кеше булуын, бергәләп әсирлектә булуларын, француз партизан отрядларында сугышуларын сөйләп бирде. Рәхимов камерада илдәге үзгәрешләр турында сөйләде. «Заманалар үзгәрә, утырсак та, бер-ике елдан артмас», – дип белдерде. Чыннан да, аның сүзен раслагандай, ике-өч көн үтүгә, Сталинның үлеме турындагы бөтен дөньяны шаулаткан хәбәр төрмәдәге тоткыннарга да килеп ирешә. Бу көнне йөзләрчә завод-фабрикалар, сәгать саен гудок биреп, «халыклар атасы»н искә алды. Тоткыннар өчен исә бу гудок тиздән яңа тормыш, үзгәрешләр башланачагын хәбәр итүче сигнал булып яңгырады. Бу вакыйгалардан соң Барыйны, Уфада озак тоткарламыйча, Казанга кайтардылар.

Аның эше беренче тапкыр Колымага озату өчен күп «хезмәт» куйган следователь кулына эләкте. Ул инде подполковник. Сөйләшү рәвеше генә элеккечә. Аның өчен монда эләккәннәр кеше исәбенә керми иде, билгеле. Барый да элеккеге тоткын түгел иде инде. Казанда аны әсирлектәге иптәше Василий Зайцев белән очраштырдылар. (Аңа да хәзергә кадәр кагылмаганнар булып чыкты.) Барый Василийны танымаганга сабышты.

Тикшерүченең янаулары да, куркытуы да тәэсир итмәде аңа бу юлы.

– Без үлемне күрдек инде. Кешене ике тапкыр үтереп булмый. Син безне Колымага җибәрдең. Шунда бетәрләр, югалырлар, дип уйладың. Аннан да исән кайттык. Ирекле булмасак та, безгә ышандылар, дошманга санамадылар. Безгә Ленин әсәрләрен дә укырга рөхсәт итәләр иде. Эшләгәнгә акча да түләделәр. Син үлемгә җибәргән урыннан мин акча белән кайттым. Безнең чыгар вакыт җитеп килә. Ә менә синең һәм синең шикеллеләрнең утырасы алда әле!

Бу Барыйның подполковникка әйткән соңгы сүзләре булды. Аны бер кешелек таш камерага ташладылар. Ай буе янына керүче дә, сорау алучы да булмады. Иң куркынычы – ялгызлык икән. Дөньядан аерып, кешеләр белән аралашуны чикләсәң, һәркемне бик тиз акылдан яздырып була, дип сөйләгәннәрен ишеткәне бар иде аның. Инде моның дөреслегенә үзе дә ышанды. Берничә метрлы кечкенә генә таш бүлмә. Түрдәге төнлек тишеге кадәрле тәрәзәдән аз гына яктылык төшеп тора. Шуңа күрә монда һәрвакыт ярымкараңгылык хөкем сөрә. Көннең кайсы вакыты икәнлеген дә белеп булмый. Калын таш стеналар тоткынны тышкы дөньядан тулысынча аера. Ник шунда бер шылт иткән тавыш ишетелсен. Монда вакытның чиге юк. Камерада үткәргән бер сәгать көннәр, айлар булып тоела башлый. Бетон таш стеналар арасында тычканнарга да юл юк, дымсу почмакларга үрмәкүчләр дә оя кормый, хәтта тараканнар да күренми. Беркөнне бүлмәгә чебен очып керде. Мондый хәлгә тарымаганнар бәлки көләр, ышанмас, ләкин ялгыз

тоткын өчен ул да бер бәйрәм булды. Барый аны көн дә көтеп ала башлады. Тумбочка өстендә аз гына юеш шикәр комы калдыра килде. Нәрсә генә әйтсәң дә, егетне тышкы дөнья белән бәйләп торучы бердәнбер җан иясе иде шул ул... Аллаһы Тәгалә Барыйны монда да кызганды. Психологик яктан сындырырга тырышулары барып чыкмады. Барый үз сүзеннән кайтмады. Аны Мордовиягә, каты режимлы лагерьга озаттылар. Лагерь урман эченә урнашкан. Бар җирдә тәртип, чисталык хөкем сөрә. Яңа килгәннәрнең барысына да номер сугылган кара төстәге спецовкалар өләштеләр. Барыйның номеры – Е-4535. Монда да мебель җыю цехы эшли икән. Аны шифоньер җыюга билгеләделәр. Яңа килүче өч көн эш белән танышып йөрергә тиеш, дүртенче көнне үзе мөстәкыйль рәвештә норма үти башлый. Көнгә өч шифоньер җыю каралган. Барый икенче көнне үк эшкә тотынды. Норманы да тиешенчә үтәде. Тора-бара лагерьда алдынгы осталарның берсенә әйләнде. Өч шифоньерны ул 5-6 сәгать эчендә җыя иде. Калган вакытын иптәшләренә булышып йә ял итеп үткәрде. Дүртне иркен рәвештә эшли алса да, иптәшләренә авырлык китерермен дип шикләнде. Аңа карап, башкалар өчен дә норманы арттырырга мөмкиннәр иде бит. Егетнең фотосын «Почёт тактасы»на куйдылар. (Фото бүген дә альбомда саклана.)

Килүләренә 15-20 көн вакыт узмады, «каты режим»ны күрсәтүче номерлы киемнәрне салдырып аттылар. Үзәктән килгән приказ нигезендә, ул гомуми режимдагы «төзәтү-хезмәт лагере» итеп үзгәртелде. 1954 елда Барыйны тагын башка лагерьга күчерделәр. Монда килгәч, агач кыру станогында эшли башлады. Бук, каен агачларыннан шахмат фигуралары кырдылар. Барый «турка»лар җитештерде. Токарь сменага 140-160 фигура ясарга тиеш. Оста монда да норманы арттырып үтәде, монда да рәсеме «Почёт тактасы»на менде.

Беркөнне йоклар алдыннан Борис исемле танышы (партиягә каршы нииндидер союз оештыручы буларак хөкем ителгән):

– Озакламый сезнең статья буенча хөкем ителүчеләрне кайтарырга тиешләр. Минем апа Кремльдә эшли, шул язды, – дип, Барыйга сөенечле хәбәр җиткерде.

Бер атна вакыт узгач, Барыйның кулына чиста документ бирделәр, «гаебе булмаганга акланды» дигән белешмә белән (җиде ел төрмәдә утырганнан соң!) кайтарып җибәрделәр.

Авылда аны хатыны Мәрьям һәм үзе китеп дүрт ай үткәннән соң дөньяга килгән җиде яшьлек улы каршы алды. Әле беренче тапкыр әтисен күрүче бала, бер дә тарсынмыйча, Барыйның тезенә менеп кунаклады, үпкәләгән тавыш белән:

– Әти, син кайда йөрдең соң, ник бик озак кайтмадың? – дип, аның муеныннан кочаклап алды.


Нәрсә дип җавап бирә ала иде соң Барый бу сабыйга... Ата яшь тибеп чыккан күзләрен улыннан читкә борды.

Барыйны иң авыр вакытларында иптәшләренең яхшылыгы, үзенең тырышлыгы, киләчәккә булган өмете саклап калды. Тормышның шундый сынауларына карамастан, Барый бүгенге көндә үзен бәхетле кеше дип саный. Әйе, ул бәхетле, инде менә 73 нче тапкыр җиңү язын каршылый. Әйе, ул бәхетле, бүген дә үзенең яраткан балалары, оныклары тәрбиясендә мул тормышта яши, өлкән яшьтә булуына карамастан, яраткан эше белән әле дә шөгыльләнә ала.

Уйларыннан арынырга теләгәндәй, Барый тирә-юньгә күз ташлады. Язгы табигатьтә барган үзгәрешләргә, анда кайнаган тормышка шатланып, сокланып карап торды. Яшәешнең нигезендә ятучы бетмәс-төкәнмәс мәңгелек хәрәкәт. Шулвакыт бернйчә өй аша булган күршесенең үзләренә таба килгәнен күреп, каударланып, аягына басты, береткасын рәтләп куйды. Күршесенең кызы Сабантуйда кияүгә чыгарга әзерләнә, шуңа бер атна элек «килен сандыгы» эшләргә заказ биреп киткән иде. Ә Барыйның әле сандык читләрен бизәкләп бетерәсе бар. Шуларны уйлап, остаханәсенә таба кузгалды ул. Туксан бишенче яше белән баручы Барыйны анда гомере буе эшләп тә туйдырмаган, күп тапкырлар үзен үлемнән алып калган, яраткан эш-шөгыле көтә иде.

**Айдар ГАРИПОВ,**
*Саба районы Олы Шыңар урта мәктәбенең тарих укытучысы*

# «МИЛЛИ ҮЗАҢ БУЛМАСА, ҮСЕШ ТӘ ЮК»


*«Мөхәммәдьяр» ролендә – Айдар Хафизов.*

*Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты **Айдар ХАФИЗОВ** белән әңгәмә.*

**– Айдар абый, Сез – сәнгать дөньясында үз юлын булдырган күренекле шәхес, халкыбызның яраткан артисты, оста режиссёр. Артист булам, театр дөньясында иҗат итәм дигән уй-хыял күңелегездә кайчан бөреләнде?**

– Бу сорауга озаклап җавап биреп булыр иде. Бернәрсәне дә, кырт кына башыңа килде дә, шулай булды, дип әйтә алмыйсың бит. Мин – сугыш чоры баласы, 1943 елда туганмын. Сугышның иң кызган чагы. Гаиләдә сигезенче бала. Бу авыр елларда исән калуым да икеле булган. Әти-әниемнең беренче баласы, безнең иң өлкән абыебыз, 1944 елда унтугыз яшендә Смоленскида һәлак була. Без аның туганнар каберлегендә күмелүен белә алдык һәм эзләп таптык. Икенче абыебыз армиядән кайтып, колхозда үзебезнең үгезне җигеп эшли башлагач кына, рәхәтләнеп, авыз тутырып ипи ашый алдык. Аңа кадәр ипи дигән әйбер юк иде. Бәрәңгедән пешерәләр, аны көнендә генә ашап була. Урып-җыю чорында 1932 елгы апам – ун яшьлек бала – кырда башак җыйган вакытта, бераз гына башакны үзе теккән кечкенә киндер капчыкка тутырып яшереп калдыра. Мин, нарасый, бер айлык булганмын. Шушы ун яшьлек апам мине карарга кала. Елыйм да елыйм икән. Әни дә туйганчы ашый алмагач, сөте күпме булгандыр инде?! Шулчакта апа үзе җыеп куйган башакларын кул тегермәнендә ваклата. Аннары ботка пешерә һәм чүпрәк имезлеккә салып миңа каптыра. Әни кайтканда, мин йоклыйм икән. Әни: «Нишләттең, ничек йоклаттың?» – дип куркып кала. Апа сөйләп бирә инде. Шуннан мин бер тәүлек буе йоклаганмын. Аннары, искә төшереп сөйләгәндә, ачка елаган булгансың икән, дип әйтә иде әни. Менә шундый авыр заманда туып үскәнбез. Нинди монда артист булу турында хыяллану?! Шулай да, балачакта киләчәк һөнәремне үзләштерүдә миңа тәэсир ясаган кешеләр булды. Безнең урамда Муллахмәт абый бар иде, аның хатыны Сания апа – безнең беренче укытучыбыз. Ә Муллахмәт абыйның сугыштан алып кайткан патефоны бар. Ул патефонын тәрәзә төбенә куя. Авыл кешеләре җыелышып тыңлыйбыз, күңелләр үсеп китә инде. Аннары радио-тәлинкәләр куя башладылар. Алардан спектакльләр тыңлыйбыз. Үзебез күргән кебек күз алдына китерәбез. Балачакның кызык хатирәләре... Минем абый белән дус Галимхан абыйны да еш искә төшерәм. Аның вараксин гармуны бар. Яшь, җилкенчәк чаклары, өздереп уйныйлар гармунда. Ә мин аларга карап, тын да алмый тыңлап утыра идем. Шуннан үзем дә, гармунны кулга алып, көйләр чыгара башладым. Галимхан абый миңа каршы килми, киресенчә, уйнарга теләвемне сизеп өйрәтә башлады. Өченче сыйныфта укыганда, колхоз кырында күмелеп калган биш-алты капчык бәрәңге җыйдым. Шуннан әтигә: «Әти, без әйбәт кенә бәрәңгеләрне барыбер малларга ашатабыз. Әйдә, мин кырдан җыйган бәрәңгене яхшыларга алыштырыйк та гармун сатып алыйк әле», – дидем. Әти берсүзсез риза инде. Шулай итеп, гармунлы булдым. Дүртенче классларда

миннән бер яшькә генә олы Миңнулла исемле малай белән концертларда катнаша башладык. Безгә ул чакта ун-унбер яшь. Мин гармунда уйныйм, ә Миңнулла моңлы итеп җырлый. Беренче тапкыр сәхнәгә чыгуларым бу. Сәхнәгә тартылуымда, сәнгать дөньясы белән тагын да ныграк кызыксына башлавымда тәэсир ясаган тагын бер кеше бар иде, ул – Мәхмүт абый. Миннән җиде яшькә олы, үзе сукыр иде. Аның дүрт төрле гармуны бар. Мәхмүт абый үзлегеннән өйрәнеп, бик оста итеп гармунда уйный иде. Мин аны клубка репетицияләргә, концертларга озатып йөрим. Ул кулына гармун алса, авыл кешеләре елап тыңлый иде. Йөрәкләргә шулкадәр үткәрә белә. Шаккатмалы инде. Мәхмүт абыйдан да гармун уйнау осталыгына төшендем. Ә бишенче сыйныфларга җиткәч, Гөлшат Зәйнашеваның бер пьесасын өйрәндек. Рус теле укытучыбыз Мария апа режиссёр булды. Шаккатам, без балаларны туплап, озын гына пьесаларны сәхнәләштерәләр иде бит. Район газетасында шушы спектаклебез турында зур гына мәкалә дә басылып чыкты. Танылган журналист Рахмай Хисмәтуллин безнең спектакльне килеп караган булган. Төп рольдә Айдар Хафиз уйнады, дип мине аерып язуына бик куандым шул чакта. Җиденче сыйныфны бетергәч, укуны дәвам итәр өчен, Шәлегә барырга кирәк иде. Без – сигез бала: олы абый башка чыкты, апам кияүдә, 1936 елгы абый армиядә, әнигә – 57, әтигә – 67 яшь. Бернинди пенсия түләү дигән әйбер юк. Колхозда эшләгәнгә бер тиен дә акча бирмиләр. Сыерыбыз һәм егерме биш сутый бәрәңге бакчасы гына бар. Укырга барыр өчен китап-дәфтәрләр алырга, өс-башны карарга кирәк. Кыскасы, акча булмагач, мәктәпкә бармадым. Кыш буе күрше авылга йөреп, Мишә буеннан таш чыгаруда катнаштым. Олылар вата, без ташыйбыз. Шул вакытта мин бертуктамый уйлыйм: «Нишләргә, нишләргә, нишләргә?» Уйлый торгач, бер фикергә килдем. Күрше егете Харис белән киңәшеп, авылның баш көтүчесе Каюм абый янына бардык та эшкә алуын сорадык. Авыл көтүен көткән өчен мең ике йөз сум акча түләнә, шуңа өстәп кырык пот бәрәңге җыела. Ул вакыт өчен бик зур акча инде. Каюм абый безне алырга ризалык бирде. Шулай итеп, ике ел көтү көттем. Авылда иң беренче булып ике рәтле хромка гармун алдым. Ул вакытларда бригадир абыйның гына велосипеды бар иде. Икенче елны, үзем эшләгән акчага, Казанның Бауман урамына барып, велосипед сатып алдым. Һәм авылга кадәр велосипедта кайттым. Өс-башны карадым. Абый армиядән кайтуга, безнең тормыш шактый җайланган, ризык бар, маллар бар иде инде. Болар барысы да уналты яшь тулганчы эшләнгән эшләр бит... Менә уналты яшь тулды. Паспорт бирделәр. Хәзер укуны дәвам итү турында уйлана башладым. Васильеводагы механика техникумында автомеханиклар чыгара торган бүлек бар икән. Мин, тәвәккәлләп, шунда киттем. Имтиханнарны тапшырып, Казанга кайтып барам, Юдино станциясендә минем яшьтәге малайлар килеп керде. Үзләре Шәмәрдәннән икән. Алар арасында, соңыннан Хезмәт Герое булган, «Оргсинтез»ны, «КамАЗ»ны төзегән Вазыйх Мавликов та бар иде. Бу шома малайлар: «Без тимер юл техникумына кердек, анда ике генә ел укыйсы, форма бирәләр, стипендия дә зур, әйдә, син дә безнең белән», – дип мактанырга тотындылар. Мин, «эх», дип көрсендем. Әмма, бу малайлар сүзләрендә нык тордылар, бергәләп кире Васильевога бардык та документларымны сорадык. Аларның русчасы бик әйбәт. Бирделәр документларымны. Шулай итеп, мин дә тимер юл техникумына укырга кердем. Шул елны анда зур гына мәдәният йорты ачылды, монда төрле түгәрәкләр эшли. Мин укудан кайтам да шунда йөгерәм. Хорга язылдым, биюгә йөрим. Бервакыт гармунда уйнаганымны ишетеп алып, мине татар ансамбленә баянчы итеп чакырдылар. Рус төркеменең баянчысы Александр абый, ул музыка училищесын тәмамлаган. Миңа нота грамотасын өйрәтте. Бик күңелле чаклар. Кварталга бер агитпоездларда станцияләргә барып, лекцияләр укыйбыз, концертлар куябыз. Ике ел сизелмичә дә үтте. Техникумны тәмамлагач, Владимир өлкәсенең Муром шәһәренә эшкә җибәрделәр. Укыган өчен ике ел эшләргә тиешсең.

Бераз вакыт узуга, ансамбль җитәкчебез Әхәт абый мине эзләп килеп җиткән бит. Мәдәният йортының директоры Борис Юрьевич, отпуск алып кайтсын, дип җибәргән. Отпуск бирделәр, Казанга кайтуга, агитбригада поезды белән чыгып та киттек. Инде ялга тиешле вакытлар да үтеп китте, Муромга кире барып, за прогул уволнять итегез,

дидем, алар каршы торсалар да, ризалаштыра алдым. Кайтып, Юдино мәдәният йортында эшләвемне дәвам иттем.

Тыныч кына эшләп йөргәндә, Кайбыч районында гастрольләр вакытында бер игълан күреп алдым: Галиәсгар Камал театрының баш режиссёры Ширияздан Сарымсаков театр училищесында курс җыя. Тәвәккәлләдем... Күчмә театр ул вакытта Кремль башнясында урнашкан иде. Шунда имтихан бара. Алты йөзләп кеше җыелган. Шигырь, мәсәл, прозадан өзекләр укыдык. Иң төп имтихан көне килеп җитте, икенче тур. Карасак, егерме-утыз кеше калган. Шаккаттык. Имтиханны СССРның халык артистлары Хәлил Әбҗәлилов, Николай Якушенко, Габдулла Шамуков, танылган, көчле артистларыбыз Фатыйма апа Ильская, Шәхсәнәм Әсфәндиярова, Празат Исәнбәт, Рифкать Бикчәнтәев, Шәүкәт Биктимеров кабул итә. Этюдлар күрсәтергә кирәк. Бу – иң катлаулысы. Поездда Казанга кайтып төшәм янәсе, һәм мине анда сөйгән кызым каршы ала, менә шул хакта этюд күрсәттем. Рәфкать Бикчәнтәевнең, өстәлгә суккалап, поезд тавышын чыгарып утырганы әле дә колагымда яңгырый. Күрәсең, алар мине ошатканнардыр. Имтиханнарны уңышлы тапшырып, мин дә театр училищесы студенты булдым. Ул елны егерме ике кеше алырга тиешләр иде дә, барлыгы ундүрт кешене генә кабул иттеләр. Курсташларым арасында Наил Әюпов, Хәлим Җәләлов, Наил Шәйхетдинов, Дамир Нәбиуллин, Венера Хөснетдиновалар бар иде. Соңрак тагын өч кеше өстәлеп, без унҗидәү булдык. Менә, шулай итеп, мин дә театр дөньясына кереп киттем.

**– Театр дөньясыннан тыш, Сезнең иҗат юлыгызда филармония һәм режиссёрлык эше дә бар. Бу юнәлешләрдә ничек эшләп киттегез? Күпкырлы иҗатыгызда зур нәтиҗәләргә ирешүегезнең сере нәрсәдә?**

– Театр училищесында әйбәт кенә укып йөргәндә, мине армиягә алдылар. Кайтканда, курсташларым инде укып бетергән иде. Беренче курслар – бөтенләй башка төркем. Алар арасында булачак хатыным Фәридә дә бар иде. Әмма миңа инде укыган программаны яңадан уку кызык түгел. Шуннан яңа курсның җитәкчесе Марсель Сәлимҗанов миңа эшләп торырга тәкъдим итте. Алар өченче курска җиткәч, килерсең дә укуыңны тәмамларсың, диде. Шулай итеп, Күчмә театрда эшли башладым. Ә бераздан өйләндем. Фәридә апагыз белән матур гына гаилә кордык. Гаиләле булгач, ерак гастрольләргә чыгып йөрү уңайсыз, шуңа да филармониягә эшкә күчтем. Монда сүз остасы булдым. Ай буе программа әзерлисең дә гастрольләргә чыгып китәсең. Илһам Шакиров белән бик көчле программа әзерләгән идек ул чорда.

Режиссёрлык эшем хакында әйткәнче, тагын бер нәрсәне искәртеп үтәсем килә. Укыган вакытта Ширияздан абый Сарымсаков миңа музыка училищесына күчәргә тәкъдим иткән иде. Дәресләрдән соң бервакыт баянда уйнап утырам, Ширияздан абый мине тыңлап торган да шаккаткан. «Син шулай уйный беләсеңмени? Синнән зур музыкант чыга, әйдә, мин Әүһәдиевка әйтәм, һәм син музыка училищесында укып бетер», – ди. Мин инде: «Юк, юк, гармунда болай да уйный беләм, театр дөньясы үзенә күбрәк тарта», – дип баш тарттым. Чак кына музыкант булмый калдым. Әмма шулай да театрда музыка юнәлеше буенча эшләп алырга туры килде. Ул вакытларда театр бер урында гына түгел, ә бер кичтә берничә җирдә спектакльләр куя иде, ә музыкант берәү генә – Рәис Сәфиуллин. Ул үзе урынына читтәге спектакльга мине баянда уйнарга җибәрә иде. Шул вакытларда Рәис абый мине Сара апа Садыйкова белән күрештерде. Бауман урамындагы Горький клубында Сара апаның танылган халык хоры эшли иде. Аңа аккомпаниатор кирәк икән. Шулай итеп, армиягә киткәнче, студент вакытымда ук, Сара апа Садыйкова белән дә эшләп өлгердем. Ул хәтта мине армиягә озатырга да килде. Ә аннары армиягә җыр язып җибәрде. Сара апаның үз кулы белән язылган ул хатны әле дә кадерләп саклыйм. «Солдатым» дигән җырның текстын Мостафа Ногман язган, клавирдан карап, без бу җырны өйрәндек. Тәрҗемә итеп җырладык. Ул җыр бик популярлашып китте.

Студент елларыннан ук башлап, шушындый зур шәхесләр белән аралашу, эшләү, сәнгать дөньясында көн-төн кайнау үзе бер зур мәктәп булды. Режиссёр эшенә дә үзеннән-үзе тартылдым. Училищеда укыганда, «тәрәзәләр» (буш дәресләр) вакытында

театрда кала идем. Театр училищесының аерым бинасы булмагач, дәресләрнең күбесе театрда уза иде ул чакта. Буш вакыт булуга, курсташларым таралыша. Мин галеркада утырып, репетицияләр карыйм. Спектакль дигән могҗизаның ничек барлыкка килүен күрәм. Әле яшь Сәлимҗановның диплом спектаклен әзерләгәнен дә хәтерлим. Алар уйнаганда, һәр детальне анализлап утыра идем. Шушы хәл миңа үзе зур сабак булган. 1970 елда, укуны тәмамлап, театрда эшли башладык. Артист булу белән беррәттән, режиссёрлык эшенә дә кереп чумдым. Элек профессиональ театрлардан тыш, халык театрлары күп иде. Һәр зур оешманың мәдәният йорты бар. Аларда профессиональ дәрәҗәдәге спектакльләр куела. Мин Казан дәүләт университетының халык театрында һәм Ленин исемендәге мәдәният сараенда режиссёр идем. Туксанынчы еллардагы милли күтәрелеш чорында зур театраль чараларның режиссёры һәм оештыручысы булдым. Бу эш мине үзенә суырып алды, дисәм дә ялгыш булмас. Мөхәммәдьярның 500 еллыгы, Мәрҗанинең 180 еллыкларын уздыру... Кыскасы, шактый масштаблы эшләр эшләнде.

**– Традицион соравым да бар – яраткан рольләрегез турында да сөйләгез әле?**

– Артистның уйнаган рольләре берәү-икәү генә булмый бит. Гомер буе эшләгәч, рольләр саны дистәләп була. Рольләрне берсен яраттым, берсен яратмадым, дип аерып булмый. Аларның бөтенесе дә якын, чөнки һәр роль ачылган, табылган образ рәвешендә барлыкка килә. Роль турында бик күп уйланасың, бик күп чагыштыруларга нигезләп төзисең. Бик күп йокысыз төннәр, зур хезмәт, көч куеп тудырыла рольләр. Әлбәттә, күңелгә аеруча уелып калганнары була. Әйтик, Чыңгыз Айтматовның «Ай тотылган төндә» пьесасында Дәрвиш ролен уйнадым. Бик катлаулы образ. Мин бу рольне бик эзләнеп тудырдым. Туфан Миңнуллинның «Ат караклары»нда Листунов дигән ак гвардиячене уйнадым. Трагик һәм катлаулы роль. Аманулланың «Кылый Кирам балдагы» комедиясендә үзен доцент дип таныштыручы аферист бик кызыклы образ булып истә калган. Фәрит Бикчәнтәев Гаяз Исхакыйның әсәрләренә нигезләнгән «Курчак туе»н куйды. Андагы сәүдәгәр роле – фаҗигале образ. Аның фаҗигасен ачар өчен күп эзләндем. Гомумән, бу спектакльдә барлык образлар да үтә трагик. «Курчак туе» соңгы елларда куелган иң көчле спектакльләрнең берсе дип әйтер идем.


**– Татар театры зур үсеш юлын узган. Бүгенге көндә аның хәле ничек дип уйлыйсыз? Киләчәге өметлеме?**

– Мине бик борчыган бер мәсьәлә бар. Бүгенге көндә Әлмәт һәм Минзәлә театрлары балаларга рус телендә уйный башлады. Бу нәрсә дигән сүз? Бу – үзең утырган агач ботагын үзең үк кисеп төшерү белән бер! Менә 1970-1980 елларда Казанда татар мәктәпләре беткән иде, ләкин без беркайчан да рус телендә уйнамадык. Камал театры һәрвакыт әдәби татар телен саклады. Ул бик зур тәрбияви дөреслек булды. Ә хәзер нәрсә? Безнең татар театрлары русча уйный икән, алар киләчәктә үзләренең тамашачысын югалтачак. Алар татар театрын яратучы тамашачыны тәрбияләргә тиеш бит. Ә монда татар телен оныттыру өстендә эш алып баралар булып чыга. Шулай ук русларның татар мохитенә ят булган пьесаларын уйнау да мантыйкка сыеп бетми. Безнең халык кабул итми андый пьесаларны. Ләкин рус һәм дөнья классикасы театр репертуарында һәрчак булырга тиеш. Үзебезнең драматургларны да үстерергә кирәк.

Милли үзаң юк икән, үсеш тә юк дигән сүз. Сәнгать дөньясында кайнаган яшь буынга киңәшем – эшләрендә күпмедер дәрәҗәләргә ирешкәч тә, мин инде югары баскычка җиттем, дип, тукталып калмасыннар иде. Бу бик зур хата. Тагын да үсәргә тырышырга, бик күп уйланырга, һәрчак эзләнүдә булырга кирәк. Бервакытта да тукталып калырга ярамый.

**Айсылу ИМАМИЕВА**

# МӨБАРӘК ТӘСБИХНЫҢ БЕР ТӨЙМӘСЕ




Безнең буын XX гасыр татар әдәбиятының Тукай, Дәрдемәнд, Фатих Әмирхан, Гаяз Исхакый, Галимҗан Ибраһимовлардан башланып, Һади Такташ, Хәсән Туфан, Муса Җәлилләр ялгап җибәргән тәсбихын тартырга туры килүе белән бәхетле. Ул тәсбихның һәр төймәсе изге: Нәкый Исәнбәт, Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Мирсәй Әмир, Нурихан Фәттах, Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев, Туфан Миңнуллин..., шигърияттә – Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Нажар Нәҗми, Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, Роберт Әхмәтҗанов, Рөстәм Мингалим, Фәнис Яруллин... Җөмләдән, без фәкыйрегезгә дә аларның яңа гына «табадан төшкән» әсәрләрен кайнар кульязма хәлендә үк бик күп укырга насыйп булды. Бәрәкәтле иҗатларын күңелемә сеңдереп, үзләре белән аралашу ләззәтен кичереп узган гомернең шул өлеше, шөкер, кайчандыр «тамыр тирәнлеген яфрак тоя» дип әйтелгән сүзләремнең кайтавазы – тормышымның бүгенгесе булып яшәвен дәвам итә...

«Казан утлары»нда эшләп торган җиремнән кинәт кенә нәшриятка китү вакыты тиздән әдәби мохиттә башланачак торгынлык чоры белән кисешә кебек. Әле дә искә төшерәм: кызым укый торган мәктәптә язучылар белән очрашу көтелә иде; бер классташының әнисе, димәк, минем кордашым, шунда барырга рөхсәт сораган баласына: «Кит әле, нинди очрашу, ди, ул?! Писәтелләр әллә кайчан үлеп беткән бит инде», – дигән. Үзе дә белмәстән, кыек атып туры тидергән кинаяле сүзләр! Хәер, рус әдәбиятына да 90 нчы еллар шаукымы кагылды булса кирәк. Университетта безне рус совет әдәбиятыннан «тимер-бетон» романнарны укырга мәҗбүр итсәләр, татар әдәбияты лекцияләрен тыңлаганда, «киртек реализм»нан ары китә алмадык, ахрысы, һәрхәлдә, үзләре ишетеп белсәләр дә, мөхтәрәм мөгаллимнәребез Г.Исхакый исемен, «Идегәй» дастаны кебек җәүһәрләрне атап кына узарга да курыктылар...

Газета-журналда эшләгәндә – көндәлек матбугат укудан, нәшриятта – китаптан биздем бугай, дип, уенын-чынын кушып сөйләгәнем бар. Укырга дип алган әсәрне, китапны еш кына читкә куярга әдәбиятның күңелне кузгатырлык хәле калмаган чоры гына түгел, сыныкка сылтау булып тоелса да, эшемнең юнәлеше, эчтәлеге үзгәрү дә сәбәпче булгандыр. Язмыш кушып, дәреслекләр чыгару белән генә шөгыльләнергә тиешле «Мәгариф» Милли нәшриятының беренче һәм соңгы директоры булып 20 елга якын хезмәт итү дәверендә киңәюгә (заманча әйткәндә, диверсификациягә) йөз тотып, әдипләребезнең иң затлы әсәрләрен генә туплап, йөзгә кызыллык китермәслек китапларын чыгардык, дип уйлыйм. Алар арасында «кибәнне очлап куйганы», ягъни иң соңгысы – Мөхәммәт Мирзаның «Адәм баласы» булуы да очраклы түгел иде, әлбәттә. Миңа, тегенекен чыгар, моныкын чыгарма, дип басым ясый алмадылар, анысы, ә химаяче таптым, дип килүчеләрне башка нәшриятларга бүләк итә тордым...

Мөхәммәт Мирза әсәрләренә алда саналган зур иҗат куәсенә ия әдипләрнең яктысы, җылысы төшкәнә аермачык сизелеп тора. Менә бу биштомлык Илдар Юзеевтагы кебек йомшак-лирик юмор, әллә кайчангы бер шигырендә «Шундый хәл, Мирза, гомерләр уза», дип язган Гамил Афзалдагы әче сатира янәшәсенә барып

басарлык шигырьләрне, чәчмә әсәрләрне тулырак күз алдыннан кичерергә мөмкинлек бирә. Ул андагы зирәк күзәтүләр, сурәтләр байлыгы, тел сафлыгы, ул җор һәм тапкыр сүз тантанасы!..

Әйе, «сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт белән...» дигән фикерне шагыйребез әлегә башкалар яулый алмаган үрдән торып раслый. «Мәгариф» нәшриятына килеп кергәнче, университет галимәләре төзегән «Мин әйттем: татар язучыларының афоризмнары, хикмәтле сүзләре, фәлсәфи уйланулары» дигән тупланманың илһамчысы нәкъ менә Язучылар союзы башлыгы булуы мине беркадәр гаҗәпсендергән иде. Шул чакта ул үзе «Мең дә бер гыйбарә»сен шифалы тамчылар сыман бер бәллүр касәгә җыя барган икән! Аларда шагыйрь фәлсәфәсе ислам дине, халкыбызның «тел,ләгать, гадәт вә әхлак» кануннары белән тыгыз үрелеп яши. Кайчакта әле аның, Дәрдемәндчә әйткәндә, «күңелендә әзрәк кенә кинәсе бар, теленең дә зәһәр очлы инәсе бар»лыгы да сизелеп-сизелеп ала.

Чәчмә әсәрләрендә Мөхәммәт Мирзаның сизгер күңелле, игътибарлы әңгәмәдәш, уникаль хәтерле каләм әһеле булуына игътибар итәсең дә, күңелеңдә, ул, мөгаен, эзлекле рәвештә көндәлек алып баргандыр, дигән фикер-фараз уяна.Әлеге язмаларда Гамил ага, Рөстәм Мингалим, Фәнис Яруллин, Туфан Миңнуллин нәкъ тормыштагыча, тавышлары магнитофон тасмасына яздырып калынган кебек, «телгә киләләр». Туфан абыйчалап әйткәндә, «кызыклы драматург булыр иде Мирза, әйе...». Әңгәмәдәшенә тиң акыл-зирәклек һәм ихласлылык әнә шунда да ачыла. Ельцин, Путин портретлары күз алдына баса, Никита Михалков киносы, Мәскәү МСПСы корылтае турындагы язмаларның «аягына ияреп», сәясәт тә, тарих сабаклары һәм бүгенге вазгыять турында тирән уйланулар да килеп керә. Мөхәммәт Мирзаның каләмдәшләренә (алда атап үтелгәннәргә Рабит Батулланы да кушып) игелекле мөнәсәбәте, туган төягендәге һәр үлән яфрагына кадәр изге мәхәббәте, якташларына карата ихтирам һәм ихлас горурлык хисләре мөлдерәмә тулып ташкан язмалары – һәркайсы зур бер бәянның аерым бүлекләре сыман, бер-берсенә үрелеп китә (күргәнебезчә, алар арасында яңа тарихыбызда җуелмас эз калдырган Беренче Илбашыбыз Минтимер Шәймиев, әдәбият-сәнгатьтә тиңсез талант ияләре Гамил Афзал, Әлфия Авзалова... да, газиз әтисе белән әнисе дә, гыйбрәтле һәм аяныч язмышлы ерак һәм якын туганнары да бар), тормышның төрле хәл-әхвәлләрен, кайчак караңгы якларын да ачкан әдәби-публицистик язмалар, гәрчә, автор, үзенә хас тыйнаклык саклау аркасында, бер-икесенә генә хикәя яки нәсер дип куйса да, зур бәянның – өзелмәс җепкә тезелгән дисбенең – бүлек-мәрҗәннәре булып кабул ителә. Ирексездән, заманында «баш китәрлек» фикерләрен ипләп кенә җиткерә белгән Сибгат ага Хәким прозасы искә төшә.

Мөхәммәт Мирза иҗатының төп хасиятләре биштомлыкның һәркайсына саркып кергән өлкән һәм яшь буын галимнәр, илдә-көндә танылган каләмдәшләре фикере аша әйтеп бетерелгәндер кебек. Әлбәттә, аларның һәркайсы, мәгълүм гыйбрәтле хикәяттәге шикелле, филнең асылын күрү өчен, аны төрле төшеннән тотып караган... Әмма вакытында әйтелгән сүзнең бәһасе кыйммәтле һәм югары! Бу күптомлыкта бергә туплап бирелгәнгә, әдипнең иҗатын төрле яктан ачкан әлеге мәкалә-фикерләрнең бөтенесе белән берьюлы таныша алган кешегә инде аларга нәрсәдер өстәү, аларны узып сүз әйтү мөмкинлеге һәм хаҗәте калмагандыр да.

Сәхифәдән сәхифәгә күчкәндә, Адәм баласы галәменең чиксезлеген, күңел тирәнлеген тоеп, Җирдән Күккәчә биеклекне яуларга, офыктан офыккача киңлекне колачларга омтылган бу Шәхесне үзе өчен яңабаштан ачучы, иҗатының куәтен, соклану катыш гаҗәпләнү хис-тойгылары кичереп, йөрәгеннән кайта-кайта уздыручы бер мин генә түгелмендер, киләчәктә дә бер мин генә булмамын, дип уйлыйм.

Сүземне Мөхәммәт Мирзаның үзеннән зур гына өземтә китереп, «ефәк пута белән бәйләп» куясым килә: «Бәя бирүне, әдәбият белгечләре тарафыннан язылган фәнни мәкаләләр дәрәҗәсендә дөньяга чыгуны, әлбәттә, һәр иҗатчы көтеп яши, – ди ул бер өлкән каләмдәше-остазы турындагы язмасында. – Күпсанлы укучыларның бәясенә дә өметләнә иҗатчы... Әмма хак бәяне бары галиҗәнап вакыт үзе генә бирә ала».

**Мөдәррис ВӘЛИЕВ**

# ЗАРИФ БӘШИРИ

*(1888-1962)*



Шагыйрь, язучы-прозаик, мәгърифәтче-педагог Зариф Бәшири (Зариф Шәрәфетдин улы Бәширов) 1888 елның 5 маенда хәзерге Татарстан Республикасының Кайбыч районына кергән Чүти авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә.

Зарифның укуга сәләте, әдәбиятка омтылышы да бик иртә уяна. Башлангыч белемне туган авылында әтисеннән алгач, укуын 1898-1902 елларда Буа мәдрәсәсендә, аннан соң (1902-1906) хәзерге Яшел Үзән районына кергән Акъегет авылы мәдрәсәсендә дәвам иттерә. Беренче иҗат тәҗрибәләреннән «Яшә, хөррият, яшә!» исемле шигыре «Казан мөхбире» газетасының 1906 елгы 20 гыйнвар санында басыла. Шул ук елларда Оренбургта чыккан «Шура» журналында чуваш халкының гореф-гадәтләре турында этнографик характердагы берничә мәкаләсе дә дөнья күрә.


Акъегет авылы мәдрәсәсен тәмамлап, бер кыш үз авылларында мөгаллимлек иткәннән соң, 1907 елның көзендә Казанга килә һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый башлый. Казанга килгән елда ук аның «Милләт кайгысы» исемле беренче шигъри җыентыгы басылып чыга.

1908 елның язында З.Бәшири, Оренбург шәһәренә китеп, Кәримев-Хөсәеневләр матбагасында корректор һәм берникадәр вакыт юмор-сатира журналы «Чүкеч» редакциясендә мөдир (сәркатип) булып эшли. 1908-1910 еллар арасында Орск, Оренбург нәшриятларында шагыйрьнең нәүбәттәге шигырь җыентыклары – «Тутый тавышы» (1908), «Язгы кояш» (1908), «Иртәнге азан» (1909), «Ядкяр» (1909), «Җуаткыч» (1909), «Яз тамчылары» (1909), «Хиссият бишекләре» (1910) исемле китаплары дөнья күрә. Мәгърифәткә, яктылыкка өндәү, тормыш-көнкүрештә очрый торган тискәре якларны тәнкыйть итү, гади кешеләрнең бәхетсез язмышына уфтану, табигать күренешләре, мәхәббәт кичерешләре – З.Бәшири шигырьләренең төп тематикасы. Әмма сан ягыннан күп язарга омтылу, ашыгу еш кына З.Бәшири шигырьләренең сәнгатьчә эшләнешен түбәнәйтә. Шуңа күрә аның шигъри иҗаты үз заманында Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Камалларның каты гына тәнкыйди чыгышларына, фельетоннарына тап була. Әче телле Шәехзадә Бабич та, әдипнең талымсызрак, әдәпсезрәк шигырьләрен күздә тотып: *«Әй, Зариф, чык ялтырап, тик бар да китсен аптырап, / Дошманыңны калтырат, борчакларыңны шалтырат!»* – дип, аны зәһәр генә чеметеп ала.

З.Бәшири бу елларда проза әсәрләре дә язып бастыра. Алар арасында «Шаян Фәһим» исемле балалар хикәясе (1910) һәм «Чуваш кызы Әнисә» повесте (1910) әдипнең иҗатында күренекле урын тота. Чуваш кызы белән татар егетенең фаҗигале мәхәббәтен романтика катыш реалистик буяулар белән сурәтләгән әлеге повесть кат-кат басылып, соңыннан (1960 елда) чуваш теленә дә тәрҗемә ителә.

1910-1917 еллар арасында З.Бәшири Пенза һәм Тамбов төбәкләрендәге Аллагол, Вәрәки авылларында, аннан соң Казакъстанның Капал шәһәрендә балалар укыта. Февраль инкыйлабыннан соң Алма-Ата шәһәренә күчеп, анда уйгур газеталарында эшли. 1918-1919 елларда Казакъстанның Җарканат шәһәрендә мәгариф бүлеген җитәкли, соңыннан, 1930 елга кадәр, Ташкент шәһәренең мәгариф оешмаларында, газета-журнал идарәләрендә төрле җаваплы вазифалар башкара, Урта Азия дәүләт университеты каршындагы рабфакта үзбәк, уйгыр телләре һәм әдәбиятлары буенча дәресләр алып бара. 1930-1932 елларда әдип – Донбасста, татар шахтёрлары өчен чыгарыла торган «Пролетар» газетасының әдәби хезмәткәре. 1933 елда ул Уфага күчеп килә һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр шунда яши. З.Бәшири 1962 елның 21 октябрендә вафат була.

# ЭНЕСЕ КЕМ – АБЫЙСЫ ШУЛ...



Рәшит Әхмәтҗанов турында

Әдәбиятның башка жанрларында ничектер, шигъриятькә яшьләр өер-өер булып киләләр. Ярышып, узышып, бәхәсләшеп, фикердәш булып иҗат итү өчен яшеңнең бер тирәдәрәк булуы кирәктер, күрәсең.

Рәшит Әхмәтҗановлар буыны да татар шигъриятендә зур һәм көчле төркем иде. Күпләр арасыннан кайберләре алгарак чыгып, алар күз уңаенда булдылар, исемнәре газета-журнал битләрендә еш күренде, трибуналардан еш яңгырады; кемнәрдер күләгәдәрәк калдылар.

Дөресен әйтим, Рәшиткә мин әлләни игътибар итми тордым. Язамы яза, эшлиме эшли – шул гына. Аралашуыбыз да шундый гына – исәнме, саумы гына иде. Аның иҗатына мин энекәше артист Илдус Әхмәтҗанов аша кереп киттем. Әллә нindiерәк сәер егет, талантлы, шигырьгә гашыйк җан, фикер йөртү рәвеше дә үзенчә – „синдәй, миндәй бозаулар“га охшамаган. Шуннан уйлап куйдым: „Туктале, мәйтәм, энесе шулай булгач абыйсы да моның кызыклы кешедер“.

Рәшит белән очрашып сөйләшкәндә, аны җентекләбрәк күзәтергә керештем. Бусы да сәер икән. Төртмә телле, тиз үпкәләүчән, зарланырга ярата. Мин аңа якыная алмадым, ул да миңа якынаерга бик ашкынмады. Шулай да бер сыйфаты Рәшитнең мине җәлеп итте: үз-үзеннән көлеп, мәзәк ясар өчен кеше үзеннән өстен булырга тиеш.

Һәм мин Рәшит Әхмәтҗанов язганнарның бөтенесен дә җыеп укып чыктым. Тетрәндем, шаккаттым дип купшы сүзләр әйтмим, аның зур шагыйрь икәнен аңлап, аңа хөрмәт белән карап, шигырьләренең матбугат битләрендә күренгәнен көтеп ала башладым.

Миңа Рәшит Әхмәтҗанов иҗатында иң кадерлесе – сагыш. Кешеләргә сөйләп тә аңлатып булмый торган. Хәтта үзең дә аңлап бетерә алмаган сагышлы хисләр була. Рәшит шигырьләренең үзәгендә әнә шул әйтелмәгән сагыш ята. Шул булганда гына шагыйрь чын шагыйрь була ала.

Туфан Миңнуллин

26 июль 1997 ел.

Әдәбиятның башка жанрларында ничектер, шигъриятькә яшьләр өер-өер булып киләләр. Ярышып, узышып, бәхәсләшеп, фикердәш булып иҗат итү өчен, яшеңнең бер тирәдәрәк булуы кирәктер, күрәсең.

Рәшит Әхмәтҗановлар буыны да татар шигъриятендә зур һәм көчле төркем иде. Күпләр арасыннан кайберләре алгарак чыгып, алар күз уңаенда булдылар, исемнәре газета-журнал битләрендә еш күренде, трибуналардан еш яңгырады; кемнәрдер күләгәдәрәк калдылар.

Дөресен әйтим, Рәшиткә мин әлләни игътибар итми тордым. Язамы яза, эшлиме эшли – шул гына. Аралашуыбыз да шундый гына – исәнме, саумы гына иде. Аның иҗатына мин энекәше артист Илдус Әхмәтҗанов аша кереп киттем. Әллә ниндиерәк сәер егет, талантлы, шигырьгә гашыйк җан, фикер йөртү рәвеше дә үзенчә – «синдәй, миндәй бозаулар»га охшамаган. Шуннан уйлап куйдым: «Туктале, мәйтәм, энесе шулай булгач, абыйсы да моның кызыклы кешедер». Рәшит белән очрашып сөйләшкәндә, аны җентекләбрәк күзәтергә керештем. Бусы да сәер икән. Төртмә телле, тиз үпкәләүчән, зарланырга ярата. Мин аңа якыная алмадым, ул да миңа якынаерга бик ашкынмады. Шулай да бер сыйфаты Рәшитнең мине җәлеп итте: үз-үзеннән көлеп, мәзәк ясар өчен кеше үзеннән өстен булырга тиеш.

Һәм мин Рәшит Әхмәтҗанов язганнарның бөтенесен дә җыеп укып чыктым. Тетрәндем, шаккаттым дип купшы сүзләр әйтмим, аның зур шагыйрь икәнен аңлап, матбугат битләрендә күренгәнен көтеп ала башладым.

Миңа Рәшит Әхмәтҗанов иҗатында иң кадерлесе – сагыш. Кешеләргә сөйләп тә аңлатып булмый торганы. Хәтта үзең дә аңлап бетерә алмаган сагышлы хисләр була. Рәшит шигырьләренең үзәгендә әнә шул әйтелмәгән сагыш ята. Шул булганда гына шагыйрь чын шагыйрь була ала.

**Туфан МИҢНУЛЛИН**

## Яра

Туфан Миңнуллин ТНВдан сөйли: «Шагыйрьнең җанында, эчендә һәрвакыт яра булырга тиеш. Ул һәрвакыт авыртып торырга тиеш. Шул чагында гына ул әйбәт шагыйрь була ала...»

Шифаханәдә телевизор карап яткан Роберт Миңнуллин, бу сүзләрне ишеткәч, эченнән генә сөенеп куя. «Миндә дә ашказаны язвасы таптылар, минем дә эчем постоянно авыртып тора. Димәк, мин дә әйбәт шагыйрь булып чыгам», – ди ул, эчен уа-уа.

## Җиденче том

«Татар тарихы»ның беренче томын тәкъдим итү мәҗлесе бара. Президент чыгыш ясый: хуплый, мактый, авторлар белән, чыгачак томнар белән кызыксына. Тарих институты директоры Рафаэль Хәкимов, канатлана-канатлана, проект турында мәгълүматлар бирә.

Иң ахырдан Минтимер Шәймиев әйтеп куя:

– Әйдәгез, җиденче томга тотыныгыз! Мин дә шунда берәр мәкалә язармын!

Рафаэль Хәкимов шунда ук эләктереп ала:

– Менә җиденче томга авторлар коллективы туплана да башлады!

P.S. «Татар тарихы»ның җиденче томы чыннан да чыкты. Анда М.Ш.Шәймиевнең дә мәкаләсе бар. Ышанмасагыз, укып карагыз!

## «Паркинсон»

*(Рамазан Абдулатипов сөйләгән иде)*

Авыру Рәсүл Гамзатовны чыгыш ясарга чакырып, ерак авылдан вәкил килгән.

– Бик тә барыр идем дә, «Паркинсон» җибәрми шул, – дигән Рәсүл. Вәкил аптырап калмаган:

– Борчылмагыз, Рәсүл ага, «Паркинсон» белән үзебез сөйләшербез, – дигән.

– Сөйләшегез, сөйләшегез, «Паркинсон» җибәрсә, барырмын, – дип җавап кайтарган Рәсүл.

– Рәхмәт, Рәсүл ага, рәхмәт! – дип, вәкил «Паркинсон» белән сөйләшергә чыгып киткән.

## Татармы, башкортмы?

Хәбир Иштирәков Башкортстанның Гафури районына ял итәргә бара. Шәп кенә кунак итәләр моны. Бераз кызып алгач, авыл советы рәисе кунакның колагына килеп пышылдый:

– Беләсеңме, мин дә татар бит!

– Ә паспортыңда кем дип язылган?

– Соң, татар булгач, башкорт дип язылган инде, – ди рәис, бер дә исе китмичә генә.

## Кайсы матуррак?

Камал театры.

Халык Галимҗан Ибраһимовның 120 еллыгына җыелган. Фойеда татар театрының 100 еллыгына багышланган скульптура ансамбле дә куелган. Авторы – Рада Нигъмәтуллина. Скульптураның берсендә Шәүкәт Биктимеров (Әлмәндәр), Марсель Сәлимҗанов һәм Туфан Миңнуллин сурәтләнгән.

Әлеге композицияне язучылар сырып алган. Камил Кәримов озак кына карап тора да:

– Туфан абыйны бигрәк ямьсез ясаганнар инде, – ди.

Янында басып торган Роберт Миңнуллин игътибар беләнрәк карый да:

– Юк, нәкъ үзе! Туфанны тагын ничек ясыйсың инде аны? – Аннары ерактанрак узып барган Туфанның үзенә төртеп күрсәтә. – Әнә бит, чагыштырып кара әле!

Камил Кәримов бер тере Туфанга, бер скульптурага карый да:

– Шулай икән шул, скульптурада матуррак та килеп чыккан әле, – дигән нәтиҗәгә килә.

## Татарның иң негры

«Җиде йолдыз» фестивале бара. Сәхнәгә Финляндиядә яшәүче җырчы Җәмилә белән негр егете Ндиоба чыга. Татарча җырлый башлыйлар. Сәхнә артында басып торган Илһам Шакиров Салаваттан сорый икән:

– Кара әле, Салават, татарларның негрлары да була микәнни ул?

– Нигә, Илһам абый, татарның негрдан бер артык җире дә юк инде аның. Негр кебек үк эшли, негр кебек үк яши, – дип җавап кайтара Салават, уйлап-нитеп тормыйча гына.

Шуннан ни әйтергә белми торган Илһам Шакиров:

– Алай булгач, татарның иң негры мин буламдыр инде, – дип авыр сулап куя да негр малаеның татарча җырлаганын тыңлый башлый.

## Яңа бүрек

Шагыйрь Роберт Миңнуллин беркөнне Язучылар берлегенә яңа бүрек киеп килә. Моңа барысы да игътибар итә. Ркаил Зәйдуллага да ошый бу бүрек. Киеп тә карый.

– Кара әле, миңа да таман икән бу. Синең баш та шундый зурмыни? – дип сорый ул бүрек хуҗасыннан.

– Әлбәттә, зур! Тик мин аны, синең кебек, башкаларга күрсәтеп кенә йөрмим, – ди дә Роберт Миңнуллин, яңа бүреген яңадан башына киеп куя.

## Төнәтмә

Күренекле тел галиме Латыйф Җәләй авырып ята икән. Кайсысыдыр, киңәш йөзеннән, бер өлеш коньяк, бер өлеш чәй, бер өлеш тагын нindидер үлән төнәтмәсе тәкъдим иткән. Яшь галим Фуат Ганиев, кибеткә барып, кирәк әйберләрне алып кайтып, төнәтмә эшләп эчерткән. Латыйф ага эчеп куйган да: «Икенче тапкыр коньягын күбрәк салырсың», – дип борылып яткан.

## Марат Кәбиров белән сөйләшү

Роберт Миңнуллин Уфада яшәүче язучы Марат Кәбировтан сораштыра икән:

– Башкорт язучыларының ел йомгакларында быел булдыңмы соң?

Марат Кәбиров:

– Юк шул, бу юлы барып булмады.

Роберт Миңнуллин:

– Элекке елларда ничек үтә торган иде соң?

Марат Кәбиров:

– Белмим шул, башка елларда да барып булмаган иде.

**Роберт МИҢНУЛЛИН** *тупламасыннан*

# «ҖӘҺӘТ ТӘНКЫЙТЬ»КӘ КАЙТАВАЗ

Айгөл Әхмәтгалиеваның «Ак читек» бәянына карата Дания Заһидуллинаның тәнкыйди анализын укыгач, кайбер фикерләр белән килешмәскә булдым. Иң элек мин әсәрдә әкияттәгечә ак-кара бүленешен күрмәдем. Япь-яшь хатынның аяксыз калуына сәбәпче Ренатның утыз җиде елдан соң да үкенүе турында Нургаянга белдерүен, Зәйтүнәдән бәхиллек сорарга теләвен күрү һ.б. аның ул кадәр үк адәм актыгы булмавын күрсәтә түгелме соң? Әлбәттә, аның күңел кичерешләрен, уй-фикерләрен тирәнрәк һәм бераз элегрәк үк күрәсе килә. «Гафу сорарга көчем җитмәде» диюен акларлык-аңларлык күренешләр дә бераз иртәрәк кирәк. Ни уйлый ул Зәйтүнәне хастаханәгә илткәндә яки йөрмәячәген белгәч? Хатыны белән бу турыда сөйләшү булмаска мөмкин түгел ич һ.б. Нәзирәнең дә психологик яктан тулысынча ачылып бетмәвен танымый булмый. Ирдән аерылып кайткан, ләкин «ирсез торганы да булмаган» хатынның башкалар өчен күренмәгән күңел дөньясын кайбер детальләр белән булса да ача төшү отышлы булыр иде. Шулай да аларны тулаем тискәре геройлар дип әйтәсе килми. Шул ук Нәзирәнең оекларына тиклем чыланган ирләргә җылы оекбашлар китереп тоттыруы аны кайгыртучан хатын-кыз итеп күрсәтмимени?

Ә менә Нургаян белән Зәйтүнә мәхәббәтен «Золушка сюжеты» буларак кабул итә алмыйм мин. Тормышта бәхетле мәхәббәт тарихы әкият итеп кабул ителәмени инде хәзер? Намаз карты булган, чын күңеленнән Аллаһыга ышанган кешенең эчке монологлары да ышандыра мине. Ул башкача уйлый да алмый бит инде. Аның бар вөҗүде дини-әхлакый кыйммәтләр белән тулы. Төрмәдән кайтып төшкән яки башы сәрхушлектән чыкмаган кешенең шулай гамәл дәфтәре, рәнҗетүләр турында уйланулары, чыннан да, гайре табигый булыр иде. Ә Нургаян ул – тормышта сирәк булса да очраучы, кызганычка каршы, типик булмаган (!) иманлы, олы җанлы ир кеше. Без хәзер тормышта да, әдәби әсәрләрдә дә катлаулы, каршылыклы кешеләрне генә күрергә өйрәнеп беткәнбез, уңай девиацияне кабул итә алмый башлаганбыз кебек тоела миңа. Зәйтүнәләр дә бар ул чынбарлыкта. Беркемгә дә ачу-рәнҗеш тотмый торган, уңган, сабыр, түземле, ире белән бер сүздәге хатын ул. Әйе, бу очракта да Зәйтүнәнең кичерешләрен тирәнәйтү кирәктер, шулай икән, идеаллаштыру тәэсире булмас та кебек.

Әсәрне мин әкияти тарих итеп түгел, әдәбиятта сирәк сурәтләнә торган дәвамлы чын мәхәббәт тарихы буларак кабул иттем. Бүгенге көндә нәкъ менә шундый уңай үрнәкләр кирәк дип саныйм.

**Лилия ФӘТТАХОВА.**
*Чаллы шәһәре*

# МАКСАТЧАН ӘСӘР

Айгөл Әхмәтгалиеваның «Ак читек» повестеның теле шома гына күренсә дә, үзен бик шома укыла торган әсәр, димәс идем. Һәрхәлдә миңа шулай тоелды. Вакыйгаларның һәм геройларның чамадан тыш идеаллаштырылып, калку итеп сурәтләнүе, бигрәк тә әсәр ахыры коры дидактикага кайтып калу белән килешергә теләмәгән акыл, чыгырымнан чыгарып, журналны берничә тапкыр читкә тибәрергә мәҗбүр итте. Тик кабарынкы күңел бераз басыла төшкәч, Дания ханым Заһидуллина сүзләре белән әйткәндә, әсәрнең җырлап торган йөгерек теле һәм миңа коточкыч чынбарлыкның үзеннән яхшы таныш булган сюжет сызыгы яңадан үз эченә тартып кертә торды. Әйе, повестьның төп геройлары – Зәйтүнә белән Нургаян язмышына дучар булучылар безнең Абдулла авылында да яшиләр. Күршеләрем Сәмирә һәм Рафаэль Кыямовларны хәтта күпмедер дәрәҗәдә әлеге персонажларның прототиплары дияргә дә мөмкиндер, чөнки Рафаэль Нургаян шикелле үк озак еллар «Алга» колхозында механизатор булып эшләде. Эшләү дәверендә

алдынгылыкны бирәүгә дә бирмәде, өстәвенә бал кортларының телен шәп белгән оста умартачы да ул. Сәмирә әүвәл идарәдә бухгалтер, аннары сөтчелек тармагында лаборантка булып эшләде. Фаҗига аны каенапасы, каенсеңлесе белән колхоз «УАЗиг»ына янәшә утырган килеш сәйраннан кайтып барганда, бәләкәй урманлык – авыл арасындагы нибары бер чакрым юлда сагалап тора. Шулай итеп, егерме елдан артык тәрбияли инде Рафаэль Сәмирәсен. Авызыннан ник бер зар, сыкрану сүзе ишетелсен. Тыштан әсәрдәгечә барсы да ал да гөл, барсы да әйбәт. Җәберсетәме аны Сәмирәнең хәрәкәтсез калуы, әлбәттә, җәберсетә, әмма бу турыда башкаларга сүз кату йә үзе тану түгел, киресенчә, эш-гамәле белән икърар итәргә тырыша ул моны. Тик үз эченә бикләнебрәк йөри башлавы һәм яшелчә бакчаларына ут сузып, Сәмирә йоклаганда, төннәрен чүп үләннән тазартуы гына аның шундый ук көчле булып калганлыгын расларга теләвен, башкалардан бер дә ким түгеллекләрен дәлилләргә омтылуын күрсәтә иде. Кызганыч, повестьта Нургаянның бу ягы тулы күрсәтелми. Хатынының, авырлык белән булса да, кашык тотарлык хәлгә килүенә сөенеп туя алмады Рафаэль, чөнки моңарчы гел үзе ашатты. Аякларына бастыру ниятеннән кайларга гына алып бармады ул Сәмирәсен, нинди генә санаторийларга, реабилитация үзәкләренә йөртмәде, мәчеттә өшкереп дәвалаучы мулла булуын белгәч, хатынын алып шунда йөгерде, хәтта чиркәүдәге попка күрсәтүдән дә чирканмады, тик файдасы гына сизелерлек дәрәҗәдә булмады. Уллары, авыл мәктәбеннән соң, югары белем алып, Димитровградта төпләнгәч, үзе дә шуннан квартира сатып алды. Хәзер кышын шәһәрдә яшиләр, җәйләрен, берничә оя умарта белән әвәрә килеп, авылда торып китәләр. Моннан күренгәнчә, әсәр тулаем әкияти сюжетка корылмаган икән, чөнки аның нигезендә реаль вакыйгалар ята. Дания ханым күрсәтеп үткән повесть геройлары, мәгърифәтчеләрдәгечә, уңай һәм тискәрегә генә бүленә, төп геройларда олы характер күренми, җитәкче ролендәге персонажларга психологизм җитешми, әсәр иҗтимагый, фәлсәфи катламнар белән баетылмаган кебек кимчелекләр белән күпмедер дәрәҗәдә килешкән хәлдә, бөтен гаепне Айгөл ханым өстенә аударырга ашыкмас идем. Телеэкраннардан һәрвакыт «позитив» күрсәтү, әдәби әсәрләрдә заманча уңай герой образын яктырту модага кереп барганда, Айгөл Әхмәтгалиева гына бу шаукымнан читтә кала алмый бит инде, бигрәк тә безнең прозада уңай герой проблемасы һәрчак игътибар үзәгендә булуын күз уңында тотканда. Шуңа ул бу повестен сәнгатьчә камил итеп эшләүгә караганда, уңай герой проблемасын хәл итүне алгырак планга чыгарган булса кирәк. Кайбер урынсыз күпертүләрне һәм бердәнбер иң дөрес юлга чакыру белән кирәгеннән артык мавыгуларны исәпкә алмаганда, язучы, нигездә, максатына ирешә: күз алдыбызга башкалардан бер ягы белән дә аерылырга теләмәгән, «сызлана, көнләшә, рәнҗи» белмәгән гап-гади чордашларыбызның коеп куйган образларын китереп бастыра. Кызганычка каршы, зур батырлыклар эшләргә сәләтлеләр генә герой була ала, андыйлар олы шәхес дәрәҗәсенә ирешеп, «фикри киңлеккә дә алып чыгарга мөмкин», дип башларыбызга сеңдерелгәнгә, күп очракта көндәлек тормышта бернинди героең да кыла алмас батырлыклар эшләүче гап-гади күршеләребезнең каһарманлыгына битараф булып калабыз, ким дигәндә, ис китмәгән кыяфәткә кереп, салкын канлылык күрсәтергә тырышабыз. Айгөл ханым кешелек дөньясын һәрдаим озата килгән бу күренешне вакытлы тотып алган. Ул бу әсәре белән, игътибарыңны төртеп күрсәтелгән якка гына түгел, ә үзең күрергә теләгән, үзеңне борчыган нәрсәләргә дә, һәрхәлдә, якыннарыңа, тирә-күршеләреңә, авылдашларыңа да юнәлтергә, зәгыйфь кенә кызганган булып кылануга караганда, аларга сокланып, эчке дөньяңны, күңел байлыгыңны шуларныкы дәрәҗәсенә күтәрергә тырышырга кирәк, дип әйтә кебек. Айгөл Әхмәтгалиеваны «Казан утлары»ндагы хикәяләре буенча теләсә нинди темага, теләсә нинди әсәр иҗат итәргә сәләтле киң диапазонлы язучы буларак күз алдына китерәм. Ихтыяҗ туа калган очракта, сәнгатьчә эшләнешләре бик югары булган камил әсәрләр белән дә сөендерәчәк әле ул безне. Ә «Ак читек»не тулаем бер-ике сүз белән генә, максатчан язучының максатчан әсәре, дияр идем.

**Ирек ФИРГАЛИЕВ.**
*Ульяновск өлкәсе*
*Чардаклы районы*
*Абдулла авылы*

# İctimagi-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ ТУУЫНА 132 ЕЛ

Габдулла Тукайның туган көнендә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов Казанда Тукай скверында шагыйрьнең һәйкәленә чәчәкләр салды. Чәчәк салу тантанасында ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, ТР Президенты Аппараты Җитәкчесе Әсгать Сәфәров, Казан шәһәре мэры Илсур Метшин, ТР хөкүмәте әгъзалары, министрлыклар, ведомстволар җитәкчеләре, Дәүләт Советы депутатлары, әдәбият, сәнгать әһелләре, фән эшлеклеләре дә катнашты.

***

Казанда М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында Габдулла Тукайның тууына 132 ел тулуга багышланган тантана булды. Анда Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенең быелгы лауреатлары игълан ителде. Бу мәртәбәле премиягә язучы Камил Кәримов – «Карурманда кара песи», «Игезәкләр йолдызлыгы» китаплары; рәссам Михаил Кузнецов – «Белые холсты. Народы Поволжья» эшләре сериясе; «Таттелеком» акционерлык җәмгыяте иҗат төркеме: Лотфулла Шәфигуллин һәм Рөстәм Зәкуанов – Татарстанда яшәүче халыкларның милли байлыкларын һәм тарихи мирасын, мәдәниятен үстерүгә, саклап калуга керткән өлешләре өчен лаек булдылар. Аларны ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов котлады.

***

Казанның Ирек мәйданында Габдулла Тукай һәйкәле янында шигырь бәйрәме булып узды. Анда Г.Тукай бүләге ияләре Разил Вәлиев, Ренат Харис, Равил Фәйзуллин, Роберт Миңнуллин, Ркаил Зәйдулла чыгыш ясады. Бәйрәм кунаклары арасында Саха-Якутиянең халык шагыйрәсе Наталья Харлампьева, Азәрбайҗан кунагы, «Каспий» газетасы мөхәррире Фәрит Хөсәенов, Башкортстанның халык шагыйре Равил Бикбаев, Мәскәүдән Владимир Бояринов, Палестинадан Абдулла Исса, Чувашстан халык шагыйре Валерий Тургай бар иде. Шигырь бәйрәмен Фәнис Җиһанша һәм Гүзәл Гайнуллина алып барды.

## ТУГАН ТЕЛ ФОРУМЫ

Казанда М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында татар теле форумы булып узды. Форум кысаларында татар теле һәм әдәбияты буенча VI халыкара олимпиада җиңүчеләре бүләкләнде. Бу чараның йомгаклау турында Татарстаннан, Россия төбәкләреннән һәм Казакъстан, Финляндия, Төркия, Япония, Үзбәкстан, Кыргызстан, Эстония, Франция, Индонезия, Кытай, Пакъстан, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Азәрбайҗаннан татар балалары катнашты. Гран-прига Финляндиядән – Ильяс Кадер һәм Казаннан Альмира Хәкимуллина ия булды. Аларны ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов котлады.

Аннары сәхнәгә яшь каләм ияләренең халыкара «Илһам» иҗат бәйгесендә җиңүчеләре күтәрелде. Алар – Таңсылу Хафизова (Актаныш), Эльмира Хәбибуллина (Балык Бистәсе), Ләйлә Алимбикова (Аксубай), Гүзәл Мәҗитова (Балтач), Нияз Хөснуллин (Казан), Рамазан Әхмәдуллин (Казан), Зәлия Гыйниятова (Саба), Рәзил Сәмигуллин (Казан), Эльвина Иванова (Балтач), Алия Сабирова (Арча). Гран-при иясе – Чистайдан Илүсә Гатауллина.

Бәйрәмдә шулай ук милли белем һәм тәрбия бирүдә иң яхшы эшләүче укытучыларны, тәрбиячеләрне, мәктәпләрне һәм балалар бакчаларын да игълан иттеләр.

***

Казанда Г.Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт яшь тамашачылар театрының яңа бинасы ачылды. Аны ачу тантанасында ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты, театр коллективына яңа өйдә яңа иҗади уңышлар теләде.

## ТАТАР КИТАБЫ – АЛМАН ИЛЕНДӘ

Лейпцигта уздырыла торган китап ярминкәсендә беренче тапкыр Татарстан китап нәшрияты да катнашты. Монда нәшрият йөздән артык төрле жанрдагы басмаларын тәкъдим итте. Былтыр Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Лейпцигка эшлекле сәфәре вакытында Германиядә яшәүче милләттәшләребезне татар китаплары белән тәэмин

итү мәсьәләсен телгә алган иде. Быел Татарстан китап нәшриятының танылган ярминкәдә катнашуы – әнә шул максатны тормышка ашыруга беренче омтылыш булды.

### ЮБИЛЕЙЛАР

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында шагыйрә, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Саҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты Эльмира Шәрифуллинаның юбилей кичәсе үтте. ТР Дәүләт Советы депутаты Таһир Һадиев аңа ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин исеменнән Рәхмәт хаты тапшырды. Бәйрәмдарны ТР Президенты каршындагы мәдәниятне үстерү фондының башкарма директоры Нурия Хашимова Татарстан Президенты Аппараты Җитәкчесе Әсгать Сәфәров исеменнән дә котлады. Котлау сүзләрен Актаныш муниципаль районы башлыгы Энгель Фәттахов, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов һ.б. да ирештерде.

***

Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай клубында язучы-прозаик, журналист Госман Гомәргә 85 яшь тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә булды. Анда юбилярга ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшинның Рәхмәт хатын тапшырды.

Язучының иҗаты турында ТР Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, әдәбият галиме Фоат Галимуллин, каләм әһелләре Хәлим Җәләй, Шәмсия Җиһангирова, Фатих Кутлу, «Ватаным Татарстан», «Татарстан яшьләре» газеталарының баш мөхәррирләре Миңназыйм Сәфәров белән Атлас Гафиятов һ.б. сөйләде.

### КИТАП ТӘКЪДИМ ИТҮ

«Казан» милли-мәдәни үзәгендә шагыйрь, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Ркаил Зәйдулланың «Янды сөю чатырлары» исемле китабын тәкъдим итү кичәсе булды, автор һәм нәфис сүз осталары башкаруында шигырьләр яңгырады.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Төркиянең Кастамону шәһәрендә төрки телле әдәби журналлар баш мөхәррирләренең чираттагы IX конгрессы узды. Әлеге конгресс 2014 елда Казанда үткәрелгән иде. Форумда Евразия Язучылар берлеге рәисе, «Кардәш каләмнәр» әдәби журналының баш мөхәррире, язучы Якуб Өмәруглы чыгыш ясады. Әлеге тантанада Татарстанның халык шагыйре Зиннур Мансуров төрки дөньяда «2018 ел шәхесе» буларак игълан ителде.

***

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булып узды. Утырышта М.Горький исемендәге премияне кабат торгызу мәсьәләсе каралды. Аны үз вакытында ТР Президенты да хуплап чыккан иде. Утырышта Татарстан Язучылар берлегенә яңа әгъзалар кабул ителде. Алар – Әхтәм Зарипов (Казан), Сәрия Бикмөхәммәтова (Әлмәт), Роберт Сәләхиев (Актаныш).

### ОЧРАШУ

Татар язучылары һәм журналистлары танылган румын язучысы Танер Мурат белән очрашты. Чарада «ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры урынбасары, «Мәгариф» журналының баш мөхәррире Сөмбел Таишева, Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин, «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррире Вахит Имамов, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон, «Идел» журналының баш мөхәррире Радик Сабиров, «Сабантуй» һәм «Ялкын» журналларының баш мөхәррире Илназ Фазуллин, язучы Илдар Әбүзәров катнашты.

***

Таҗикстан җәмәгатьчелеге Таҗикстан Фәннәр академиясенең беренче президенты, галим, җәмәгать эшлеклесе Садреддин Айнинның тууына 140 ел тулуны зурлап билгеләп үтте. Бу чараларда филология фәннәре докторы, Казан федераль университеты профессоры Хатыйп Миңнегулов катнашты һәм чыгыш ясады.

2018 елның 6 апрелендә 91 нче яшендә язучы-прозаик **Габдулла Гали улы Галиев** вафат булды.

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман Х.КАМАЛА «Проклятие»; повесть Ф.ХУЗИНА «В тени войны»; рассказы Т.ГАЛИУЛЛИНА «Татарская полынь», Г.ДАУТОВА «Генерал»; юмористический рассказ Р.ХУЗИ «Старая дева»; поэма М.МИРЗЫ; стихи Л.ШАЕХА, Т.ШАМСУАРОВА, Л.ГИБАДУЛЛИНОЙ.*
*«Актуальная критика»: рубрику ведёт Д.ЗАГИДУЛЛИНА.*
*«Литература родственных народов»: стихи Н.ХАРЛАМПЬЕВОЙ.*
*«Литературный конкурс «Достояние»: рассказ Г.СУЛТАНОВОЙ «Факел».*
*«80 лет со дня рождения Б.СУЛЕЙМАНОВА»: Ф.САЙФУЛЛИНА. «Мелодия родного края».*
*«Публицистика»: А.ГАРИПОВ. «Преодолевая испытания судьбы».*
*«Искусство»: А.ИМАМИЕВА. «Без национального самосознания нет и развития». (Интервью с Народным артистом Татарстана А.ХАФИЗОВЫМ).*
*«Книжное обозрение»: М.ВАЛИЕВ. «Одна из пуговок благословенной чётки».*
*«Наш календарь»: Зариф БАШИРИ.*
*«Тоскуя по былому»: Т.МИННУЛЛИН. «Кто братец – тот старший брат...»*
*«Юмор-сатира»: юморески из сборника Р.МИННУЛЛИНА.*
*«Мнение читателя»: Л.ФАТТАХОВА. «Отклик на «Актуальную критику»; И.ФИРГАЛИЕВ. «Целенаправленное произведение».*
*Из фотоархива журнала.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: «Дороги фронтовые». Картина Хариса Якупова; памятник Льву Толстому в городе Казани. Фото из сайта tourtrans.ru.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and Poetry»: novel by H.KAMAL «The Curse»; story by F.KHUZIN «In the shadow of war»; stories by T.GALIULLIN «Tatar wormwood», G.DAUTOV «General»; humorous story y R.KHUZI «Old maid»; poem by M.MIRZA, poetry by L.SHAEKH, T.SHAMSUAROV, L.GIBADULLINA. «Actual criticism»: heading is conducted by D.ZAGIDULLINA.*
*«Literature of kindred peoples»: poetry by N.KHARLAMPIEVA.*
*«Literary contest «Heritage»: story by G.SULTANOVA «Torch».*
*«80t anniversary of B.SULEYMANOV»: F.SAYFULLIN. «Melody of the homeland».*
*«Journalism»: A.GARIPOV. «Overcoming the challenges of destiny».*
*«Art»: A.IMAMIEVA. «There is no development without national consciousness». (Interview with People's Artist of Tatarstan A.HAFIZOV.)*
*«Book review»: M.VALIEV. «One of the buttons of the blessed rosary».*
*«Our calendar»: Zarif BASHIRI.*
*«Pinning for the past»: T.MINNULLIN. «Who is the brother – the older brother...»*
*«Humor-satire»: humorous pieces from the collection of R.MINNULLIN.*
*«Feedback of the reader»: L.FATTAKHOVA. «Response to the «Actual criticism»; I.FIRGALIEV. «Purposeful work».*
*From the photo archive of the magazine.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: «The front-line roads». Picture by Kharis Yakupov; monument to Leo Tolstoy in Kazan. Photo from the website tourtrans.ru.*

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Фронт юллары». *Харис Якупов картинасы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* Казан шәһәрендә Лев Толстой һәйкәле.
*Фото tourtrans.ru сайтыннан алынды.*